# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
КЫРЫК СИГЕЗЕНЧЕ ЕЛ ЧЫГА

**11**

НОЯБРЬ
1969

## Бу санда:

ЛЕНИН — БӨЕК ЯКТАШЫБЫЗ

Төрле иллэрдән, төрле телләрдән

**Х. ТУФАН. Ленин каены. Ленин.** Шигырьләр . . 3
**ПАБЛО НЕРУДА. Ленинга мәдхия.** Поэма . . . 4
**В. ТЕЛЬПУГОВ. Бияләй. Легенда. Чаң тавышы. Репортер.** Ленин турында **хикәяләр** . . . . . 7
**Л. КОНДЫРЕВ. Кокушкинодан репортаж.** Шигырь. 15

Казаннан киткәч

**М. ХӘСӘНОВ. Псковта сиксән өч көн.** Очерк . . 16

РОМАН, ПОВЕСТЬ, ПОЭМА, ШИГЫРЬЛӘР

**Н. АРСЛАНОВ. Романтика.** Поэма . . . . . . 25
**А. ГЫЙЛӘҖЕВ. Урамнар артында яшел болын.** Роман. . . . . . . . . . . . . . 30
**Х. КАМАЛОВ. Ленин сүзе. Туган җирем... Дәмин.** Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . . 75
**С. ГӘРӘЕВА. Урал!.. Кайтып килэм... Сүзсез генә...** Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . . 78
**А. ЗАКИРОВ. Буяу. Буш күңелең белән... Март җилләре... Бик күпләрнең...** Шигырьләр . . . 79
**Ф. ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА. Игенче һәм тургай. Чаптар атлар кире кайтмады. Чишмәләр дә серле.** Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . . 81
**Ә. БАЯНОВ. Декабрьның унөченче көне.** Повесть. 83

ТАТАРСТАННЫҢ 50 ЕЛЛЫГЫНА

**Р. САБИРОВ. Нефть һәйкәлләре.** Очерк. 117

БЕЗ УТКӘН ҮРЛӘР

**Ф. МУСИН. Реализм юлыннан** . . . . . . . . 128

ЗАМАНДАШЛАРЫБЫЗ

**Э. МӨЭМИНОВА. «Бәхетле булырсың дигән иде».** Очерк . . . . . . . . . . . . . . . 140

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

СӘНГАТЬ КЕШЕЛӘРЕ

**Р. КӘРИМОВ.** Киң колачлы иҗатчы . . . . . 145

ШӘРӘФ МӨДӘРРИСНЕҢ ТУУЫНА 50 ЕЛ

**Н. ХИСАМОВ.** Үлемсезлек җырчысы . . . . . 152

ФОЛЬКЛОР

**Х. МӘХМҮТОВ.** «Коман мәҗмугасы»ндагы табышмаклар . . . . . . . . . . . . . . . 157

ИСТӘЛЕКЛӘР, ЯЗМАЛАР

**Ә. САФИН.** Муса — Татрабфак студенты . . . . 165

КИТАП КҮЗӘТҮ

**М. МӘҺДИЕВ.** Шагыйрь күңелендә нинәр бар! . 169

Бәләкәй рецензияләр . . . . . . . . . . . . 173

БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

Дәрдмәнд . . . . . . . . . . . . . . . . . 177
**Ф. ГАНИЕВ.** Татар филологиясенә зур өлеш керткән галим . . . . . . . . . . . . . . 179
Латыйф Җәләйнең Афзал Шамовка язган хаты . 181

БАЛАЛАРГА УКЫГЫЗ

**Р. ФӘЙЗУЛЛИН.** Дүрт сүзе бар улымның. Бәллибәлли. Шигырьләр . . . . . . . . . . 186
**Р. ХӘЛИУЛЛИНА.** «Бөрлегән». Илгиз, без һәм үгез. Шигырьләр . . . . . . . . 188

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . . 190

**Редакциягә килгән кульязмалар кире кайтарылмый**

Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар: баш редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-39-52, бүлекләр — 2-39-52.
Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары».*

Баш редактор **Зәки Нури.**
Редколлегия: **Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Әмирхан Еники, Ләбибә Ихсанова, Шәйхи Маннур, Рафаэль Мостафин, Газиз Мөхәммәтшин, Рәфикъ Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир.**

Производствога бирелде 10/IX-1969 ел. Басарга кул куелды 23/X-1969 ел. ПФ 09040.
Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 36.406 экз.
Заказ В-465. Бәясе 50 тиен.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, йорт 19, 1969 ел.




# *ЛЕНИН — БӨЕК ЯКТАШЫБЫЗ*

*Төрле илләрдән, төрле телләрдән*

## Хәсән Туфан

### Ленин каены

Көтә аны, көтә һаман
Йөзгә җиткән олы каен.
Бик якынның, бик танышның
Туган көне җиткән саен,
Сагынуларын сөйли-сөйли
Яшьлек дусын көтә каен:

«Ничә еллар узды инде
Бу яклардан киткәненә,
Ничә еллар булды инде
Хуш әлегә дигәненә.
Кайда йөри, нигә килми
Туган-үскән җирләренә?..»

Хәбәр кайта, сәлам кайта
Киек кошлар канатында,
Анголадан, Вьетнамнан
Аның туган якларына,
Язлар саен хәбәр кайта
Идел буе ярларына:

«Зәнки[1] кызы йолдыз чигә
Ул китергән байракларга.
Ханой кызы патрон ташый
Ул юнәлткән солдатларга,
Көрәшләрдә йөри Ильич
Еракларда, еракларда...»

### Ленин

Бу исем — ирек авазы,
Бу исем — сыйнфый нида.
Бу исем бөтен җиһанның
Колларын, ярлы-гидаен
Фидакарь сафка җыя.

Бу исем — безнең халыклар
Тел ача торган исем.

Бу исем — азат булуга,
Фаныйны бакый кылуга
Юл саба торган исем.

Боралмый безне бу юлдан
Ни бер Сил, ни бер Давыл:
Дөньяның һәрбер ягында,
Гарасат мәйданнарында
Бу исем — безнең пароль.

---

[1] Зәнки — негр, африкалы.

## Пабло Неруда

Чили шагыйре

# Ленинга мәдхия

1

Ленин! Синең турыда җырлар өчен
тиеш мин
сүзләр белән хушлашырга —
кирәк миңа агачлар, орлыклар,
сабан, көпчәкләр белән язарга.

Син — яңгыравык та, төгәл дә —
фактлар яки Җир шикелле.
Булмагандыр
Владимир Ульянов кебек, икенче
бу җирнең иң җир кешесе.
Була озын буйлы кешеләр,
алар күнеккәннәр —
биек чиркәүләр кебек үк,
болытлар белән сөйләшергә.
Алар — озын, ләкин ялгыз кешеләр.

Ленин Җирнең үзе белән килешү ясаган.
Ул һәркемнән ераграк карый алган.
Елга, таулар, кырлар
аның өчен ачык китап булган.
Шуны укыган.
Укыган — бар кешедән озаграк,
аңлаган —
бөтенесеннән күбрәк.
Күз карашы белән үтеп кергән
халыкларга, кешегә,
кешене тирән коедай күреп баккан,
караган кешегә —
билгесез бер минералдай күреп,
гүя аны үзе ачкан да,
тиеш хәзер минералның
динамик яктысын
халыкларның яшерен хәзинәсеннән алырга,
барысы бергә кушылып, өр-яңадан тусын,
халыклар — Вакыт, Җиргә лаек көчле булсын, дип.

II

Әкрен! Салкын җанлы инженер белән буташтырма аны.
Әкрен! Кайнар канлы мистик белән дә бутама.
Янган аның акылы — көлгә әверелмәгән,
һәм үлеме — утлы йөрәген суыта алмаган.

## III

Хәтерлим: Разливта син балык каптыргансың.
Үтә күренмәле сулар — күзгә кебек —
гүя салкын, көмешләнгән чал төньякның
болынына ташлаганнар аны.
Ят, кешесез ялгызлык,
үсемлекләр төн һәм кардан арган,
шалашта Арктика җиле тавышы.
Күрәм: тыңлый Ленин
су тавышын,
кошлар канат кагышын,
һәм урманның көчле йөрәк тибешен.
Ленин колак сала урман тавышына
һәм тормышны тыңлый,
табигать тантанасы аша
җил адымына, тарих адымына колак сала.

## IV

Булды кешеләр — фәкать тикшеренүчеләр,
һәрберсендә китаптай тирәнлек, фән дәрте.
Һәм берәүләрнең җан эше иде — хәрәкәт.
Ленинда исә ике канат:
акыл һәм хәрәкәт;
уй белән эш иткән,
серләр чишкән,
дөреслеккә, кешегә ябылган
битлекләрне ачкан
һәм һәр җирдә була алган,
бер үк вакытта — һәр җирдә.

## V

Ленин! Кулларың армаган-талмаган.
Һәм акылың ял белмәгән,
горизонтта күренгәнче
нур балкыткан образ,—
канга баткан үзе, һәйкәл кебек,
сәламәләргә төренгән җиңүче,
нурдан да гүзәл хатын-кыз,
җәрәхәтләнгән, ысланган бер нәрсә.
Иң ерак илләрдән күрделәр халыклар:
бу — ул иде, шөбһәсез,
революция иде.
Карт йөрәге дөньяның яңача типте.

## VI

Ленин, Җир кешесе!
Күккә ашты синең кызың!
Йолдызларны хәрәкәткә китерә синең кулың —
шул ук кул ул —
икмәк турында,
халыкка җир турында декретлар беркеткән,
шул кул —
йолдызларга җиткән.

## VII

Хәзер бар да башкача, ә ул чакта
заман кырыс иде,
ә көннәр әче, чәнечкеле, авыр иделәр.
Күпме еллар — чикләрдә бүреләр улады
тормыш һәйкәлен аударырга теләп,
ачлык, ут,
газ, үлем белән
яшәү күзләрен яндырырга теләп.
Теләделәр алар, үлсен дип,
Синең кызың-җиңү белән бергә —
иркен, бөек, затлы һәм көчле
Советлар иле дә.
Барып чыкмады.
Икмәк, күмер җитмәсә дә,
гомер үзе җитмәсә дә,
яндырылган өйләргә, алачыкларга
күктән — яңгыр, кар, хәтта кан яуса да.
Төтен-ут аша күрделәр аны
иң ерак илләрдән халыклар —
күрделәр, ничек ул — тормыш һәйкәле —
көрәште, үсте, һәм үсте, һәм үсте,
куркусыз йөрәге
йолдызга әверелгәнче.

## VIII

Ленин! Еракларда рәхмәт тапшырабыз сиңа.
Син бөек карарлар кылганнан алып,
йөгерек адымнарың, йөгерек күзләрең вакытыннан алып,
шатлык өчен көрәштә
ялгыз түгел инде халык.
Чиксез ирекле ил бар,
камалышны өзде,
янауларга, сугышларга бирешмәде,
җимерелмәс крепостька ул әверелде —
һичкем җиңә алмас аны.
Кешеләр яши инде яңача,
һәм яңа икмәк ашыйлар —
өмет ипие ул.
Чөнки җир үзәгендә —
Ленин кызы — Җиңү.
Барысын яктырта үз нурында.

## IX

Ленин! Рәхмәт сиңа
тәгълиматың өчен.
Рәхмәт, рухи ныклык өчен,
Ленинград өчен, чирәм җирләр өчен,
чиксез иген бөртекләре, мәктәпләр,
солдатларың — чын титаннар өчен.
Рәхмәт, синең җирдә мин сулаган һава өчен,
ул бүтәнчә һава:
киң дөньяга хуш ис аңкыта ул,
зәңгәр таулар төсле балкый...
Ленин! Рәхмәт сиңа
икмәк өчен, өмет өчен!

РӘДИФ ГАТАУЛЛИН тәрҗемәсе.

**Виктор Тельпугов**
Рус язучысы

# ЛЕНИН ТУРЫНДА ХИКӘЯЛӘР

## Бияләй

Язмас ул... Синең белән хат язышып торырга бүтән эше юк дисеңме аның. Әнә газеталарны укып кара,— дип, күршеләре күпме генә сөйләнсәләр дә, Дарья һаман да Мәскәүдән хат көтә иде.

Газеталарны укып бара иде ул баруын, хатка каршы җавап язарга тиешле кешесенең эше үтә тыгыз булуын да аңлый иде, шулай да ул бер минутка да өметен өзмәде.

— Эшем бик кирәкле эш бит. Кеше язмышына бәйле эш,— ди иде ул.

Һәм җавап хаты чыннан да килде.

Көннәрдән бер көнне иңенә авыр сумка аскан Каланча кушаматлы почтальон Саша абзый, туп-туры көрт ерып, карчыкның өй капкасына килде һәм тәрәзәгә шакып:

— Дарья, ач ишегеңне, сиңа пакет бар,— диде.

Пакеттагы хатта ниләр язылганлыгын ул чагында берәү дә белмәде, әмма карчыкның сүзен сүз иткәне күренеп тора иде. Авыл халкы әбинең кем тарафыннандыр рәнҗетелгән ялгыз, авыру бер укытучы карчык турында кайгыртып йөргәнен белә иде, шуңа күрә, аның Мәскәүдән хат алуын ишеткәч, җиңел сулап куйдылар.

Бер атналап вакыттан соң, авыл өйләренең тәрәзәләре тагы да гаҗәбрәк хәлләргә шаһит булды. Хәлсезлектән ун еллап инде өеннән чыкмый яткан Дарья карчык, кулына бәләкәй генә төенчек тотып, каядыр станция ягына таба ашыгып китеп барды.

Дарья әбине зур шәһәр шау-шу, ыгы-зыгысы белән каршы алды, ләкин карчык беркая да тукталып тормады, вокзалдан туп-туры шәһәр үзәгенә юнәлде һәм, нинди могҗиза беләндер, озакламый кирәкле урынына барып та житте.

— Сезгә кем кирәк, әбекәй? — дип туктатты аны пыялалы зур ишек төбендә басып торган хәрби киемле бер кеше.

— Үзен күрергә кирәк миңа.

— Аның өчен пропускың булырга тиеш бит.

— Тиеш икәнен үзем дә беләм, вакытым юк шул минем пропуск артыннан йөрергә. Бүген генә килеп төштем менә, бүген үк кайтып китәргә дә кирәк. Син инде, улым, үзең шалтырат тиешле урынына,— дип гозерләп сорады әби хәрби киемле кешедән.

Ильич белән көрешкәч нәрсәләр әйтәсен, ни рәвешлерәк сөйләсен Дарья карчык поездда килгәндә үк уйлап куйган иде, ә менә көрешкәч югалды да калды. Ленин эшләп утырган кабинетның бусагасын атлау керүе булды, әзерләп куйган сүзләре башыннан чыгып та бетте. Ә Ленин, ул керү белән, өсте-өстенә китаплар өелгән өстәле яныннан тиз генә торды да беренче булып үзе сүз башлады:

— Исәнмесез, Дарья Семеновна. Менә монда яктыгарак узып утырыгыз, ни йомыш белән килдегез, сөйләгез,— диде ул.

Дарья беравык бер сүз дә әйтә алмый торды, ул әле һаман поездда уйлап килгән сүзләрен исенә төшерергә тырыша, тик берничек тә хәтеренә китерә алмый иде!

— Минем кайгыдан башка да эшең күплеген беләм! — диде ул ниһаять, телгә килеп.— Озын-озак сөйләп тормыйм. Рәхмәт әйтергә дип кенә килдем. Үзем өчен түгел, укытучыбыз өчен мәшәкатьләдем сине. Рәхмәт ярдәм итүең өчен.

Владимир Ильич сүзнең кем турында, ни турында икәнлеген тизрәк аңлап алыр өчен Дарья әбине игътибар белән, күңел салып тыңлап торды, ләкин күпме генә тырышса да, сүзнең кем турында икәнлеген исенә төшерә алмады.

Ә карчык, Ильичның уңайсызлануын күргәч, аны-моны сиздереп тормады, урыныннан кузгалып Ленинның янына ук килде дә кулындагы төенчеген чишә башлады.

— Моны сиңа дип алып килдем. Ачулана күрмә, әниеңнән алган төсле итеп ал,— диде әби һәм өстәлнең кырыена гына бер кием күк бияләй куйды. Бияләйләр өстәлгә җәелгән яшел постау өстенә йомшак кына килеп ятты, мамыктай йомшак җыерчыклары әкрен генә язылды.

Карчыкның да әкрен генә көрсенеп куйганы ишетелде.

— Авыл бияләе. Җылы кулыңда тузсын,— диде ул ягымлы итеп.

— Ильич бер бияләйне алып киеп карады, бияләй аның кулына тап-таман булып чыкты.

— Безнең якларда да шушылай итеп бәйлиләр, эрләгән йонны катып. Бик зур рәхмәт сезгә,— диде Ильич.

Өстәп тагын нидер әйтмәкче булган иде, өлгермичә калды, карчык ашыгып саубуллаша да башлады һәм килеп кергәндәге шикелле үк кинәт кенә чыгып та китте.

— Син гафу ит инде мине, ашыгам, Можайдан ары төнлә кайтырга туры килә,— диде ул, чыгып барышлый.

Ләкин пыялалы ишектән чыгу белән ашыгуыннан да, кабалануыннан да туктады. Шәһәр шикелле зур ишек алды буйлап, үз ишек алдыннан барган шикелле ашыкмыйча, дәрәҗәсен белеп кенә атлап китте. Январь аеның тәңкә карлары да аның шәл бөркәлгән иңнәренә нәкъ авылдагыча үз итеп, якын итеп төшеп куналар иде.

Карчык баруыннан туктады. Борынгы чиркәүләрнең алтын гөмбәзләрен, инде бик иске булуына да карамастан, менә хәзер генә төзелеп беткән шикелле кып-кызыл булып күренгән, тешле-тешле кремль стенасын, әллә кайчан атудан туктап тып-тын гына тезелеп торган тупларны — барсын-барсын ашыкмый гына карап чыкты һәм күңеле күтәрелеп, җаны тынычланып калгандай булды.

Курантлар суккан аваз ике тапкыр яңгырап, ике тапкыр Мәскәү елгасы аръягына, кояш баеп килгән Зарядье ягына китеп югалды. Ә карчык, үз уйларыннан үзе елмайган хәлдә, баскан урыныннан кузгалып китә алмыйча бик озак торды.

Боровицкий капкасы янына килеп җиткәндә, карчыкны урәчәле чана җиккән ат көтеп тора иде.

— Ленин вокзалга илтеп куярга кушты,— диде кучер, салкыннан кызарган кулларын уа-уа.

Дарья авылга битләре алсуланып шатланып кайтып керде. Аның сөйләгәнен тыңлап бетергәч, авылдашлары:

— Син ашәреп киткәнсең түгелме соң?! — дигән булдылар.

— Миңа нәрсә булсын ди? Әнә шәһәрдәге туплар өчәр йөз кыш тоташ кар астында да торалар әле, алай да күгәрмәгәннәр,— дигән булды Дарья.

Тик ул үзе илтеп биргән бияләйләрне Ильич кияме, кимиме икәнен генә белми иде.

— Үзең уйлап кара: нишләп кисен ди ул синең бияләйләреңне. Аның кош мамыгы белән астарлаган күн бияләйләре бардыр. Аннан да яхшырагы — ангор сарыгы йоныннан эрләп бәйләгән бияләйләре дә бардыр әле,— диләр ана күршеләре.

— Ансы шулай инде,— ди карчык алар әйткән белән килешеп.— мин илткән бияләйләрнең аңа киргәге шуның хәтле генәдер. Алай дисәң, белеп булмый, салкын көннәрне әллә гел кия торгандыр.

Үзе күңеленнән кия торгандыр, дип уйлый иде.

Шул араларда авыл егетләре шәһәргә барып кайттылар. Кайту белән Дарья янына керделәр.

— Киеп йөри икән бияләйләреңне! Үзебез күрдек. Мактый-мактый кия, ди. Җылы бияләйләр икән, теләсә нинди ангор бияләйләреннән җылырак, дип әйтә икән,— диделәр егетләр.

Аларның сүзен Дарья әби дәшми-тынмый гына тыңлап утырды. Кичке шәфәкъ яктысында аның кулындагы биш энәләре генә күзлегенә тиям-тиям дигәндәй, көмештәй елык-елык ялтырый иде. Дарья янындагы тәрәзә төбендә бәйләп беткән әзер бияләйләр ята. Бер бияләйнең йонлач бармакчасы кемнеңдер бик дәү кулына кигертелгән сыман тырпаеп тора иде.

— Дарья Семеновна, ә болары кемгә соң?

— Менә монысы Ильичның кучерына. Монысы үзебезнең хат ташучыбыз Саша-Каланчага. Хат тутырган авыр сумкасын күтәреп кыш буе нинди салкыннарда йөри бит ул.

...Ул заманнан бирле күп еллар үтте инде.

Хәзер Ленин да юк, Дарья карчык та юк...

Дарьялар авылына таба, кар кертләрен ерып, бүтән хат ташучы сукмак сала, ә карчыкның кадерле бүләкләр бәйләгән биш энәләре әле дә исән, ал-ял күрми бәйлиләр дә бәйлиләр икән.

Күршебездә яшәүче герой очучы яна ел алдыннан якташларыннан, Можай ягындагы бер авылдан посылка алды. Фанер тартманы ачсак, анда бер кием бияләй иде.

Нәкъ әнә теге чактагы төсле.

## Легенда



Без Горкига иртәнге беренче поезд белән килеп төштек һәм шул көнне бар нәрсәне — йортны да, паркны да, әйләнә-тирәне дә карап чыктык. Йорт эчендә карамаган бер генә почмак та калмады. Хәтта такталары шыгырдап торган һәм каты авырудан соң терелә башлаган Владимир Ильич өчен махсус ике яклап култыкса куелган текә баскычтан да саклык белән генә менеп карадык. Тәрәзәләре киереп язгы бакча ягына ачылган кечкенә генә бүлмәгә кереп тып-тын басып тордык. Аның гомеренең соңгы минутлары шушында үткән. Паркта кайчандыр Ленин йөргән бөтен юллар, бөтен сукмакларны йөреп чыктык. Янәшә-тирәдәге кырыс тынлыкка чумган урман-басуларга карап тордык.

Мәскәүгә кич житкәч кенә, сөйләшә алмас дәрәжәдә хис һәм уйлар белән тулышкан хәлдә кайтырга чыктык.

Безнең барыбызда да шундый хис иде, әйтерсең, без музейда түгел, ә Ильичның үзендә кунакта булып кайтабыз сыман иде. Текә агач баскычның лаклы култыксалары да әле аның кул жылысыннан суынып өлгермәгәндер шикелле иде. Ленин белән, аның истәлеге белән бәйле нәрсәләр безнең өчен беркайчан да күптәнге тарихка әйләнеп кала алмыйдыр, күрәсең. Әмма вакыт жиле дигән нәрсә борынгы Горки туфрагында үскән мәһабәт имән яфракларында торган саен сиздеребрәк шаулый, һәм ул якларда инде бик күптәннән бирле берсеннән-берсе гажәбрәк легендалар, истәлекләр йөри.

Гажәп бер вакыйга турында безгә вагонда бер солдат сөйләде. Безнең юлдашыбыз — карт солдатның түшенә таккан медальләре поезд тәгәрмәчләре көенә кушылып моңлы гына чыңлыйлар иде.

...Ленин үлгәч һәм кар баскан Мәскәүгә аны соңгы тапкыр озату сәгате житкәч, Горки комендантының йөрәге кинәт жу-у итеп куя: йорт белән станция арасындагы күпер тузып, какшап беткән, аның Ленинны озата баручы халыкны күтәрерлек чамасы калмаган.

Нишләргә? Ничек котылырга бу хәлдән?

Яңа күпер салу әле гадәти хәлләрдә дә авыр эш санала, ә монда буран котыра, тау-тау кар өемнәре, төкерек катарлык салкын, кулга балта тота торган түгел. Күзләрне кара кайгы баскан. Байракларны бәс каплаган — кызыл төснең кайда бетеп, кара төснең кайда башланганын да аерып булмый.

Тиз генә Мәскәүдән инженерлар, махсус хәрби частьлар чакырталар. Егерме икенче январь көнне иртә белән иртүк Горкига төркем-төркем саперлар килә башлый.

— Сүз дә юк, тиз килеп життеләр,— дип авыр сулап куйды түшенә медальләр тезгән солдат,— килүен килделәр ансы, тик вакытында килеп житәргә генә өлгермәделәр.

— Кит әле?! Өлгермәделәр диген, ә? — дип кемдер кайнарланып бүлде солдатның сүзен.— Әйбәтләбрәк сөйләп бир әле.

— Әйбәтләп сөйлим бит инде, килеп төштеләр инженерлар, ә Горкида иске күпернең эзе дә юк, әйтерсең, ул күпер бөтенләй булмаган да. Искесе урынында яңа күпер тора. Чын, чын. Могжизадыр дип уйлый күрмәгез тагын,— бер төн эчендә мужиклар үзләре салып куйганнар күперне: әйләнә-тирәдә авыллар күп, йорт башыннан берәр бүрәнә сөйрәп килгәннәр, һәркайсы учак ягып жибәргән дә — күпер әзер дә булган. Калганын инде аның рус халкының тапкырлыгы да жинә. Иң авыры чокыр казу була. Жир тоташ тун, ут та алмый, кувалда да алмый. Лом белән китереп бәрәләр, чуенга бәргән шикелле яңгырап кына китә жир. Таң алдыннан шулай да эшләр жайлана төшә.

Дөресен әйтсәк, без беребез дә солдатка ышанырга да ышанмаска да белмәдек. Солдат сөйләвеннән туктап бераз тынып торды. Тәмәке кабызды, күзләрен тәрәзәдән төн карангылыгына текәде дә тагын сөйли башлады:

— Инженерлар күпер тирәсендә тегеләй дә, болай да йөреп карадылар, чүкеч белән бүрәнәләренә дә суккалап чыктылар, аннары күпернең ныклыгын тикшереп, бер ун тапкыр булыр, бер яктан бер якка батальоны белән саперлар йөреп карады. Берни булмады күпергә. Селкенми дә, сыгылмый да! Мужикларның эшен яхшы дип таптылар инженерлар. Кагыйдә буенча булсын дип, ул күпергә паспорт та яздылар хәтта...

— Легендадыр бу! — дип, тагын кемдер бүлде кызып киткән солдатның сүзен.— Легенда булса да шәп чыгарганнар. Ышанырлык итеп.

— Легендамы, түгелме, ансын белмим,— диде солдат, утырган урыныннан торып,— теләсә нәрсә дип уйлагыз, ә миңа ул күперне

минем атам,— урны җәннәттә булсын,— минем этием үз куллары белән төзеде.

Солдат ашыкмый гына ишеккә таба юнәлде. Вагон ишеге төбенә җиткәч, безгә таба борылды да артык кычкырмыйча, әмма безнең барыбызга да ишетелерлек итеп әйтте:

— Легенда икән, легенда булсын! Сез әйткәнчә булсын. Ләкин минә шунысы бар: егерме икенче январь көнне мин шул күпердә сапер булып үз аякларым белән йөрдем. Ун тапкыр бер якка, ун тапкыр икенче якка чыктым. Менә шулай ул!..

Поезд туктады. Солдат кечкенә генә бер станциядә төшеп калды. Без китеп бардык.

Мәскәүгә җиткәнче, әле бик озак, поезд тәгәрмәчләре тыкылдавы арасында карт солдат түшенә таккан медальләр чыңы ишетелгәндәй булып барды.

# Чаң тавышы

*А. Д. Андреевка багышлана*



Бу хәл Совет власте урнашуның иң беренче елларында булды.

Березки авылында чиркәү янып көлгә әйләнә. Чиркәү агачтан салынган, инде искергән була. Йөз ел буе кар-яңгырда чыланып, йөз ел буе җил-кояш киптергән була аны. Гөлт итеп кабынуы була, минут эчендә янып та бетә, ә чаңы хәтта эреп ага. Чиркәү янып көлгә әйләнгән урында түгәрәк җиз күләвек торып кала.

Авыл мужиклары кайгырып, хәсрәтләнеп арганнан соң, Мәскәүгә хат язарга карар итәләр, менә шулай, шулай янәсе, шуңа күрә ярдәм итүегезне сорыйбыз, диләр.

Карасы кипкән кара савытына су салып кара ясыйлар да, каяндыр бер бит кәгазь табып, өстәл тирәли тезелешеп утыралар. Утыруын утыралар, ә яза белүчеләре юклыгын онытталар, чөнки авылда берләнбер яза белгән кеше герман сугышына китеп хәбәрсез югала. Ә яшь писарьлар әле үсеп җитмәгәннәр.

— Почтасы да йөрми торгандыр әле анын хәзер? — ди көтүче Никодим.— Иң яхшысы үзебез бару. Эш барып чыксын өчен туп-туры Ленинның үзенә керергә кирәк.

— Син инде бигрәк арттырып җибәрдең. Баралар ди сиңа Ленинга шундый йомыш белән! — дип көлешәләр мужиклар.

— Ә нигә бармаска? — дип сүзен сүз итә көтүче.— Җаны белән аңлый ул безнең тормышыбызны. Аның белән сөйләшә белеп сөйләшергә генә кирәк, тыңламый калмас ул безне.

— Алай бик белдекле дә, бик житез дә булгач, үзең генә бар инде алайса! — диләр.

— Ә нигә бармаска, барырмын да шул,— ди аптырабрак калган Никодим, колак артын кашып.

Ул чагында нинди авыр йөк алганын абайламаган икән көтүче. Мәскәүгә барып житүе ансат булмый аңа. Күпме вагон буферын тәне белән җылытып бара ул, барырга ризалык биргән сәгатен ничә тапкыр ләгънәтләп каргамый.

Ләкин иң зур кыенлыклар аны тегендә, Ленин кабинетында көтеп торган икән. Ишек бусагасын атлап керүе була, коела да төшә Никодим. Ленин аннан ничек килеп житүе турында сораштыра, авыл халләрен сораша, ә Никодим Кремльгә ни йомыш белән килгәнен әйтә генә алмый бит. Җыен вак-төякне сөйләп тик тора Ленинга.

Аннары тырысыннан төче күмәч алып, Ленинны сыйлый башлый. Ильич елмая-елмая ашый:

— Тәмле,— ди.— Бигрәк тәмле! Ләкин сез шундый ерак җирдән ни йомыш белән килүегезне яшермичә әйтегез инде,— ди.

— Яшермичә әйтсәм, болай, Владимир Ильич, без сезгә чаң сорап килдек. Чиркәвебез янды безнең...

— Сез чынлап сөйлисезме моны!?.

— Чынлап, Владимир Ильич. Бөтен авылыбыз белән гозерләп сорыйбыз сездән.

Ленин бик аптырап өстәл яныннан тора, кулларын җәеп җибәрә һәм шаркылдап көлә башлый.

— Шәп, бик шәп! Гаҗәп, искиткеч хәл бу! Иң хәтәр алласыз кешегә чиркәү чаңы сорап килсеннәр әле! Лев Толстой үзе дә уйлап чыгара алмас моны! — ди.

Ленин вак-вак атлап Никодим янында әрле-бирле йөри, үзе шундый рәхәтләнеп, кычкырып көлә, аңа карап торган көтүче Никодим да гаепле кеше сыман аптырап елмая башлый.

Ә бит аның эшләре бер дә көләрлек түгел.

Ленин, нидер исенә төшергән сыман, кинәт кенә борыла да өстәленә таба юнәлә. Никодимга таба борылганда аның йөзендә көлүеннән җыерчыклар гына торып кала.

— Хөрмәтле иптәш Никодим, сезгә илдәге хәлнең никадәр авыр икәнен сөйләп торасы юк,— ди ул.— Илдә икмәк белән ягулык кытлыгы гына түгел, металл кытлыгы да зур. Менә минем бик ашыгыч рәвештә бер чит ил әфәндесе белән сөйләшәсем бар, икенче атна инде һич эшли алмыйм шуны, линияләр өзелгән, ә чыбык сузарга җиз юк.

Ленинның кыяфәте шундый җитдиләнә, аны шундый кырыс йөзле итеп күрермен дип Никодимның башына да килми.

— Барысы да аңлашылдымы, Никодим иптәш,— ди Ленин көтүчегә.

— Барысы да аңлашылды, Владимир Ильич.

— Алай булгач, бирегез кулыгызны! Минем өчен авыл кешеләреннән гафу үтенегез. Ленин чаң бирмәде, диегез, бер дә ыспайлап маташмагыз, бик җитди сәбәпләр аркасында, Ленин чаң бирмәде,— диегез.

— Барысын да әйтермен, Владимир Ильич.

Авылга кайткач Никодим ничек булганын барысын да сөйләп бирә.

— Юкка гына кешенең эшен бүлеп йөргәнсең,— диләр мужиклар башларын селкеп.

— Юкка булды шул,— ди Никодим авылдашлары белән килешеп,— аның эше дә күп, безнекеннән кирәгрәк тә.

Ә яз көне, Никодимның сәяхәте онытылып, инде ул турыда сөйләнми дә башлагач, Мәскәүдән авылга чаң китерәләр.

— Ленин җибәрде. Кремльдә саклана торган кыңгырауларның берсе,— ди Никодимга шундый гаҗәп посылканы китерә килгән эшче кыяфәтендәге бер кеше.

Бу гаҗәп кыңгырауны карарга бөтен авыл җыела. Кыңгырау зур түгел, гадәти киледән бераз гына зуррак, ләкин чәче-башы тузгыган Никодим кулына алып баш очына күтәргәч, кыңгырау май кояшында көмеш кантары шикелле күзләрне чагылдырып ялтырый иде.

Көтүче белән янәшә басып торган эшче кыңгырауның кабыргасына сырлап-сырлап славянча язу белән язылган сүзләрне халыкка кычкырып укып бирә.

«1808 елда Валдай шәһәрендә оста койды» — дип язылган кыңгырауның читенә.

Ул халыкка таба борыла, тынып калган кешеләрнең күзләренә туп-туры карап:

— Иптәшләр! Владимир Ильич сезгә күп сәлам тапшырырга әйтте,

аннан аның Россиядә иң баш алласыз кеше икәнен исегезгә төшерергә дә кушты. Калганын инде үз башыгыз белән уйлап карагыз,— ди.

Кыш житәр алдыннан Березкида мәктәп салына. Мәктәпне салып бетергән көнне мужиклар жыелып шундый фикергә киләләр:

— Безнең чиркәү барыбер юк инде. Әйдәгез чанны мәктәп түбәсенә жайлап эләбез, соныннан күз күрер тагын,— диләр.

Янәшә-тирәдәге авыл балалары, китапларын күтәреп, шул кыңгырау тавышын ишетүгә мәктәпкә йөгерәләр.

Озакламый шул якларда беренче колхоз төзелгәч, кыңгырау крестьяннарны эшкә, тарихта беренче тапкыр әле бәхетле, сөенечле хезмәткә чакыра торган булып китә. Бөек Ватан сугышы башлангач та әлеге чанның шомлы авазы дулкын-дулкын булып шул яктагы авыллар өстенә тарала һәм халык, олысыннан алып кечесенә чаклы, үзләре яраткан кыңгырау тавышын танып алалар. Халык туган илне дошманнан сакларга кузгала.

Ильич бүләк итеп жибәргән кыңгырау, кояшта көмештәй ялтырап, әле дә булса мәктәп түбәсендә эленеп тора. Березкига гомерендә бер генә тапкыр булса да килеп киткән кеше йөз илле ел моннан элек рус остасы тарафыннан коелган һәм шушы көнгә чаклы көмештәй саф авазын саклап калган кыңгырауны инде беркайчан да оныта алмас.

Березкида кыңгырау авазы яңгырый. Аның авазы елдан-ел сафланадыр, яңгырабрак һәм ерак̆карак ишетеләдер төсле тоела миңа.



## Репортер

Машина белән барамы, жәяүме — кая гына бармасын, Ленинга ияреп яшь тә түгел, карт та түгел, боек та түгел, шат та түгел, дигәндәй, бер сәер кеше йөри. Ленин сиздерми генә аңа күз салгалый һәм:

«Кем соң бу кеше? Каян ул, нишләп йөри икән? Сакчылардан түгелме? Дзержинскийга әйтергә кирәк булыр, монын ише сакчылар куймасыннар мина»,— дип уйлый.

Ләкин күпме генә күз салмасын, Ленин аның кем икәнен белә алмый һәм ахырда сабырлыгын югалтып:

— Гафу итегез, иптәш, нәрсә язасыз сез бер туктаусыз? — дип теге сәер кешенең үзеннән сорый.

— Газетага хәбәр язам. Репортер мин, Владимир Ильич, «Правда»-га язам,— ди әлеге кеше.

— Репортермыни?! Ә мин бөтенләй башкача уйлаган идем,— ди Ленин, дусларча елмаеп.— Дөресен әйтергә кирәк, мин үзем сез газитәнаптән зарланып жалоба язмакчы идем әле. Болай булгач инде, хезмәттәшем буларак, бер ризасызлыгым да юк сезгә карата. Тик бер нәрсә генә үтенәм, һәрвакыт төгәл булыгыз. Безнең эштә башкача мөмкин түгел.

— Тырышырбыз, Владимир Ильич!

Һәм чыннан да аның газетага бастырып чыгарган мәкаләләрендә артык сүз булмый иде. Ленинның Трехгорка тукучы хатын-кызлары алдында ясаган чыгышы турында да, тимер юл депосы комсомоллары белән үткәргән әңгәмәсе турында да, Россиядәге иң беренче тракторның, зәңгәр төтен йомгаклары бөрки-бөрки, кара туфракта иң беренче буразналар салганын карарга Мәскәү янындагы бер авылга баруы турында да хәбәрләрне ул дөрес, төгәл язган иде.

Ләкин шулай да бер мәлне бер хәл килеп чыкты бит...

Ленин бер бик житди жыелышта чыгыш ясады, жыелыш бетәрәк, житмәгәндә, Ленин янына репортер килде дә:

— Владимир Ильич, бу жыелышта нәрсә турында сөйләгәннәрегез не ике сүз белән генә әйтеп бирегез әле,— диде.

— Ничек инде ул алай? Сез үзегез кайда булдыгыз, коллега? — дип аптырап сорады Ильич.

— Мин соңга калган идем...

— Аңлашылмый...

— Соңга калдым, дим. Трамвайлар йөрми, бер генә линиядә да ток юк.

— Ничек килдегез соң? Җәяүмени?

— Шулай булып чыга инде. Башта кызу гына килгән идем дә, соңыннан арытты, шуна менә...

Уңайсызланып торган репортерга Ленин игътибар беләнрәк карады һәм шунда беренче тапкыр репортерның «карт та түгел, яшь тә түгел» кеше булмавын, ә чын-чыннан олыгайган, ап-ак чәчле кеше икәнен күрде.

— Ни генә булса да соңга калырга ярамый,— диде Ленин.

Репортер башта Ленинның чынлапмы, шаярыпмы әйткәнен аңламый торды. Әмма Владимир Ильич шаярып әйтми иде. Ул репортерга яңадан бер тапкыр карап алды да һич шаяртусыз, бик җитди рәвештә әйтте:

— Ә хәзер бер читкәрәк китик тә, эшчеләр белән нәрсә турында сөйләшүемне язып алыйк. Дисциплина турында да сөйләштек, ул хакта язу чын-чыннан файдалы булачак,— диде.

Алар бушый төшкән цех конторасына керделәр һәм анда шактый вакыт юандылар. Инде күптән кичке смена эш башлады, пролетлар яңадан шау-шу белән, төтен белән тулды, ә Ленин белән репортер сөйләштеләр дә сөйләштеләр. Дөресрәге, аларның берсе сөйли, икенчесе блокнот битләрен ачарга чак кына өлгергән хәлдә, кызу-кызу яза иде.

Ленин сөйләп бетергәндә, репортер блокнотының да соңгы чиста бите язылып беткән иде инде.

— Нинди үкенечле,— диде Ильич,— бер генә бит җитми калды, гонаһ шомлыгы, минем үземдә дә бер генә бит тә чиста кәгазь юк, ичмасам.

— Әйтеп торыгыз, Владимир Ильич, ә мин ятлап алам да редакциядә сүзен сүзгә язып куярмын,— диде репортер.

— Юк, алай булмый,— диде Владимир Ильич, елмаеп,— кәгазь кирәк, безнең эштә кәгазьсез ярамый.

Шул чагында әкрен генә контора ишеге ачылып, ишектән цех башлыгы килеп керде һәм репортерга кыяр-кыймас кына, юл аралары тар гына калдырылып сызык сызылган һәм майланып беткән,— нарядлар яза торган бланк булса кирәк,— яшькелт кәгазь кисәге сузды.

— Юк, юк, бу кәгазь миңа,— диде Владимир Ильич. Аннары кискен хәрәкәт белән артсыз урындыкны өстәл янынарак этәрде, кәгазьне цех башлыгының селкенеп торган бәләкәй генә өстәле өстенә куеп, аңа кызу-кызу бер ике сүз язды да репортер кулына тоттырды һәм:

— Иртәгә Совнаркомга керегез дә менә шушы язуны эш башкаручыга бирегез. Сезне мин үзем дә илтеп куйган булыр идем, икенче бер урынга барырга ашыгам. Тоткарлавым өчен гафу итегез,— диде дә цех башлыгы һәм репортер белән кул биреп саубуллашып китеп барды.

Ильич китеп берничә минут үткәч, төтен тулы конторадан аптырашта калган репортер да чыгып китте. Икенче көнне иртә белән ул Халык Комиссарлары Советына юнәлде. Ленинның теге кәгазь кисәгенә нәрсә язганын репортер шунда гына белде.

Кәгазь кисәгенә «Правда» хәбәрчесе карамагына җигүле ат бирергә кирәклеге турында, аның инде олыгайган кеше булуы һәм андый олы яшьтәге кешегә редакция эше белән көннәр буе җәяү чабып йөрүе кыен икәнлеге турында язылган иде.

**Ш. МАКСУДОВА** тәрҗемәләре

## Лев Кондырев

Рус шагыйре

# Кокушкинодан репортаж

Зур юллар йөгерә ерак зәңгәрлеккә...
Хәтер, бүгенге көнгә син дан җырла!
Кокушкино...
Монда сәяси сөргендә,
Беренче сөргендә
УЛ була.
Флигель бик иске,
Кайчан төзелгән ул?..
Бәлки йөз ел элек?..
Тик чәчәкләр шиңми.
Әйтерсең, һаман да
Аксыл куртка кигән,
Урта буйлы егет —
Шул студент йөри...
Аңа атап салган
Бу һәйкәл янында
Мин туристлар белән
Озак басып торам.
Һәм уйланам һаман:
Аны, Ульяновны
Мин соң кемнәр белән
Чагыштыра алам?..

Гранит ташлардан
Һәм нык бронзадан
Коелган Ульянов
Охшый тик үзенә!
Йөзе генә түгел,
Сыны гына түгел —
Аның уйлары да
Бары тик үзенчә!

Тик галәмдә әле
Ильичның төп аслын
Тулы тасвир итәр
Көчле бер оста юк.
Ленин ул — могҗиза!
Кадерле зур исем.
Ленин ул —
Дөньяда халыклар остазы!

Ул безгә үлемсез дөреслек күрсәтте,
Һәм безнең һәр эштә яши ул!
Ильичның Мәңгелек шикелле яшь күңеле,
Син безгә мәңгелек канат бул!

Гәрәй РӘХИМ тәрҗемәсе.

**Мәхмут Хәсәнов**

# ПСКОВТА СИКСӘН ӨЧ КӨН

Владимир Ильич Ленин Псковта нибары 83 көн яшәгән. Әмма безнең партиябез өчен гаять әһәмиятле чорда. Ильич сөргендә вакытта ук Россиядә эшчеләр хәрәкәтен җитәкләргә сәләтле, марксистик революцион партиягә башлангыч булып әверелергә тиешле гомум-рус газетасын чыгару планы белән янып яши.

Псковка ул таркау социал-демократик группаларны бергә туплап, яңа типтагы, үз алдына яңа максат куйган партия төзүнең теоретик проблемаларын хәл итәргә, пролетариат хәрәкәте өчен революцион теориянең әһәмиятен нигезләргә, Россиянең иҗтимагый-экономик строена фәнни анализ ясарга дип килә. В. И. Ленин ул чорда күп санда әсәрләр яза. Әсәрләрендә революцион марксизмның идея дошманнары — народникларга, «экономистлар»га һәм «легаль марксистлар»га каршы мәрхәмәтсез рәвештә көрәш алып бара.

1900 елның 26 феврале. Петербургтан килгән иртәнге пассажир поезды Псков станциясенә килеп туктый. Бик иртә булгангамы, төшүчеләр әллә ни күп түгел. Алар да төшү белән таралышып, иртәнге куе сыкы эчендә эрегәндәй, шунда ук юк булалар.

Поезд карлыккан тавыш белән кыска гына итеп кычкырта да, тирә-якка куе пар бөркеп, яңадан кузгалып китә. Бераздан перрон тәмам бушап кала.

Юк, барысы да таралып бетмәгән әле: шул вакыт, нәкъ җир астыннан калкып чыккан кебек, перронда тагын бер пассажир күренә...

Бу — Псков җиренә беренче тапкыр аяк баскан В. И. Ульянов. Кулында җиңел саквояж аның. Иң элек ул, җитез-җиңел атлап, вокзалга керә. Әмма пассажирларның кетеп тору залына түгел, шәһәргә чыга торган ишеккә таба юнәлә ул.

Извозчик-фәлән очратырмын, дип уйлагандыр бәлки. Әмма вокзал мәйданы буш. Атлылар түгел, җәяүлеләр дә күренми.

Тирә-якка күз сала. Сирәк-мирәк кенә җемелдәшкән утларны исәпкә алмаганда, кала әле эңгер-меңгер эчендә.

В. И. Ульянов үзенә таныш булмаган бу калага килеп төшкәндә, шушы кадәр иртә булыр дип уйламагандыр, күрәсең. Әйе, ерак Себердә, Шушенскоеда бу вакытта инде алар Надежда Константиновна белән эшләп ара торганнар иде. Хәер, моннан нәкъ егерме генә көн элек, 6 февральдә генә, Уфада да бу вакытта инде яп-якты иде бит.

Владимир Ильичка Уфада калырга, ә Надежда Константиновнага Псковка килергә рөхсәт итмиләр. Шулай итеп аларга бераз ел чамасы аерым яшәргә туры киләчәк...

Бераздан вокзал тирәсенә җан керә башлый. Иртәнге пассажир да бер-бер артлы килеп туктаган извозчикларның берсе янына килә дә, үзенә кирәкле урамны әйтеп, җиңел чанага менеп утыра.

Владимир Ильич сөргендә вакытта ук инде берничә адрес барлаган була. Иң элек ул Любовь Николаевна Радченко квартирасына юл тота. Ул аны Петербургта «Эшчеләр сыйныфын азат итү өчен көрәш Союзы»нда бергә революцион эш алып барган чаклардан бирле белә. Любовь Николаевнаның суд белән хөкем ителеп өч елга Псковка сөрелүе дә Владимир Ильич өчен сер түгел.

Владимир Ильич Любовь Николаевнаны өйдә очрата алмый. Шуннан соң ул икенче бер танышы — статист В. А. Оболенский квартирасына юл тота.

Өч көннән соң В. И. Ленин купец Поташов йортында өч бүлмәле квартир алып яшәүче Любовь Николаевна Радченко янына күчеп килә.

В. И. Ленинның сөргеннән ничек кайтып төшүе турында энесе Дмитрий Ильич истәлекләре бар. Менә шул истәлекләрдән берничә юл: «Владимир Ильичның юлга чыгу вакыты турындагы хәбәрне алгач, мин аны Мәскәүдән 50 чакрымнар ераклыкта, ул чакта үзем торган Подольскида каршы алдым. Аны ерак юл поездының III класс вагонында таптым; бөтен нәрсә халыкның салкын яктан кайтканлыгын күрсәтеп тора иде — мех туннар, дохалар, себер халкы кия торган колакчын бүрекләр, киез итекләр һ. б. белән вагон тулган. Владимир Ильич тазарак, сәламәтрәк кебек күренә, әлбәттә, һич тә предварилкадан соң диярлек түгел иде».

Гомумән, В. И. Ленинны Псковта көтеп каршы алалар. Яше утызга да җитмәгән ялкынлы марксистны күрергә, аның белән якыннанрак танышырга теләүчеләр күбәя. Берничә тапкыр конспиратив очрашулар да була. Яшь Ульянов белән кызыксыну көннән-көн арта. «Кем соң ул?» дигән сорауга: «Белмисезмени? Соң бит ул «Россиядә капитализм үсеше» дигән китапның авторы»,— дип кенә җавап кайтаралар. Петербург төрмәсендә язылып та, үзе Себердә сөргендә вакытта чыккан бу әсәре марксистлар арасында инде ул вакытта зур популярлык казанган була. Хәер, бу бер дә гаҗәп түгел. В. И. Ленин үзенең бу хезмәтендә народникларны идея ягыннан тар-мар итүне тәгәлләп кенә калмый, бәлки «легаль марксистлар»ны да фаш итә. XIX—XX гасырлар арасында «Россиядә капитализмның үсеше» Маркcның «Капитал»ыннан соң марксистик тәгълимат буенча иң күренекле хезмәт ул.

В. И. Ульянов туктаган Любовь Николаевна квартирасына килүчеләр, яшь марксист белән танышырга теләүчеләр көнләп түгел, сәгатьләп арта. Бу хәл Ильичны сагайта. Чөнки ансыз да яшерен күзәтү астында яшәгән квартира хуҗасын уңайсыз хәлгә куюдан саклана ул. Һәм төп-төгәл атна үтте дигәндә, Владимир Ильич провизор Лурья квартирасында аерым бүлмә алып, шунда күчә.

Дүрт катлы шул йортның өченче катындагы бу бүлмәдә хәзер В. И. Ленин музее урнашкан. Ә йортның стенасына, парад баскычының уң ягына: «Бу йортта 1900 елның мартыннан июненә кадәр Владимир Ильич Ленин яшәде. Монда ул «Искра» һәм «Заря» редакциясе белдерүе проекты»н язды», дигән мемориаль такта куелган.

Буйга дүрт, аркылыга өч адым тәшкил иткән ул бүлмәне бер мәртәбә күргән кеше гомеренә дә онытмас.

Гап-гади бүлмә. Ишектән кергәч тә сул якта ялтырап торган дүрт җиз шарлы тимер кровать. Стенага терәп үк куелган ул. Өсте шакмаклы бизәк төшкән гади одеал белән капланган. Түрге почмагында ак тышлы ике мендәр. Кровать каршында шактый таушалган иске диван. Түрдә, урамга чыга торган бердәнбер тәрәзә каршында ук, яшел сукно белән капланган ике тумбалы язу өстәле. Аның өстендә абажурлы керосин лампасы. Шунда ук кара савыты һәм таратып салынган язу кәгазе. Өстәлнең уң ягында, почмакта, китап киштәсе. Анда — китаплар, журналлар һәм газеталар... Шушы кечкенә генә бүлмәдә В. И. Ленинның шәхси китапханәсе дә булган. Кечкенә булмаган ул, анда философия, статистика, тарих һәм экономика буенча дүрт йөзгә якын, икенче төрле итеп әйткәндә, 15 потка якын китап булган. Арада К. Маркcның «Капитал» томнары тезелеп торалар. Шунда ук Ф. Энгельс һәм инглиз экономисты Д. Рикардо, француз утописты Ш. Фурье әсәрләре. Икенче киштәдә чит ил телләрендә язылган Гегель, Фейербах, Кант, Фихте, Спиноза һәм башка философларның томнары. Монда матур әдәбиятка да күп урын бирелгән. Рәт-рәт булып Гончаров, Тургенев, Салтыков-Щедрин, Бальзак, Гете һәм башка бөек язучыларның китаплары тезелешеп торалар.

Өстәлдә дә ачык китап ята. Урта бер җирдә — яза башлар өчен әзерләп куелган кәгазьләр. Чак кына уңдарак җиз саплы аслыкка утыртылган стакан. Эчендә бал калагы...

В. И. Ленин әле яңа гына урыныннан кузгалып киткәндер дә бары тик һава алыштырып керер өчен чыккандыр, бераздан керер дә яңадан эшенә керешер төсле...

Кичкә таба ул һәрвакыт һавада йөрергә яраткан. Аннары инде төнгә каршы эшләргә утырган. Владимир Ильич янына кунаклар бик сирәк килгәннәр. Килгәндә дә бары тик кереп кенә чыга торган булганнар. Аның каравы, караңгы төштеме, баскыч төпләрендә, өй тирәсендә сәер ир-атлар (шымчылар) еш чагылып-чагылып киткәләгәннәр...

Владимир Ильич һәр көнне төнгә каршы самовар куйдыра торган булган. Үзе ясап, каты итеп чәй эчәргә яраткан ул.

Владимир Ильичның иң яратып, теләп аралашкан кешеләре Псков статистлары булалар. Ә кайчак үзе дә революцион эшчәнлеген яшерү нияте белән һәм бераз хезмәт хакы алу өчен губерна земствосының статистика бүлегеннән эш алгалый. Хәтта Ульянов аена 25 сум күләмендә хезмәт хакы алып статистика идарәсендә эшләгән дигән фикер дә яши. Әмма мондый версия бернинди документлар белән дә рәсми рәвештә расланмый. Ул вакытта статистика идарәсе башында М. Горькийның һәм В. Короленконың якын дусты Н. Кисляков тора. Үзе марксист булмаса да, ул революционерларга күп ярдәм күрсәтә. Губерна земствосында Н. Сергеевский, А. Стопани

кебәк марксистлар эшлиләр. Ленин сөргендә вакытта ук бу турыда яхшы белә. Бәлки шул хәл аны Псковка тарткандыр да.

В. И. Ленин Псков интеллигенциясе белән яшерен рәвештә атнасына кимендә бер тапкыр очрашулар оештыра. Ул очрашулар гадәттә Радченко яки Оболенский квартирасында булалар. Андый конспиратив кичәләрдә, гадәттә, политик яки экономик темаларга рефератлар укыла. Төп чыгышларны һәрвакытта да диярлек В. И. Ленинга ясарга туры килә.

Псков интеллигенциясе арасында эшләү җиңел булмый. Чөнки анда ул чорда Россиядә яшәгән барлык политик агым вәкилләре дә аралашып беткәннәр. Монда народниклар да, либераль оппозиция дә, экономистлар һәм социал-демократлар да була.

Ул көннәрдә Владимир Ильичның бер генә минут та буш вакыты булмый. Бөтен көчен куеп, социал-демократлар группировкасы кушуы буенча ул үзенең атаклы «Искра» һәм «Заря» редакциясе белдерүе проекты» дигән әсәрен яза.

Аннары бит әле бөтенләй көтмәгән яктан «зәһәр җилләр» дә исеп куйгалыйлар. Владимир Ильичның экономистларны, бигрәк тә «легаль-марксистлар»ны тетеп чыккан «Россиядә капитализмның үсеше» дигән китабы бик күпләргә ошамый. «Легаль-марксист» П. Н. Скворцов Ленинның бу әсәрен үзенчә бик тәнкыйтьли. В. И. Ленин аңа каршы «Некритическая критика» дигән үзенең үтергеч җавабын бирә.

Әмма Ильичның төп максаты легаль булмаган марксистик матбугат оештыру була. Шул максат белән ул, катгый рәвештә тыелса да, яшерен рәвештә берничә тапкыр Питерга бара. Анда булачак «Искра» өчен хәбәрчеләр һәм агентлар әзерли. Булачак матбугатның финанс якларын җайга сала. Шул ук максат белән Ригага да барып килә.

Шул ук максаттан чыгып, Владимир Ильич (немец телен яхшы белүенә дә карамастан) 1900 елның 19 мартында «Псковский городской листок» газетасында: «Немец теленнән дәресләр алырга телим», дигән белдерү бирә. Атна да үтми, Ильич әнисенә язган хатларның берсендә: «Монда бер немецтан, дәресенә 50 тиен түләп, немец теле буенча дәресләр алам», дип яза.

Бөтен гомерен, бөтен шәхси язмышын азатлык өчен көрәшкә багышлаган кешенең дә күңел түрендә бары тик үзе өчен генә калдырылган почмагы буладыр шул... Ильич та Уфада калган тормыш иптәше Надежда Константиновна белән аерым яшәвен авыр кичерә. Сагына, юксына. Шуның өстенә Надежда Константиновнаның сәламәтлеге дә чамалы. Баштарак Ильич аны үзе янына Псковка алдыру чараларын күреп карый. Әмма аның барлык үтенечләренә дә бер үк төрле җавап килә: катгый рәвештә тыела.

Ахыр чиктә В. И. Ленин 1900 елның 20 апрелендә (ул вакытта инде тарихи «Псков киңәшмәсе» үткән була) полиция департаменты директорына язган гаризасында үзен Уфага җибәрүләрен үтенә. Надежда Константиновнаның чирләвен дә (телеграф белән тикшерә-нитә калсалар дип), дәвалаучы докторның Филатов икәнлеген дә атап яза.

«Югарыда әйтелгәннәрдән чыгып,— дип дәвам итә Ильич,— мин сез галиҗәнаплардан миңа ай ярым чамасы Уфа каласында яшәргә рөхсәт итүегезне үтенәм».

Кәефсез чакларында, көннәр буе эшләп арыгач, төнгә каршы «Җәйге бакча» дип атала торган кала паркында йөрергә яраткан Ильич. В. И. Ленин музееннан ерак түгел ул бакча. Аның бер ягында, Петр I нчегә бернинди катнашы булмаса да, ни өчендер Петровские дип атала торган биек таш стена сузыла. Кайчандыр, борынгы заманнарда, шәһәр чите булган бу тирәләр. Ә ике якта, иге-чиге күренмәгән аллея булып, карт тирәкләр сузылалар. һәркайсына берничәшәр йөз бардыр аларның.

...Соң инде. Кеше-кара күренми. Бары тик бөек Ленин исемен йөртүче шәһәр проспектыннан соңарган троллейбуслар гына үтәләр. Агач кәүсәләре аша аларның тәрәзәләреннән төшкән яктылык кына чагылгалап кала. Тынлык. Бары тик таңкә-таңкә булып кар төшә. Уйларда исә Ленин. Ул да менә шушы аллеялардан узгандыр. Бу карт тирәкләр аның да баш очында шаулаганнардыр...

Ә күңел һаман үзенекен итә, Ленинны уйлый, аның белән серләшә, сөйләшә. Ул гына да түгел, якасын күтәреп, кызу-кызу атлап үзе дә килеп чыгар төсле...

Ленин!

Никадәр якын син, шулкадәр кирәк син!.. Үзеңнең шәхси тормышыңны эшчеләр сыйныфының тарихи язмышына бәйләп, нинди генә авырлыклар, нинди генә мәхрүмлекләр һәм җәфалар кичермәдең син!

Ленинның бөеклеге, даһилыгы турында акыл ияләре тарафыннан әйтелгән меңләгән һәм уннарча меңләгән цитаталар китерергә мөмкин. Ләкин бары тик бер кеше, Бернард Шоу сүзләре генә дә күпне аңлатыр кебек: «Ул... башкалардан өстенрәк торучы, бик аз кешеләр белән генә бер сафка куярлык кеше иде,— дип язды бөек әдип.— Бик азлар кергән бу сафтагы кешеләр арасында да Ленин башкалардан бик күпкә өстен торды.

Мин белмим, шундый ук әһәмияткә ия булган башка берәү кайчан да булса тагын яшәрме-юкмы».

Ә Ленин үзе исә болай дип яза: «Минем язмышым — политик ахмаклыкларга, кабахәтлекләргә, оппортунизмга һ. б. ш. каршы берсе артыннан берсе булып торган сугышчан компанияләрдән гыйбарәт. Бу 1893 елдан башлап. Кабахәт кешеләрнең мине күрә алмавы да шуның аркасында. Ләкин шулай да мин бу язмышымны әшәке кешеләр белән «килешеп яшәү»гә алыштырмас идем». (Әсәрләр, 49 том, 340 бит).

Нинди генә авырлыклар кичерергә туры килмәсен, В. И. Ленин үзен һичкайчан да бәхетсез итеп тоймаган. Өермә-давылларга каршы очарга көч-егәр тапкан горур кош кебек бәхетле булган ул. Чөнки үз идеяләренә тирән инанган, ару-талуны белмәүче, үзенең мохитын яхшы аңлаучы, тимер ихтыярлы, бөтен табигате белән көрәшче, кыю һәм тәвәккәл булган. Гомумән, курку дигән нәрсә аның өчен ят булган. Ул чорда Ригада яшәгән М. А. Сильвин истәлекләрендә мондый бер эпизод бар. Катгый тыелуга да карамастан, В. И. Ленин, кирәк кешеләрне күрү нияте белән, яшерен рәвештә Ригага бара. Истәлектән күренгәнчә, башында — йомшак фетр эшләпә, кулында — перчаткалар һәм җылкылдап торган трост. Кыскасы, В. И. Ленин чын джентельменнарча киенгән. Яшерен рәвештә килүенә дә карамастан, качып-посып йөрми ул, дошманның күзенә керә, үзенең немец теле акцентын тикшереп карау нияте белән, посттагы полисмен белән сөйләшеп тора. «Бик канәгать калдым, бер-беребезне бик һәйбәт аңладык», ди Ильич, шул вакыйганы исенә төшереп.



В. И. Ленинның Псковтагы икенче музее — Плеханов тыкрыгында, җәйге бакчадан әллә ни ерак түгел. Шунысы кызык: бу урыннар бөтенләй диярлек үзгәрмәгән, нәкъ В. И. Ленин яшәгәндәге кебек сакланган, дип сөйлиләр. Урамның як-ягында — кечерәк кенә гап-гади авыл өйләре. Һәрбер өй янында җиләк-җимеш бакчасы.

Тагын шул кадәресе бар: музейга бару юлын кешедән сорап торасы юк монда. Елның кайсы гына чорында барма, синең юлыңа сап-сары ком сибелгән булыр.

Музей йорты тар тыкрыкның иң түренә, тыкрыкка аркылы куеп салынган. Урам якка дүрт тәрәзәсе карый. Ул үзенең зурлыгы һәм яшелгә буялган булуы белән тирә-яктагы башка йортлардан аерылып тора. Стенасында — мемориаль такта. Аңа шушы йортта В. И. Ленин җитәкчелегендә, яшерен төстә, Коммунистлар партиясе тарихына «Псков киңәшмәсе» дип кергән тарихи киңәшмә үткәрелүе турында язылган.

Өй янына килеп җитү белән тагын бер нәрсә күзгә ташланды. Февраль аеның чатлама суык көне булуга да карамастан, мемориаль тактадан чак кына астарак, йортның нигезе өстендә, зур гына тере чәчәкләр бәйләме куелган иде. Юк, теплицада үстерелгән чәчәкләргә охшамаган иде алар, каяндыр бик ерактан китерелгән булсалар кирәк.

Менә тарихи Псков киңәшмәсе үткән бүлмә. Шактый зур өйнең залы бу. Урта бер җирдә аякларын бөгеп, бизәклап эшләнгән гаять зур өстәл. Бер почмакта клавесин тора. Аның өстендә яшел абажурлы лампа. Кара-каршы ике стенада — билгесез художникларның рамага куелган рәсемнәре. Җиңел челтәрләр эленгән зур-зур өч тәрәзә Псковка дип атала торган елга ягына карый. Тәрәзәдән текә яр буенда тезелешеп үскән карт тирәкләр күренәләр...

Шушы бүлмәдә 1900 елның март ае ахырында-апрель ае башларында атаклы киңәшмә уздырыла. Киңәшмәдә нибары алты кеше катнаша. Социал-демократлар дүртәү: В. И. Ленин, Ю. О. Мартов, А. Н. Потресов, С. И. Радченко һәм ике «легаль-марксист»: П. Б. Струве, М. И. Туган-Барановский.

Үзенчәлекле киңәшмә була бу. Бернинди протоколлар, бернинди язмалар алып барылмый. Иң элек В. И. Ленин үзенең алдан ук хәзерләп куйган «Искра» һәм «Заря» редакциясе белдерүе проекты»н кычкырып укый.

Менә ул тарихи документның беренче юллары:

«Ике социал-демократик орган — фәнни-политик журнал белән бөтен Россия күләмендәге эшчеләр газетасын чыгара башлаганда, без үзебезнең программабыз турында, нәрсәгә омтылуыбыз һәм үз бурычларыбызны ничек аңлавыбыз турында берничә сүз әйтергә кирәк дип саныйбыз.

Без рус эшчеләр хәрәкәте һәм рус социал-демократиясе тарихында бик әһәмиятле момент кичерәбез; күрәсең, бөтен нәрсә безнең хәрәкәтебезнең күчү стадиясендә торуы турында сөйли: бу хәрәкәт шулкадәр киң җәелде һәм Россиянең төрле-төрле почмакларында шулкадәр күп һәм сәламәт үсентеләр җибәрде ки, хәзер инде аның ныгырга, югары форма алырга, билгеле бер физиономия һәм оешма тудырырга тиеллегысыз көч белән омтылуы сизелә. Чыннан да, соңгы еллар безнең интеллигенция арасында социал-демократизм идеяләренең искиткеч тиз таралуы белән характерлана, ә промышленность пролетариатының, социализмга нык омтылыш күрсәтеп, үзен изүчеләргә каршы берләшә һәм көрәшә башлаган пролетариатның бөтенләй мөстәкыйль, стихияле хәрәкәте әнә шул иҗтимагый фикер агымына таба бара. Һәркайда эшчеләр һәм социал-демократик интеллигентлар түгәрәкләре килеп чыга, җирле агитацион листоклар килеп чыга, социал-демократик әдәбиятка сорау үсә һәм тәкъдимнән чиксез узып китә,— хөкүмәтнең бик көчле эзәрлекләүләре дә бу хәрәкәтне тоткарлый алмый...»

Ленин, проектның авторы буларак, ул шушы зур өстәлнең түрге башында утыргандыр. Укыганда, әлбәттә, басып торгандыр. Үзенчәлекле сөйләм, кискен хәрәкәтләр. Вакыт-вакыт кулъязмасыннан аерылып, аңгәмәдәшләренең йөзләренә караштыргалап та алгалагандыр. Ул бит өстәл тирәсендә кемнәр утырганны бик яхшы белгән. Россиядә берничә төрле буржуаз партияләрнең төзелеп яши башлаулары нәтиҗәсендә яңа типтагы партиягә идея көрәше алып бару аеруча кыен булачагын да ул яхшы белгән.

Владимир Ильич укуын дәвам итә. Үзенең хаклылыгына, үзенең көченә нык ышанган кешеләргә генә хас тынычлык, тавышы да көр чыга аның:

«Без социал революция партиясе булган, хәзерге иҗтимагый строй җирлегендәге барлык сыйныфларга рәхимсез дошман булган социал-демократиянең революционлыгын йомшартырга яки томаларга омтылуларның бөтенесен кискен рәвештә кире кагабыз. Аерым алганда, без рус социал-демократиясенең тарихи бурычы — самодержавиене бәреп төшерү дип саныйбыз...» (Әсәрләр, 4 том, 320—328 битләр).

Барысы да нәкъ социал-демократлар көткәнчә була. Проект чыннан да гаять зур бәхәс, шау-шу кузгата. Россиядәге революциянең башында пролетариат түгел, ә либераль буржуазия торырга тиеш дигән фикердә торган, гомумән пролетариат гегемониясен инкарь итүче «легаль-марксистлар» белдерү проектына аеруча нык каршы чыгалар. В. И. Ленин каршы чыгучыларның һәркайсына тиешле отпор бирел бара. Аңа проектның һәрбер өлешен якларга, исбат итәргә, теоретик һәм практик яктан нигезләргә туры килә.

Гомумән, В. И. Ленин тиңдәшсез полемист булган. Аның белән бәхәсләшә, сүз көрәштерә алмаганнар. Бу турыда меньшевик Ф. Данның бик кызыклы бер истәлеге бар. «Ленин җиңелүне белми,— ди ул.— Чөнки тәүлекнең 24 сәгате буенча революция белән шөгыльләнгән, революциядән тыш нәрсәдер турында уйламаган һәм хәтта төшендә дә бары тик революцияне генә күрә торган башка андый кеше юк. Бар, җиңешеп кара син аның белән».

Тарихи Псков киңәшмәсе дә В. И. Ленинның тулы җиңүе белән тәмамлана. «Легаль марксистлар» булачак «Искра» газетасын үз рупорлары, үз органнары итә алмауларына шушы киңәшмәдә үк бик ачык төшенәләр. Чөнки аларның ялкынлы марксист В. И. Ленинга каршы торырлык чаралары юк, аргументлары да булмый.

Без Псковта вакытта тагын бер зур бәйрәм булды. Совет Армиясенең һәм хәрби Диңгез флотының 51 еллыгы уңае белән Псков шәһәре читендә, Кресты дип атала торган урында, гаять тантаналы шартларда һәйкәл ачылды. Әле яңа гына оешкан эшче-

крестьян Кызыл Армиясе чит ил империалистлары һәм акгвардиячеләр белән көрәштә нәкъ менә шушында, Псков — Нарва тирәсендә, беренче җиңүләргә ирешә. 1918 елның феврале Кызыл Армиянең туган көне булып санала.

Бик үзенчәлекле һәйкәл бу. 49 метр биеклектәге штык үзенең очлы башы белән күккә чөелгән. Ә аста ярым түгәрәк итеп салынган тимер-бетон стена-стендка Кызыл Армиянең беренче җиңүләрен чагылдырган барельеф фрагментлары эшләнгән. Шунда ук алтын хәрефләр белән Ленинның: «...Сак булыгыз, илебезнең һәм Кызыл Армиябезнең оборона сәләтен күз карасы кебек саклагыз»,— дигән сүзләре язып куелган.

Монументны ачуга багышланган митингта да Ленин исеме телдән төшмәде. Әйе, Кызыл Армия белән Коммунистлар партиясе юлбашчысы, Совет дәүләтен оештыручы В. И. Ленин аерылгысыз. Чөнки Ленин социалистик Ватанны корал көче белән саклау кирәклеген нигезләгән һәм шундый саклауның формаларын билгеләгән, ил оборонасын экономик, мораль-политик һәм фәнни-техник яклардан әзерләү юлларын күрсәткән, социалистик дәүләтнең хәрби оешмасы нигезләрен салган кеше.

Һәркайсыбыз белә: яшь Совет иленең иң авыр көннәрендә В. И. Ленин һәрвакытта да халыкка мөрәҗәгать итә. Аның «Социалистик Ватан куркыныч астында!» дигән ялкынлы декрет-мөрәҗәгатеннән соң уннарча һәм йөзләрчә мең эшчеләр армия сафларына басалар. Чын ирекне, азатлыкны татып караган халыкның шул вакытта бөтен ил белән бер кешедәй күтәрелүе бик табигый. Бу күтәрелешне бик ачык чагылдыра торган берничә документка күз саласы һәм мисал өчен берәр генә җөмләсен китерәсе килә. Мәскәү губернасыннан, мәсәлән, болай дип язалар: «Кызыл Армиягә язылу шулкадәр киң колач алды, доброволецлар агымын ничек туктату мәсьәләсе туды». Яисә менә Харьковтан алынган хәбәр: «Эшчеләр Кызыл Армия сафларына бөтен заводлары белән язылалар».

Белгәнебезчә, оештырылган отрядлар, полклар шунда ук фронтка озатылалар һәм дошманга каршы сугышка керәләр.

Монументны ачканда шул вакыйганы үзләре күргән һәм шул сугышларда үзләре катнашкан бик күп ветераннар җыелганнар иде.

Гомумән, Псков җире хәрби традицияләргә бик бай. Бәлки шуңар күрәдер, аны «шәһәр-зодчий» дип кенә түгел, «шәһәр-солдат» дип тә атыйлар. Әйе, борынгы Псков каласы үз тарихында 118 сугышта катнаша, 30 тапкыр чолганышта кала, дошман тарафыннан камап алына.

Бөек Ватан сугышы елларында монда өч елга якын партизаннар көрәше барды. Бу якларны партизаннар крае дип атыйлар. Псков тирәсе, аның тирә-ягындагы урманнары, баткак-сазлыклары немец юлбасарлары өчен җәһәннәмгә әверелде.

Гитлерчылар Псков янында оборона линияләре төзеп, шунда уннарча һәм уннарча дивизияләр туплыйлар. Моның белән генә дә чикләнмиләр, күпне күргән бу борынгы шәһәр тирәсен үлем лагерьлары белән чуарлап бетерәләр. Ул лагерьларда йөзләрчә мең кешене җәзалап үтерәләр. Мироносицк зиратының туганнар каберлегендә, мәсәлән, 30.000 кеше күмелгән, «Пески» дип аталган җирдә 50.000, Кресты дигән урында 65.000.

Псков тирәсендә яман каты сугышлар була. Ләкин алга омтылган безнең армияне берниндиоборона линияләре дә, мең төрле ныгытмалар да тоткарлый алмый. Совет Армиясе һәм флотына 25 ел тулган бәйрәм көнендә, 1943 елның 23 февралендә, Уфада тәрбияләнеп үскән һәм эшләгән комсомолец Александр Матросов Псков өлкәсенең Локня районының Чернушка авылы янында күкрәге белән дошман амбразурасын каплый...

Псков якларына килеп чыккан һәрбер кеше шул изге урыннарга барып килүне үзенең бурычы итеп саный. Әмма үзен мәңге үлемсез иткән тиңдәшсез герой исеменә бәйле булу сәбәпле бөтен дөньяга билгеле Чернушка авылы юк хәзер. Фашистлар, чигенгәндә, аны яндырып көл итәләр, җир белән тигезләп китәләр.

Ләкин бу тирәдән кеше өзелми: монда тантаналы рәвештә комсомол сафларына алалар. Яшь патриотлар Саша кебек булырга ант итәләр, үзләренең хезмәттәге уңышлары турында рапортлар бирәләр.

Автобус артыннан автобуслар килеп кенә тора. Экскурсиягә килүчеләр болар. Тиңдәшсез батырлыкка баш иярга киләләр алар.

Менә сезлыклы урман авызына урнашкан дзот. Жиргә иңгән шушы шыксыз амбразура безнең бик күп сугышчыларыбызның гомерен өзә. Аны шартлатырга дип якынлашкан күп батырлар кар өстендә ятып калалар...

— Миңа рөхсәт итегез! — дип сорый Саша үзенең командирыннан.

Рөхсәт алгач, җир-анага мөмкин кадәр елыша тешеп, үлем чәчүче амбразурага таба шуыша... Дошман дзотына өч-дүрт метр каларак кинәт күтәрелә дә гранаталар бәйләме ыргыта. Дзот эчендә гөрселдәп шартлау ишетелә. Шул чак безнең сугышчылар «ура-а!» кычкырып атакага күтәреләләр. Әмма дзот яңадан терелә, яңадан ут ачып, тирә-юньгә үлем чәчә башлый. Шул вакыт Матросов күз иярмәслек тизлек белән сикереп тора да бөтен гәүдәсе белән амбразура авызына каплана. Дошман пулеметы тына, тончыга...

Ирексездән күңелгә Александр Матросовның соңгы хатларының берсеннән алынган юллар искә төшә. Менә алар: «Әгәр миңа һәлак булырга язган булса, сугышта мин йөзем белән Көнбатышка таба карап үләр идем...» Әй-йе, Ленин комсомолы сафында тәрбияләнгән Саша сүзендә тора, курку белмәс ялкынлы йөрәге кушканча һәлак була.

Хәзер дзот авызы алдына обелиск куелган. Алар янәшә торалар. Җиргә иңгән шыксыз амбразура һәм өскә чөелгән ак һәйкәл! Һәйкәлнең як-ягыннан сузылган чылбырлар ут ноктасын урап алган. Үзенә күрә символ бу: үлемсезлек үлемне авызлыклаган, богаулаган...

Великие Луки шәһәренең үзәк мәйданында биек пьедестал өстендә бронзадан коелган Александр Матросов тора. Юк, тормый, ә алга таба омтылган ул, анда дошман амбразурасын каплаган момент гәүдәләндерелгән: йодрыкланган сул кулы күкрәгенә кысылган, уң кулында автомат. Ә өстендәге плащ-халаты алга очкан бөркет канатыдай җилферди...

Псков җирендә кыю, батыр кешеләр яшиләр. Бөек Ватан сугышы елларында гына да Псков өлкәсенең 134 кешесенә Советлар Союзы Герое дигән исем бирелә.

Монументны ачу тантанасына кайчандыр Псковщинаны азат итү өчен барган сугышларда катнашкан бик күп иптәшләр килгәннәр иде. Митингларда, заводларда һәм фабрикаларда үткәрелгән очрашуларда алар яңарган, хәрабә арасыннан калкып чыккан бүгенге Псковны күреп хәйран булулары турында сөйләделәр.

Владимир Ильич 1900 елның 5 маенда әнисе Мария Александровнага язган хатында үзенең җирле полицеймейстердан чит илгә чыгу өчен паспортка таныклык алуы, 10 сум пошлина түләве турында яза. Бу эштә Ульяновка В. А. Оболенский ярдәм итә.

Владимир Ильич, дәртләнеп, китәргә җыена башлый. Ашкына ул, ашыга. Иң элек үз квартирасыннан 13 пот багаж (китаплар) чыгарып аны станциягә илтеп тапшыра. Шул ук сәгатьтә бу турыда хәбәр полиция департаменты директорына ирешә: махсус беркетелгән шымчылар Владимир Ильичны бер генә минутка да күздән яздырмыйлар. Билгеле инде, Мәскәү охранкасы начальнигына да багажны җентекләп тикшерергә күрсәтмә бирелгән була.

Ниһаять, Владимир Ильич 19 май көнне кичен борынгы Псков каласы белән саубуллаша. Иң элек ул Мәскәү янындагы Подольскига, туганнары янына кереп чыгарга була. Аннан — Уфага, Надежда Константиновна янына. Бары тик шуннан соң гына олы юлга, чит илгә, Швейцария һәм Германиягә...

Ленин белән Мартов, төнгә карап, яшерен рәвештә Петербургка чыгып китәләр.

Хуш, Псков! Сау булыгыз, дуслар!..

Ике төнге пассажир артларыннан күзәтүче шымчылардан котылу өчен бөтен чараларны да күрәләр, хәтта башкалага да бөтенләй икенче яктан, икенче поезд белән килеп төшәләр. Әмма кулэгә кебек ияргән шымчылардан качу бик үк җиңел булмый. Икенче көнне, Малченко квартирасыннан чыгып килгәндә, Владимир Ильичны кулга алалар.

Соңыннан В. И. Ленин үзе үк бу турыда: «Берсе — уң кулымнан, икенчесе сул кулымнан эләктереп шундый каты тоттылар, селкенер хәл дә юк... берәр нәрсә йотып җибәрергә кирәк булган булса, һич мөмкин булмас иде», ди.

Ильичны шунда ук извозчикка утыртып градоначальствога алып китәләр.

Допрос башлана: «Ник килдегез? Сезгә башкалага килү тыелган булуы мәгълүм бит?» диләр аңар. Билгеле инде, башкалада гына түгел, хәтта университетлы шәһәрләрдә һәм завод-фабрикалы, эшчеләр үзәге булып саналган калаларда да эшләргә рөхсәт ителми дигән документка кул куйганлыгы турында да исенә төшерәләр.

Шуның өстенә әле тентегәндә Владимир Ильичның кесәсеннән берьюлы 1.300 сум акча килеп чыга. Бу исә бәйләнергә һәм Подольск адресы белән озатылган багажны тикшергәләгәнче тоткарлап тору өчен сәбәп була.

Акчалар исә «Искра» газетасын оештыру һәм аны чыгара башлау өчен Псков, Петербург, Рига шәһәрләрендә яшәүче социал-демократлар тарафыннан җыелган була. һәм В. И. Ленин: акчалар үземнеке; әдәби эш белән шөгыльләнеп, төрле редакцияләрдән һәм нәшриятлардан алдым,— дип исбат итәргә керешә. 850 сумын Сидней һәм Беатриса Веббларның «Англия тредюнионизмы теориясе һәм практикасы» дигән китапны инглиз теленнән тәрҗемә иткән өчен, ә 150 сумын «Жизнь» журналы редакциясеннән алдым дип, акчаларны конфискацияләүдән саклап калу чараларын күрә башлый.

Полиция сотрудниклары шунда ук Владимир Ульянов әйткән нәшрият һәм редакцияләргә чыгып чабалар. Алай итәләр, болай итәләр, учет кнегаләренә кадәр күтәреп бик җентекләп тикшерәләр. Ахыр чиктә кайтып: бар да дөрес дип рапорт бирергә мәҗбүр булалар.

Чыннан да Владимир Ильич Шушенскоеда сөргендә вакытта Веббларның «Англия тредюнионизмы теориясе һәм практикасы» дигән китапның беренче томын тәрҗемә итә, ә икенче томын (күп өлешен өр-яңадан язып чыгып) редакцияли. Бу эштә аңар инглиз телен ана телен белгән кебек яхшы белгән Надежда Константиновна бик нык ярдәм итә.

Әмма ул эшләрдән алган акчалар Себердә вакытта ук инде тотылып беткән булалар.

В. И. Ленинны, тентегәндә табылган акчаның үзенеке икәнлеген исбат итсә дә, багажны җентекләп тикшерү турында хәбәр алынганчы охранкада газаплыйлар. Ниһаять, 31 май көнне аны азат итәргә мәҗбүр булалар. Анда да әле Подольскига кадәр конвой белән озаталар.

Ә аннан инде ул, иреккә чыккан кош кебек, Уфа, Самара, Сызрань, Смоленск шәһәрләрендә булып социал-демократлар белән очраша, булачак газета һәм аның программасы белән таныштыра, элемтә булдыра, газетаны тарату мәсьәләләрен хәл итә.

һәм 1900 елның 16 июнендә Владимир Ильич Ленин Россия дәүләтенең читен үтеп чыга. Шулай итеп Санкт-Петербургның барлык градоначальникларга, губерналарның барлык полиция департаментлары чиннарына: Владимир Ульяновны табарга һәм кичекмәстән кулга алырга, дигән катгый карары тормышка ашырылмыйча кала.

...Шул ук елның декабрь аенда, чит илдә, яңа типтагы партия төзүдә хәлиткеч роль уйнаган «Искра» газетасының беренче саны басылып чыга.

Ленин «Искра»сының Россиядә барган барлык политик һәм иҗтимагый вакыйгаларны бик җентекләп белеп торуы чын-чыннан хәйранга калдыра. Моны раслау өчен бары тик бер мисал гына китереп үтәсе килә. РСДРПның Казан Комитеты тарафыннан 1903 елның гыйнварында татар телендә чыгарылган беренче социал-демократик прокламация Казан өчен бик зур вакыйга була. Аның текстын Хөсәен Ямашев яза. Ул прокламациянең нигезе итеп элек рус телендә басылган прокламациянең эчтәлеге алына. Листовка азатлыкка чыгуның бердәнбер юлы — самодержавиегә каршы кискен көрәш ул дип, самодержавиене җиңү өчен барлык милләт хезмәт ияләре марксистик партия байрагы астына тупланырга тиешләр дип аңлата.

Ә шул ук елның 1 мартында чыккан Ленин «Искра»сы, листовканың чыгуына югары бәя биреп, болай дип яза: «Татарларның үз ана телендә чыккан прокламациясе кайнар рәвештә кабул итүләре комитетка шундый ышаныч бирә ки, ул листовкаларны бер үк вакытта ике телдә басып чыгару татар эшчеләре массасына яктылык кертеп кенә калмаячак, бәлки моңарчы тик Казан капиталистларына гына файдалы булып, эшчеләр хәрәкәтенә, һичшиксез, зарар китергән милли дошманлыкны да тамырыннан җимерәчәк».

Татар халкының ялкынлы революционеры Х. Ямашев турында В. И. Ленин күп ишеткән булса кирәк. Чөнки 1905 елда ук инде Женевада Владимир Ильич редакциясендә чыккан большевистик газета Хөсәен Ямашевка: «...милләтчелекнең аз гына да катнашы булмаган «ортодоксаль» караштагы төпле социал-демократ» дигән характеристика бирә.

Бу язманы Ленинград язучылар союзы Псков бүлекчәсенең җаваплы секретаре шагыйрь Игорь Григорьевның «Искра» турында баллада» дигән шигыре белән тәмамлау урынлы булыр:

**Порт-Артурда булган бу хәл**
**Моннан күп еллар элек.**
**Окопта яткан бер солдат,**
**Бик-бик тартасы килеп.**

**Сүз каткан матроска: «Туган,**
**Үлеп тартасы килде;**
**Газет күргән идем синдә,**
**Төрик бер чыгар инде».**

**Әйтә моряк пехотага:**
**«Тыңла, абзыкай, кара!» —**
**Күкрәгендә саклап йөргән**
**Газетасын чыгара.**

**— Ленин «Искра»сы бит бу,**
**Килер көн, вакыт җитәр;**
**Бу Очкыннан кара дөнья**
**Гөлт итеп кабынып китәр.**

**Шулай солдат йөрәгенә**
**Ленин Очкынын сала.**
**Иртәгесен жандармнар**
**Матросны кулга ала.**

**Матроска богау салалар,**
**Ә Очкын яна, яна!**

**Халыкка соң рәшәткәләр**
**Куркынычмыни аңа.**

**Сүнми Очкын һәм югалмый,**
**Көннән-көн нык үсә ул.**
**Солдатлар кулыннан кабат**
**Моряларга күчә ул.**

**Кронштадтка кайта Очкын**
**Моряклар белән бергә;**
**Саклый аны «Аврора»да**
**Ышанычлы егетләр.**

**Көннән-көн күбрәк җирә**
**Очкын артыннан халык.**
**Яктыра кеше Очкыннан**
**Яңа чаткылар алып.**

**Туп көпшәләренә үтеп**
**Дарыга Очкын бәрә...**
**Залимнарның йөрәгенә**
**«Аврора» ут җибәрә.**

**Кремль йолдызлары якты —**
**Карый дөнья таң калып;**
**«Искра»дан капкан ут бу,—**
**Дип сөйли барлык халык.**

**Нури Арсланов**

# РОМАНТИКА

ПОЭМА

Атлар, атлар... Мондыйларны
Бар микән күргән:
Күкрәкләр — калкан, ә яллар —
Тезләрдән түбән.
Баш кадәрле зур тояклар
Лап-лоп атлыйлар...
Менә нинди хәтәр икән
Кызыл атлылар!
Сәйран казакъ җырләрендә,
Алтай, Себердә,
Булмаганга күрә мондый
Дәү атлар бер дә [1],—
Фил шикелле сыннарына
Карап таң калдык,
Берәм-берәм әкиятләрне
Хәтергә алдык:
Арыслан авызын каерган
Салсаллармы бу?
Аргыннар, Алып батырлар
Күтәргәнме ту? [2]
Кәркеданнарга атланган
Шаһзадә Гарун
Килгән кебек, салмак атлап,
Килә эскадрон.

Бу чагында без ничердек
Гаҗәеп хисләр.
Аклар явын тар-мар иткән
Кавалеристлар
Марсельеза уйнап керде
Безнең калага.
Күрелмәгән тантанадан
Бала-чагага
Бәйрәм туды... Килде бәйрәм
Барлык халыкка:

---

[1] Эре сөякле йөк атлары турында сүз бара. Беренче тапкыр кызыллар Павлодарга шундый атларда керделәр.
[2] Ту — байрак.

Руска, татарга, казакъна —
Ярлы-ябыкка.
Артын-алдын уйлап тормый,
Кушылдык без дә
Урамнарга сыймый кергән
Кызыл диңгезгә.

Кызыл йолдызлы шлемнар
Балкый кояшта.
Бер эскадрон — җирән кашка,
Берсе — күк кашка...
Аркаларда карабиннар,
Билдә кылычлар,
Талпына җилдә буркалар —
Нәкъ сәмруг кошлар.
Сөнгеләрнең очларында
Кызыл кыекча
Җилферди-җилферди яна —
Ялкыннар оча.
Сары тузан күтәрелә,
Болытка аша:
Әллә төтен, әллә томан...
Мәхшәр, тамаша!

Менә обоз: санитарлар,
Яшел арбалар,
Поход кухнясы... Аккоштай
Кызлар баралар.
Без, кулларны артка куеп,
Карап торабыз.
Безгә ымлый атлы батыр
Һәм кухнядан кыз.
Менә нидер әйтеп, көлеп,
Кыз шикәр суза:
Дустым кухня якка, ә мин
Батырга узам.
Ул, атыннан иелә дә,
Кулымнан ала,
Мин икенче кулым белән
Ябышам аңа.
Әни: — Тапталасың, Нури,
Я ходавәндә! —
Ташлана миңа, өлгерми,—
Ялт,— мин ияргә.
Әни миңа бармак яный:
— Ах сине, мордар!
— Хафаланма,— ди бер абзый,—
Болар — кызыллар!
Бераз баргач атлы әйтә:
— Я, төш инде, шук,
Йөгер тизрәк әниеңә,
Гуляй, татарчук!
Күкрәктәге кызыл бантын
Такты ул миңа,
Шул минуттан минем өчен
Үзгәрде дөнья!

Шатлыгымнан җиргә аяк
Тими йөгердем, —
Мин үземне иң бәхетле
Бала дип белдем.
Әни дә, бик борчылса да,
Миңа тимәде,
Сүзен тыңламаган өчен
Бары тиргәде.
Гаҗәп, тиргәп кенә калды,
Усал булса да,
Эһ тә итмәс идем хәтта
Колак борса да...
Чөнки минем өчен дөнья
Ал иде хәзер:
Минем түштә дә ал тасма
Бар инде хәзер!
Мин чын батыр менгән атка
Атланып бардым,
Аның чын сөнгесен үзем
Тотып карадым!
Юк, мин җирдә түгел идем,
Җиргә төшсәм дә,
Канатланып оча идем
Толпар өстендә.
Сабыйның хыялый аты
Йөгәнсез иде!
Хәер, мин хәзер дә шулай —
Сабый шикелле...

Бөтен Кәрәкәү [1] җыелып
Мәйданга тулды.
Бер якта — халык, бер якта —
Иртеш дулкыны:
Тынгысыз бүген елга да
Ил белән бергә,
Талпына төсле дулкыннар
Мәйдан күрергә.
Яңарды тагын музыка,
Башланды парад.
Алдан барган бер атлыга
Сокландык карап:
Атланганы бурлы толпар,
Ял-койрыгы — чал.
Әйттеләр: — Комдив яралы,
Бусы — комиссар.
Кызыл комиссарның аты
Сөлектәй сылу,
Баягы «фил», «каркеданнар»
Түгел инде бу!
Музыкага биеп атлый
Ничек иттереп —
Бер уңга, бер сулга борылып,
Көйгә китереп.

[1] Кәрәкәү — Павлодар шәһәренең борынгы исеме. Элек аны татарлар һәм казакълар шулай атыйлар иде.

Котлый кебек ирек белән
Малкай безне дә,—
Чайкый башын, буйсынмыйча
Тарткан тезгенгә.

Кинәт оркестр шып булды,
Халык тын калды:
Менә комиссар уртага
Чыгып тукталды.
Өзәңгегә басып, аттан
Бераз калыкты,
Тәбрик итте ирек белән
Ярлы халыкны.
Ул: — Революция! — диде,—
Азатлык! — диде,—
Питердан Камчатка кадәр
Кызыллар җиңде...

Күп сүзләре аңлашылмый,
Тик йөрәк тоя:
Безнеке,
Үзебезнеке Революция!
Без кечкенә, ә байгуралар
Кабагын тея:
Безнеке,
Үзебезнеке Революция!
Халык, вакыт-вакыт гөрләп,
Бүрекләр чөя:
Безнеке,
Үзебезнеке Революция!
Без сабыйлар шулай инде:
Ил шат — без дә шат.
«Ур-ра-а!» тавышы яңгырады
Ничәмә кабат.

Комиссар, сүзен тәмамлап:
— Иптәшләр! — диде,—
Бар бер батыр, яулашучы
Һәрбер җиңүне,
Ленин ул — безнең беренче
Кызыл комиссар.
Яшәсен Ленин,
Өченче Интернационал!

Ленин! Ленин! Кайда соң ул?
Ник юк парадта?
Мин эзлим, эзлим табалмыйм,
Күпме карап та.
Нинди тылсымлы батыр ул
Күтәргән илне?
Нинди икән менгән аты
Күрәсе иде...
Комиссарның бурлысыннан
Ким түгелдер шәт.
Нинди булса да бик әйбәт,
Безгә шундый шәп!..

Гаҗәп түгел, әфсүн әрсә —
Күренмәс күзгә.
Ләкин тоя күңел, тоя —
Килгән ул, бездә!
Ленин, Ленин! Ул шушында,
Безнең арада!
Ленин кызыл байракларда
Керде калага.
Марсельеза, Варшавянка
Җырлары булып,
Бәхет ләйсәннәре сыман
Күзләргә тулып
Керде, рух-дәрт бирер безнең
Җанга, күңелгә.
Ул монда, мәйданда, сафта,
Бик якын, бергә!

Кинәт күз алдыма килде
Тиңдәшсез батыр.
Мин хыялга бирелеп шулай
Ничәмә тапкыр
Күтәрелдем инде җирдән,
Очам әле дә...
Тик үкенмәм беркайчан да
Мондый хәлемә!
Ленин — Алпамыштай өлкән,
Гайрәтле, көчле,
Аргы яктан сикереп чыгар
Менә Иртешне,
Килеп туктар минем алга
Һәм әйтер: — Әйдә,
Батыр булыйм дисәң, атлан
Минем иягә!

Әй кадерле романтика!
Шул көннән бирле
Гел шулай күрәсем килә
Бөек Ленинны.
Шул көннән изге бер исем
Булып урнашты
Нәни сабый йөрәгендә
Бөек юлбашчы!
Мин шул көннән, шул чын сөнгә
Тотканым хәлдә,
Барам туры, нәкъ шул атта,
Нәкъ шул иярдә.

1969.

**Аяз Гыйләҗев**

# УРАМНАР АРТЫНДА ЯШЕЛ БОЛЫН

РОМАН[1]

## II

Идрис, кабаланып, Декабристлар урамына чыкты.

Көл төсле такси әллә кайларга китеп югалыр вакыт узса да, ул ымсынып як-ягына каранды. Айдарның әтисен шушы вакытта ук күрәсе, хисләр яңа чакта сөйләшәсе, ныгытып аңлашасы килде. Кичә, өченче көн аның яшәешен тыгызлаган уйлар шушы шадра, шома кешегә барып тоташмыйлар микән?

Ата булу җәмгыять, кешелек, милләт алдында үз өстеңә яңа бурычлар алу түгелмени?..

Ашыгыр урыны юк, детсад мәсьәләсе ачыкланды, ул җәяүләп кенә Восстание урамына таба китте. Филателия кибетенә кагылды. Маркалар белән мавыкмаса да, үткән-сүткәндә шушында кереп чыгарга ярата ул. Нигә икән?

Кайнар, дымлы учларына көмеш, бакыр акчалар йомарлап, рәхәтлектән күзләрен кыса-кыса пыяла өстәлләр өстенә иелгән малайларны күзәтергә яратамы?..

Бүген абыйсы Илдус искә төште... Медицина институтын бетереп, авылның нәни генә больницасында баш врач булып эшли ул. Хатыны Бәллүр үле малай тапкач, Илдус җансыз сабыеның гәүдәсен күтәреп әллә ничә сәгать өй тирәли йөрде дип сөйләделәр.

— Улым, нигә бер тапкыр булса да мекердәмисең? — дип, ялынып-ялынып сорый икән бичара...

Дүрт-биш үсмер шыпырт кына сөйләшәләр, саныйлар. Яңа Гвинея, Бурунди, Бразилия телгә алына... Берсе Мөэзкиргә охшаган, кечерәге Айдарга...

Бүген малайларны карап торып аның күңеле тулды...

Урам. Почмакта чия саталар. Молдавиядән китереп тә җиткергәннәр. Илең киң булгач рәхәт!.. Чират. (Малайларына, кызларына күчтәнәч алалар!)

---

[1] Дәвамы. Башы 10 санда.

Восстание почмагына барып житкәч, ул чаттагы сәгатьне күреп алды. Эш вакыты бетеп кенә килә. «Өлгерәм!» диде ул үзенә-үзе, сулга борылып. Восстание урамы буйлап китеп барды.

Урамдагы эскәмиядә әле биш-алты кеше утыра, көтәләр, димәк, райбашкарма хезмәткәрләре китеп бетмәгән!

Коридор буш. Җыештыручы бер бүлмәне ачып куйган да камыш себеркесе белән җил-җил килә. Борынны ачы гузан исе ярды... Кайлардан, кайсы урамнардан җыелган тузан икән?

Икенче ишек тә ярым ачык. Өч-дүрт кыз җыр-җыр көлешеп ирен буявы сайлыйлар. Идрис, алар янында тукталып, райбашкарма председателенең урынбасарын сорады. Детсад, балалар турында шунын янына керергә кирәк дип уйлады ул.

Кызларның берсе, аның килеш-килбәтенең һәйбәтлеген күздән кичергәч, юри генә мутланып:

— Әллә мине эзләп килдегезме дип торам,— диде.

Үзенә кирәкле бүлмәне эзләп тапкач, ул ишекне кыю гына ачты. Кечкенә, йомры гәүдәле, тулы балтырлы, сипкелле секретарь кыз футлярга төрелгән язу машинасын тәбәнәк тимер сейф өстенә куеп маташкан җиреннән исе китмичә генә Идрискә борылып карады.

— Миңа иптәш Жаденко кирәк иде,— диде Идрис.

— Соңга калдыгыз. Виталий Петрович хәзер кабул итми.

— Ул мондамы? — диде шатланып Идрис.— Мин редакциядән.— Ашыгыч йомыш бар.

Үз ныкышлыгына үзе сокланып, ул кара дерматин белән тышланган салкын ишекне ачты. Ишек артында тагын бер ишек бар иде. Анысын да ачкач, бүлмә яктылыгы күренде. Кабинетта ике кеше. Сул яктагы диванга, өендәгедәй бераз таралып, Жаденко үзе утырган. Аңа каршы якта өстәл кырындагы йомшак күн кәнәфидә алҗыган чырайлы, әмма солтанатлы, олы сымак кыяфәтле ханым утыра. Моңарчы күргәне булгангамы, Идрис кергәч тә ханымга текәлде. Ярты минут чамасы торгач кына сәлам бирде, Жаденко кырыс кына баш какты, ханым исә, кызыксынып аңа карады.

— Редакциядән мин, иптәш Жаденко,— диде Идрис.— Сезне күрәсе бар иде.

Жаденко эре, тигез тешләрен чак кына күрсәтеп елмайды, горгылдык, көчле тавыш белән көлеп куйды:

— Карагыз алайса, тик күз тидермәгез! Йомышыгыз шул гына икән, карарга рөхсәт.

Рәсми урындагы кешенең мондый шуклыгын Идрис аңламады, ул бераз аптырап ханымга карап-карап алды. Жаденко профессиональ сизгерлек белән аңлатып бирде:

— Сөйләгез, сөйлә. Нина Михайловна Булавина — райбашкарма члены. Район санэпидстанциясенең баш врачы.

Идриснең хәтеренә келт итеп Ренат Кәримовның санврачны ничектер бер тиргәве килеп төште. Үзе булып чыга түгелме соң бу?

— Алайса, бер атуда ике куянга тидерәм икән,— диде Идрис тә ярым шуклык тоны белән.

— Аучылык сезоны бүгенгә ябылды, кадерле иптәш. Сез иртәгә берәр вакыт табып керә алмассызмы?

— Иптәшне тыңлыйк,— диде ханым, ризасызлык белән. Жаденко Идрискә карап кулларын җәйде...

— Балаларның җәйге ялы турында тәгаен сезнең белән сөйләшергә кирәктер бит?

— Виталий Петрович быел Ленин районы буенча лагерь комиссиясе председателе,— дип ачыклады ханым.

— Куянга тидерәм дисез алайса...

Жаденко тагын бер көлеп алды.

— Мин унҗиденче детсад турында сорашырга дигән идем.

— Ә-һе,— диде Жаденко, тәмәке кабыза-кабыза. Ул шырпысын сундермичә яшен ташы кебек һавада уйнатып тотты.— Ниһаять, ул борынгы җыр сезгә дә барып ишетелгән икән. Сез кайсы редакциядән әле?.. Искергән җыр бит ул, кадерле иптәш. Сезгә аның кайтавазы гына барып ирешкән.

Идриснең яшьләр газетасыннан икәнен белгәч, урынбасарның йөзендә үзгәреш күләгәсе чагылды. Аның каравы Булавина җанланды:

— Күкрәве байтактан булса да, болытлары таралмаган, Виталий Петрович,— диде ул, Идрисне дәртләндереп.

Санврач сүзне көчәйтергә теләсә дә, Жаденко кабынмады, әйе, юк дигән сүзләр белән котылып, исе китмичә генә утыра бирде.

— Нина Михайловна үзенә тагын бер союзник артты дип шатлана,— диде ул бераздан.

— Шулай түгелме әллә? — диде Булавина, гаҗәпләнеп.

— Үз күңелемдәген әйтеп ычкындырдыммы? — диде Идрис.

— Беләм,— диде Жаденко.— Газетачыларга вак-төяк, җанны кытыклап, күз яше сыгып чыгарырлык материал гына булсын... Мин элек тимер юлда инженер булып эшләдем, шактый эләктем алар теленә.

Идрис, түземсезлек белдереп:

— Минем сорауга җавап булмады,— дип искәртте.

— Һәм булмас та,— дип ачыклады Булавина.

— Нигә?

— Мәсьәлә хәл кылынмаган әлегә.

— Мәсьәлә күптән хәл кылынган,— диде Жаденко.— Комиссиянең барлык членнары сез күздә тоткан «Тын күл» балалар шәһәрчеген кабул итү актына кул куйдылар.

— Миннән башкалары,— дип өстәде Булавина.

— Аңлашыла башлады,— диде Идрис, гәрчә ни булса да аңлау әлегә кыенрак иде.

— Тагын бәхәскә чакыруыгыз булдымы бу? — диде Жаденко Булавинага.

Булавина сабыр гына төшендерде:

— Сез кергәндә без нәкъ шул «Тын күл» турында әңгәмәләшә идек. Иртәгә төштән соң без анда барып кайтырга җыенабыз. Виталий Петрович, әйдәгез журналист иптәшне дә ияртик. Арада бер битараф кеше дә булсын.

— Мөмкин,— диде урынбасар, икеләнеп,— иптәшнең вакыты ничектер бит?

— Барам,— диде Идрис, нигәдер тиз үк ризалашып.

— Алайса, иртәгә кадәр? — диде Жаденко, урыныннан торып.

Идрис хушлашып урамга чыкты.

Эш Рәкыйп көткәннән чуалчыграк булып икенче якка авышса да, Ренат Кәрамовны күргәннән бирле Идриснең детсад белән кызыксынуы арткannан-арта иде. Ул берни дә уйламыйча гына басып торды. Кинәт ишектән Булавина тавышы ишетелде:

— Сез китеп өлгермәдегезме? Менә яхшы булган!.. Нигә иртәгәгә кичектерергә? Мин Виталий Петровичны бүген, менә хәзер «Тын күл»гә барырга күндердем. Сез ничек?..

— Мин дә риза,— диде Идрис.

— Хәзер машина килеп җитәргә тиеш...

Утыз өч яшькә җитеп тә моңарчы өйләнмәгән Виталий Петрович райбашкармага эшкә сайлангач та Булавинаны очратты һәм гашыйк булды. Ләкин беркемгә берни сиздермәде. Хәзер аның һәр адымы диярлек кеше күз алдында иде. Бәлки әнә шул аны сагаерга мәҗбүр

иткәндер дә?.. Әллә Булавинаның үрелмәслек югары авторитеты аны икеләндердеме?..

Ләкин Нина Михайловнаның гаилә бәхете дә түгәрәк булмады: моннан ел ярым элек аның ире һәм дүрт яшьлек улы автомобиль катастрофасында һәлак булды...

Яшь, чибәр һәм ялгыз хатын күңеленә юл ачылса да, Виталий нечектер сабырланып, үзен-үзе йөгәнләп килде. Булавинаның маңгай чәчен чаларткан хәсрәт бераз тоныкланырга, аның күңелендәге якын кешеләрнең исемнәре чак кына онытылырга тиеш иде. Шатланмады Виталий Петрович аның фаҗигасенә, ләкин буласы бәхетсезлек булып үзгач, яшь хатын гомере буе аның эскәнҗәсендә тырпылдап ятар дип тә уйламады.

Яшьләре олыгайган саен, эш урыннары югарырак булган саен ир белән хатын-кыз арасында аңлашу кыенга әйләнә. Һич кирәкмәгән әйләнечләр, тулганышлар ясала, һәр адым җиде кат кына түгел, ун-егерме кат үлчәнә.

Иң зур кыенлык — аларның бергә, бер оешмада эшләүләре иде. Шушы кыенлык соңгы көннәрдә аерата ачык сизелде. Аралар якынаеп кына килгәндә юк-бар өчен чуалышып киттеләр... Дөрес, «Тын күл» дачасына балаларны чыгарыргамы-юкмы дигәндә, бәйләнерлек сәбәпләр дә табып булыр иде... Тапсыннар иде комиссиянең башка членнары!.. Тик унбер кешедән нибары Булавина вакчыллык күрсәтте (таләпчәнлек дип атый алмый моны Виталий!) һәм актка кул куюдан үзеп баш тартты.

Үз кул астындагы хезмәттәшләрдән мондый ачыктан-ачык хыянәтне күреп өйрәнмәгән, эшне тиешле тынычлыкта юнәлтергә яраткан Жаденко яшь хатынга икенче күз белән карый башлады... Тышкы матурлыгы астында нәрсә яшеренгән бу кешенең? Искитәрлек вак, быжгак кеше, ялган принциплар колы түгелме ул?.. Ике ел элек кенә ачылып, шаулап эшләп килгән дача быел нигә ярамады? Былтыргы кабул итү актында шул ук Булавинаның имзасы ярылып ята ич!..

Жаденко бүген Булавинаның күңел кылларын тартып-тартып карарга да ниятләнде. «Тын күл»гә барып кайту, чынлап караганда, ялгыз очрашырга бер сәбәп кенә иде. Әллә каян гына газетачысы килеп төште. Ах, бу журналистларны!.. Кермәгән тишекләре юк... Нина Михайловнасын әйт, өрә белмәгән көчек күк, бәйрәм узгач кунак чакыра!..

Жаденко машина килгәнне күреп урамга чыкты. Брезент түбәләренә тузан да кунып өлгермәгән өр-яңа яшел «УАЗ» иде бу. Шоферы да көяз генә киенгән, өстендә әллә ничә чылбырлы замша куртка, беретындагы значокта Эйфель башнясы. Машина йөртүчедән бигрәк, ял итәргә руль артына утырган галимгә охшаган иде шофер. Ул үзе таслап чепчиста зәңгәр постау кисәге салды. Жаденко шул урынны Булавинага тәкъдим итеп караса да, тегесе ризалашмагач, үзе менеп кунаклады. Идрис белән Нина Михайловна артка керделәр.

Кузгалып китүгә Жаденко аларга йөз белән борылды, Булавина белән шәһәр төзелеше, юллар, курортлар, дачалар, төзү материаллары, Мәскәүдәге «Россия» гостиницасы турында гәпләшергә тотындылар. Алар Идрис барырга өлгермәгән курорт шәһәрләрен беләләр, кайсы диңгездә елның кай чагында пляжларның шәп булуын, кайсы ресторанда ничек ашатуларын да һәйбәт өйрәнгәннәр. Якын көнчыгыштагы хәлләр турында берәр сүз алышырлармы болар дип көтте Идрис, юк, телгә алмадылар...

Шәһәр кысасыннан ычкынгач, һава сизелерлек үзгәрде, тәрәзәдән тәнне һәм күңелне кымырҗытып юл җиле ургылып керде. Казан — Горький шоссесыннан Аккош күленә таба байтак машиналар тәгәри-

лар. Яшел «УАЗ» аларны уза-уза Аккош күлен, «Каенсар» рестораның үтте дә бераздан сулга борылды.

Идриснең аркасына дым бәрде: Дилә белән бу урыннарда йөргәне бар аның... Кышын, февраль ахырларында, кояш нурлары сизелерлек йомшакланганда... Аяз күктән вак кына кар бөртекләре сибелеп тора иде... Бу ярда Диләнең чангысы ычкынды, хәзер ул урында дүрт егет, чишенеп ташлап, карта сугалар... Менә бу егет белән кыз янәшә кызынып яткан җирдә алар Дилә белән кофе эчкәннәр иде...

Кояшта чуенланган яшьләрнең гәүдәләре таза, килешле иде...

Нигә Дилә дә алар кебек булмады икән?

Менә хәзер кайчандыр югалган сәламәтлегенне эзләп, шушы матурлыкны, шушы иркенлекне ташлап, әллә кайларга тәнеңне ремонтка илтеп йөр инде... Ничек булды әле бу?.. Путевканы җәй урталарында булырмы-юкмы дип йөрделәр-йөрделәр дә, майның иң соңгы көннәрендә Диләне чакырып алып: «Путевкалар яна, тиз-тиз санаторий-курорт картагызны тутырыгыз!» дип боердылар... Ике-өч көннән Якын Көнчыгышта сугышлар башланды... Сугыш башланасын һәм аның көнен сәгатен, безнең ил өчен хәвефле булачагын белеп, чиккә якын санаторийга барудан кем дә булса баш тарттымы икән әллә?!.

Шушылар турында Жаденко белән сөйләшәсе килеп китте...

Тик кешеләр «Россия» гостиницасының туалетына дигән кара кафельны каян китерүләрен, Рига култыгындагы «Юрас перлос» ресторанында җылан балыгын ничек ыслауларын тәмләп сөйләшкәндә ничек аларны бүлдерәсең?

Машина тәбәшәк челтәр коймалар арасындагы тыкрыклардан бара. Дачалар, пионер лагерьлары... Балалар, балалар... Бөтен матурлык, урман-җир аларга бирелгән. Машина, барды-барды да, тып-тын, кешесез ишек алдына барып керде. Төштеләр. Тынлыкка иялнә алмыйча беравык миңгерәп торылды. Кайдадыр якында гына күке кычкыра иде.

Жаденко эшлекле, эре адымнар белән бизәкле верандалы корпусларның берсенә бара башлады. Йортлар арасыннан нәзек, ябык кына бер хатын чыгып аңа каршы килде. Хатын дача каравылчысы икән. Жаденко аннан нидер сораштырырга тотынды.

Идрис үзенең ни өчен монда килүен уйлап аптырады, ярдәм эзләгәндәй, Булавинага карады һәм әсәреп китте, бәләкәй таганнар, агач аюлар, сары кикрикле этәч янына баскан Нина Михайловнаның күзләрендә яшь иде. Моны Жаденко да абайлады, ул, каравылчыны калдырып, тиз-тиз Булавина янына ашыкты. «Юкка килдек без монда, юкка!» дип уйлады ул һәм беренче тапкыр бүген икәүдән-икәү генә булмауларына сөенде. Урынбасар килеп җиткәндә Булавина аз-маз тынычланып өлгергән иде. Ул көрсенеп кенә:

— Ягез, Виталий Петрович, инде монда чакыруыгызның серен ачсагыз да ярый,— диде.

— Бернинди сер дә юк,— диде Жаденко, бераз каушап.

— Шушында күңелемне нечкәртеп, шушы матурлык белән сукырайтып йомык күз белән актка кул куяр дип өметләнмисездер бит?

— Матурлык алдында баш игәнегезне күрә алсам да житкән. Галия апа, ач ишекләрне!

Галәмәт олы койрыклы дәү сары эт ияртеп, каравылчы хатын корпустан корпуска йөреп ишекләрне ачты.

— Хәзер, хөрмәтле иптәш журналист, күзегезне йомыгыз! — диде тантаналы горгылдык тавыш белән шаулап Жаденко.— Мин ярты сәгатькә генә тылсымчыга әйләнәм... Борынгы гарәп әкиятләрендә дә мондый унайлы, сихри сарайлар булмаган... Тарих баскычларына күз ташласак, без ни күрәбез?.. Дөньякүләм атаклы Браманте, Перуцци, Сансовино, Бартоломео, Фальконетто кебек талант ияләре кем өчен

мөзәян сарайлар төзегәннәр, кем кәефен күргәннәр? Епископлар, папалар, байлар, купецлар өчен!.. Ә бу гүзәл сарайлар балаларга багышланган!.. Егерме жиде проект арасыннан сайлап алдык без аны, әйтергә кирәк, ялгышмадык. Йокы бүлмәләренә рәхим итегез!

Эчтәге чисталык, пөхтәлек күзгә ташланып торганга, өчесе дә аяк киемнәрен салып керделәр. Кеше-кара булмаса да, аяк очларына гына басып, шыпырт сөйләшеп йөрделәр.

Жаденко ак җәймәләргә төрелгән караватларга дәү учлары белән басып-басып карады:

— Артык изрәтми дә, тәнне дә ватмый... Тәрәзәләр герметик ябыла, тавышсыз ачыла... һәрвакыт саф, озонга бай нарат урманы һавасы... Салкын көннәрдә җылытырга тәрәзә асларына электрокалориферлар урнаштырылган.

Ул юлдашларының хәйран калганын күреп тагын да дәртләнде, киң кул хәрәкәте белән аларны ашханәгә чакырды.

— Кайда бар төсле пластиктан ясалган мондый нәни өстәлләр? Камыш урындыклар, тәрәзә янында яран гөлләре. Аквариум!.. Ташларын, кабырчыкларын Кара дингез ярыннан кайтарттык. Карагыз, ашыкмагыз: алтын балыклар, фтерофиллум!..

Ял бүлмәләрендә тагын да искитмәле иде. Зур залның бер башында курчак театры өчен ширма. Шунда ук Чипполинолар, Буратинолар арасына Казан арты урманнарының йөнти Шүрәлесе дә кереп кысылган, озын бармаклары белән мичкә билле Матрешканы кочаклаган...

Жаденконы танып булмый, ул җинеләеп, барын да белеп тәмләп, чын күңеленнән сокланып сөйләде, бу сүзләрне бер генә кабатламавы да сизелеп тора иде. Шарлы лампалар Польшадан, ваннадагы никель краннар, идәндәге метлах плитәләр барысы да Чехословакиядән китерелгән икән.

— Шушы дачаны салуга бөтен дөнья катнашты. Дөрес, без монда Артектагы гаҗәеп камил комплекслар, Ленин тауларындагы Пионерлар сараендагы зиннәтле интерьерлар белән ярыша алмадык, юрганына карап аягыңны сузасың диләрме әле?.. Хәзинәдә бары, кадерле иптәшләр!

Дачаларны, детсадларны болай җентекле күз белән караганы юк иде Идриснең, исе-акылы китте, бу кәҗәлә врач шушы оҗмахның ни гаебен тапты икән дип уйлады.

Ашханәгә ябык галлерия белән тоташкан кухняда да чисталык һәм гадәттән тыш уңайлылык күзгә бәрелеп тора иде. Монда артык сөйләп торуның һич кирәксез икәнлеген аңлатып, Жаденко кулларын җәйде дә, иңнәрен селкеп:

— Эм-м,— дип кенә әйтте.

Яп-якты салкынча бүлмәдә бераз сокланып торгач, һавага чыктылар.

— Урынның уңышлы сайланышын искәртүнең дә зарурлыгы юктыр?.. Күзе бар кеше күрерлек, зиһене таралмаган кеше бәяләрлек. Җыеп кына әйткәндә, мондый дача безнең республикада бер генә.

— Һәм шул дача буш тора... Дәүләтнең меңләгән средствосы җилгә оча. Ни өчен? — дип өстәде Идрис.

— Сез үзегез шуны абайламадыгызмы? — диде Булавина.

— Юк,— диде Идрис, уңайсызланып.

— Сыныйбызмы? — диде кинәт Жаденко, наянланып.

— Сыныйбыз,— диде Булавина.

— Болай килешәбез,— диде Жаденко, житдиләнеп,— әгәр журналист иптәш бер гаеп тә тапмаса, Нина Михайловна актка кул куя. Ярыймы?

— Ярый! — диде Булавина көтмәгәндә.

Идрис тә ризалашты һәм тикшерү сәяхәтен баягы эздән — йокы бүлмәсеннән башлады. Ул үзенең көлкегә калу ихтималының бик зур икәнлеген сизеп каушады. Каян уйлап таптылар бу йогышсыз имтиханны? Төзүче-архитектор түгел дә түгел, ичмасам эти кеше булып та детсадларга, җәйге дачаларга барганы булса икән!.. Шулай да сынатырга ярамас: Булавина аңа ышанды, югыйсә актка кул куярга әнсат кына ризалыгын бирер идеме?

Йокы бүлмәләрен әйләнеп чыкканда ишек төбендә аны шалама койрыклы этe белән Галия апа каршы алды. Булавина да, Жаденко да моннан күренмиләр, алар аргы башта дәү каен күләгәсенә утырып хәл җыялар иде.

— Ни-нәрсә эзләтәләр синнән, улым? — дип сорады Галия апа.

— Сынаулар,— диде көләргә тырышып Идрис.

— Ә?

— Дачаның гаеп-кыекларын үзең таба алырсыңмы диләр...

— И бала, андый чатаклыкларны эзләгәч, Виталий Петрович алып кергән җирләргә аяк басалармы?.. Гайбәт булмасын, ару кеше, үткенлеге дә җитәрлек, мәгәр, хәйләкәр дә инде!.. Читтәнрәк эзлә син аны, улым, читтән!.. Сарбай, әйдә, киттек!

Идрис, чак кына тукталып уйланды да, койма буенда аерым-аерым торган бәләкәйрәк корылышлар янына атлады. Монда складлар икән. Бераздан аның янына Галия апа килде.

— Монысында нәрсә, Галия апа?

— Анысы нәүрәп, кар базы.

— Ачыгыз әле.

Кар базы авызыннан борсыган ис борынга килеп бәрелде, аста су елтырады.

— Кышын җирнең туңы шәптән булмады, шуңа күрә кар базыбызга су төште.

— Нигә моңарчы түктермиләр соң аны?

— Җитешә алмыйлардыр. Үзем өч рәт төштем инде, бетереп кенә булмый бит! Түгә торам, ул арта бара, буынсыз калып яттым, билем сызлады... Радикулитым бар, нәләт төшкән чир...

Йомгакның очы шушы кар базында булуы бик ихтимал иде... Нәүрәптә су, ә суыткычларда хәл ничек?.. Суыткычларның күләме җитәрлек түгел икән, монысын да Галия апа ачыклады... Хәзер Идриснең фикерләре бер эзгә төштеләр; актка санитария врачы кул куймаган, димәк, монда аның таләпләре үтәлмәгән дигән сүз!

Ул санврач карамагына керә торган урыннарны күз алдыннан кичергәч кыюланып китте һәм ялгышмады — кашык-аяк юу урыны юк икән, аны кухня янына ачык һавага чыгарганнар. «Чебен оясы!»...

Жаденко серле көлемсерәп, Булавина ачык чырай белән аны каршы алдылар.

— Бая искәртергә онытылган, бу дача өчен ике кеше төзүчеләр көнендә орден алды! — диде Виталий Петрович. Орденнарның берсе үзенеке икәнен әйтеп тормаса да, аңлашылды.

— Я,— диде Булавина, сабырсызланып.— Таптыгызмы?

— Бер нәрсәне белешәсе калды: су скважинасы. Монысын лаборатор анализлардан башка тикшерә алмыйм.

Жаденко шунда ук кул изәп каравылчыны чакырды.

— Галия апа!

Кулына нәни ак кружка тотып Галия апа килде.

Виталий Петрович кружкага су агызды, күз турына күтәрде һәм юри тамагын кырып тантана белән:

— Сезнең саулыкка, Нина Михайловна! — дип эчеп тә җибәрде.

Хуҗасының шаяруын тамаша итәргә җыенган кебек, шофер да

скважина янына килде, тамак астын тырмаштырып рэттэн ике кружка су эчте:
— Мәскәүскийләрең бер якта торсын, ах суы ла суы!
— Спектакль беттеме? — диде Булавина, көлмичә.
— Хәзер Бакиров иптәшкә суның составы, андагы зарарлы таякчыклар, ул таякчыклар тудыра ала торган хәтәр чирләр турында лекция укыгыз,— диде Жаденко, иренен сөртеп.— Карап карыйк, кәгазьләргә, биохимик анализларга ышанамы ул, әллә күз алдында тере кешеләр эчкән суга кайберәүләр сыман шикләнмичә карый аламы?
Булавина башын чайкады:
— Иптәш Бакиров,— диде ул,— бер литр суда өч-дүрт таякчык булуына түзәргә дә ярый. Бусы беркем өчен дә, хәтта бала организмы өчен дә куркыныч түгел. Былтыр әйбәт су биргән скважина быел начарланды. Бер литр суда таякчыклар саны уннан артык.
— Эчеп карагыз, иптәш Бакиров, курыкмагыз,— диде Жаденко.
— Виталий Петрович, суык су эчеп корсак куптермәгез. Чәй әзерләгән идем,— диде оялып кына Галия апа,— әллә нәрсә юк-югын да, кереп чыгарсыз инде.
Каравылчы бүлмәсенә керделәр. Бу бүлмә дә аерым бер купшылык, зәвык белән эшләнгән, стеналарына аксыл линкурс ябыштырылган, фанер белән ыспай капланган түшәмдә шактый кыйммәтле плафон асылынып тора. Жаденко белән Булавина кул-бит юган арада, Галия апа, Идрисне үзенең сердәше санап, гади генә тарихын сөйләргә дә өлгерде.
Утыз ел авыл мәктәбендә укыткан. Бердәнбер улы Роберт институт бетереп Казанда эшкә кергән. Галия апа пенсиягә чыккач, авылда йорт-җирләрен бетереп, барын сатып, улы янында торырга килгән. Кооперативка кереп ана акчасына өч бүлмәле квартира алганнар... Һәм яңа йортта карчык кешегә сыенып почмак табылмаган...
Әле ярый, яхшы кешеләр табылып тора. РОНО мөдире бәхетсезлеккә дучар ителгән ананы Виталий Петрович аша монда урнаштырган...
Ямансу булса да итәк белән киртә җимерә алмыйсың, тамак тук, урының коры булгач, юктан юаныч, бардан куаныч табып шөкрана иткән буласың шунда...
Анысы рас, җан сызлый, бик сызлый, оныгынны сөеп улыңның түрендә бистә бикәсе булып утырасы көнендә каравылда тору бәхет түгел, урман арасындагы тормышның аның үз мәшәкате бар, кибете ерак, аулакта куркыныч та... Төрле кеше бар!.. Ичмасам тизрәк балаларны китереп тутырсыннар иде...
— Ишетмәденме, кайчан алып киләләр икән шул сабыйларны?..
Галия апа сүзгә сусаган авызын кайчан ябар иде, Жаденко белән Булавина кергәч, ул тыелды, тиз-тиз өстәл тирәсендә әйләнгәләргә кереште.
Чәйне яратып тәмләп эчтеләр, майлы берәр телем ипи ашадылар. Шофер да керде, ухый телемена калын итеп ак май якты, бөтенесен көнләштереп, утыз ике тешен биетә башлады.
— Чәй әлеге яманаты чыккан скважинадан алынган суда пешкән, Нина Михайловна,— диде Жаденко.
— Барыбер кул куймыйм.
— Әлбәттә,— диде Жаденко, иренеп кенә.
Аларның берни дә сорашмаулары, фикере белән бөтенләй кызыксынмаулары Идриснең күңелендә бая ук калыккан шиген ныгытты: бу ике кеше арасында ул белергә ярамаган сер бар!.. Юкка гына ул алар арасына килеп кысылды!.. Менә бу чәй дә юкка гына куелмаган, Жаденко да шулай көлә-көлә ниндидер максатына ирешергә тели...
Үзенең мәҗлестә артык икәнлеген сизенгәч, ул чынаягын каплады да ике сөйләшергә урын калмаслык итеп:

— Мин кузгалам, иптәшләр,— диде.— Икегезгә дә шалтыратырмын, ачыклыйсы нәрсәләр калды... Әлегә китәм, килгән-килгән файдаланып калыйм, бу якларда йомышлар бар иде...

— Сез газетага язгалаганчы балаларны китерәбез,— диде Жаденко.

— Бирсен ходай! — дип саубуллашты Идрис.— Тик дачаның монарчы ачылмый торуы өчен дә җавап бирәсе булмасын!..

Тагын бер кат табигатьнең, корылмаларның камиллегенә сокланып, шушы бәһасыз матурлыкның юктан гына файдасыз ятуына ышана алмыйча, ул юлга чыкты. Машинада тиз үтсәләр дә, җәяү бара торгач сизелде, байтак җир кергәннәр икән.

Казан — Горький юлында машиналар гөж дә гөж, күз иярми кала. Ул шоссе кырындагы сукмактан Аккош күле тукталышына кадәр килде. Автобус көтеп торучылар байтак җыйналса да, машина тиз генә күренмәде. Идрис, шактый таптанып торгач, юлда таныш «УАЗ»ны абайлады. Тукталышка җитәрәк машина акрынайды. Идрис үзен утыртырга телиләр, ахры, дип өметләнеп бара башлаган иде, ишек ачылып аннан Булавина төште. Жаденко китешли, Идриска кул болгады. Аның йөзе сизелерлек кырысланган иде.

— Китеп булмадымы? — диде Булавина.

— Күргәнегезчә. Ә сез нигә төшеп калдыгыз?

— Сезне күреп төштем.

— Килеп сезнең кайсыгызгадыр җайсызладым, ахры, мин? — диде Идрис, ачыктан-ачык.

— Белмим тагын, миңа ярдәм генә иттегез! Виталий Петрович чөй кагарга оста ул... Дача тыштан гаҗәп шәп, бәхәсләшмим, әмма берүк вакытта күз буяуның иң асыл үрнәге. Кар базындагы суны күрдегезме?

— Бурсып беткән.

— Виталий Петрович фокусчы кебек! Членнар актка күз йомып кул куйганнар.

— Нишләргә уйлыйсыз хәзер?

— Иптәш Жаденко нишләргә уйлый дип сорагыз... Мин чигенергә җыенмыйм... Бер баланың авыруы да минем өчен әллә ни!..

Көн кичекте. Казаннан килгән автобустан яшьләр төште, алар, гитара чиртә-чиртә, дәү капчыкларын күтәреп наратлыкка кереп югалдылар. Күлләр ягыннан салкынча дымык һава акты. Сагындырган автобус килеп туктады, аңа сабыр гына кереп тулдылар. Үсмер бер кара егет Булавинага урын бирде.

— Хәзер Виталий Петрович ашыктырачак. Газетачыларны бик өнәми ул.

— Сизелде.

Идриска мәктәп тукталышында төшеп Ленин районына бара торган уникенче автобуска күчәргә кирәк иде. Ул, Булавина белән саубуллашып, арт ишектән төште, тукталышта җыелган халык арасында алар тагын очраштылар.

— Мин дә Ленин районында яшим,— диде серле көлемсерәп Булавина.

Үз тукталышына җиткәч, Идрис янә бер кат саубуллашып төшеп калды, кибеткә керде. Кибеттән кайтышлый үз артыннан кемнендер килүен тойды, борылып караса — Булавина!

— Сезне эзәрлекләмим, курыкмагыз,— диде ул саф татарча.

— Нина Михайловна, сез татармыни?

— Әйе... Керәшен кызы мин... Гаҗәпләнмәгез, без сезнең белән бер йортта торабыз. Хатыныгыз Диләмә әле?

— Ничек мин сезне белмим соң? — диде комач кебек янып Идрис.

— Төрле юлларда йөрибездер... Аннары чибәр ханымнарга игътибарыгыз да житенкерәми. Бары шул гына,— диде Булавина, егетне үртәп.

Тәрәзәләрдәге утларны күргәч кенә Идриснең хәтеренә Айдар килеп төште. Килермен дип китте, бичара малай аны көтәдер!

Баскычка менеп барган жиреннән ул түбәнгә томырылды.

— Сез кая болай?

— Мине көтәләр, Нина Михайловна! Гафу итегез...

— Эх, бу ирләрне!.. Бу ирләрне...

Идрис башаягын онытып урамга атылды. Булавина, Диләнең өйдә юклыгын белгәнгә, әрләп-кычкырып калды.

## 12

Айдар балконда юк иде.

Идриснең ялгышуы мөмкин түгел, балконы шушы... Әнә күрше балконда тартмалар, такталар, иске сандыклардан өстә бүген дә алтмышынчы үлчәүле ыштаннар жилбер-жилбер кибә...

Ул күзен алмыйча шактый ук вакыт карап торды. Эндәшсән, малай я йоклаган булыр, я әтиләре өйдәдер... Эндәшми китеп барсаң, яхшы түгел, көтеп утырадыр.

Жаденко белән Булавинага Айдар турында сөйлисе килде аның, сөйләмәде. Күңеленең бер почмагы белән Булавинага Айдар өчен рәнжеде бит ул. Юләрлек! Реаль тормышның эчке һәм тышкы законнары бар, алар янында бер Айдарның күңелсез балачагы чүп кенә. Синең өчен бик кадерле, бик кирәк нәрсәләр олы тарих күзлегеннән чыгып караганда микроскопик вак булып калмыйлармыни?

Райбашкарма председателенең мазасы бер Айдар гына ди!..

Гринберг белән сөйләшергә ярый...

Ата-анасы белән сөйләшсәң дә башка чут, анларга тиешләр, үзләренең йөрәк парәләре бит...

Күрше балконда кемдер шыбырдаган төсле булды, әнә ыштаннарны кырыйгарак кайтарып, берәү аны күзәтә... Шыпырт сөйләшкән тавыш ишетелде.

— Баядан бирле тора...

— Бурдыр ул, гөнаһ шомлыгы.

— Якимовларның элгән керләрен чәлгәннәр...

— Өй басарга йөрмәсен тагын...

— Халык ялда...

Балкондагыларның шиген таратырга теләп, ул актыгарак чыкты:

— Айдар! — дип эндәште.

Пышылдаулар туктаса да, тегеләр һаман сагалыйлар.

— Айдар, Айдар! — дип кычкырды ул тагын.

Балкон ишеге урынына форточка ачылды, аннан малайның башы тыгылды:

— Мин монда, абый! Монда. Синме бу?

— Әйе, әйе,— диде Идрис, сөенеп.— Чык балконга.

Малай ишетелер-ишетелмәс кенә үкседе.

— Бикле... Балкон ишеге дә бикле...

— Нишләп бикле? — диде аптырап Идрис.

— Әни бикләтте... Холодильникка да йозак куйдылар... Үзләре концертка киттеләр... Бүген курыкмыйм, абый... Карават асларын актарып бетердем.

— Бүген курыкмыйм дисең алайса? Молодец?!

— Курыкмыйм.

— Айдар, сезне тиздән дачага чыгаралар.

— Алдашма,— диде малай.

— Үзем барып белештем... Ике көннән мин ял итәм. Теләсән зоопаркка алып барам.
— Бармыйм.
— Нигә?
— Арысланнар анда читлектә утыралар. Читлектә утыргач арысланмыни ул?
— Алайса мондый паркка гына барырбыз. Карусельдә әйләнербез.
— Эти әллә ничо алып барасы булды инде, син дә шулай алдарсың әле. Чын, алып барасыңмы?
— Иртәнге уннарда мине көтеп тор, яме...
Ул кайта-кайта да борылып карый... Почмактан икенче тәрәзәдә һаман ут яна... Алты яшьлек Айдар шунда калды... Аның өстеннән генә, яшелле-кызыллы бүрт утларын уйнатып, самолет узды...
Урамда парлылар...
Алар урамның аулак, вакытның соң булуыннан кинәнеп рәхәтләнеп үбешәләр... Ачык тәрәзәдән кемнендер бәби йоклатканы ишетелә.
— Бәү, бәү, алтыным... Йокла, бәбием!.. Бәү, бәү!..
...Аның квартирасы ишек төбендә Әхәт белән Лида басып торалар иде. Идрис күренүгә Әхәт Лидага ымлады да сәгатьле кулын югары күтәрде:
— Финиш!.. Соңгы минутлар, секундлар... Арган-талган, ләкин бәхетле чемпион Идрис Бакиров фиништә!..
— Кунаклар бар икән, хәерле кич!
— Юхаланма,— диде Әхәт, аның сузылган кулына кагылып.
— Күптән көтәсезме?
Әхәт аны, ике беләгеннән эләктереп, көч белән ишеккә терәде:
— Сорау алу башланды. Кайда йөрдең?
— Рөхсәт булса, эчкә керик,— диде Лида.— Кызартасың кешене...
— Яле, бәйләнмә,— диде Идрис, Әхәтне читкә кагып.— Кибеттә идем. Ул ишекне ачты, өчәүләшеп өелеп бүлмәгә атладылар. Әхәт сөйләнә-сөйләнә эчкә үк узды. Идрис ут кабызды, ишек катында юаш кына басып торган Лиданы түргә чакырды:
— Адашырлык бүлмәләребез юк, узыгыз, кунаклар.
Әхәт бүлмәдән кухняга керде дә, кулын кулга ышкып, шкафны караштырды.
— Кунак тек кунак!.. Мактаулы исем... Янә шул да мәгълүм булсын, классикларыбызның уртак тырышлыгы нәтиҗәсендә яңа мәкаль иҗат ителде... Исәнбәтнең өч томлыгында юк, эзләмә... Тыңла: «Кунакларны сөреп була, кунакларны сөреп булмый». Шәпме?.. Язучы халкы кунак кабул итүнең рәхәтен еш татый... Кунак кабул итү — игәү ялау белән бер дип тә җибәрәләр... Син, чигәләре бәсәрә башлаган өметле яшь журналист, язучылардан үрнәк алырга ризамы?
— Риза, риза,— диде Идрис, сүз җаеннан гына торып. Иптәшенең шактый кәефле булуы өчен ул Лидадан бик уңайсызланды. Әхәт, аның ни уйлап хафаланганын сизгәндәй:
— Яшермә, «Әхәт үзе генә булса, шелтәләп чыгарып җибәрер идем» дип уйлыйсың,— диде.— Шулаймы?
Лида тәрәзә янына урындык тартып китерде дә бик дикъкать белән өй эчен, җиһазларның урнашуын, өстәлдәге, дивандагы газета-журналларны күзәтеп, Әхәт белән Идриснең сөйләшүен тыңлый башлады. Эндәшсәләр көлде, елмайды, үзе бер сүз дә дәшмәде.
— Мәең югын беләм, чәең бармы? Мәе үзебездә.— Әхәт шап иттереп кесәсенә сукты.
— Сез болай да кура җиләге көбек пешкәнсез.

Ул Әхәтне мондый хәлдә беренче тапкыр күрә иде. Лиданы исә болай гына, иптәшенен хәлен жинеләйтер өчен генә, санга кертте.

— Син, Идрис, Лидага ачуланма... Мин кыстагач кына керде. Рюмкаларың бармы?..

Лида, тезенә кулын куеп, аларга текәлгән...

Идрис чәй куйды. Колбаса, сыр турый башлауга, анын янына Лида керде, бөртекләп, жентекләп аны карап торды, кухнянын чисталыгына, әйбер-караларның тәртип белән тезелеп, күзгә ямь биреп урнашуларына игътибар итте.

— Өегезне кем жыештыра, Идрис абый.

— Бар шунда бер кеше...

— Ашарга-эчәргә дә шул әзерлиме?

— Үзе...

— Дилә апа барында да үзегез карый идегезме?

— Ул өйдә чакта уртак...

— Сез бик татулар, ахры?

— Нигә ямьсезләнергә? Дөнья болай да мәшәкатьле, әгәр кешенен үз өендә дә тынычлык бетсә, ул кайда ял таба?

— Ресторанда,— диде Әхәт, кухня ишегенә тыгылып.— Кыймылдагыз ятьрәк!.. Сыр бар, колбаса да ярыйсы... Яшел суган юкмы? Катык бар? Ул да шәп...

Ул рюмкаларга шампанское койды.

Идрис тә, Әхәтнен кулыннан чак ычкынып, аягүрә генә бер рюмка эчте. Жылырак эчемлек бик үк тәмле түгел иде.

— Сина иярсәң, утлы табага бастырасың, Әхәт.

— Күнелеңдә ни барын сөйлә, Лида! Идрис белән без иптәшләр... Ниса Чәймилова безне ишетми. Без ип-тәш-ләр! Эшләре ипкә килә торган кешеләр дигән сүз. Товарищлар. Хәер, «товарищ» сүзе үзе дә татардан алынган. Борын-борында товарлары бер иш кешеләр «товарищ» булганнар... Хәер, монысы мөһим түгел... Сөйлә, Лида. Тәтешкә эшкә жибәрәләр, диген... Барасы бик үк килми, диген... Бәлки, Әхәткә кияүгә чыгасы иде, диярсен...

Лида гарьләнеп, Идристән оялып, зур күзләрен тутырып-тутырып Әхәткә карап куйса да, теге тыела алмады.

— Идрис абыйдан оял. Яшәргә аннан өйрән!

Әхәт көлеп сикереп торды, рюмкага үрелде.

— Эчмә, зинһар, житкән сина.

— Соңгысы, Лидуш...

Әхәт сәгатенә карады, аннары, кулын чабып:

— Хәзер такси килеп житә! — дип әйтте.

— Сез китәсездәмени? — диде Идрис, өметләнеп.

— Әйдә, син әфәндене дә алып чыгабыз... Соңгы хәбәрләрне тыңладыңмы?

— Ә нәрсә бар соң?

— Бар шул, картлач. Мисыр жиналә... Корал калдырып чигенәләр... Хәрби комиссариатта булдым... Кирәксә үзебез чакырырбыз диләр... Кем билгели ул «кирәк чакны»?.. Дөньяның асты-өскә килгәнче көтеп ятыргамы?

Әхәт балконга чыкты, Идрис тә ана иярде. Һавада аның башы ачылып китте, ул, култыксага ята төшеп, сугыш хәлләрен кискен тавыш белән сөйләп алды.

Кыска-кыска гудоклар биреп, Идрисләр ишек алдына такси керде.

— Озатып жибәрәм мин аны,— диде Идрис.

— Тукта, үзем.

Әхәт, шактый кызмача күренсә дә, төп-төз атлап ишек янына килде дә, борылып көлеп:

— Лида, озатырга чыкма! — диде.

Кыз ашыкмады, Идриснең кулларыннан тотып алды да тезеп китте:

— Идрис абый! Әчермәгез аңа, зинһар... Сезне тыңлар ул... Сез бик, бик әйбәт кеше бит... Сөйләсәләр, ышанмас кебек тиям... Мин бит ятим, ир туганнарым юк. Агай-энебез читкә таралган... Бар белгәннәрем шул Тәүфыйк та Әхәт...

Әхәт, кире кергәч, ачык ишектә юри сузынкы звонок биреп торды.

— Дөнья, котыплар, меридианнар турында барамы сүз?

— Безнең нәрсә турында сөйләшә алуыбыз сиңа сер түгел,— диде Идрис, ишекне ябып.

— Мине өйләнергә кыстыйсыздыр әле.

— Кыстыйбыз,— диде Идрис, ышандырып,— әйбәт хатын алсаң, ичмасам, тиешле чагында өеңдә утырырсың. Үзеңне кем өчен булса да кирәкле зат дип исәпләрсең.

Әхәт изүен чиште дә, пружиналарын сыкратып, диванга утырды.

— Булмый, картлач, өйләнмим... Өйләнден, бала туар... Гафу ит, Лида!.. Атом бомбалары ява башласа, кая куярмын мин аны? Хиросимада адәм баласы дигән горур һәм тәкәббер заттан нәрсә калуын онытмадыгызмы? Күләгә!.. Үземнән соң күләгә калса да бер хәл... Ә балалар... Бала бит — варис, өмет, көч, киләчәк!..

— Лида, ышанмагыз, Әхәт шаярта.

Тик Әхәтнең сүзләре шаяруга бер дә охшамаган иде.

— Шушы кадәр өметсезлек белән ничек дөнья көтмәк кирәк? — диде Лида Әхәткә.— Болай сөйләргә синең нигезең юк.

Әхәт күзләрен йомган килеш башын чайкады:

— Күпләр шушы иман белән яшиләр, Лида!.. Әнә, статистикага кара. Бала туу елдан-ел кими. Демографлар бүгенге көнгә безнең ил буенча гына сигез миллион кешегә ялгышканнар. Ил күләмендә без сигез миллион баланы тудырып житкермәгәнбез. Бу бит бер-берен котлы салып, гомум сөйләшү җирлегендә эшләнгән хәл түгел... һәркем үзалдына нидер уйлаган, иртәгәге көненнән курыккан, әйе, әйе, нигә бу сүздән шигәергә? Бала — кешенең иртәгәге көне түгелмени?.. Һәм кинәт: сигез миллион бала тумый калган... Бу бит, дусларым, бүген чыгарылмый калган руда яки салынмый яткан йорт кына түгел... Демографлар, егерме-егерме биш елдан соң эш көчләрен ничек житкерәрбез дип, хафалы прогнозлар әйтәләр...

Идрис Әхәтне бүлдерде:

— Мин дә ул отчетны укыдым!.. Ләкин бу күренешне нибарысы курку белән генә аңлату дөрес түгел. Төрле аспектлардан чыгып карарга кирәк.

— Аспектлар ни сөйли?

— Өметсезлек белән шәхес тә, кешелек тә яши алмый. Дөньяның киләчәген бомбалар түгел, ә идея, гаделлек хәл итәчәк.

— Шулай. Ярар,— диде Әхәт, кузгалып.— Син хаклы... Ләкин мин дә хаксыз түгел. Хәзер яши алу уен түгел. Кеше булып кала алу — җаваплылык... Идрис, син хуҗамы монда, минме?.. Хуҗа икәнсең, сыйла!

Кунакларның китәргә ниятләре сизелми. Әхәт радиоалгыч янына килде.

— Соңгы хәбәрләр узды, ахры.

— Кирәкми...— Ул пластинкалар тартып чыгарды.— Оһо! Шейк?! Менә мал! Картлач, каян килде бу сиңа?

— Дилә сатып алган.

— Картлач, өйләнү файдасына бүген кич әйтелгән сүзләрнең иң нигезлесе менә шул! Гафу кыл: хатының синнән акыллырак!.. Лида, минем яита.

Пластинка әйләнә башлауга, Лида күндәм генә аның янына барып басты, тегесе нәзакәт белән аның нечкә биленнән кысты, алар күңелле генә бии башладылар. Идрис, комачауламас өчен, аякларын җыеп диванга менеп утырды. Аның авырайган күз кабаклары бер ябылып, бер ачылып йөдәтте. Әхәт, кухняда гына калдырып, залда утны сүндерде.

Ярым карангыда алар житез генә бөтереләләр. Лида, Әхәтнең иңбашы аркылы нидер әйтергә теләгән сыман, зур, моңлы күзләрен тутырып Идрискә карый. Әхәт биегән шәпкә көйли, пластинка әйләнеп беткәч, шуны кире борып җибәрә...

Нинди матур бу Лида...

Нинди гүзәл...

Идрис диван аркасына терәлде, аяк кыштырдаулары, музыка яңгырашлары аны һаман оеттылар...

Берзаман йокысы ачылып уянып китсә — бүлмә буш. Сәгать төнге икенче ярты. Яктыра башлаган. Кухняда ут яна. Радиоалгыч кызып кабыныр хәлгә җиткән. Өстәл җыештырылмаган.

Ул кухнядагы утны сүндерде, чалбар-күлмәген салып ыргытты да урынга ауды.

Кемгәдер сигнал биргән сыман, болын ягыннан әтәчләр кат-кат кычкырды...

## 13

Ренат Кәрамов детсад ишек алдында иң элек эшчеләрне күрде: алар ашыкмыйча гына машинадан материаллар бушаталар иде.

— Боз кузгалдымы! — дип кычкырды ул.— Башлана! Чынлап тотынганда, монда ике көнлек эш. Шулаймы, осталар?!

Аның җилдәй килеп керүе, сүзгә керешеп, башланмаган эшне тәмамлап та куюы сүсәргән әрҗәле машина тирәсендәге эшчеләргә хуш килмәде. Алар читкә карап тынладылар:

— Әйе, әйе,— дип мыгырдадылар. Арадан берәү:

— Тумаган колынны иярләп, билен сындырма,— диде.

Ренат Гринбергны күрергә дип кергән иде. Уйлансыннар әйдә, кыймылдасыннар. Бүген июньнең ничәсе?.. Җәйнең иң асыл көннәре узып бара... Пашка Тихонов көн дә диярлек шалтыратып Займищега чакыра... Яльчик күленә барып кайтырга да уйлашканнар иде. Я, ходай. Казан тирәсендә никадәрле матур урыннар бар!.. Ялга киткәнче шуларны әйләнеп чыгасы да... шул каһәр суккан малай тоткарлый! Куна китә алмыйлар...

Ишек ачык, тәрәзә дә ачык, арада җил йөгереп йөри. Шактый юантык гәүдәле, чал чәчле Фаина Наумовна телефоннан сөйләшә. Телефонның теге башында ата-аналарның берәрсе, ахры, мөдирнең сүзе кыска, тавышы коры...

— Юк әлегә... Белмим... Билгесез... Юк... Хушыгыз, хуш...

Трубканы куйгач ул, эре-эре сипкелләр чәчелгән кыска буынлы юан беләген өстәлгә куеп, тунган кеше сыман бер мизгел куырылып алды.

— Казанның иң чибәр егете килде,— дип көлде ялагайланып Ренат.

— Күрәм.

— Фаина Наумовна, күгәрченкәй, кайчан безне бу шайтан бәжрасыннан коткарасыз инде?

— Әгәр мин тылсымчы булсам... әлләниләр эшләр идем! — диде мөдир.

— Нишләр идегез, Фаина Наумовна?

— Бердәнбер улларыннан ничек котылырга белми чапаланган шәфкатьсез әтиләргә бер чарасы табылыр иде.

— Фаина Наумовна,— диде юри үпкәләп Ренат.— Сез бит акыллы хатын, зирәк!

— Дача мәсьәләсе урынында тора, Кәрамов,— диде Гринберг, аның төчелегеннән туеп.

— Нишләргә соң безгә?

— Үз сүземне әйттем шикелле.

— Безнең хәлгә дә керегез инде,— диде Ренат, ялварып.

— Гафу итегез, иптәш Кәрамов, хәлегезгә керә-керә үзебез көлкегә калмадыкмы икән? Артык дәрәҗәдә кешегә салынасыз. Бала сезнеке, үзегез карагыз азрак. Кайгыртыгыз, борчылыгыз, төннәр йокламагыз... Якынлык хисләрегез бер дә юкмыни?.. Улыгыз сезнең ничек яшәвегезне күрми. Телегезне белми. Сезнең нинди уйда яшәвегезне сизми.

— Тәрбия эшен жыйнаулашып сезгә тапшырдык, Фаина Наумовна.

Гринбергка чыбык белән төрттеләрмени, авыр гәүдәсен жил күтәргәндәй тизлек белән урыныннан купты:

— Ни сөйлисез сез! — диде ул, чак тыелып.

— Әхлак, мораль турысында бер-беребезгә ан-белем биреп утырышыйкмы әллә?

Ренатның күзләрендә мөдирне кимсетү, түбәнсетү утлары кабынды.

— Балалар арасында гомерем уздырдым,— диде Гринберг, сабыр гына.— Сезнең бала дигән жан иясе белән очрашуыгызга нибарысы биш-алты ел... Ә мин Казанда гына егерме биш ел... Саный башласаң, чутына чыга алмаслык ата-аналарны күрдем. Төрлесен. Мең-мең рәхмәтләр ишеттем... Шушы атналык бакчалар оешкач кына, яратмыйм ук дип әйтергә телем әйләнми, шулай да дәртем сүрелде. Астыртын, киләксез, нәтижәсез эшкә катнашып яшим кебек... Бакчадан кайткач үз-үземне сөймим... Ә кеше эштән соң үзе башкарган эшнең рәхәтен татырга тиеш... Мин аннан мәхрүм, һәм шуның сәбәпчесе сез, Кәрамов.

Ренат иреннәрен мыскыллы кыймылдата-кыймылдата урынында кыбырсыды.

— Мең баланы тезеп куегыз миңа... Шушы мең арасыннан мин һич ялгышмыйча атналыкка йөрүчеләрне аерып алам... Өс-башлары әшәкерәк булганга түгел, гәрчә атналыкка килүче балалар алам-саламны ешрак кияләр... Менә бездә Ира Зубова бар... Айдарлар группасында. Әти-әниләре хезмәт хакын аз алалармы?.. Өч йөз сумнан артыграк. Ә Ира кигән кофтаны күрсәгез, исегез китәр, кылкасы гына калган. Әнисе бакчада ике атнага бер генә күренә, әтисе бөтенләй йөрми... Нигә Ирага яңа кофта алмыйсыз дим... Ярамаган тагын, ди... Ике атнага бер күренеп кызына бер алма яки кәнфит алып килсәче!.. Ашауэчү зарланырлык түгел бездә, шулай да балаларны бераз иркәләргә дә, назларга да кирәк ич! Юк кына бит, алып килми. Шул ханым килә, киенгән-ясанган, ишек төбенә баса да тик тора... Балам, кил! дип кычкырып алмый. Шимбә-җомгаларда сабыйларның әти-әниләрен көтеп зарыкканын күрмисез бит сез... Шул чагында алар янына керсәм, йөрәгем телгәләнә. Тилмерәләр бичаралар... Нәтижәдә балаларның күңелләре боек, китек... Чын ятим бала ятим инде ул, үсә-үсә үзенең кемлеген аңлый... Монда бит ата-аналы бала ятим!.. Айдар исәйгән, аңлы малай, йөрегез көймәдә үзе белән! Балыкка барыгыз. Сораулар белән тинтерәтсен сезне, күрсен, илне белсен. «Тын күл» өлгергәч, билләһи, үзем өегезгә кереп хәбәр итәрмен... Йончытмагыз безне... Телефоныгыз юктыр әле?

— Без үзәккә күчәргә уйлыйбыз,— диде Ренат.

— Бик яхшы, күчегез.

Гринберг, балаларны сүз белән артык иркәләмәсә дә, гомергә дә

ларны рәнҗетмәде, тавыш күтәрмәде, тәмле тел, аз сүз белән дә дус-
анә арадашлык урнаштыра белде.

— Инде бер җае чыккач шуны да әйтим,— дип дәвам итте ул.—
Сез бит үз зарыгыз белән генә монда керәсез... Мин кырык икенче ел-
а Минск геттосында өч баламны, иремне, туганнарымны югалттым...
Үзем адәм ышанмаслык могҗиза белән генә котылдым... Өч баламны
ына югалттыммы мин шул җәһәннәмдә, Кәрамов?.. Оныкларымны,
асселемнен дәвамын кисте фашист-явыз... Балаларымның берәрсе исән
булсын иде!.. Мин яшь кеше түгел, искечә уйлый да торганмын, киче-
регез, әмма сез бала тәмен, бала бәхетен, бала кадерен анламыйсыз
шикелле. Мин, мин дисез сез... Эшлим, мин яңа кеше, ял да итәм ди-
сез... Ләкин балалар әтиләренен карашларынын иске яки яңа булу-
лары белән кызыксына алмыйлар. Аларга көлә белә торган, үчти-үчти
итеп кояш нурларына чөя торган, әкиятләр сөйли белә торган чын,
көчле, матур әти кирәк. Тәмле исле, татлы кәнфит бирә торган йом-
шак куллы әни кирәк. Ибраһимның әтисе төсле, Светаның әнисе төс-
ле... Детсад, түгәрәкләп кенә әйткәндә, бераз гына казарма да ул. Ә
сез... үз балагызның сабыйлыгын урлап шушы казармага китереп
ыргытуыгызга бик шат. Кансызлыкмы, җансызлыкмы бу? Айдар шун-
дый анлы, тере малай... Сез шунын дәртен, матурлык тойгысын акрын
гына үтереп киләсез!

Ренат рух ягыннан булсын, кичергән тормышынын зурлыгы, тәҗ-
рибәсе ягыннан булсын Гринбергнын дәлилләре, хөкеме алдында бик
бәләкәйләнеп калды. Ләкин анын шушына охшаган хөкемнәрне ишет-
кәндә худка җибәрә торган сыналган коралы бар иде.

— Ә без?.. Тормышнын ямен татып калырга тиештербез бит? Нигә
бала аяктагы богау булырга тиеш?

— Кем өчен яшисез? Киләчәк өченме?.. Әйттерәсегез килсә, килә-
чәк ул завод-фабрикалар, яңа калалар гына түгел, барыннан да
элек — кешеләр... Гафу итсен мине, тапкырлау җәдвәлен өйрәткән
укытучымны онyттым, ә яшәү дәреслеген аерырга өйрәткән кешемне
бүгенгедәй хәтерлим... Күптән мәгълүм булган хакыйкатьләрне сөйләп
сезне ардырдым, Кәрамов, әмма сез дә шактый ялыктырдыгыз мине.

Ренат детсадтан икеле-микеле уйлар белән чыкты. Луиза кибетләргә
кереп калган, килеп җитеп, сабырсызланып аны көтә иде.

— Кайчан? — дип каршылады ул аны.

— Белүче бер алла.

— Кеше акылы чишмәслек нинди бәла булды сон бу?

— Үзен кереп сораш.

— Кердем ди... Шул гомер эчендә бер җен карчыгын үгетли алма-
ган ирне әйтер идем...

Ренат детсад ягына карап алды да, хатынын култыклап, тиз-тиз
китә башлады.

— Сөйләшик әле, Луиза.

— Өйдә, хатын янында сөйләшергә сез оста.

— Син берәр атна ял ала алмыйсынмы?

Луиза шикләнеп кулын тартып алды:

— Мине берәр яры озатырга телисенме?

— Айдар белән өйдә утырырсын дим...

— Нишләрмен мин анын белән?

Егерме дүрт сәгать буена шул юньсез малай янында булуны ул күз
алдына да китерми иде.

Ренат ирлегеп сиздерергә булды:

— Башка әниләр уллары белән нишлиләр? Әкият сөйләрсен, тәм-
ле әйберләр пешерерсен.

Луиза кычкырып көлеп җибәрде:

— Син мине шаяртырга уйлыйсынмы?

— Һич...

— Алайса, ялны үзең ал, әкиятләрне үзең сөйлә, тәмле әйберләрне пешер!

— Татар хатыннары тиз европалаштылар,— диде Ренат, канәгатьсезлек белән.— Әбиләренең, әниләренең тула оек киеп боярга урак уруларын, мич арасыннан башка урында йөз күрсәтергә хокуклары булмавын онытып та бетерделәр.

Луиза бу турыда күптән уйлап куйган инде:

— Шул бичаралар өчен дә без бәхетне күбрәк умырырга тиеш,— дип, иренең авызын томалады.

Декабристлар урамына чыкканда алар бу якка ашыгып килүче Идрисне очраттылар. Ренат аны бер күрүдә таныды.

— Кая таба юл тотыш, иптәш журналист,— диде ул.

— Иске эздән,— диде Идрис, сәлам биреп. Ул Луизага карап текәлде: шушымы, шушы түгелме Айдарның әнисе?..

— Бөтен өмет сездә,— диде Ренат.— Безнең язмыш сезнең кулда!

«Шушы!» диде Идрис үз-үзенә...

— Аллаларны бик еш алыштыра башладың, әфәндем! — диде Луиза.

«Шушы түгел!».. Кайбер урыннары тулышып торса да, зифалыгын югалтмаган яшь, мөлаем бу ханымда усаллыкның эзе юк кебек иде. Киресенчә, йомшак түгәрәк ияге, чиста маңгае, килешле йөз сызыклары аның ягымлы, хискә бай булуы турында сөйләми микән әле?

— Әрләп бетермәдеңмени әле, Луиза!

«Шушы!»

Хатыны белән сөйләшеп ялыккан Ренат Идрисне үзләре белән шәһәр ягына кыстарга тотынды:

— Детсадта сез карарлык берни дә юк, әйдәгез, борылдык.

— Мөдирне күрәсе иде. Андамы ул?

— Ярык тагарак янындагы карчыктан ни таләп итеп була?..

Идрис кергәндә Фаина Наумовна валидолын суырып бетереп кенә килә иде.

— Мин яшьләр газетасыннан,— диде Идрис.

— Сезмени ул?.. Мина Мироныч сөйләгән иде. Утырыгыз, чак кына көтегез...

— Кәефегез начармы әллә?

— Түгел, түгел...

Ул туалетка керде, көннең шулай иртә кыздыра башлавына зарлана-зарлана, крандагы җылымса су белән чигәләрен, шешенкерәк күз кабакларын чылатты. Ренат Кәрамовтан соң беркем белән дә, бигрәк тә гаеп эзләп килгән журналист белән һич тә утырасы килми иде. Ул юри вакытны озаграк сузды. Идрис аны көтелмәгән хәбәр белән каршылады.

— Мин кичә «Тын күл»гә бардым, Фаина Наумовна.

— Уф... Өлгер кеше булып чыктыгыз сез алайса... Эх, эссе... Жаденко белән сөйләшмәдегезме?

— Аның белән дә, Булавина белән дә...

— Алайса минем белән очрашуның ни зарурлыгы калды? Капма-каршы кичләрне очраткансыз... Мин хәзер язгы ташкында утрауда калган кылый куян кебек. Мазай бабайны көтеп тик утырам... Әнә, материалларны бушатып киттеләр, эшчеләр кайчан килер...

Гринберг, кул кушырып утырмаса да, эшнең төбен егеткә ачып салмады.

— Фаина Наумовна,— диде әчке бер калтырану белән Идрис.— Дача мәсьәләсе ачык... Мине кайбер башка нәрсәләр кызыксындыра.

— Тынлыйм...

— Менә әле генә Кәрамовларны очраттым.

— Дәгъва белән сезгә дә барып життеләрмени?

— Юк... Мин аларның уллары Айдар белән таныштым. Анлап бетерә алмыйм — атналык группалар кемгә кирәк алар?

Гринберг бу юлы егеткә тулы кызыксынып карады.

— Изге ният белән төзелде ул группалар,— дип башлады ул салмак кына.— Әти-әниләре икесе дә эшләп, өйләрендә башка карар кешеләре булмаган гаиләләр балаларын кайда калдырып торсыннар? Аннары, ялгыз әниләр байтак. Сирәк-сорак ялгыз әтиләр дә очрый. Алар, шик юк, хезмәт иялəре, эшлиләр. Нигездә атналык детсадлар әнә шундый кыен хәлдәге балаларны сыендыра. Ният изге!

Ләкин мөдирнең тел язып бетермәве күренеп тора иде.

— Эш нәрсәдә соң, Фаина Наумовна? — диде Идрис, турыдан-туры.

— Һәр яхшы юлга, ни сәбәптәндер яман кешеләр дә төшкәли. Шунысы бәла.

— Хәйләсен ничек табалар?

— Кем нәрсәгә маһир инде... Кәрамовлар дидегезме әле?.. Мең оешмага гариза артыннан гариза язалар. Ир дә, хатын да укымышлы... Сүз, дәлил, исбатлау юлларын табалар... Сүз — суга караганда да остарак юл яра.

Гринбергның ни әйтергә теләве һаман ачыкланып бетмәде.

— Кәрамовлар сез санаган категорияләргә кермиләрме? Алар икәүдән-икәү генә... Икесе дә эшлиләр.

— Айдарның әбисе исән. Бу бер. Тормыш шартлары бик яхшы, теләсәләр няня ала алалар... Ярый, боларын куеп торыйк. Айдар янына икешәр-өчәр атна килмиләр, монысы куркыныч!..

Шушы сүзе кирәк иде Фаина Наумовнаның!

— Әйе, бусы бик куркыныч,— диде Идрис, килешеп.

— Кайда очраттыгыз сез Айдарны?

— Бер урамда яшибез.

— Алаймыни...— Гринберг кинәт кенә Идриска ышанды, аның бәләкәй чит малай өчен борчылып, янып утыруына ышанды.— Сезнең балаларыгыз бармы?

— Юк.

— Беләсезме, бүген Кәрамов белән нык кына тарткалашып алдык,— дип башлады Гринберг һәм Ренат белән барган әңгәмәне түкми-чәчми Идриска да сөйләп чыкты...— Шундый, шундый хәлләр, журналист иптәш. Уйлыйм да аптырыйм, очына чыга алмыйм. Үз теләгемә каршы килеп шушы эштә ярдәмче булып утыруыма кыйналам... Сезнең мине эзләп табып, шушы турыда сүз башлавыгыз мине канатландырды. Мин бер ялгызым гына исәрләнеп баш ватмыйм икән, бу мәсьәлә башкаларны да борчый икән!.. Борчылырлык та шул, иптәш Бакиров!.. Балалар интегәләр, сабыйлар газапланалар!.. Көн уза, әбиләр, әтиләр балаларны детсадтан алып китеп бетерәләр. Атналыкка йөрүчеләр генә кала. Шулар жыелалар да өзелеп-өзелеп: «Тагын ничә төн калды әле?» дип сорыйлар... Көн түгел, ничә төн калды диләр... Сабыйлар төнне белергә дә, санарга да тиеш түгелләр... Аларга төн буләк иткән мәрхәмәтсез ата-аналар байтактан йөрәгемне яндыралар... Менә шулай бала яраланып үсә... Аннан мәктәпкә керә, интернатка урнаша. Анда тәрбияләнә. Югары мәктәпкә керә. Тулай торакта яши, стипендия ала. Ахыр чиктә үсеп кеше була. Дәүләт аны туган көненнән башлап диярлек тәрбияли, белем бирә, һөнәргә өйрәтә. Шуннан әлеге әти-әниләр, яхшылык таләп итеп, балалары катына киләләр. «Мин сине тудырдым, карадым, тәрбияләдем», диләр...

(«Менә ни өчен бала туу елдан-ел кими!.. Бу да шуның бер мөһим аспекты!» дип Идрис эчтән генә Гринберг белән килешеп утырды.)

— Болар барысы да минем өчен яналык, Фаина Наумовна. Ифрат кызыклы, файдалы күзәтүләр... Менә шушы фикерләрне халыкка житкерәсе иде.

— Житкерегез сон!

— Аны сездән башка берәү дә үткәзеп яза алмас.

— Айдарга зыяны булмасмы? Артык ясалма, миһербансыз бәндәләр ул Кәрамовлар!..

Идрис төш алдыннан гына редакциягә кайтып иреште, Рәкыйп янына кагылды. Өзеп кенә бер нәрсә дә әйтә алмыйм, тикшерәм, кызыксынам, диде.

Көне буе Айдар турында уйлаудан туктамады.

Газетага язып кына Кәрамовларны тәрбияләп булмаячак, бусы факт, тырышып маташуың суга салган вакыт!.. Нидер эшләргә, үтемле чара табарга кирәк...

Тик ул чараның нидән гыйбарәт икәнен, аны тормышка ашырганда үзенең нинди урын тотачагын Идрис ул көнне белми иде әле. Ул бары битараф калмаячагын сизенә һәм җиңеп чыгачагына ышана иде.

## 14

Мөзәкир белән Зәйтүнә инеш ярындагы агачлыкта очраштылар.

Кыз яшь ана казның сонга калып чыккан бәбкәләрен сакларга төшкән, әнә алар, сары йомгаклар, таллык яныннан башланган стадионда әүпән-тәүпән яшел чирәм чемченеп йөриләр. Зәйтүнәләрнен авылда атаклы бүрекле ата казлары да шунда. Бәбкәләрне таламасын өчен аның ике борын тишегенә ике ак каурый кадап чыгарганнар. Күкрәкләренә куна-куна малайларны талаганы бар шул мәлгуньнең...

Зәйтүнә андадыр дип уйламады Мөзәкир, кармакларын күтәреп Иске буа артына үтеп китим дисә, агач арасыннан кызыйның ак җирлеккә сары арыш башаклары төшкән ситса күлмәге чагылып китте.

Басмага кергән җиреннән кире чыгып, агачлыкка юнәлде малай.

Күрештеләр...

Классташлар! Икесе дә алтынчыны бетереп җиденчегә күчтеләр. Дүртенчене бетергәнче бер партада утырдылар. Бишенчедә чакта пычак телләр «кияү-кәләш!», «җизни, җизни, күңелем синнән бизми», «килен камыры кабарамы? Кияү утынга барамы?» дип каныга башлагач, Мөзәкир арткы партага күчеп утырды. Зәйтүнә янына «җизни, җизни» дип безелдәүчеләрнең иң телчәне Чыпчык Ибрае ялт итеп кунаклаган иде, шул көнне үк, чана шуып кайтканда, Туғашлар тыкрыгы башында сагалап торып, Мөзәкир аны җир күмере ясаганчы тукмады.

Бу сугыш Зәйтүнәнең үзенә дә, башкаларга да тиз үк фаш булды. Гәрчә Ибрай «беркемгә дә чакмам, валлаһи, таллаһи, ике күзем атылып чыксын!» дип, юеш борынын тарта-тарта ант иткән булса да, икенче көнне үк, әләк ярата торган физкультура укытучысына тыкрык башындагы вакыйганы акырып салды. Физкультура укытучысы «булачак боксер» дип Ибрайны шәбәйтеп йөртә иде...

Шушы буталышлардан соң Мөзәкир белән Зәйтүнә бер-берсеннән читенсенә торган булдылар... Алтынчыда бу ятсыну тагын да көчәйде, ялгыз калганда сөйләшкәләсәләр дә, кеше арасында бер-берсенә бөтенләй эндәшмәс булдылар.

Түгел, дошманлык аркасында түгел иде бу тел яшерү...

Агач арасындагы алтын башаклы кыз яныннан сызгырынып кына үтеп китә алмады әнә малай, борылып чыкты, як-ягына каранды, тизтиз «исәнме» диде, үзенең озын буеннан үзе кыенсынып Зәйтүнә янына җиргә утырды.

— Казанга барып кайттың да тагын да хәтәрләнден,— диде кыз.

— Әй...

— Өеңнән чыкмый ятасыңмы әллә? Сине Казанда алып калдылармы дип торам.

— Эштән бушатмыйлар. Мөнир белән Чыршылы тегермәненә бардык, көн узды. Аннан Рузиләнең күзе авыртты, аны ике тапкыр марига больницага алып бардым... Яшелчәгә чыктым.

— Төзәлдеме соң?

— Нәрсә?

— Рузиләнең күзе.

— Авыртмый хәзер...

Сөйләшсәләр дә, алар бер-берсенә күтәрелеп карамыйлар. Зәйтүнәләрнең бүрекле ата казлары ят кеше барын абайлап бу якка борылгалый, шәбәеп, тамак төбе белән генә тавыш бирә. Бәләкәч сары йомгаклар пи-пи килеп буп-буш футбол мәйданында йөриләр. Зәп-зәңгәр күктә аларның баш очында гына ике тилгән түгәрәк сыза. Зәйтүнә аларны куркытып бер башына көнҗәлә сүс бәйләгән таягын болгый...

— Бер күзеңә туфрак, бер күзеңә яфрак! Кө-өш!

Аръякта бәбкә саклаучылар шулай кычкыралар...

Кинәт кенә каз кангылдый башлый, тыпыр-тыпыр чабып өч кызыл бозау үтеп китә...

— Казан әйбәтме? — диде кыз, таяк очы белән җир тырнап.

— Шәп.

Шәплеген сөйләп бирергә кирәк булса да, Мөзәкир сүзләр табалмый...

— Кешеләр күпме? Кинодагы төслеме?

— Андагыдан кызыграк... Җизни белән университетка бардык. Ленин укыган аудиториягә кердек.

— Кая, кая?

— Ау-диториягә.

— Дилә апа чирләгәнмени?

— Без барганда киткән иде инде... Казан әйбәт! — диде Мөзәкир, хыялланып.— Унынчыны тутыргач мин дә укырга шунда барам.

Кыз боегып үзенең ялан аякларына күз төшерде.

— Татарча укыйсы булса мин дә барыр идем, болай кая? — диде ул, зурларча хафаланып.

— Өйрәнербез, Зәйтүнә! Менә күреп шаккатарсың... Әле ничә ел укыйсы бар... Радио, телевизор көне буе русча сөйләп тора!.. Аңа калса, минем дә ипилек-тозлык кына.

— Мактанма,— диде кыз,— син Маяковскийны да русча укыйсың.

Мөзәкир кызның йөзенә күтәрелеп карады. Язгы төн кебек ике күз сөеп кенә аңа карап алалар...

Авыл ягыннан нәзек тавыш килде:

— А-ба-й!

Бу тавышны алар колакларына да элмәделәр. Тилгәннәр һаман бер түгәрәкне сызалар, тик алар Зәйтүнәләрнең ата казларын танымыйлар бугай, түбәнәергә кыймыйлар. Җәйге коры һава чынлап, зеңгелдәп тора. Инеш аръягында колынлы бия утлап йөри... Караган саен малайның күзенә яна нәрсәләр күренә... Зәйтүнәнең бармаклары озын-озын...

— Теге чыпчык бәйләнеп азапланамы?

Кыз бу сорауны көтә иде, ишеткәч, бите алланды...

— Бәйләнмәс, ул быткыч... Син Казанга киткәч, урамнарыннан уздырмады. Көтү каршысына төшкәндә этен өстерә.

— Җилкә чокырыннан чөелдерек бавы тәләрмен әле...

— Бәйләнмә шуңа,— диде кыз,— иптәшләре ишле хәзер.

— Кемнең,— диде Мөзәкир, җирдән калкынып.— Әнисе клуб җыештырырга кергән дә, кинога буш керергә чамалап, биш-алты сәләгәй шуңа сатылып, ялманып йөриләр.

Зәйтүнә Ибрайга ялагайланып йөргән малайларны белә иде. Мөзәкирнең кискен хөкеменә ул сөенде.

— Шулай да кагылма... Йөрсен...

— Чебен тимәс чер итәр, кызлар белән сугышып йөри икән...

— Тимә.

— Ярар.

Тыкрык яктан тагын чәрелдек тавыш ишетелде:

— А-а-бый!

— Рузилә төшеп килә. Сине эзлиме шулай?

— Кемне булсын тагын? — диде Мөзәкир, калкынып.

Ул сикереп торды, кармак сапларын Зәйтүнә янында калдырып, сеңелесенә каршы китте:

— Нәрсә бу хәтле акырасын?

Рузилә имән бармагы белән борынын казый-казый тәтелдәргә тотынды:

— Әни, кайтсын! — диде... Юк балык артыннан йөрмәсен, ди... Нәгыйм абый басудан чирләп кайткан. Теше сызлый.

Мөзәкир сеңелесенең колак артыннан кытыклады да Зәйтүнә янына кайтты, кыерсытылган кеше сыман маңгаен җыерып, кармак сапларын култык астына кыстырды.

— Сине дәшәме?

— Кемне булсын?.. Мөнир гаражда... Нәгыйм чирләгән...

— Чирләгән?

— Иске буа артындагы тугайларда кара балык чиртә дигәннәр иде.

— Син хәзер җәйләүгә барасыңмы? — диде кыз да, торып басып.

— Шулайдыр инде...

— Мин дә кич әни янына барырга җыена идем. Көтү кайткач та барам.

— Кил.

— Иске буа артындагы тугайлардан куркам мин... Суы карангы... Чонгылда су анасы утырса?

Мөзәкир тавышсыз гына көлде... Зәйтүнә аңа ияреп тыкрык башына кадәр килде. Рузилә, борынын казыштырып, чыгынкы мангае астыннан Зәйтүнәгә карап-карап ала иде. Малай ялан тәпиле Рузиләне җитәкләде, кармак сапларын иңбашына салып, зурларча эре һәм салмак атлап тыкрыкка кереп китте.

Кыз шушындый рыясыз, кыю дусты һәм яклаучысы булуына куана иде... Бүген икәүдән-икәү генә шулай озак сөйләшеп утыру аның күңелен җилкендерде... Яклаучысы гынамы Мөзәкир?.. Кызлык чоры әле уянып кына килгән Зәйтүнәнең аңында исемен атау да кыен, оят булган яңа, кайнар фикер туды... Ул Мөзәкирне озатып онытылып торуын абайлап сискәнде, таягын болгый-болгый, яшь кәҗә бәрәне күк сикергәләп, агачлыкка, бәбкәләре янына йөгерде, тубырланып беткән кабыклы карт тирәк артына кереп посты...

Гөлбикә апа Мөзәкирне капка төбендә көтә иде.

— Улым,— диде ул, аның аркасыннан сөеп,— балыгына барып җитә алмагансыңдыр инде. Нәгыйм чирләп кайтты бит.

— Суык тидергәндер.

— Мәтрүшкә кайнатырга куйдым. Киптергән юка чәчәгем дә бар. Шуның парына төреп утыртырмын, чире йомшамасмы? Аларын үзем карармын да, менә әтиегез бер башы нишләр?.. Син бер-ике көнгә генә җәйләүгә бара алмассың микән?.. Атаң, килмәсен, дип әйтеп җибәргән җибәрүен, мәгәр бармасаң, читенгә китәр дим, атаңа диюем...

Мөзәкир карышусыз гына җыенды, чоланга кереп, тезе ямаулы буй-буй чалбарын, озын җиңле шотланд күлмәген киде. Әзерләнеп беткәч, мич арасында чуклы калын шәлгә төренеп утырган Нәгыйм янына кагылды.

— Бик нык сызлыймы, Нәгыйм?
Шәл астыннан малайның сыкрап мөгердәгәне генә ишетелде.
Ишек алдында Рузилә әнисенә абыйсын әләкләп маташа иде.
— Абый белән Зәйтүнә таллыкта икәү генә утыралар...
Мөзәкир сеңелесенең борынын ике бармагы арасына эләктерде:
— Әләкчегә каты җәза: борынын җәмки белән кысабыз, вәт!..
Җәйләү байтак еракта булса да, Мөзәкир җәяү генә барырга булды. Баягы тыкрыктан су буена төште. Тирәк төбендә кызның нәни пумаласы, китабы ята, үзе монда юк иде. Әнә талгын җил генә китап битләрен бер ача, бер яба... Зәңгәр күктә ике тилгән һаман әйләнәләр...
Ул иелеп китапны алды: Такташ... Такташны куйгач, ул кызны эзләде, Зәйтүнә күренмәде. Малайның күзе Гаптерииләр бакчасындагы сирень чәчәкләренә төште. Ул озын-озын уйлап тормады, коймa аша элдерде дә һәм бер-ике чемкә чәчәк өзеп алды. Чәчәкләрне китап өстендә таратты һәм, кеше-кара комачауламавына куанып, шыгырдавык басма өстенә ялт-ялт менде. Аръякка чыккач, җинел сулап сызгырып җибәрде.
Елганың уң як ярыннан, су иркенә буйсынып боргалана-сыргалана, урын юл бара. Бәләкәй, тар юл, чирәм сарып бетергән үзен. Элек шушы юлдан күрше авыллар тегермәнгә йөргәннәр. Хәзер тегермән ишелеп юкка чыккан, буасы киткән, буа артында тирән-тирән чоңгылларда каралҗым су ята. Комырыкларда тынлыкны сөюче кара балыклар үрчиләр. Мөзәкир шушында килмәкче иде...
Ул уймакланып-уймакланып аккан караңгы чоңгылга тукталып карап торды...
Унда тау тезмәсе. Тау белән елга арасында инкүлек. Инкүлектә тезем-тезем тал агачлары, тубыл-тубыл булып үскән зирекләр. Зирекләрнең коңгырт-кара ботакларына ямь-яшел колмак тожымнары уралган. Арыш камчылый башлагач, беренче ак томаннар агылганда шушы куак төпләрендә аксыл-сары итләч гөреҗдәләр үсә... Ара-тирә генә хуш ис бөркеп утырган карлыган куаклары очрый. Карлыганы вак булса да, үтә баллы — теленне йотарсың...
Кайдадыр алда трактор гөрләгәне ишетелде. Бу як — болынлык, аръякта люцерна басулары, трактор монда нишли икән? Юк, трактор шушы кадәр үкермәс, ят машина тавышы бу, әллә нефтьче-мазарлар килгәнме?
Мөзәкир адымнарын эрерәк сала башлады, караваг астында ятып ямьшәйгән күн итекләре аягын кысты. Менә алда Карабаш калкулыгы. Шуны үткәч, озын инкүлек ачыла, җәйләүгә туп-туры шуннан сыпыртасы...
Карабаш калкулыгы язын ин элек кибә. Мәктәп балаларын физкультура дәресләренә шунда алып киләләр. Беренче җиләкләр дә шушында пешә.
Малай, йөгереп диярлек, калкулыкка менде. Елганың ике ягыннан ике бульдозер ярларны ишеп инешне буып маташалар иде...
Буа буулары турында ничек ишетми калды соң әле ул? Алай дисәң, якын-тирәдә малай-шалай затыннан берәү дә уралмый... Бигрәк җайсыз урында буалар икән, житмәсә Карабашның бер ягын умырталар, җиләклекләр әрәм була...
Башта ул кызыксынып, якыная төшкәч шөбһәләнеп, килеп житкәч куркынып, яшел үлән белән капланган тәбәнәк ярларның бульдозер кискечләре алдында вак куаклары белән эшерелеп, сыдырылып баруларын күзәтте. Ул кая барырга чыгуын да, ашыгырга кирәклеген дә, кич житүен дә онытты, балалыгы белән бульдозерларның җегәренә, аларны идарә итүче егетләрнең гайрәтләренә хәйран калды. Умырта-

лар гына, җир дер-дер селкенеп тора. Ул егетләргә кәч биреп: «Һәй-һәй!» дип тә кычкырды.

Бульдозерларның алгы яктагысы чигенеп ерагайды, бу яктагысы тынып тукталды, шул чак Мөзәкир үзе артында көлгән тавышлар ишетте. Зирек куагы төбендә ике кеше кырын ятып карта сугалар. Кырыйларында буш капчыклар ята, сумкалар. Куаклар өстендә кибәргә эленгән җәтмәне ул шунда гына абайлады. Балык тотарга чыкканнар ич болар! Торна сазын тикшерергә мелиораторлар килә дигәннәр иде, шулардыр, ахрысы. Ул карта уйнаучылар янына атлады, әрекмән яфраклары белән капланган чиләккә абынды. Чиләктә ике-өч кара балык тырпылдый иде. Тегеләр аңа күтәрелеп карадылар.

— Абыйлар, сез монда ни эшлисез? — дип сорады ул, иренен чак кыймылдатып.

Җирән чәчле, кысыграк күзле егет:

— Тире җыеп күн эшлибез,— диде.

Кара мыеклысы аннан да уздырды:

— Комнан бау ишкәнне күргәнең бармы? — дип хихылдады.

Мөзәкир тиз генә ычкына торганнардан түгел, ике тапкыр:

— Буаны нигә буасыз? — дип сорады.

— Нигәме? Хәзер күрерсең. Китмә, безгә балык җыешырсың,- диде җирән.

— Китсен, китсен,— диде кара мыек.

Малайның әллә кайчан бер ишеткәне бар иде: комсыз кешеләр, тракторлар белән ашык-пошык кына елганы буып куялар да, буа артыннан коры кул белән балыкның эресен-вагын җыештырып алалар икән... Былтыр бер тәлгәш шомырт өчен бастырык юанлыгы агачны кисеп ятканда әтисе шундый комсызларның өстенә үзе килеп чыккан. Шул сөйләдеме балыкчылар турында?.. Шул бугай!

— Туктагыз! — дип кычкырды ул үзе дә көтмәгәндә. Аны, табигый буларак, берәү дә ишетмәде, аяк астында буталган малайга бульдозерчылар күз дә төшермәде. Мөзәкир, балтырдан бата-чума, елга аркылы өелгән балчык тавына йөгереп менде. Бульдозерлар улашып артка чигенделәр дә үкереп аның өстенә килә башладылар. Ул куркудан калтыранды, ике яктан да шыбырдап балчык тавы ишелде, баскан урыны вулкан тавы сыман тирбәлде, малай, урыныннан купмаска тырышып, кулларын бутады. Бульдозерчылар сүгенешеп акырдылар. Ул урыныннан шып купмады, үчекләп, күн итек үкчәләре белән суны ера башлады. Тегеләр үкереп рычагларына тотынганда, чытырдатып күзләрен йомды. Ике яктан ике балчык дулкыны китереп кыскач кына күзләрен ачты, машиналар тынды, йөртүчеләр сикерешеп төштеләр. Кай арададыр янга менгән җирән:

— Этрәк әләм, салам сыйрак! Гүр тактаңны сагындыңмы? — дип акырды.

Бульдозерчыларның берсе — киң табак битле, җәлпәк киртләч борынлы әзмәвер ир — килеп йолыккаларга тотынды:

— Ни җитми сиңа, көчек?

Боларның шулай дәррәү кысрыклаулары малайның шик-шөбһәләрен үстерде, ул:

— Нигә буасыз безнең елганы? — дип кабатлады.

— Син кирәкәнең мазасы ди ул... Тай моннан, аттыр.

— Нигә минем эш булмасын ди? Бизрә безнеке.

Балчык ишә-ишә җирән алар янына килде һәм Мөзәкирнең иненнән элэктереп үзенә таба борды:

— Ну?!

— Җибәр! — дип, малай тегенең кулын тырнады.

— Җүләр! — диде әзмәвер,— безгә буа буарга куштылар. Наряд белән эшләнгән эш.

Тешләнгән кулын балчык белән уа-уа:

— Суга ыргытыйммы, әллә үзең таясынмы? — дип ысылдады жирән.

Мыек яр буена басып чарт-чорт көнбагыш чиртә иде:

— Баш-аягы белән ыргыт шул үләтне,— дип киңәш бирде ул.

Әзмәвер белән жирән сиздермичә генә күз кысыштылар, жирән, кулын пиджак жиңенә сөртеп:

— Әйдә, малай,— диде.

— Кая алып барасың мине?

— Елганы буарга дигән нарядны күрсәтәм.

Малайның икеләнүен күреп, әзмәвер жирәнне куәтләде:

— Бар, бар! Эшне законлы йөртергә яратасың икән, тикшер.

Берьюлы ике-өч кеше раслап торгач, малай икеләнде, бата-чума жирән артыннан корыга чыкты.

— Язуыгыз кайда?

— Әнә тегендә,— диде жирән, агачлыкка күрсәтеп.— Анда палаткада безнең начальник ял итә. Кәгазьләр анда.

Куаклыкка керделәр. «Мелиораторларны Торна сазында дигәннәр иде... Начальниклары нигә монда икән?» дип уйлады малай. Бәләкәй генә сукмак ачыклыгында консерва банкалары, колбаса кисәкләре чәчелеп ята. Мөзәкир абайлады: мыек та аларга ияргән, мәзәк кенә елмаеп, иснәнә-иснәнә алар артыннан килә. Күңелне шомландырып бульдозерлар кинәт үкерергә ябыштылар. Куак арасында төлкенеке төсле очлы борынлы чуар, ялагай эт күренде.

Жирән, эткә күрсәтеп:

— Синең киләсене белеп начальник каршы алырга да чыккан,— диде.

Мыек кул шапылдатып эткә эндәште:

— Пират!

Эт, Мөзәкирне иснәде дә, сырт йонын кабартып ырлады.

— Ничек син, пионермы? Әллә комсомолга ук үрләдеңме?.. Идарәгә барып чагаргамы исәп?

— Чакмыймы бу? Чага! — дип хуплады мыек.— Пират!

Эт, койрыгын чәнчеп, абалап өрә башлады.

— Начальник күп сөйләде, тик син аңышып бетермәгәнсеңдер, тылмач булырга туры килә,— диде жирән һәм, алагаемга киерелеп, Мөзәкиргә сукты. Малай, хәлне сизенеп, кыйный башласалар каярак качарга икән дип уйлаштырып тора иде, сугу барыбер көтмәгәндә булды, ул авыртудан бигрәк гарьлек, үртәлү тоеп жиргә сыланды... Кызышып янган яңагын тотты... Жирән белән мыек, ике яктан килеп, сүзсез генә, һич кабаланмыйча, аңа типтеләр. Бульдозерлар үкерепшашып ике яктан аны кысалар, изәләр кебек тоелды. Ул актык көчен жыеп:

— Әни-и-и! — дип кычкырды.

— Житәр,— диде мыек, жирәннең юлына төшеп.— дөмекмәсен тагын.

Алар Мөзәкирнең ыңгырашып тавыш биргәнен генә көттеләр дә, тәмәке кабызып, кәефле сөйләшә-сөйләшә елга ягына киттеләр. Очлы борынлы эт малайга якынлашты, малай кыймылдагач, арт аякларына утырып күккә карап уларга тотынды...

Сәгать ярымнан соң, юеш ике капчыкны әржәгә ыргытып, балыкчылар китеп бардылар. Дәү, ялтыравык пычакларын күтәргән бульдозерлар, яман шылтырап, аларга иярде. Үрмәли-үрмәли шырлыкка кергән малайны берәү дә искә алмады.

Өйдәгеләр «китте» дип беләләр...

Жәйләүдәгеләр «килмәде» дип уйладылар...

Зәйтүнә зарыгып, ут йотып торса да, көтү бүген көндәгедән күп сонгарып кайтты.

Бәбкәләрне җилтерәтеп чиннеккә өерләде, бер аягы сынган чаякка салып аларга су кертте. Сыерны да бармаклары укмашып катканчы бер тоташтан сауды. Сөзгеч өстенә ике кат марля куеп сөтне сөзде, чүлмәккә тутырып нәүрәпкә төшерде. Әтисе кайтуга казанда аш кайный иде, учакка биш-алты йомычка ыргытып утка җан бирде дә, үзе бер сынык ипи тотып, чыгып йөгерде. Кичке савым беткәнче җәйләүгә барып өлгерергә кирәк, югыйсә Мөзәкир төнлеккә көтүгә китеп барыр.

Кыз, машина-мазар булмасмы дип, арлы-бирле тулганды, идарә янына Түбән очка йөгерергә уйлады, ул фикереннән суынып, Мөзәкир кебек, су буеннан гына элдерергә ниятләде. Аяклары нык Зәйтүнәнең, класста беренче йөгерешче...

Тизрәк, тизрәк!

Теге матур чәчәкләрне Гаптериләр бакчасыннан өзгәндер инде.

Иң куркынычы — Иске буа урыны... Алабута баскан нигез чокырлары, тегермән буасыннан калган черек баганалар, җирдән шытып чыккан гыйфритләргә охшап, кызны шомландыралар. Юл Бизрә буйлап бара-бара да Карабаш калкулыгында аннан чак кына аерылып китә.

Кыз калкулыкка тиз барып җитте... Һәр язны балалар шушында җыелалар. Казаннан килгән шагыйрь абый белән дә шушында очрашканнар иде. И-и, кызык та булган иде сон! «Тамаша»ны укыганда тәгәри-тәгәри көлделәр... Тагын, ничек әле?.. «Биек тауга менеп бара бер атлы... Көпчәкләр сөйрәлә бер-бер артлы... Ай ла, ай ла.. Тап син дегет, майла... Җайла, егет, җайла... Майла... Май-ла!»

Кыз калкулыкка коштай очып менде. Ул тагын шагыйрь абыйсын хәтерләде, аңа ошатып тиз-тиз укый-укый түбәнгә йөгерде. «Биек таудан төшеп бара шул атлы, көпчәкләр әйләнәләр бер-бер артлы... Майламасаң май-лама! Җайламасаң җайлама!».

— Җайламасаң җайлама! Әһе-һәй!

Моннан җәйләүгә ике чакрым калса калыр, әнә ул Бизрә буенда... Җәйләү артында калын-калын нарат урманнары башлана... Ерак, зәңгәр, күгелҗем урманнар, күгелҗем офыклар...

— Әһе-һәй!

Уйсулыкка кичке салкын, үләннәргә чык төшкән. Куакларда пыр да пыр кошлар очалар. Кызны сискәндереп, сукмак аша тычкан йөгереп узды. Кемнеңдер кайтмый калган сыеры агач-ботак шатырдатып йөри. И-и, Сәгыйт абыйлар сыеры ич бу, алакүз! Эзләп тинтериләрдер, мөгаен... Кара ничек тасрайган, имәнгеч, мөгезләре үткер чөй кебек, качкын мал икәнлеге әллә каян билгеле, үзе симез, былкын сыман! Елык-ялык килә... Тукта әле, мин син юньсезне!..

Зәйтүнә иелеп сыек чыбык сындырды, ачулы селтәнә-селтәнә, качакны авыл ягына куды. Сукмактан чыгып сыер артыннан китте һәм дерт итеп шып туктады. Якында гына кемдер ыңгыраша иде. Кыз чыбыгын атып бәреп:

— Әбәү! — дип кычкырды да чаба башлады, күлмәк итәге төпкә эләгеп җиргә тәкмәрләде. Тын алырга шүрләп яткан җиреннән генә тыңлана башлады: ыңгырашу тагын да ачыграк ишетелде.

Мөгаен, Чыпчык Ибрае качып ятып аны өркетергә маташадыр. Шулдыр, хак, шулдыр, юкса бу тирәдә эт куып кем йөрсен? Җимешмазар пешмәгән, гөмбәгә иртә... Тәкрарлек, балыкка дип килгәндер дә аны күреп поскандыр. Зәйтүнә, чыбыкның пешерәген сындырып алды да, уңга-сулга айкап-чайкап, тавыш килгән якка юнәлде.

— Чыпчык, синме? Чык монда. Куркалар дип белденме? Качып ята, гарьлек, гарьлек!

Ул такмаклап әйләнгәләде һәм үлән арасында бөгәрләнеп яткан гәүдәне абайлады. Аның күзләре атылып чыгардай булып ачылдылар: әчәч, кеше ич бу! Исерекме, аекмы? Дусмы, дошманмы? Кыз, томырылып чабарга җайлап, яңы белән бер-ике атлады да:

— Мөзәкир! — дип пышылдады.

Малай башын калкытты, шешенгән канлы күз кабакларын чак кыймылдатып, бияләйдәй булып күпергән иреннәре белән елмайгандай итте:

— Синме бу, Зәйтүнә?

— Әй, Мөзәкир! Бәйләнмә дидем шул Чыпчыкка! — дип үрсәләнде кыз.

Янында җан иясе булу куәт бирдеме, Мөзәкир торып утырды, учы белән иягең битен ышкып карады.

— Син моны берәүгә дә әйтәсе булма, яме?

Мөзәкир янына тезләнгән Зәйтүнә тыела алмыйча елый да елый.

Малай як-ягына каранды, көннең кичегүен, агач араларындагы куе күләгәләрнең күз алды карангылыгыннан гына түгел икәнен чамалады. Ул кулларына таянып тормакчы булды, хәле китеп чак мәтәлмәде, көчсезләгән кызга күрсәтмәс өчен:

— Су китер, Зәйтүнә, су.— диде. Кыз, каушап, әрекмән яфрагын өзде, өметсезләнеп, борынын мышкылдатты.— Тегендәрәк банкалар күргән идем.

Буш банка тотып кыз елга ягына чапты, Бизрә суының ишлегенә хәйран калды. Елганы шушы турдан гына буганнар, су, җәелеп, яр чирәмнәрен баскан. Шушы буа белән Мөзәкир арасында берәр бәйләныш бармы әллә дип шикләнде кыз... Тик бу Чыпчык Ибрае кулыннан килерлек эш түгел, бу әкәмәт олы нәрсә, әнә трактор эзләре кисешеп беткән. Ул, шикләнеп, Бизрәгә карый-карый, банканы юды, су алды, яулыгын инештә чылатып, торып йөгерде. Ул килеп җиткәндә, Мөзәкир аягына басып, кулы белән агачка ябышып тора иде. Нечкә тал сыгылган саен, ул да атынып-атынып китә... Кыз юеш яулыгы белән аның битен юды, чистартты. Мөзәкир банкадагы су белән иреннен чылатты, аннан эчеп тә җибәрде. Малайның өс-башы нык кына таланган, чалбар төбе умырылган иде.

— Буа... буа бармы Бизрәдә?

— Бар,— дип раслады кыз.

— Олымы?

— Су юл алган инде, арыктан агып ята. Начар-начар гына буылган.

Малай үзе дә арык шавын ишеткәндәй булды.

— Минем яңаклар нык бозылганмы?

— Бик үк түгел,— дип ялганлады кыз.

— Ничек очраттың син мине?

— Әнкәйләр янына чаба идем...

— Җәйләүгәме? — диде Мөзәкир, тәмам аңына килеп.— Минем дә шунда барыш.

Кузгала башлаган малайны Зәйтүнә туктатты.

— Өегезгә генә кайт, Мөзәкир.

— Анда әни...

— Әйдә алайса...

Сукмакка төшеп аллы-артлы бара башладылар. Малай иреннәрен кысып алдан атлады.

— Мөзәкир, кем белән сугыштың син?

Малай җавап бирмәде, бер кавым баргач туктап борынын сеңгерде.

— Синең этиеңнең мылтыгы исәнме?
— Чормада ауның бугай.
— Миңа кирәк ул,— диде малай борылмыйча гына.— Син аны миңа алып төшеп бирерсең, яме.
— Нигә? — диде кыз, коты чыгып.
— Мин аларны үзем эзләп табам.

Кыз, малайны ничегрәк тынычландырырга икән дип, юл буе баш ватты. Моңа хәтле аның шулай авыр итеп, җавап таба алмаслык уйлар коллыгында булганы юк иде. Мылтыкны бирәм дисә дә, бирмим дисә дә, Мөзәкир кызганыч. Ул кабатлап сорамады, кыз малайны юмаларлык сүз тапмады, алар салкынча томан җәелгән инкүлек буйлап бик озак бардылар. Мөзәкир ни ашыкса да, акрын кыймылдый иде. Бара торгач бөтенләй туктады.

— Ишетәсеңме, Зәйтүнә?
— Киләләрме? — диде куркып кыз.
Мөзәкир ишетелер-ишетелмәс кенә көлде:
— Сандугач...
Болынга чыктылар. Хәзер җәйләү бөтенләй якында... Ачыклыкта да күз бәйләнә, йолдызлар кабындылар.
— Әнкәң кайтып та киткәндер, Зәйтүнә.
— Чыккач-чыккач, барып кайтам инде.
Мөзәкирнең иңбашы үтереп сызлый, башы әйләнә иде, шулай да ул бер тапкыр да ыңгырашмады, туктап борынын гына сеңгергәләде. Ул, бара-бара да үз-үзенә:
— Барыбер эзләп табам! — дип кабатлый.
— Кемне, Мөзәкир,— дип ялынды кыз,— кем белән сугыштыгыз? Чит авыллармы?
Тик Мөзәкир бу турыда берәүгә дә әйтмәскә, теге явызларны үзе табып, үзе әмәлен сайлап, җәзаларга карар кылды...
Алар җәйләүгә барып җиткәндә кичке савым беткән, савылган сөт озатылган, савучыларның өлкәнрәкләре авылларга таралышкан иде. Урман авызында быел гына институт бетереп кайткан зоотехник кыз курач Тәслимә, каравылчы Борһани бабай, төн кунарга берничә кызкыркын гына калган иде. Алар да төрлесе төрле якка таралышканнар. Урман авызында кемдер өзелеп җыр суза, шунда ук учак дөрли, көндезге көтүдән кайткан ир-ат, тамак туйдыргач, кырын-ярын ятып тәмәке пыскыта.
Аксаклап килүче малайны Тәслимә башта танымады.
— Мөзәкирме дисәм?..
— Мин.
— Нигә болай сонгардың, нәнәм?.. Әтиең көттә-көтте дә бер башы китте.
Әйтмәсәләр дә белә иде, шулай да сорады:
— Әләкси әрчүендәме алар?.. Хәзер барам.
Зәйтүнә, җәйләүдәгеләрнең күзенә бик чалынмаска тырышып, читтәрәк тора иде. Мөзәкиргә тагын ияреп китте. Байтак баргач:
— Сызлыймы бик? Барып җитә алырсыңмы икән? — дип сорады.
— Җитәм. Сызламый, бетте инде. Син кайт, Зәйтүнә!
— Ярар.
Ник бер йомшак сүз ычкынсын Мөзәкирнең теленнән! Ул, шунын өчен әрләнеп-көяләнеп, кузгала башлаган Зәйтүнәне туктатты.
— Зәйтүнә!
— Әү.
Бер-берсенә карашсалар да, куерган эңгер аларның йөзләрен яшерде, ләкин кич шул кадәр тын иде, алар бер-берсенең сулышларын ишетеп тордылар.

— Әйбәт кыз син, Зәйтүнә... Яхшы иптәш...

Кызны малайның сүзләреннән бигрәк калтырап чыккан тавышы тирбәтте, аның күңеле тулды...

Мөзәкирнең теленнән чак кына «матур кыз син, Зәйтүнә!» дигән куркынычлы сүз ычкынмады...

— Сау бул, Зәйтүнә.

Кыз бер мизгел аның кузгалганын көтте, менә үлән чыжтырдап алды. Мөзәкир бер атлады, ике... Зәйтүнә көрсенде, башмакларын салып кулына тотты, ялан аяклап кына кыр өсләп авыл утларына карап элдерде. Мөзәкир шым булды, байтак вакыткача кызның тып-тып аяк тупырдавын ишетеп торды.

Хәлил агай, Мөзәкир килеп йөрмәсен дип әйтеп җибәрсә дә, җәйләүдән ялгызлыгына борчылып чыгып китте. Кыр иркенә чыккач, хайваннарны үз җаена таратып, учакта ут кабызып җибәргәч кенә, борсаланган авыр күңеле беркадәр үз эзенә төште. Әллә ни үпкәләр җай юк, Мөзәкир бераз үз сүзле булса да, эш сөяр, тырыш бала... Тырыш кеше үзенә хас юлны табар әле дип ышана Хәлил агай...

Мөзәкирнең көтүдән баш тартуында ул үзе сәбәпче бит, нигә яшереп торырга?..

Сыерлар, ашаудан туктап, шигәеп башларын күтәрделәр, Хәлил агай учак яктысыннан тизрәк карангыга чыкты, кемдер кыр өсләтеп монда таба атлый иде.

— Әти!

— Килдеңмени, улым? Килергә иткәнсең икән... Ярар.

Малай да ут яктысына керер-кермәстә тукталды.

— Җәйләүгә кагылдыңмы? — диде Хәлил агай, малайның каян килүен чамалап.

— Кердем.

— Туры әлдерәсең калган... Кил учак янынарак. Хәзер чәй кайнатып алырбыз. Ашыйсың киләме?

— Тамак тук. Чәй эчәр идем... Кыр чәе тәмле була ич.

Хәлил агай өчаякка чәйнек элде, текәлеп-текәлеп улына карады.

— Бит-күзләрең кара янган димме? Сугышып йөрмәгәнсеңдер лә, бала?

Мөзәкир, күзен күтәрергә дә куркып, аякларын сузып утырды.

— Учак янында әссе,— дигән булды ул.— Килешли Карабаш чоңгылында су кердем. Чумып киткән идем, тал тамырлары арасында комырыкка эләктем.

— Сак булу кирәк, улым,— диде хафаланып Хәлил агай.— Нык туналган, ахры, син. Канадымы?

— Хәзер авыртмый инде.

Өй хәлләрен сорашпыра торгач, чәй кайнады, утлы көлгә чаж да чож итеп кайнар тамчылар чәчрәде. Мөзәкир калай кружкадан чәй эчеп калды, Хәлил агай көтүне әйләнеп чыгарга китте. Көндезге эсседә борчылган сыерлар хәзер кадалып ашыйлар, бу көтүлеккә төшкәннәренә өченче көн, үлән әйбәт, күпереп тора.

Кабаланмыйча гына, бер-берсен кысташып, чәй эчтеләр. Хәлил агай чәйне һаман солдатча кайната, чәйнеккә карлыган, җиләк яфраклары сала, карлыган чәчәге йөздерә.

Төн җылы...

Күктә сирәк-сирәк кенә төссез йолдызлар.

Җиргә җәелгән кожан өстенә ятып кайнар кружкадан иреннәренне пешерә-пешерә солдат чәе эчү нинди ләззәтле, рәхәт... Малайның күпергән иреннәре сулкылдап-сулкылдап авырталар, әмма йөрәкнең ярсуы кимеде...

Әйләнә-тирәдәге сыерлар кызыктыргыч тәмле итеп курт-курт үлән умыралар, учак тирәсендә кисешә-кисешә аларның күләгәләре кыймылдый... Хәлил агай һич иренмичә учак өстенә вак-төяк чыбык-чабыкларны ыргытып тора, кәкре башлы таяк белән читтә калган сүнгән кисәү очларын сыдырып ут өстенә китерә. Аның сакалы житкән, йөзенә тирән-тирән катлы җыерчыклар тезелешкән, күзләре уйчан-моңсу. Ул, күзләрен кыса-кыса, башын артка тайчандырып утка карап тора, аннан рәхәтләнеп бер җайга гына гел бер җырны суза...

Кара-а-дагы-на-ай урма-а-н... Кара-а-нгы-ы-ый т-өөө-н!..

Мөзәкирнең сызланган тамырларына учак җылысы үтеп керә, ул бармаклардан үрелгән йомшак кул-түшәккә башын куеп иппәп кенә изри, ойый... Юл җәфалары, канлы күзле әзмәверләр, җирәннәр тирәяктагы мәңгелек матурлык алдында тирәнгә, бик тирәнгә чумалар... Рәхәт!.. Дөнья матур, дөнья матур!..

Кемнәрдер мыдыр-мыдыр сөйләшә, ара-тирә көлешеп тә куялар, ләкин йокының кочагы шул хәтле татлы, уянасы, хәтерне-аңны кузгатасы килми... Ул, аяк-кулларын кыймшатырга куркып, йокылы-уяулы килеш байтак кына изрәп ятты.

Калын тавышлы берәү сөйли:

— Хәлил кордаш, шикләнмә, улың Мөнирне институтка колхоз исәбеннән җибәрәбез, күр дә тор.

Калын тавышның «х»сы бераз катырак, Хәлил дигәне «Кәлил» кебегрәк ишетелә.

— Рәхмәт, рәхмәт, Николай Васильевич, зурладың.

— Рәхмәтне, покранимир, бүген сиңа мин әйтергә тиеш... Бурычлымын. Шуңа күрә кердем дә. Туктале димен, кордашны да сөендереп чыгыйм дим. Кермәсәм йокының тәме булмый иде бүген, Хәлил...

— Ярый, ярый... Эшләр әйбәт. Бик әйбәт!

Тагын рәхмәт укышулар, макташулар...

Кинәт аның аяк очында гына машина гәрләде, ут дерт итеп калкынды... «Волга»?.. Машина янына колхоз председателе Степанов баскан... Берәр нәрсә ишетеп килгәнме әллә? Зәйтүнә, песнәк баласы, кайтып сайрадымы?.. Алай дисәң, нигә китәләр алар? Председатель, нидер сөйли-сөйли, әтисенең кулын кысты... Машина авылга таба ыргылды...

Төш түгел лә бу, өн, әнә ич әтисе Мөзәкир янына чүгәләде, аннан кыр исе, учак көле исе, жил исе сизелеп тора... Йокы тәмле, киерелеп яңадан кожан өстенә сузыласы килә...

— Әти, нишләп йөри ул?

— Ә?

— Степанов абыйны әйтәм.

Әтисе, саран гына елмаеп, аның янына килеп чүгәләде.

— Районнан кайта...

— Шулаймыни...

— Безгә премия тия икән.

— Көтүчеләргәме?

— Барыбызга да дип аңладым мин, терлекчеләргә... Сөт буенча ин алга чыкканбыз.

Йолдызлар бөз ватыклары кебек төссезләнделәр, үләннәрне аска бөгеп, кинәт жил исте. Сыерларның байтагы учак тирәли ятканнар, күзләрен йомып тәмләп-тәмләп күшиләр... Бер сансызы шунда гына бәвел чырылдата...

— Әти...

— Туңмыйсыңмы, балам... Йокла, йокла... Хәзер таң йокысы.

— Нигә сез Степанов абый белән дус түгел хәзер? Малай чакта бергә уйнап үстек дисең бит. Нигә ул бер чакта да безнең өйгә керми?

Улының соравы Хәлил агайны бераз уңайсызландырды, ул, учагына сүнәргә ирек биреп, сихерләнгән сыман, утка карап торды.

— Элекке хәлләр бит инде...

— Әти, нигә син көтүче, ул нигә председатель?

Малайның җитдилеге Хәлил аганың күңелен эретте...

— Сөйлә димсең... Алай... Армиядән лейтенант булып кайттым мин. Укып командир булмадым, сугыш иде, күпләр һәлак булды, мин исән калдым. Ни тикле кичергәнсең, хәтәр орышларны кичкәнсең, тәҗрибәң бар, дип лейтенант ясадылар... Эльбагача бардым... Мин кичкән елгаларның исәбе-хисабы юк!.. Берзаман, демобилизациягә эләгеп, туган якларга кайтып төштем... Бүгенгедәй хәтеремдә, җәй башы иде... Беренче көннәрне, куанычтан авыз ачылды, күз йомылды дигәндәй, аны-моны әйләнеп караган булмады... Исән калып, сау-аман илгә кайтуның куанычын мең үлемгә шаһит солдат кына белсә беләдер... Әчмичә исереп, атна буе керфек какмыйча сөйләштек тә сөйләштек... Шулай, хәрби учетка керергә районга барырга җыендым... Сез, малайлар, берегез дә тумаган, Дилә апагыз гына бар. Әткәй мәрхүм, синең бабаң, лейтенант улымны җәяү җибәрмим дип, мең мәшәкать белән ат юнәтеп кайтты. Дилә апаң «мин дә барам» дип үкереп җылый, мин «алыйк үзен» дим... Бабаң әйтә, атны чыгып кара әле, Хәлил, ди... Тарталмас, ди... Эх, улым, улым! Кыш озынына лапас өрлегендә асылынып торган, хәзер дә түбә саламы белән чак тернәкләнгән күтәрәм бияне әйтимме, дүртесе тиң дөньяның дүрт ягына караган, төрлесе төрле дәүмәлектәге кылдый-былдый тәгәрмәчләрне әйтимме, күргәч, ышанырсыңмы, улым, болдырга утырдым да битемне каплап җылап җибәрдем... Дилә апаңны мондый җәһәннәм савытына утыртырга хурландым... Без юлга чыктык. Барабыз, барабыз, узган саен күңелгә шом керә. Ул ташландык кырлар, карарга имәнгеч игенсез-уҗымсыз кысыр басулар... Сугыш, бар афәтен сеңдереп, моннан да үткән икән дим... Әткәй мәрхүм сирәк сакалын учлаган да күтәрелеп тә карамый... «Кияреңә ыштаның барында бар, бар, улым, Хәлил», ди... Барам... Шулчак каршыбызга үгез җиккән, салам төягән олаулар килә. Үгезләрнең муеннары чиләнеп беткән. Гыж-гыж киләләр бичаралар...

Йөкче картларның берсе әткәйнең әшнәсе иде, гөрләп күрештеләр. «Саумысыз, саумысыз, улың кайттымыни?» «Кайтты, алланың рәхмәте». Күрше авыл малае Җәгүр дәдәң... Дөнья куйды инде, мәрхүм, белмим: рәхәтне татыды микән?.. Мин дә моны таныдым, күрештек. Ул чагында безнең колхозлар аерым иде. Әткәй үгезләргә карый да җылый, карый да җылый, җыеп сүзен әйтә алмый... «Бу нинди афәт бу, нинди гарьлек, авылыгызда тәгәрмәч тугымы бөгәрлек кеше калмадымыни, хайваннарыгызны кырып бетерәсез бит!» — ди. Йөкче мари да аңа кушылып җылый... «Юк, ди, тугым бөгүче дә, тимерче дә, самовар төзәтүче дә кайтмадылар, Гитлер кырып бетерде»,— ди. Шул вакыт безнең яннан, тузан туздырып, җиңел машина узды... Төсе дә хәтеремдә, карга канаты кебек кап-кара иде. «Кем узды бу шулай?» дип сорыйм әткәйдән... «Ә, бу теге инде, кем... синең ыштансыз малай чактагы иптәшең Күлә... Николай Васильевич Степанов... РИК председателе...

Район үзәгенә килгәч, иң элек райбашкармага кердем. Степанов янына. «Исәнме-саумы» дип шаулап күтәрелде бу. «Хуш килдең дә хуш килдең... Лейтенант? Орденнар! Өчәү!.. Шәп. Шәп... Котлыйм»,— ди, теге-бу. Аз-маз аңгәмәләштек тә, мин моңа баягыны китереп чыгардым. «Минем яннан узды́ң ич син, әллә күрмәдеңме?» дим. Юк ди, күрмәгән. Салам сөйрәүче тәмуг үгезләрен дә абайламадыңмы, дим, мин шулар янында басып тора идем, мәйтәм. Тәрәзәдән карыйм, ишек алдында ялтыр-йолтыр килеп теге машина тора. Немецлардан байтак

алдык без аларны... Аны-моны сөйләшкән булып утырабыз, гел теге сүзне китереп чыгарасы килә, чак түзәм... Шуннан бу: «Дәрәҗәңә тиң килерлек сина нинди кулай эш бирик, сайла, синдәй егетләр кирәк безгә!» диде. Мин аңа: «Юлдагы үгезләрне күрмәслек хәлгә җиткәч, ай-һай, мина туры һәм хак юл сайлый алырсыңмы икән?» — дидем. Көлеп торган Коля дустымны җен алыштырдымыни, кара коелды... Үз авылыбызда калмадым, күрше мари колхозына барып балта эшенә тотындым. Инеш янында тырлау бүлеп тугым бөктем, арба букәне кырдым, тәртә, араталар ясадым. Чабагачына кадәр юк иде, дистәләп-дистәләп аларын ясадык... Барына өйрәндем!.. Кеше көченең чиксезлеген сугышта гына күреп була дип йөри идем, әй, улым, сугыштан соңгы елларда кешенең тиңсезлеген дә күрдек!.. Эшләр акрын гына җайга салына торды, бәхетсезлек килде мина... Диләнкәдә каен кисләндә бүрәнә астында чак калмадым, кул имгәнеп кенә котылдым... Кайтып үзебезгә көтүгә ялландым...

— Ә Степанов абый?

— Аны әйтәсеңме?.. Ул гел күчеп йөрде... Йошкар-Олага да чакырып алдылар, шуннан, колхозлар берләшкәч, безгә председатель булып кайтты. Менә шулай тагын очраштык... Тик ул теге вакытны һаман онытмый, күрәсең.

— Син ул вакытны оныттыңмы? — диде малай кыюсыз гына.

— Сиңа сөйләдем бит, онытмаганмын значыт... Син дә онытма, ата-бабаңныңниләр күргәнен онытырга ярамас. Мондаен рәхәт тормыш, муллык алла кодрәте белән кыктән иңмәде. Кукрәк көче, кан, яшь түгеп, бәхет турында хыялланып ирештек без аңа. Көч салып. Ачыны белмәгән, татлыны бәяли алмас, диләр, хак ул...

— Әти, Степанов абыйга кинә саклыйсыңмы?

— Юк, улым... Рәнҗемим мин аңа. Унган кеше Николай Васильевич, җирне белә, игенчене таный, дуамаллыгы бар барын... Нишлисең, характер кемдә дә бар. Ансыз кешенең сырт сөяге булмый... Я, ярар! Бер әйләним булмаса...

Мөзәкир учакка таяк тыгып күмерләрне калкытты, ашыгып-ашыгып вак-төяк ботак-сатак ыргыткалады.

— Әти,— диде ул, якынаеп килгән атасына йөзен күрсәтмәскә тырышып,— шул чагында районда эшкә калган булсаң, без ни төсле үсәр идек икән?

Әтисе чак кына уйланып торгач:

— Сезне белмим... Тик үземне әйтәм... Керердән алда чыгарыңны, менәрдән алда төшәреңне уйла ди иде әткәй мәрхүм.

Хәлил агайның кайсыбер фикерләре Мөзәкиргә аңлашылып та җитмәде, кайберләрен малай күңеле кабул итмәде, әмма ул бу турыда кыеп әтисе белән ныгытып сөйләшә алмады...

Әнә, таң ата, яктыра... Хәлил агай гел аяк өстендә, әле кыр буйлап йөреп килә, агачлыкка кереп киткән качкын сыерларны өерләп чыгара...

— Әй, улым, улым,— диде ул, йомшак кына әрләп.— Комырыкка чуммагансың син! Сугышып йөргәнсеңдер, наян, күз төпләрең кара янган, битең ярылган, колак төбең сыдырылган... Борыл әле, борыл, чалбар төбең умырылган ич! Әнкәң алама чалбар кигертеп җибәрмәс, чалбар киеп чуммагансыңдыр ла? Кая, сал әле.

— Анысын аның... эт тешләде.

— Маҗаралы юлга тап булгансың икән,— диде әтисе, чалбарны таза, кара җеп белән ямый-ямый.— Яраларына бал сөртергә кирәк. Суган пешереп капларбыз...

— Тал тамырына эләктем.— диде малай, киреләнеп.— Аның нәрсәсен алдыйсың?

Хәлил агай башын чайкады, күрсенде...

## 16

Әхәтнең бер гадәте бар: берәү белән мавыкканда башка дус-ишләрен тәмам онытып тора. Диләне озаткан кичтән бирле аның күңеле гел Идрискә тартылып йөдәтте. Башта Әхәтнең Идрис квартирасында бераз шаяргалап алу максаты бар иде, ул теләгенең булып чыкмаслыгына төшенгәч тә, һаман Идристән аерылып китә алмый азапланды. Әхәттә янача кызыксыну туды: минемчә булырга теләмисең икән, димәк, син башкача яшисең!.. Ләкин ничек яшисең? Һәм нигә минемчә булырга теләмисең?

Синме акыллырак, минме?..

Моңарчы сүздә дә, эштә дә гел өстенлек тоеп килгән Әхәт чак кына икеләнеп калды. Дөрес, ул Идриснең беркатлы сафлыгына ышанмады. Ничек инде, егерменче гасырның алтмыш җиденче елында шундый кадим фикерләр белән яшәргә мөмкин?..

Әхәтнең сынаулары сабын куыгы кебек бер-бер артлы шартлап ярылып тордылар. Идрис төшке аш вакытында коры шәраптән баш тартты, кичен, әллә нинди кызыктыргыч сәяхәтләр тәкъдим итсәң дә, тиз үк өенә сызды. Иң гаҗәбе шул иде. Әхәт аны эзләп барганда Идрисне бер чакта да өендә туры китерә алмады...

Идрис югалып тора икән, аның сере бар дигәнне раслый түгелме?

Әхәткә ашарга-эчәргә бирмә, берәүнең сере бар диген, егетең кызыксынып дөнья читенә китәчәк!..

Бүген якшәмбе...

Башка вакытларда атна башында ук Әхәтнең якшәмбе ялы планы өлгергән була иде, бүген ул буш... Шуңа күрә торды да... тагын Идрисләргә барасы итте. Бүлмәсенә шыпырт кына басып керергә дә җәймәсен тартып төшереп уятырга кирәк...

Әнисе кычкырып калды:

— Чәй дә эчмисеңмени?

Эчмәде. Идрис белән берәр кая сугылырлар әле. Я Аккош күленә «Каенсар»га китәрләр, я Левченко поселогы янындагы урманга сугылырлар. Бүген дә Идрисне сөйрәп чыгарга хәйләсе җитмәсә, Әхәтнең егетлеге корысын!..

Капка төбендә Әхәтнең кордашы, хан заманында өйләнеп ике бала атасы булырга өлгергән Борис очрады. Кызын җитәкләп мактанып йөргән була!..

Әхәтнең бераз мутлыгы барын беләләр. Борис та төрттерде:

— Кая кузгалды бүген Әхәт? Иске сукмакларданмы? — дип көлде.

— Бүген — билгесезлеккә! — диде ул каш сикертеп, авызын мыймылдатып.

Аның клоун кыяфәтеннән Борисның кызы матур итеп көлде...

Бусы да бик сәер килеп чыкты: Ленин районына барырга дип чыккан Әхәт һәйбәтләп кенә Бауман районына баручы дүртенче троллейбуска кереп китте. Халык, халык! Кая агыла икән шушы кадәр халык. Әхәтне төрле яктан китереп кыстылар, шунда аның уң ягында тәбәнәгрәк, агач аяклы кеше пәйда булды.. Әхәт аның иңбашыннан сөеп:

— Кайгырма, коллега, Ватан чакырса без үзебезнең агач аякларыбыз белән Берлингача тагын барып җитәрбез,— диде. Исләре китеп тәрәзәгә йотылган урта рәтләрдәге яшьләр, кемнәрнедер кысып-этеп, аларның икесенә дә урын бирделәр. Әхәт, бер аягын туры катырып,

уфылдап инвалид белән янәшә кукыраеп утырды. Шунда гына үзенең Бишбалта дамбасында бөтенләй кирәкмәгән якка баруын чамалап көлеп куйды.

— Син кайсы фронтта булдың? — диде аксак.

— Төньякта... Аннан Ерак Көнчыгышта, Квантун маймулларын кырдым,— диде Әхәт, хәтәр генә.

Вагонда гаҗәп сылу бер кыз бара иде. Әхәт тәҗрибәле күз белән шундук аңа йотылды һәм үзенең адашып шушында килеп керүенә чын күңеленнән сөенде. Мондый чибәр туташлар вагон саен утырып йөрмиләр!..

Кыз сүз белән аңлатып булмый торган дәрәҗәдә нәфис, сылу иде. Егет юл буе керфек тә какмыйча аңа табынып, күңеленнән генә сәҗдә кылып килде. Кыз Спорт сарае туктагышында ишеккә бара башлагач, Әхәт, үзенең агач аягын онытып, халыкны ера-ера аның артыннан чыгарга атлады. Гел кирәге булмаса да, шунда төшеп калды. Аның шәп кенә сикереп төшүен күреп, кыз:

— Аягыгыз авыртса? — дип сорады.

— Авыртмый!

— Сез инвалид түгелмени?

— Репетиция. Мин артист...

Кыз телефон будкасы янына барып басты да янадан эндәшмәде.

Әхәт аның янына кыю гына килеп, читенсенмичә туп-туры кызга челәеп карап торды. Кыз, уңайсызланып, урамның икенче ягына чыгарга теләде, Әхәт аның юлына аркылы төште.

— Рәхмәт сезгә, зур рәхмәт,— диде ул, дулкынланып.

— Ни өчен? Троллейбуста урын биргән өченме?

— Бүгенге иртәмне бизәгән өчен... Матур йөз — табигать-рәссамның иң гүзәл казанышы. Ни өчен адәм баласы гүзәл сыннарны, илһамлы илаһи йөзләрне музейларга гына барып карарга тиеш?.. Менә сез... Я, хода!.. Юл буе сездән күз ала алмадым... Шушы матурлыгыгызны бәяләрлек һәм кадерләп тотарлык пар табылсын!

Сылу кызарынды, әмма елмайды...

Ләкин бу яшь, сабыйлыктан яңа гына чыккан матурлык алдында Әхәт саф була белде:

— Гүзәллегегез алдында чал башымны иям! — дип, дулкынланудан аксаклый-аксаклый трамвайга сикереп менде, вокзалга кадәр барды. Күңеле тулды егетнең: үзен бер изге, нечкә күңелле саф кеше дип тапты ул.

Матбугат йортына кадәр җәяү генә барды. Болак күпере өстеннән яңа цирк төзелешенә, аның сәер силуэтына карап торды. «Чыршыкай»-га кагылды, ләкин анда төче-мәчеләрдән, баллы-буяулы шәраплардан башка бернәрсә дә юк иде.

Китап кибете янында беренче троллейбуска утырды, тәрәзә янына кысылып урын алды. Кремль туктагышында вагонга Тәүфыйк керде. Кемне-кемне, әмма бу елтыр күзлене, кызлар тәкәсен очратасы килми иде Әхәтнең. Әле генә шундый илаһи матурлыкка тап булып күзеңә яшьләр килсен дә каршыңа шул килеп чыксын! Тьфу!.. Лида шуны ничек ярата алды икән?!

Соңгы вакытларда алар Тәүфыйк белән сирәк күрешәләр. Ул башы-аягы белән диссертациясенә чумган. Очрашуга, иң элек пиджак төймәнне эләктереп ала да, Габдулланың бавыры, Иванның бәвел капчыгы турында сөйләргә тотына... Кешене кисәкләргә турагач, аның нинди матурлыгы калсын?..

Бәлки Лида турында гайбәт кузгалудан куркып кына Тәүфыйк янына бармагандыр ул бүген?

Лиданы хәтеренә төшергәч, Әхәт Тәүфыйктан тагын да тырышыбрак яшеренде. Соңгы кат Идрисләрдә уздырган кичтән соң аның күне-

ләндә ул кызга карата якынлыкмы, хөрмәтме, әлегә ачыкланмаган янәчарак хис туды. Лиданы озатып кайткач, ул, яшь егетләр сыман тынгысызланып, йокысыз аунап төн чыкты... Мәхәббәт дип әйтергә ашыкмый Әхәт, ул гыйшык-гашрәт эшләренә ышанып та бетми. Яңа заман яңа кешеләр әзерли, яңа кешеләр яңа мөнәсәбәтләр тудыралар...

Троллейбуста халык ишлелегенә куанып, чит күзләрдән качып Әхәт акрын гына Идрисләргә таба бара бирде...

«Нарат урманы»на җитәрәк, ул сискәнеп китте: тәрәзәгә борыны белән терәлеп бара иде, тукталышта торучы Лида белән күзмә-күз очраштылар. Кыз да агарынып катты. Тәүфыйк ачык ишектән кул изәде:

— Монда, монда, Лида, кер!

Лида Тәүфыйкны көтеп торган икән, тегесе тукталышта төшеп тә тормый, калай әтәч, кул болгап кына чакыра! Кыз керде, алар ягымлы гына күрештеләр. Лида Әхәткә арты белән басты да аны күрүен Тәүфыйкка белдермәде.

Әхәт әле иңен уйната, әле сикереп торып алга иелә, артына борылып карый... Караган саен Тәүфыйкның шома каралҗым яңакларын, батынкы чокырлы, алгарак чыгып торган ияген күреп ала... Көлә, явыз!.. Троллейбусны янгыратып көлеп җибәрә!..

Ни булды, Әхәт көнләшеп маташамы әллә югыйсә?.. Чираттагы тукталышта сикереп төшеп калырдай булды, аягы тартмады. «Кая барырлар, нишләрләр?» дигән кызыксыну корты егетнең горурлыгын җиңде.

Лида белән Тәүфыйк Воровский тукталышында төштеләр, Әхәт тә алгы ишеккә ташланды, керүчеләрдән ләгънәт сүзләре ишетә-ишетә чыгып калды һәм газета витринасы артына посты. Лида аны төшәр дип уйламады, борылып та карамады, гөнаһсыз күзләре белән елмаеп Тәүфыйкка карады.

— Ник чакырдың, Тәүфыйк? Кая барабыз?

— Мин тамакка ашамаган. Кафега кереп белешеп чыгыйммы?

Ул «Көз» кафесының ишегенә кереп югалуга Әхәтнең витрина артыннан атылып чыгасы, кызны җитәкләп, җилтерәтеп шушы кеше явыннан алып ычкынасы килде. Я, ходавәндәм, көнләшәме әллә? Кызга ачуланды, үпкәләде, җене котырып йодрыкларын йомарлады, әмма витрина артыннан чыкмады...

Тәүфыйк бер чакта да кафе-рестораннарга кыз-хатын ияртеп керми, иң әлек позицияне ачыклый, тиешсез кешеләр юклыгын күзәтә, урын сайлый. Бүген барып керүенә ап-ак чәчле, нечкә билле, өске күз кабагын сыерчык канаты күк каралткан официантка аңа кул болгады:

— Толик, ник югалдың!.. Дачаңа кайчан барабыз!

— Кызыл кар яугач! — диде ул кемнедер эзләгән булып һәм шундук борылып чыкты.— Монда ярамый... Юньле ашар әйбер юк...

— Кирәсем дә килми,— диде кыз, тынычландырып.— Әгәр ашар өчен генә чакырган булсаң, рәхмәт.

(Аларның бөтен сүзләре Әхәткә ап-ачык ишетелә.)

— Ач карыннан җитди сүз сөйләшеп буламы? Төшеп каласы түгел иде.

— Төшик диден, Тәүфыйк.

— Капкалагач безгә китәрбезме әллә дигән идем.— Ул олы эш башларга җыенган кеше сыман гаҗәп җитди иде.— Төш вакытында бер иптәш кайта... Шуңа кадәр мин буш...

— Тәүфыйк, ул иптәшең хатын-кызмы?

— Сиңа барыбер түгелмени, бәхет валчыгым?

(Тәрҗемәче! дип теш шыкырдатты Әхәт, «крошканы» татарчалый янәсе! Агач авыз!)

— Берсекөнгә имтиханым, Тәүфыйк... Мин урманга чыгабыз дип торам, китапларымны да алдым.

— Укырга өлгерерсең,— диде төксе генә Тәүфыйк.— Сагындым... Я, сайла, өйгә кайтабызмы? «Маяк»ка барабызмы?

«Нигә төкеренеп китеп бармый,— дип изаланды Әхәт.— Шунлык та горурлыгы юкмыни?..»

Телепатия диләр, еsettled торып кешегә тәэсир итеп була диләр, бөтен дөнья сноблары шуның белән җенләнә, әгәр рас икән, газета витринасының икенче ягында гына янәшә басып торган Әхәтнең янып-көюен сизмәс идеме кыз?! Әнә ич, туфлясының очлы башлары күренеп-күренеп китә, әллә чүер таш алып башмагына саласы инде?

Тәүфыйк үгетләргә үк тотынды, Әхәтнең эченә җылы керде, күп төрле юллар сайлагач, алар, ниһаять, шушында Ленин районы бакчасыннан гына әйләнеп чыгарга килештеләр.

Парлашып алар бара, алар артыннан, кешеләр арасына кача-поса, Әхәт тә китте.

Ул үз хәленең яман эшәке икәнен дә, түбәнлек икәнен дә сизенде, әмма акылын томалап билгән үҗәтлек хисе, нык ышлык аны алар артыннан әйдәде. Монда ул аңламаган берничә ваклык бар иде: беренчедән, нигә Лида аны күрмәмешкә салышты?.. Нигә аның турында Тәүфыйкка әләкләмәде?.. Икенчедән, Тәүфыйк үзе үк «Лида белән араларны өздек, күрешмибез» дигән иде ич...

Лида исә елдан артык күрешми торган иске танышын очратуга шатланмады. Урамда очраклы гына туры килештеләр, Лида иптәш кызлары белән кинодан чыккан, Тәүфыйк ялгызы гына иде. Иптәш кызлары алдында шушындый чибәр егет белән мөнәсәбәте өзелгәнен күрсәтәсе килмәдеме, әллә кинодан соң күңеле уйнап тора идеме, егет, «күрешик» дигәч, карышырга дип ачылган авызы ризалык бирде дә куйды.

Әмма бүген ресторанга бармаска, квартирадан бөтенләй баш тартырга ныклыгы житте, малаең үзе юаш кәҗә бәрәне күк ияреп бара! Кунак килә, фәлән дип алдан ук үгекләп куюын кара син, өйрәнгән үз көен генә көйләргә... Бик күтәрмә борынынны, Лида бүген барын да үзенчә эшләргә дип килде...

— Төкселәнден, Тәүфыйк...

— Корымга манчылып, комда аунасымны белеп алдан ук куаныйммы?

Тәүфыйк ТЭЦ трубаларыннан бөркелеп-бөркелеп торган кара-соры болытларга ишарәләде.

— Казанның кара чатыры!.. Нишлисең, ансыз да булмый...

— Хурлыгы диген...

— Мин синең янда ич,— диде Лида, юри уенчакланып.— Шул азмы сиңа?

Паркка барып керделәр. Көн иртәдән чалт аяз булып торса да, хәзер жирне күләгәләп-күләгәләп дәү-дәү болыт юрганнары тирбәлеп уза. Бакча буш диярлек, көрән алъяпкыч япкан апа себеркесен болгый-болгый соскысына кәгазь-мәгазьләрне тутыра.

— Килдек. Күрдек. Утырып жылашабызмы? — диде Тәүфыйк.

— Әле бу башы гына. Эчтәрәк тын урыннар, агачлыклар бар. Утырып ял итик, сөйләшик.

— Ашап аласы иде.

— Корсак колы булма. Болай да түгәрәкләнеп киләсең.

— Кая, моны да күпсенсән,— диде Тәүфыйк, корсагын сыпыргалап.— Кандидат кешегә аз-маз түгәрәклек гәнаһ түгелдер?

— Әле син кандидат түгел.

— Һич югында сыра эчәсе иде.

Тәүфыйкның сөйләшер сүзе дә, теләге дә юк иде, шуңа күрә ул нәрсә булса да эшләргә, хәрәкәт итәргә кирәклеген чамалап сыра эчәргә димләде.

— Тамак яна януын... Әнкәй бүген пәрәмәч пешергән иде.

— Кызыктырып үтермә,— дип ялынды Тәүфыйк.

Ике палаткага кагылдылар, сыра килеп җитмәгән, көтәбез, диделәр. Әхәт, бер адым калмыйча, алар артыннан күзәтеп барды. Шулай йөри-йөри балалар почмагына килеп чыктылар. Монда да халык аз, тир янында өч-дүрт үсмер аның ачылганын көтәләр. Тәүфыйкның әдәплелек түземе шушында чигенә чыкты:

— Я,— диде ул буш таганнарны күрсәтеп,— бәлки син миңа бүген таган атынырга да кушарсың?

— Зарары булмас! — диде канатланып кыз.— Әйдә, атыныйк бер! Карусельдә әйләник... Кеше төсле ял итик, кеше төсле яшик. Нигә гел-гел мине җәмгыятьтән алып качарга тырышасың? Яле!

Ул, уенчакланып, китапларын Тәүфыйкка тоттырды да көлә-көлә нәниләр мәйданчыгына кереп китте, таганнарны этеп-этеп җибәрде, кулларын аккош канаты күк селкә-селкә бүрәнә өсләп узды, аммиак исе килеп торган, буяулары купшакланган агач крейсер өстенә менде.

— Ничек, рәхәтме? — дип кычкырды аңа Тәүфыйк.

— Искиткеч,— диде Лида, битен җилгә куйган булып.— Дулкыннар, дулкыннар! Әй, егет, кил монда!..

Тәүфыйк башын чайкады, кыз сикереп төшеп аны куып җитте, җитәкләде:

— Әйдә, карусельдә әйләнәбез!

Ул, аны әйди-әйди, касса алдында утыручы хатыннар янына алып килде дә:

— Карусель эшлиме? — дип сорады.

— Унбердә ачабыз,— диде хатыннарның берсе.— Ике-өч кеше өчен аны кузгатып булмый...

— Әнә самолетка утырыгыз,— диде юантык икенче хатын.

— Самолетка утырырга каршы килмәссең бәлки, әфәндем,— диде Лида кыланып, чырык-чырык көлә-көлә.— Сезнең югары дәрәҗәгезгә тап төшерməмe?

Лиданың шук кызчык кебек арлы-бирле чабуына, кирәкле-кирәксезгә шаркылдавына, Тәүфыйкның исә ачуташ капкан кебек җимерелеп йөрүенә халык җыелуын көтеп касса алдында утыручы атракцион хезмәткәрләре дә игътибар иттеләр.

Берәрсенә утырмыйча бу бәйләнчек кыздан котылып булмаслыгын төшенгән Тәүфыйк «Самолет»ларның үз абруена тап төшермәслек бердән-бер нәмәрсә икәнлеген аңлады. Сабыйлар белән рәттән карусельга агач атка атланып булмас инде!

— Утырсак утырыйк,— диде Тәүфыйк, кесәсеннән вак акча эзләп.

Кеше-кара югында утырып калырга кирәк иде. Лида шаяртып кына аның кул сыртына астан китереп сукты, егерме тиен көмеш һавага очып китте, кыз иелеп аны эзләп алды, касса алдындагы хатыннар бер-берсенә карашып баш чайкадылар.

— Син «Кожедуб», мин «Чкалов»! — дип кычкырды кыз шул исемдәге самолетларны күрсәтеп. Сикереп кенә менеп китмәкче иде, таеп егылды, җиргә ятса да, һаман шаркылдады, Тәүфыйк аны күтәреп торгызды.

— Җеннәр кытыклыймы әллә сине, кызчык?! — дип, Лидага самолетка менәргә булышты.

Атракцион хуҗасы юантык ханым аларга карап тора иде.

Тәүфыйк чигәсенә бармагын терәп, «шөрепләре бушаган!» дигән ишарәне ясап күрсәтте.

Тәүфыйк Лида артындагы самолетка менгәч, юантык хатын, моторны тоташтырып, баягы иптәшләре янына китеп барды.

Әхәт куак артыннан боларның барын да күреп, мыегына чорный торды. Уң ягында бәләкәй кафе, яшеренергә җай житәрлек. Менә кафе алдына алгы тәрәзәсенә кызыл хач төшерелгән «Москвич» килеп туктады. Кызыл хачка күзе төшкәч, Әхәт дерт итеп куйды: таптым! дип пышылдады... Аны-моны исәпләп тормады, туп-туры касса янына чапты һәм, юантык ханымга бармагы белән төртеп күрсәтеп:

— Сез ни эшләдегез! — дип кычкырды.

Аның кискен, эшлекле кыяфәте, яман куркыныч аерылган кашлары иркенәеп кенә утырган хатыннарны куркуга төшерде.

— Ни бар, ни бар? — диде хатын, шомланып. Учындагы көнбагышлары итәгенә шыбыр-шыбыр коелды.

— Кемне утырттыгыз самолетларга?

— Без паспорт тикшермибез,— диде хатын тупас кына.

— Мин психбольницадан,— диде Әхәт, кесәсенә бер-ике тапкыр шапылдатып.— Әнә безнең машина!.. Бу ир белән кыз бүген иртән генә психбольницадан качтылар.

Тирә-яктагылар берәм-берәм тая ук башлады. Самолетка утырткан дежурныйның йөзе кумгәкләнде, ул, бот чабып:

— Менә бәла, менә бәла! Утыртмаска да келәгән идем бит... Менә бәла! Күзләрендә акыл нуры юк, кыланышларында мөрәвәт беткән... Сизенде күңелем, кулым егерме тиенгә үрелде!..

Хатынның буасы ерылганын күреп, Әхәт аны туктатты:

— Без шофер белән икәү аларны алып китә алмыйбыз... Күрәм, сездән дә ярдәм аз! Монда белә белеп эшләгәндә генә... Өянәкләре башланса, барыбызны харап итәрләр... Мин иптәшләрне алырга китәм, сез аларны, зинһар, самолеттан төшермәгез!

Ул тагын кесәсенә шап итеп сукты һәм хәтәр генә борылып:

— Сез — җавап бирәсез! Карагыз! — дип янады.

— Җиргә кадалсалар? — диде аның артыннан теркелдәп юан хатын.

— Үләселәре килмәс,— дип көлемсерәде Әхәт.

«Кызыл хач»лы машинаның шоферы ул арада папирос алып чыкты, Әхәт йөгереп барып аның янәшәсенә кереп утырды. Шофер фырт кына аңа карады.

— Мин редакциядән,— диде Әхәт, тагын кесәсен шапылдатып.— Ашыгыч эш бар! Троллейбуска кадәр алып чыгыгыз әле!

— Ярар...

Машина кузгалгач ул көлүен учына яшереп пырхылдады, трамвай тукталышында төште һәм борылып җан-фәрманга балалар почмагына йомылды...

Очу Лидага бик кызык, бик мәзәк тоелды. Шактый калынайган Тәүфыйкның уңайсызланып, аякларын бөкләп самолетка чак сыешып утыруын күргәч үк күтәрелгән күңеле гел уйнап, гел очынып торды. Нәни генә булса да җинү бит бу!.. Моңарчы да әйт дигәнгә, тәйт дип няреп йөрелгән... Утыр әле бер Лида кушканча, оч!.. Ул, борылып карап, чырык-чырык көлде, кул селкеде, егетнең дә бераз йөзе ачылды... Атракционнан соң бераз капкаларлар да өйгә кайтып китәрләр...

Шулай бер-берсенә шук сүзләр сибә-сибә, чыркылдашып байтак кына әйләнделәр дә алҗып тындылар. Тәүфыйк бу мәгънәсез очудан туеп тирә-ягына караштырса да, касса алдында да, якында да кешемазар күзгә чалынмады. Иске агач крейсерда гына ике-өч малай тә-тә-тә сугышлы уйнап маташалар. Атракцион, билгеле вакыттан соң, үзе тукталырга тиештер бит, әллә механизмы бозылганмы?.. Лида да көлүдән туктады, агарынып башын иде...

«Кожедуб» белән «Чкалов» тавышсыз-тынсыз һаман әйләнәләр дә әйләнәләр. Выжт-выжт... Выжт-выжт!..

— Тәүфыйк! — дип кычкырды кыз.

— Оныттылар безне, Лида...

— Баш әйләнә,— диде кыз.

Байтак тинтерәгәч, Лида, хәлсезләнеп, түше белән самолетка ятты, куркышыды, кул яулыгы белән авызын каплап косты да... Тәүфыйк калтырынып якын-тирәдән сүз катарлык өлкән кеше эзләде, менә куаклар арасыннан баягы хатынның зәңгәр халаты күренеп китте.

— Туктатыгыз, туктат! — дип акырды ул аңа.

Бакча эченнән ике-өч егет йөгереп чыктылар, тик дежурный аларның юлына төшеп нидер аңлата башлады.

Әлбәттә, тәвәккәл кешегә бу самолеттан сикереп төшү бернәрсә дә түгел иде, әмма Тәүфыйкта анлык гайрәт тә, куәт тә юк иде...

Тавыш, ыгы-зыгыга килгән милиционерлар психбольницага шалтыраттылар, «самолет»ларны туктатканда Лида белән Тәүфыйк һуштан язар хәлгә җиткәннәр иде.

Әхәт үзенең бик куркыныч эш уйлап чыгаруын байтактан аңлаган иде инде. Башта ул качарга, беркемгә дә күренмичә юк булырга теләде...

Поса-кача сукмак буйлап бара башлаган иде, Идрис белән каракаршы очрашып шып туктады. Идрис янында биш-алты яшьлек малай да бар иде. Бөтен кеше йөгергәч, алар да «әкәмәт хәл»не карарга балалар почмагына ашыгалар иде.

— Нидер булган анда! — диде Идрис Әхәткә.

— Вак-төяк...

— Шулай да?

— Искитәрлек нәрсә юк...

Дежурный хатын ни арада Әхәтне күреп өлгергәндер, кычкыракычкыра алар янына килде:

— Менә ул! Менә ул!

— Кем? — дип сорады милиционер.

Качып китүдән мәгънә юк иде, Әхәт бәлага дучар булып әле җирдән калкына алмаган Тәүфыйк белән Лида янына килде. Лида күзләрен ачты һәм:

— Әхәт?.. Идрис абый? — дип җылап җибәрде.

## 17

Лида милиционерга бер сүз дә әйтмәде, Тәүфыйк исә өс-башын ызрак рәткә китерүгә, бармакларын бөкли-бөкли сөйләргә керешә...

Кыз беркемгә дә күтәрелеп карамыйча халык арасыннан чыгып йөгерде. Әхәтне милиция бүлегенә алып китәргә булдылар. Тәүфыйк Идрис янына килеп:

— Ахмак Бишбалта батырын моңарчы кешегә чутлап йөри идем, ике аягын бер балакка тыгам хәзер! — дип бик каты янады.

Ике милиционер арасына баскан Әхәт тә Идрискә борылды:

— Өйгә шалтырат... Мине командировкада диярсең... Шефка аңлатырга тырыш. Хәер, анысын үзем сәфәрдән кайткач...

— Чыннан да синең катнашың бармы, Әхәт? — диде гаҗәпләнеп Идрис.

— Аңлау да, аңлату да кыен аны, картлач. Салют!

— Аңлатырбыз,— диде усал елмаеп милиционер.— Атла, әйдә, атла!..

Айдар боларның барын да бик кызыксынып тыңлап, Идристән бер адым да калмыйча ияреп йөрде.

— Син бу хулиган абыйларны каян белдең? — диде ул Әхәтне алып киткәч.

— Очраштык,— диде Идрис таркау гына.

— Ай-яй тегесе куркыныч...

— Кайсысы?

— Милиция эләктергәне. Гангстерга охшаган... Аның пестигы да бардыр, мөгаен...

— Пестигы юк... Әмма кайсысы гангстерга ныграк тартымдыр, монысын әйтү кыен!

Бакчада кәеф-сафа чигеп йөрүчеләр шушы почмакка килеп бөялделәр. Моңарчы песи кебек кенә йөргән юантык ханым көннең батырына әверелде, ул күз ачып йомганчы булып узганнарның биш-алты вариантын иҗат итте, Әхәтне явыз бандит ясады, аны тотканда күрсәткән геройлыгын катлый-катлый сөйләде.

Карусель, самолет тирәсенә бала-чагадан, олылардан озын-озын чират тезелде. Бу шау-шулы, хәрәкәтчән чиратта торуы үзе бер тамаша иде, тик Идрис Айдарны карусельгә керткәндә ал-сары яллы, зәңгәр койрыклы хәтәр бахбайларны үткенрәк, олырак малайлар иярләп бетергән иде, аңа сытык кызлар янына урындык-күпергә утырырга туры килде. Шулай да карусель аңа искиткеч ошады, рәттән ике чират әйләнде. Икенчесендә иң хәтәр, ялы дингез дулкыны кебек каерылып торган, борын тишекләрен йодрык кадәр киергән кызыл айгырга менеп алды. Айдарның башы күккә тиде, ул, Чапай булып кулын селки-селки, «әй-әй!» дип кычкыра-кычкыра, Идрис яныннан выжылдап уза торды...

Аннан таганда атындылар.

Икесенең дә таганда беренче атынулары булгангамы, башта, ватык сәгать теле кебек, туктар-туктамас селкенгәннәр иде, бер заман кызып киттеләр, җир-күк буталды, аяк астындагы кешеләр әле бер якка, әле икенчегә таба ургылып киттеләр, колак төбендә җил сызгырды.

— Норма! Во! — дип кычкырды малай авызын җыя алмыйча.

— Бик рәхәт,— дип ризалашты Идрис.

«Менә бу малай әтисе янында ничек батыр!» дип, тирә-якта җылак кызларын җитәкләгән эби-чәбиләр аларга кызыгып карап тордылар.

Аннан парк участогындагы кафега керделәр, бик шәп кайнар пәрәмәч белән икешәр чынаяк чәй сорадылар. Буфетчы хатын да:

— Улыгыз бигрәк сөйкемле икән... Әтисе бигрәк ярата икән бу малайны,— дия-дия, чәйне куе итеп, шикәрне мул салып ясады.

Кафедан чыккач Айдар азрак ышкынып торды да:

— Абый, синең акчаң калдымы? — дип сорады.

— Кассир буласың киләме?

— Болай гына,— диде малай, читенсенеп.

Паркның тимер юлга таба башында стадионда футбол уены бара икән, шуңа хас гөрелтене ишетеп барып керделәр.

Завод командалары ярыша. Зуп-зур стадионның муртаеп беткән такта утыргычларында, җәйге кичтә телефон чыбыкларына тезелешкән карлыгачлар кебек, байтак кеше утырышкан. Уен шактый сүлпән барса да, тамашачылар таныш уенчыларын чын күңелдән кызыксынып карыйлар. Командалар регби уенындагы кебек унарлап өелешәләр, көрмәкләшәләр, туп капка янына таба бөтенләй тәгәрәми, я бер кырыйга чыга, я икенче янга кача. Капкачыларга рәхәт, яннарында чуалган малайларның учыннан көнбагыш алып чарт-чорт шуны яралар. Башка мазалары юк!

Айдар тик кенә утыра алмый. Уенны карап ялыкты да үрмәләп өске эскәмияләргә менеп китте, үзе кебегрәк бер малайның картузын йолкып алып йөгерешчеләр сукмагына ыргытты. Китте җылаш...

— Өеңә илтермен дә куярмын,— диде Идрис, ачуланып.
— Кайтмыйк,— диде Айдар, үзе җылак малайны үртәп телен чыгарды.
Футболчыларны, паркны калдырып урамга чыктылар. Капка төбендә өч-дүрт тартмадан мороженое саталар.
— Сыйланасыңмы? — диде Идрис.
— Юк.
Үзенең ашыйсы килүе ап-ачык иде, мороженое тоткан малай-салай күренгәндә борыла-борыла кызыгып калды.
— Син миңа нинди мороженое алырга теләгән идең? «Эскимо»мы?
— Нindине телисең.
— Алма син аны, акча гына бир.
Көтелмәгән әрсезлектән Идрис хәтта сызгырып җибәрде:
— Ну, малай... Нәрсәгә сиңа акча?
— Кирәк.
— Нигә кирәк?
— Әйтмим.
— Нәниләргә акча бирмиләр. Алар аның бәясен дә, дәрәҗәсен дә белмиләр. Акча — уенчык түгел, ул хезмәт белән табыла торган нәрсә.
Малай белән булганда вәгазь укымам дип үзенә-үзе вәгъдә бирсә дә, ул бу юлы тыела алмады. Пәрәмәч сатучы лотогы янында Айдар Идрисне тартып туктатты.
— Асылынма, Айдар. Егет булып бар.
— Өч пәрәмәч ал, абый,— диде малай чак ишетелерлек итеп.
Идрис карулашмады, сораганны сатып алды, малай пәрәмәчләрне иснәде дә кәгазьгә төреп кулына кысып тотты.
— Әйдә, үзебезнең урамга кайтабыз да болынга барабыз,— диде ул, шатланып.
— Монда күңелсезме?
— Анда рәхәтрәк... Шәп! Анда скрипкәчеләр уйный...
— Нинди скрипкәчеләр? Чегәннәрме?
Малай рәхәтләнеп көлде.
— Чикерткәләр... Син аларны яратасыңмы?
— Белмим шул.
— Кызык кеше син! Скрипкәчеләрне яратмыйсың, арысланнарны яратмыйсың.
— Мин алай димәдем.
— Барабызмы соң?.. Шундый шәп сайрыйлар алар!
— Иң элек безнең өйгә кагылырбыз...
Ул иртәнге почтада Диләдән хат-хәбәр юкмы дип өметләнгән иде, хат юк иде, газеталарны алгач, малайның өйне күреп чыгасы килде.
— Керик әле,— дип сорады ул.
Идрис ишек төбендә аңа сокланып карап торды, малай эшлекле төс белән бүлмәне, кухняны әйләнеп чыкты.
— Сезнең өегездән тәмле ис килә,— диде ул.
— Ошаса, кунакка килеп йөрерсең.
— Нигә малаең юк икәнен белдем инде,— диде ул баскычтан төшкәндә.
— Нигә?
— Синең хатының юк. Шуңа...
Үз өйләренә җиткәч, ул күтәрелеп тә карамады, йомылып Идриска артылды, өч пәрәмәчен кысып тотып, такыр кырга үтеп китте.
— Минем хатыным санаторийда,— дип аңлатты Идрис.
— Нишли ул анда?
— Дәвалана.
— Ул усалмы?
— Түгел.

— Сине кыйнамыймы?

— Кыйнамый,— диде көлеп Идрис.

Урамга чыгуга ул җанланды, сикергәләде һәм ашыгырга тотынды. Алар кәҗә житәкләгән бер апаны куып җиттеләр. Малай, апаның ачуын чыгарып, кәҗәне иркәләргә, сөяргә тотынды. Кинәт әрәмәләр өстендә мылтык аткан тавыш яңгырады, кәҗәле хатын шып туктады.

— Әстәгефирулла тәүбә, ахырзаман галәмәтедер бу, көпә-көндез дөнья тынычлыгын алып йөриләр явызлар...

Ул, алга тартылган кәҗәсен аяк терәп тыя-тыя, сукранып туктап калды.

— Кара әле, кара! — дип пышылдады Айдар.

Сул якта алар төнлә күргән алачык тора иде. Төнлә ул зуррак та, куркынычрак та булып күренгән. Иске шифер белән ябылган такта алачык тирәсе төнге кебек үк буш иде.

— Китик, абый,— диде малай, калтырап,— теге сихерче күреп калмасын, малайларны тотып ашый ул.

— Бусын арттырдың, Айдар.

— Әни әйтте.

Алар әрәмәгә таба йөгерделәр. Алачык ишеге ачылды, аннан чатан карт килеп чыкты, ул нәрсәдер әйтеп кычкырды, Айдар тагын да шәбрәк йөгерә башлады, абыйсын да сөйрәде. Бераз баргач, Идрис туктады ба борылды. Июнь кояшы астында җәйрәп яткан шәһәр тын, ыгы-зыгысыз һәм күңелгә үтә ягымлы булып күренде. Шәһәр янында гына шундый аулак, күләгәле алачыкның булуына ышану кыен иде. Анда-санда куак ышыгында ашап-эчеп кәеф-сафа чигүчеләр күзгә чалынды.

— Әйдә, абый,— диде Айдар, аны ашыктырып.

Сискәндереп тагын мылтык шартлады, бу юлы якында гына, әнә генә. Теш шыгырдаткандай ямьсез тавышлар чыгарып саесканнар фыр итеп күтәрелделәр. Агач арасыннан ике-өч җир буе баргач, Айдар кинәт юкка чыкты. Саесканнар санап барган Идрис качкан малайны эзләде:

— Чык, чык, Айдар! Барыбер табам!

Үзе күренмәгән малайның тавышы ишетелде, тавышыннан Идрис үзен дә эзләп тапты. Малай, мүкәләп, куак астында нидер эзли иде.

— Ни эзлисең анда? — диде Идрис, иелеп.

— Монда иде ул, шушында гына иде! — дип малай җылап җибәрде.

— Кем?

— Этем бер иде, Рекс. Аның ике бәләкәче дә шушында иде.

— Бәйдә идемени?

— Түгел.

— Алайса моннан киткәндер.

— Китә алмый ул... Аның арт саны гарип... Аны кемдер сугып сындырган... Ничек китсен ул? Китми, китми... Ул мине ярата иде... Рекс, Рекс! Бәләкәчләр!

Малай, мүкәләп, анда керде, монда тырманды, туктаусыз җылады.

— Җыламыйча эзли аласыңмы?

— Алам.

— Менә шулай. Табарбыз. Ерак китмәгәндер...

Малай аңа ышаныч белән карады.

— Беркөн, әллә кайчан инде, күбәләк куып йөри идем. Рексны күрдем... Башта курыктым. Карасам, ул йөри алмый икән... Мин аны чакырырга тотындым. Рекс, Рекс дим... Ул шатланып өрә дә өрә... Янынарак барсам, ике бәләкәче... Җып-җылы, койрыклары без кебек кенә!

— Пәрәмәчләрне шуларга алдырттыңмы?
— Әһе.
— Шешәләрне дә шуңа урладыңмы?
— Шешәләрне элек кафедан ала идем... Аннан складтан.
— Складка да барып ирешкәнсең икән.
— Аракысы-ние белән алам да аракысын җиргә түгәм... Аннан шешәсен тапшырам. Тик хәзер тәрәзәне бикләделәр, кул сыймый...
Идрис чын күңеленнән этне эзләште, байтак куак төпләрен караштыргач, алҗып, икәүләшеп сукмакка чыгып утырдылар.
Кырыйда гына мылтык аттылар, бу юлы яман тузгынып каргалар күкке күтәрелде.
— Кич тагын киләм,— диде малай, борынын мышкылдатып,— бабыбер табам... Пәрәмәчләрне шушында калдырам, кайтсалар ашарлар.
Шул чак куаклыктан алар янына дүрт үсмер чабып чыкты. Уноч-ундүрт яшьлек малайлар арасында башына белен төсле киң түбәле шакмаклы картуз кигән малай озынлыгы белән аерылып тора иде. Аның кулында һәм бер тәбәнәк сипкелле малайда куш көбәкле ау мылтыклары. Алар чабышып чыктылар да бер-берсен бүлеп:
— Әнә, әнә! — дип акырдылар.
Куак өстеннән канатларын авыр гына җилпеп ике карга очып чыкты, озын малай мылтыгын иңенә терәде, бүксәсен киерде, күзен кысып атып та җибәрде. Каргаларның берсе җиргә мәтәлде, икенчесе яман ачы аваз белән каргылдап кире борылды, дәү, алама канатларын җил-җил кагарга кереште. Малайлар шатланышып агачлыкка ташландылар һәм сипкелле борын әле җан да биреп өлгермәгән карганы тотып чыкты. Карга гыжылдый, аның җир казый-казый агарган томшыгыннан кып-кызыл куе кан тама иде...
Айдар ике куллап Идриска ябышты.
— Нишлисез сез? — диде чәчрәп Идрис.
Канлы җиңеш тантаналарына чит кеше килеп кысылуны үсмерләр һич өнәмәделәр, ерык дүрт авыз шундук җыелды, алар куш йодрык чебек дүртесе бергә йомарландылар да нурсыз күзләрен челәйтеп ир белән малайга карадылар. Идриснең дәү, нык гәүдәсе калтырап китте. Ул, аякларын киң ерып, алар алдында басып тора...
— Нигә атасыз аларны?
— Атсак ни булган?
Идриснең үсмерләрне каушатып җибәргән һөҗүм минуты узды, малайлар, икеләнмичә, дошманлыкларын белдерделәр:
— Синекеме әллә алар?
— Карга җәлләгән була...
Айдар абыйсының чалбарын йолыккалады:
— Кайтыйк, абый, кайтыйк...
Сипкелле малай иптәшләреннән алгарак чыкты, аның ак керфекле тонык күзләрендә шәфкать-мәрхәмәт юк иде.
— Аттыр моннан, күсәк! — диде ул.
— Авызыңны үлчәбрәк ач!.. Оятсызлар, үзегез укучылар... Белә торып файдалы кошларны кырасыз. Тирга йөрегез!
Мылтыклы усаллар алдында мондый дәлилләрнең үтә йомшак икәнлеген белсә дә, Идрис кулында сүздән башка корал юк иде, үсмерләр мыскыллы көлемсерәп аны бүлдермичә генә тыңладылар... Карга тырпылдавыннан туктаса да аның канлы борыныннан яшел үләнгә һаман кан тамчылар өзелеп-өзелеп төшә иде.
Малайлар кыймшанып алдылар.
— Нәрсә лыгырдый ул анда! Әй, Чал!
Сипкелле (аның кушаматы Чал иде, ахрысы) карганы ыргытты да мылтыгын алгарак сузды. Иң артта торып, вакыт-вакыт ыштанын күтәргәләгән ябыграк үсмер чәрелдәде:

— Тукмарга кирәк аны, Чал!

— Чиген,— дип кычкырды Идрис, Айдарны артына яшереп.

Ләкин кирәкле момент кулдан ычкынды, үсмерләр бер-берсен усаллыкка өндәп, котыртып өлгерделәр, алар укмашып Идрисне чәйнәп ташларга әзерләр иде. Озын үсмер мылтыгын тезенә сугып сындырды да яңа патроннар тыгып корып алды.

Эш уеннан да, үгеттән дә узып бара иде. Идрис, Айдарны артында тотып, акрын гына чигенә башлады, абынды, иелеп кыска, әмма саллы гына күсәк алды. Хәзер, качкан булып, бер якка ташланырга да күсәк белән мылтыкларын сугып төшерергә... Чал кушаматлы малай мылтыгын күтәрә башлады, аның иптәшләре тонык кына гөрләделәр, Айдар чыр итеп кычкырды, үсмерләр артында нык, каты тавыш яңгырады.

— Туктал!

Алар ялт итеп артка борылдылар, шул вакыт Идрис Айдарны агач артына этеп кертте:

— Пос! Чыкма!

Үсмерләр артында бая алачык янында кычкырып калган карт тора иде. Ул Чал янына килде дә аның мылтыгын тартып алды.

— Бир патроннарыңны. Исемең ничек? Фамилияң? Тиз бул!

Чал, бүре кебек, бер күзен уңга, икенчесен сулга төбәштерсә дә, чалбар кесәсеннән патроннар чыгара башлады. Озын үсмер:

— Нигә бирәсең? — дип акырды.

— Син дә, әй, суз мылтыгыңны!

— Тотмыйсыңмы?

— Уйнап әйтәмме әллә? Суз!

Үсмерләр дәррәү чигенделәр.

— Әтиләрегез белән сөйләшкәнне көтәсезме?

— Минем эти юк,— диде Чал.— Мылтыкны кире бир.

Карт, мылтыкны җайлап кына тотты да, Озынга эндәште:

— Күпме көтәргә була сине? Суз мылтыгыңны! Бир патроннарны! Тизрәк, тизрәк!

Идрис картка ярдәмгә ашыкты:

— Сиңа әйтәләр бит!

Малайлар, төрекөмеш кебек, дүртесе дүрт якка сибелделәр. Карт, мылтыгын төбәп:

— Туктагыз! — дип кычкырды.

Үсмерләр туктамадылар, алар, үзаралай талашып, картка ачыктан-ачык янап, шәһәр ягына сыпырдылар.

— Әниең килсен, мин алачыкта булам! — дип кычкырды ул Чалга.

Җилкәсенә кинәт төртүдән Идрис сискәнеп китте, борылса — Айдар.

— Курыктыңмы? — диде ул, елмаеп.

— Китик,— дип пышылдады малай.— Сихерче бу!

Мылтыклы дүрт хулиган белән бәрелешүгә караганда, бер сихерче белән генә очрашу, әлбәттә, күңеллерәк иде. Идрис малайның җилкә чокырын кашыды:

— Ашыкма...

Үсмерләр алдында каушап калуыннан ул бик нык ояла иде. Карттан да оят, Айдардан да... Типсә тимер өзәрлек, басса бакыр изәрлек агай көчсезлек күрсәтте... Агач аяклы бетәшкән карт тегеләрне боргычлап кына алды бит. Тыннары да чыкмады батырларның, суга төшкән күркәдәй җебеп калдылар...

— Ник бәйләнделәр алар сезгә? — диде карт.

— Кош аталар...

— Ә-ә...

Картның тавышы көр генә, күзләре дә тишеп кергәндәй булып үткен карыйлар...

— Мылтыкны милициягә илтеп бирәсезме?

— Белгән юк...

— Сезгә тынгылык бирмәсләр алар...

— Анысы шиксез... Айдар ни хәлдә соң?

Идриснең күзе дүрт булды:

— Сез аны беләсезмени?

— Безнең урамда кем белми Айдарны?..

Алар өчәүләшеп кайтып баралар иде, исемен атап эндәшсә дә, малай картка җавап бирмәде, аның куркуы әле үтмәгән, карт кулында кылык-җылык килгән кара көпшәле мылтыкка шикләнеп кенә карап бара.

— Килеп чыктылар да мылтык төзәп маташалар,— диде акланыбрак Идрис.

— Әйе, әйе... Хәвефле малайлар! Куркыныч кешеләр!.. Утыра, утыра мин менә мондый фикерләргә дә килләм... Гафу итегез, исемегезне белмим?..

— Идрис.

— Менә, Идрис энекәем, гаҗәп кешеләр очраштыра безнең арада. Әле менә күптән түгел булган хәл: университет доценты төнге уникеләрдә кунакларын озата чыккач, ике кеше тегене имгәтеп китәләр... Чеккән дияр иде, бөтенләй ят кешеләр... Академия театры артистының аркасына билгесез кешеләр пычак кадады... Билгесез кешеләрме инде шулар?.. Юк, болар безнең арадагы дошманнар... Менә әйтик, бу үсмерләр. Бүген карга аталар. Ә бит шулардан кайсы да булса берсенең кайчан да булса бүтән яманлык та эшләп ташлавы мөмкин... Без андыйларга карата рәхимсез булырга тиеш, шулай түгелме?

Картның салмак йөреше җаена атлап алар да иплән кенә киләләр иде, алачык янындагы көчекләрне күргәч, Айдар кычкырып җибәрде:

— Бәләкәчләр! Рекс, Рекс!..

Эт малайны таныды, өреп үзенең бәләкәй дустын сәламләде, карт белән Идрис аларның очрашуларын карап тордылар.

— Бу кунаклар ничек сездә булып чыктылар?

— Алачыкта аларга хәвефсезрәк,— диде карт.

— Пәрәмәчләр тегендә калды,— диде үкенеп Айдар.— Алып килимме?

— Тамаклары тук аларның. Ашаттым.

Бәләкәчләр дә малайны юксынганнар иде, алар йоп-йомшак борыннарын төрткәләп, йөнтәс кәкре тәпиләре белән Айдарны кочарга кыштылар.

— Әле ярый сез килеп чыктыгыз,— диде Идрис.

— Мин бит сезгә кычкырып калдым.

— Без аңламадык...

— Беркөн әтисе белән очрашканнан соң этне монда алып кайттым.

— Бабай,— диде Айдар күтәрелеп.

— Ни әйтерсең?

— Рекс сездә торсынмы?

— Син рөхсәт итсәң, тора, әлбәттә.

— Мин аның янына килеп йөрерменме?

— Шуның өчен алып кайттым да мин аларны. Кил, уйна, ашат, ура.

Малай, шатлыгыннан дөньясын онытып, көчекләрне йөгерергә кыстый башлады.

— Япан кырга алачык салып куйгансыз икән,— диде Идрис.

Карт, җыелма урындыкта утырып, чилемен кабызды.

— Элек монда яшелчә бакчасы булган. Алачык шул заманнан калган... Буш вакыт тапсам килгәлим... Шәһәрдә ничектер һава җитеп бетми... Монда бик рәхәт...

Карт шулай дигәч, Идрис тирә-якка икенчерәк күз белән карады... Кайтырга бик вакыт иде, ләкин Айдарны ничек моннан аерып аласың... Рекс, колакларын гына хәрәкәтләндереп, малайның көчекләр белән әүмәкләшкәнен карап ята... Ә Айдар... Дөньяда бүгеннән дә матур, бүгеннән дә рәхәт көн булды микән?.. Карт та малайдан күзләрен алмый, Идрис тә...

Өстә генә тургайлар чырылдый...

Тургайлар, тургайлар...

Әнә-ә берәү! Тагын, тагын...

Ән-ә-ә болыннар! Әрәмә артында ук түбәләр күренә. Шул ич инде авыл... Әтәч тавышы аннан ук килеп җитмәс...

Картның аяк очында гына кап-кара көпшәле мылтык. Эчләренә ут, үлем яшергән кәгазь патроннар чәчелеп ята...

— Сезгә тынгылык бирмәсләр алай, малайларны әйтәм.

— Карап карарбыз...

Аяк тавышлары ишетелде, Идрис сагаеп баш калкытты. Кулына ак тастымалга төргән савыт тотып, алачыкка таба Булавина килә иде. Ул Идрисне, малайны монда очратуына сәерсенмәде, ахрысы, тыныч кына сәлам бирде. Аннан картка атап эндәште:

— Әткәй, кайнар чакта ашап алыгыз,— диде.

Идрис утырып көлә-көлә тезен уды:

— Вата-җимерә русча сөйләшеп азапланабыз тагын...

— Мин сезнең татар икәнлегегезне әллә кайчан сиздем,— диде карт...

— Сездә нихәлләр, Нина Михайловна? — диде Идрис, аягүрә басып.

Булавина ялт кына картка карап алды.

— Бездәме?.. Ярыйсы... Сез миңа кирәк идегез дә... хәзер түгел. Мин сезгә шалтыратырмын, ярыймы.

— Шалтыратыгыз, шалтырат,— диде Идрис, куанып.

— Яхшы...

Карт тастымалны җиргә җәеп табын әзерләде, Идрис белән Айдарны да чакырды, алар рәхмәт әйтеп баш тарттылар. Нина Михайловна картның килене булып чыкты. Кемнең кем булуын ачыклагач, барысы да рәхәтләнеп көлештеләр.

Алачык тирәсенә тәмле шулпа исе таралды. Рекс картка карап колакларын уйнатты, көчекләр исә шәһәр ягына китә башлаган малайга ияреп байтак җир бардылар. Аш исе болай да карыннары ачкан сәфәрчеләрнең адымнарын кызулатты. Идрис белән Айдар туптуры «Бишбармак» кафесына юл алдылар.

*Дәвамы бар*

## Хисам Камалов

### Ленин сүзе

Кешеләргә оҗмах вәгъдә итеп,
Патшалар һәм күпме түрәләр
Трибунада күкрәк суга-суга,
Төкерек чәчеп антлар биргәннәр.
Халык ышанган һәм ышанмаган...
Көчле сүзләр белән алганнар —
Кешеләрнең ватанчыллык хисен
Бик мәкерле файдаланганнар.
Коры сүзгә халык ышанмый ул,
Нәтиҗәне шундук ясый ул:
Сүзләр эшкә туры килми икән,
Халык кырын карый башлый ул.
Тәҗрибәле халык: белеп тора
Юмалауны, җайлау-көйләүне.
Нәрсә генә күтәрмәде халык?!
Күтәрми тик ялган сөйләүне.
Хикмәтле ул халык: күпне белә,
Тиз аера чынны ялганнан...
Килеп җитә бер көн Ленин сүзе
Әллә Мәскәү, әллә Казаннан.
«Безгә әле зарарлы булса да
Дөреслекне кирәк әйтергә»,—
Дигән Ленин.
Чынлык ярдәм итә
Балаларне җиңеләйтергә.
Чынбарлыкны бер дә буямаган
Ленин сүзе әле бүген дә
Һәр начарны җиңүче көч булып
Постта тора безнең күңелдә!

●

Туган җирем — Идел йорт,
Җаным дөнья белгән җир,
Туфрагына бабамнарның
Хәләл каны сеңгән җир.

Туган җирем — Идел йорт,
Туган көлләр яткан җир.
Башлар шуны онытса да,
Ташлар истә тоткан җир.

Туган жирем — Идел йорт,
Эшчәннәргә имле жир.
Киң Рәсәйнең үзәгендә
Тук төш кебек жимле жир!

Туган жирем — Идел йорт,
Күпме милләт сыйган йорт,
Юмартлыгы, татулыгы
Белән илләр жыйган йорт.

Туган жирем — Идел йорт,
Татар һәм рус туган йорт,
Бер-берсенең бәхетләре
Бер-берсеннән торган форт.

Туган жирем — Идел йорт,
Шәфкатьле, бәгырьле йорт,
Без Иделдә туганнарга
Анадай кадерле йорт!

Туган жирем — Идел йорт,
Йөрәгем ябышкан жир.
Иң якын дусларым белән
Үземне табышкан жир.

## Дәмин

«Дәмин кайткан» — диләр,
Бер башкисәр
Малай иде безнең авылда.
Читкә китеп, кеше булган ди бит,
Ышануы моңа авыр ла.
Үзен күрдем, олыгайган, житди,
Һич сизмәссең элекке эзләрне.
Тыштан кеше нык үзгәрә, ләкин
Эче аның артык үзгәрми.
Киеменә карап кына әле,
Юк, мин түгел фикер әйтүче!
Күп мал жыеп,
Буш баш белән була кайтучы.
Дәмин сөйли читтә йөргәннәрен,
Төпле сизелә, сатмый бакырга...
Шигем бетә бара,
Түгел бер мал,
Жыеп кайткан икән акыл да:
— Эшенә дә, каты салкынына
Тиз күнектем анда баруга.
Ләкин менә һич тә түзеп булмый
Туган-үскән жирне сагынуга.
Караганда — тавын сагынасың,
Су эчкәндә — чишмә суларын...
Кайчагында ачуымны китерә
Шул сентимент, йомшак булганым.
Жирсуларга чыдап булмый икән,
Төшкә кереп зарны кубәйтә.

Нәрсәсе бар безнең бу җирләрнең
Нәкъ тәкъдирчә җанны сөмәйтә?
Шундый таулар анда да бар иде,
Шундый чишмә, шундый камыш-күл.
Гейзерлар бар, зәңгәр
калкулыклар,
Юк, берсе дә җанга хуш түгел.
Эх,
Сагындырды авыл тыкрыклары,
Җанны иги торган моң сарды.
Акчаны да күп төшерә идем,
Шул туган җир тартып кайтарды.
Ышанмассың, шахталарда эшләп
Башым ачылды.
Томаланган фикер әллә ничек
Кабыгыннан гүя әрчелде.
Баш эшләсә рәхәт!..
...Мин сорамыйм:
«Нинди шахта?» — анысы хәрби сер.
Сизәм, серне тота белә торган,
Ышанычлы, мәнле һәм сабыр.
Ул тутыккан иде, хәзер инде
Җиз самовар кебек ялтырый.
Тормыш ничек ача кешеләрне! —
Сөенә-сөенә шуңа аптырыйм.
Очраганмы яхшы кешеләргә,
Яхшырганмы тормыш әмереннән?
Әнисенә ачы кайгы иде,
Сөенеченә хәзер әверелгән.
Һай, молодец, күтәрелгән Дәмин.
Барысы алда, шуңа юл тота.
Юк, яшәмәс бүтән яктысында,
Ул үзе дә инде яктырта.

# Салисә Гәрәева

●

Урал! Урал! Синең урманнарың
Башкорт көен көйли әле дә,
Зөлхиҗҗә-кыз, чулпы чылтыратып,
Суга килә, төренеп шәленә.

Бөркет куна мәрмәр кыяларга,
Тау башлары томан яшергән,
Зөлхиҗҗәнең көмеш чулпысыдай,
Көмеш күлләр җиргә чәчелгән.

Урманнарда карагай да каен
Аралашып, үрелеп үскәннәр,
Көмеш орчык кебек ракеталар
Манзарага синең өстәлгән...

Хәрәкәттә синең заводларың —
Чуен кайный, җырлый станнар,
Чуен коя башкорт егетләре —
Үзебезнең Башкортстаннан.

Урал! Урал! горур исемеңә
Матурлык та, көч тә кушылган
Илебезнең корал арсеналы
Башланадыр менә шушыннан.

●

Кайтып киләм туган якларыма,
Әй, күңелдә хисләр ташуы!
Сагындырган сары гәрәбәдәй
Бодай урган Тулбай басуы.

Дулкыннарга тияр-тимәс кенә
Ракетада очам Казаннан,
Туган җирем!
Сине сөю җырын
Күңелдәге кебек язалмам.

Уралларны урап кайтам сиңа,
Җанда җырлар ташып ургыла,
Тау чишмәсе булып шаулар идем,
Әйтелмәгән хисләр урынына!

●

Сүзсез генә кысып беләгеңне
Яңәшәңнән атлар идем мин;
Сөюеңне синең, ышануыңны
Кер тидерми саклар идем мин.
Күзләремдә түгелергә торган
Моңнар барын сизсәң иде бер,
Сүзсез генә кайнар кулларыма
Горур башың исән иде бер!

Сүзсез генә сызып йөрим, йөрим
Ә күңелдә... моң да чакыру...
Хыялларым, йөрәк ялкыннарым
Җырга гына күчәр ахыры.
Сүзсез генә янам, кайнар яшьләр
Сүзсез генә ага яңактан.
Яратмаган кешем янда йөри,
Юлларыма чыкмый яраткан...

1969.

## Альберт Закиров

# Буяу

Кулларымда калды кызгылт буяу
Табутыннан дусның буялып.
Буяу сеңгән шушы кулларыма
Карап тордым озак уйланып:
Ник кетмәдек —
Аның табутында
Буяу да бит әле кипмәгән.
Без шулкадәр ашыкканбыз икән
Соңгы юлга дусны илткәндә.
Җир дошманы белән алышканда
Җир-анага ауды кан коеп.
Яшен кебек үткән яшь гомерен
Хәтерләрбез әле сагынып.
Без ашыктык,
Тизрәк аны җирләп,
Ал кояшка карап атларга.
Без ашыктык...
Безнең дустыбызны
Телсез таллар калды сакларга.
Тик кулыма сеңгән
Кызгылт буяу
Сүзсез генә мине битәрли.
Безне шулай
Нәрсә ашыктыра,
Бу тынгысыз заман микәнни?

1966

●

Буш күңелең белән туган җиргә,
Беләм, кайту мөмкин түгелен.
Тәпи баскан тәүге сукмагыма
Күз яшьләрем калган түгелеп.
Сагындырган яшьлек истәлеген
Йөрәгемдә күпме сакладым.
Юл буенда күрәм, башка гөлләр
Башка төрле чәчкә атканын.
Күпме йөрмим яшьлек үткән юлдан,
Аякларым арый белмиләр.
Ә күзләрем
Сөйгән кешем белән
Киткән матурлыкны эзлиләр.

Мин онытылып кабат тыңлар идем
Таныш былбыл сипкән моңнарны.
Эчәр идем минем яшьлегемне
Агызып алып киткән суларны.
Кайда икән кулга-кул тотышып
Кечкенәдән үскән талларым?
Ак болытлар түгел, оча мәллә
Бала чактан таныш казларым?

1964

●

Март җилләре килеп ишек каккан,
Март җилләре хәбәр китергән.
Тууымны минем каршы алган,
Тәүге тормыш моңын эчергән.
Гомеремнең минем башлангычы
Март җилләре илткән авазда,
Ярылмаган бөре исләрендә
Һәм... туачак матур һәр язда.

1964

●

Бик күпләрнең тик сүзләре истә,
Сакламаган хәтер үзләрен.
Алар бәлки күптән исән түгел,
Әле дә исән ләкин сүзләре.
Алар миңа һаман тынгы бирми,
Киләләр дә бергә җыйналып,
Кайберләре аугач торгызалар,
Кайберсеннән китәм кыйналып.
Бу сүзләр бит тормыш авазыдай
Давылларны кисеп ашыккан.
Авыр чакта җылы икмәк кебек,
Саклап калган яман ачлыктан.
Башкалардай мин дә кыеклардан
«Тамам» диеп торган бер тамчы.
Яңып кибеккәндә, салкын судай
Бик кирәкле бер сүз булсамчы!

1966

◆◆◆◆◆◆

## Флюра Гыйззәтуллина

### Игенче һәм тургай

Жырчы тургай, и сокланам сиңа,—
Кыйблаң синең — кая борылма.
Зармы, моңмы, шатлык,
горурлыкмы,—
Ни могжиза, әйтче, җырыңда?

Баш өстемдә сайрап торасың да,
Омтыласың биек-биеккә.
Мине дә син чакырасың кебек
Үзең белән зәңгәр киңлеккә.

Канатлар юк миндә синдәгедәй,
Күзләр белән үлчим җирләрне.
Шулай да бит бер үк болын-кырлар
Зарыгып көтә безнең килгәнне.

Әйтче, тургай, әйтче, нигә шулай
Талпына соң күңел бу язда?
Шатлыкларың булса, чәч син тизрәк,
Тәмам итәм соңгы бураэнам!

### Чаптар атлар кире кайтмады

Атлар китте чабып узышка...
Нәкъ шул чакны бөтен җир өстен
Кара томан, болыт каплады.
Без җыелган олы мәйданга
Чаптар атлар кире кайтмады—
Чаптар атлар кызыл яу булып,
Кара томан аша ургылып,
Күтәрелде дошман каршына!

Офыклардан күккә җәелде
Өрмәле ялкын катламы.
Офыкларга таба юл алып
Тагын чаптар атлар үттеләр.
Киткән атлар кире кайтмады.

Кайтмый калган атлар исеме
Тимер кукме, жирән кашкамы...
Офыкларга үрелеп карасам,
Үткәннәрне искә төшереп,
Мәңге сүнмәс ялкын теледәй,
Чайкала күк әле дә аларның
Кызыл яулык чөйгән башлары.

Әле дә бии кебек аларның
Тимер тояклары ут чәчеп,
Ал шәфәкъле офык читендә...
Кайтмый калган чаптар атларның
Хуҗалары кемнәр булганнар?
Хуҗалары кайда бу көндә?..

## Чишмәләр дә серле

Чишмә юлы, чишмә юлы үрле,
Чиләкләрем минем аллы-гөлле.
— Уф, йөрәгем, уф йөрәгем! —
дисең,
Яннарыма тукталганнан бирле.
Сөйләр сүзләреңнең бармы чиге?
Үрле чишмә буйларына кире
Нинди язмыш кайтарды соң сине?

Яшел хәтфә кебек чишмә үре,
Чишмә төбе бриллианттай ак таш.
Чишмә булып чишмәләр дә серле,
Йөрәк — диңгез...
Анданиләр ятмас!

Әхсән Баянов

# ДЕКАБРЬНЫҢ УНӨЧЕНЧЕ КӨНЕ

ДҮРТ МОНОЛОГ[1]

## ДҮРТЕНЧЕ МОНОЛОГ

Вәкил энем!

Соравыңа җавап табыйм дисәң, син минем кем икәнлегемне, ул чакта сезнең арага нинди кеше килеп кергәнен белергә тиеш.

Мин — Исәнбәк абыең, Әхмәтгали улы Гайсин.

1904 елның 13 декабрендә туганмын.

Колак сал — унөченче...

Бу көнне кешеләр олы эшкә тотынмыйлар, юлга чыкмыйлар — шайтан дюжинасы... Ә мин туарга батырчылык иткәнмен!

Күз алдыңа китер:

Дөньяга кеше килгән — ябык, хәлсез, зәгыйфь, бүтәннәргә һич тә охшамаган. Ана кыенсына, кимсенә, каушый, баласын күрсәтергә оялә — хәл белергә кергән күршеләре, танышлары күзеннән ераграк яшерергә тырыша. Беренче баласы белән горурланырга тәңресе кушмаган аңа. Кулына тотып урамга да алып чыга алмаган. Бердәнбер юанычы шул: туган чакта битлек белән туган ул бала... Исән үссә, бәхетле булыр дип яшертен генә өметләнгән ана һәм шул юанычын да сер итеп саклаган.

Атам — үзенең фамилиясен дә яза белми торган надан — дөнья белән кызыксыз күрәшкән: ялчылыкта йөргән, урман кискән, кучер, ат караучы булган. Тормыш аңа ачык чырай күрсәтми, кага-суга торган булгач, атам үзе дә тормыштан үч ала — аның ачы суын эчә... Эчә дә дулый, эчә дә котыра. Тойгысыз, коры кеше — газетага да тәмәке төрергә кирәк өчен генә языла. Үзенә-үзе кереп бикләнгән, үшән, көчсез, кызганыч бер адәм.

Кышкы чиллә.

Әти ерак пристаньга ашлык ташый — кара таң белән китә, кич кайта. Беркөнне кайтмый калды. Әни һәрвакыттагыча, аш әзерләп, туңып үлмәсен дип ут йотып, авылны инде бер генә кат әйләнмәгән. Төн буе керфек тә какмыйча тәрәзәдән карап утырган. Икенче көнне төш жит-

[1] Ахыры. Башы 10 санда.

кән тирәләрдә ихатага бер гәүдә китереп ташладылар. Әни елый-елый ишеккә ташланды, мин — аның артыннан. Әти урынына — агарынган йөзле, һушсыз гәүдә. Көч-хәл белән өстерәп өйгә алып кердек. Әни аны чишендерде, салкын су белән башларын, битләрен юды, чип-чиста түшәккә яткырды. Кичкырын, гырлавыннан туктап, әти һушына килде. Рәхмәт әйтер, гафу үтенер дисеңме? Юк, берсүзсез генә каеш камчысын алды да, дөньядагы барлык әшәке сүзләрне тезеп акыра-акыра, әнине камчылый башлады.

Әни кычкыра, үкси, ярдәм сорый, ә күршеләр кешенең «шәхси» тормышына катнашмый — гадәт шундый, йола: теләсә нишләтсен. Без — балалар — кая туры килсә шунда постык. Үзенә ашарга әзерләп, көннәр буе көткән иң якын кешесен ник тукмый ул, әйтә алмыйбыз. Сорасаң, үзе дә җавап бирә алмый... Дулап тагы камчы күтәрә.

Бүтәннәр белән дә, минем белән дә шулай: чак кына гаебем булса,— сабан сөргәндә арып үзем егылсам, ат егылса да — камчы, пеше тал чыбыгы, ни эләксә — шул. Һәм мин аны яратырга тиеш.

Азрак үсә төшкәч, исәйгәч, сүз бирдем: ләгънәт төшкән бусагасын атлап кермәячәкмен, бу өйне, күрше-тирәне, бу җирне мәңгелеккә ташлап китәчәкмен, мәңге сагынмаячакмын...

Озакламый менә нәрсәләр беләчәкмен: организмдагы кара пигментның — меланинның күп булуы аркасында, кайбер бүтән төстәге җәнлекләр кара төскә керә икән. Андый җәнлекләрне меланистлар дип атыйлар. Атамнан усаллык пигментлары күчкән булса, мин дә меланист булырмын — кара бүре, ...кара ат... Яки аклы-каралы...

Бөре шәһәре — беренче тукталыш, татар-башкорт теле курслары.

Уку дәверендә, шәһәрдә яшәгәч, аз-маз рус теленә дә күнегә башладым.

Беренче мәлне кызык хәлләрдә калуым истән чыкмый. Парикмахерскийга кергәч:

— Будете брить голову,— дидем.

Рәхәтләнеп көлделәр.

Авыл малае — чабатадан, кызыл киндер ыштан һәм ак күлмәктән йөрим. Урамга чыгарга оялсам да — нишлисең, түзәргә туры килә һәм түзәм.

Курслар беткәч, авылыма секретарь итеп җибәрмәкчеләр иде — кайтмадым... Яңавыл станциясенә киттем: тимер юл аппаратына күчереп язучы (соңрак бу һөнәрне машинисткалар алыштырды) булып урнаштым. Җәмәгать эшләренә үз теләгем белән катнаша башладым, профсоюзга, комсомолга кердем. «Яңа юл» дигән газетага хәбәрләр дә язам.

Станциянең хәлен төшендем, канцеляриянең ни икәнен аңладым: ошамады. Миңа хәзер чын шәһәргә китәргә кирәк, дөньяның яңа почмакларын күрергә, яңа фикерләр, хисләр белән фәкыйрь җанымны баетырга... укырга, укырга.

Утырдым да киттем бер поездга — ул мине Уфа дигән шәһәргә илтеп ташлады. Совет-партия мәктәбенә кердем. Ул елларда башында зиһене булган һәр кешегә теләсә нинди мәктәпкә юл ачык иде — конкурслар кайда ул — иркенлек.

Әйбәт бара минем уку. Җитмәсә политик-экономик темаларга докладлар ясарга өйрәндем. Халык әйбәт каршылый, кул чаба. Ярый, бу хакта соңрак.

Тәү тапкыр кинокартина дигән нәрсә белән таныштым. Экрандагы геройлар тормышын кызыксыну белән күзәтәм. Кайберләренә охшарга телим. Ул чакта күбрәк чит ил картиналары күрсәтелә иде. Мин бигрәк тә Гарри Пиль дигән Америка киноактерын яраттым. Аның герое табигый стихия белән көрәшә, күп мажараларга очрый, ләкин җиңә. Хатын-кызларга карата булган оятсызлыгын йолкып ташласаң, калган ягы —

минем төсле... Ул стихияне җиңгән кебек, мин дә җәмгыятьтә искедән калган әшәкелекләрне җиңәргә тиеш. Эшләр шуңа бара.

...Авылдан хат килде: әни үлгән... туберкулез авыруыннан. Энем бик авыр кичергән, көн-төн елаган мескенем. Ә мин нык булырга сүз бирдем бит — түздем, бәхетсезлекне шактый тыныч кичердем: шулай булачагын, бүтәнчә мөмкин түгеллеген киткәндә үк сизгән идем. Югыйсә, ник китте дисең...

Ул чакта безнең авылда шулай дәвалыйлар: тамчылар бирәләр, туберкулезга — томау даруы. Һәм син терелергә тиеш.

Мине авылга кайтарырга мөмкин булган бердәнбер көч юкка чыкты. Узган көннәр белән минем арам бөтенләйгә өзек.

* * *

Армиягә киттем. Анда, ни хикмәттер, авылны сагына башладым. Әниемне күрермен төсле... Аена унбишәр хат җибәрәм.

Бу вакытта мин үземдә сыйнфый аң ачыкланганын сиздем. Һәм үз-үземә Совет власте өчен соңгы тамчы канымача көрәшергә сүз бирдем. Антыма хыянәт итсәм, пролетариатның корыч кулы миңа җәза бирсен.

Хезмәтне тутыргач, уку теләге авылны сагынудан көчлерәк булып чыккандыр, күрәсең. Саратов шәһәренә юл тоттым. Шуннан башланды инде менә...

Шәһәр үзенең НЭП дигән, өч хәрефкә сыя торган шәрә каршылыклары белән каршылады. Күрәм: яшәү өчен монда көрәш ачыктан-ачык бара. Бер яктан — иске йортлар, җимерекләр уртасында әр-яңа төзелешләр, заводлар, фабрикалар, электр станцияләре... Ялангачлыкны күралмыйча, күңелләренә бөек социаль хис сыйдырган чын геройлар һәм... Икенче яктан — төрле учреждениеләрдә, предприятиеләрдә, бигрәк тә көнкүрештә — аларны теләсә нинди әмәлләр белән мәсхәрәләргә тырышучы сәүдәгәрләр, саботажниклар, бюрократлар, карьеристлар... Көнчелек, алдау, хәйләкәрлек, ялагайлык, икейөзлелек, тупаслык, комсызлык һәм башкалар, һәм башкалар — максатка ирешү өчен табигый чаралар. Ә максатлары — матур киенү, бүтәннәрдән мөмкин кадәр аерылып тору — күргәзмәгә куярлык дәрәҗәдә. Тәмле һәм күп ашасыннар. Максат — тормыш белән, физик мәхәббәт белән ләззәт чигү. Авыр хәлдә яшәүчеләрнең күз яшьләрен күрмәү — тыныч яшәү. Шәһәрдәге даирәм белән ныграк танышкан саен, бу күзәтүләрнең дәреслегенә ныграк ышана бардым. Кайвакытларда хәтта шәһәрдә барлык кешеләр дә шулай бозык һәм таш кебек булып, төзәлмәслек булып каткан, ә йөрәкләре тимер шкафка бикләнгән шикелле тоела. Менә кайда икән минем сыйнфый дошманнарым! Күкрәгемдә — антым... Аяусыз көрәшәчәкмен... Ничек? Корал тотып атыша башлау — мөмкин булмаган эш. Бер генә юл — аларның чын хезмәт кешеләренә дошман икәнлекләрен халыкка туктаусыз аңлату — докладлар, әңгәмәләр, лекцияләр... Клуб һәм кызыл почмакларга барам — бөтен шәһәрне аркылыга-буйга әйләнеп йөрдем. Кул чабу, ачык чырайлар арасыннан төйнәлгән йодрыклар, бүре күзләре белән карап озатучыларны да күрмәү мөмкин түгел. Кара син сүзнең көчен! Чын көрәш бу, кискен көрәш!

Укулар да ярыйсы бара. Кинолар, театрларга да вакыт табам, күп укыйм.

Ял иткәндә, кайвакыт өчәү булабыз — Габбас Насретдинов, Харисов Сәхип һәм мин. Өчебездә өч төрле характер. Габбас — чыгышы белән приказчик, җаны белән сәүдәгәр, ифрат хәйләкәр, җиңел карашлы кеше. Аның өчен дөньяда бернинди проблема юк — бөтен нәрсәне җиңел хәл итә, рәхәт яши. Шундый ук җиңеллек белән дусларны да сата белә. Безнең белән бик шәп бер егет укый иде: әтисе кайчандыр мулла булган да хәзер укытучылыкка күчкәнгә, үзенең чыгышын укы-

тучы гаиләсеннән дип күрсәткән. Габбас — эт, иснәнеп, шул ифратта булдыклы егетнең ышанычына кереп, сөйләндергән дә тиешле кешесенә язып та биргән. Чыгышын яшергән мулла малае дип рабфактан кудылар, Шундый «куркыныч элементларны» фаш итүче дигән даны йөри Габбасның шәһәр буйлап. Соңгы көннәрдә миңа елыша башлады — берәр исәбе бардыр инде... Бергә укыгач, сөйләшми дә булмый. Уку дигәннән, белем — аның өчен, әлеге дә баягы, тормышта җайлырак позиция эләктерү ысулы. Сәхип, шушы сыйфатларның күбесен үзенә сеңдермәгән алмаган хәлдә, алаша кебек күндәм. Габбасның барлык мажараларына катнаша, ләкин үзе кызлар белән йөрми. Дөресрәге, кызлар аны санлап бетермиләр.

Әллә кайдагы, шәһәр читендәге бер клубта лекция укыганда, мещаннар хәтта рабфакларга кереп тә һава агулыйлар дип, Габбас исемен атаган идем, икенче көнне үк аудиториягә керү белән:

— Син нәрсә минем даңны сатып йөрисең? — дип изүдән бөтереп алды бу.

— Мин бит приказчик түгел, ничек сатыйм,— димен.

Сүз тирәнәеп киткәнче, ярый, аердылар. Акырынырга гына мәҗбүр Габбас:

— Кала егетләрен белмисең әле син. Өйрәтербез әле без сине.

Шулай да инцидент тора-бара онытылгандай булды. Күрше бүлмәләрдә генә яшәгәнгә күрә тагын аралаша башладым. Ялга каршы беркөнне укудан чыгып килешли, Габбас тавышы куып җитте.

— Беләсезме бүген кая барабыз? — диде ул һәм икебезнең дә җилкәгә кулын салды.— Сез моны башыгызга да китерә алмыйсыз.

Сәхипнең тиз генә эндәшмәсен белгәнгә, үзем сорадым:

— Кая?

— Чамалап карагыз.

— Землячествога.

— Түгел.

— Бүген парк ачыла — шунда.

— Анда да барырга була.

— Кинога.

— Түгел.

— Алайса кая соң?

— Ә мин каян белим?

Җилкәдән кулын ычкындырдым.

— Ифрат шаян кеше син, Габбас.

Үзе рәхәтләнеп көлә, артыннан Сәхип мөгерди:

— Кая барсак та була, һи-һи-һи.

Мин ул чакта озын соры шинель, кавказ папахасы һәм зәңгәр галифе чалбар киеп йөрим. Кыш та, яз да. Бүтән кием юк. Иртән салкынча, болытлы булганга, ул көнне дә шул формадан идем. Габбас минем өскә карап чәнчеп куйды:

— Папахаңны калдыра күрмә, бер күрүдә гашыйк булырлык булсын.

— Ансын карарбыз.

Торакка кереп, китап-дәфтәрләрне калдырдык та — киттек. Чүпчар сөйләшеп бакчаны бер-ике кат әйләнгәч, Габбас миңа бик озын бер эскәмия күрсәтте:

— Син чак кына утырып тор шушында, без хәзер урап киләбез.

— Кая барасыз?

— Сер, килгәч әйтербез,— диде ул, күз кысып,— мин бу егетне,— Сәхипне була инде,— адаштырып килим әле.

Калдым — яңа гына кыяк сузган үләннәргә, шатлыклы кояш нурларыннан җемелдәгән яшь-яшь үләннәргә, яфракларга карау күңелле. Күңелле, ифрат.

Язгы табигатьнең үзе кебек үк мөлаем бер кыз. Кып-кызыл сумкасыннан нидер эзли. Миңа таба карамый, билгеле, күрми дә торгандыр әле. Ләкин тукталды, утырды — эскәмиянең икенче башына. Илтифат итмәгән кыяфәт белән утырсам да, күзләр аңарда. Башыннан аякларына чаклы тикшереп чыктым. Тип-тигез киселгән чәчләре, яшүсмер кызларда булганча, алдан маңгайга, ә арткы яклап, чия-көрән бүрегеннән, яшь ат ялы төсле, җилкәсенә төшеп тора. Чем-кара пальтосы, чем-кара туфлиләре таза кыяфәтенә, чибәр алсу йөзенә мәзәгрәк килешү белән килешә — мин аны, ничектер, үзем күргән кинокартиналардагы бер героиня төслерәк кабул иттем.

Кыз сумкасын тагын ачып ниндидер китап чыгарды да укый башлады. Шактый утыргач, сүз кушарга җай да чыкты: ниндидер зур гына бөҗәк кызның аягына кунган иде, ул аны китап битләре актарыр өчен генә яратылган нәфис кулы белән тиз генә эләктереп тә алды.

— Эләктеме? — дидем мин, чын күңелдән көлеп.

— Эләкте,— диде кыз фәрештәләргә генә хас булган ягымлы һәм гөнаһсыз тавышы һәм елмаюы белән.

Мин аннан тагын ниндидер сүз көткән идем дә, тик ул сүз ычкынмагач, көктән иңгән баягы форсатны ычкындырмаска тиеш табып, тагын сорадым:

— Чикерткәме?

Чикерткәнең бу иртә язда, бигрәк тә шәһәрдә юклыгын белгән килеш шулай дим. Нәрсәдер әйтергә кирәк ләбаса. Соравым әйбәт тә булып чыкты. Кыз, баягы беркатлы елмаюы белән елмаеп, сәерсенгәндәй әйтеп куйды:

— Юк, кигәвен. Чикерткә тешләми.

— Әйе шул, чикерткә сайрый гына.

Кыз тагын китабына иелмәкче иде дә, мин ике арадагы нечкә генә җепнең өзелүеннән куркып, дәвам итәргә ашыктым:

— Рәхмәт инде шул кигәвенгә.

— Менә сез ничек — кешенең тәнен авырттырганга рәхмәт әйтәсез.

— Анысы өчен түгел.

— Ә ни өчен соң?

— Безне таныштырган өчен. Сезнеке кебек матур сумкам булса, мин аны шунда салып кына саклар идем.

Кыз бу урында чын мәгънәсендә сабыйларга хас самимилеге белән көлеп җибәрде һәм китабын тезләренә — нинди тезләр диген! — куйды. Аның карашы, үзен тотышы хәзер ныклап торып сөйләшергә риза икәнен аңлата иде һәм мин үзем яулап алган бу форсатны ычкындырмаска булдым — янына ук барып утырдым.

— Сез шундый кызык сөйләшәсез!

— Мин кызлар белән генә шулай сөйләшә беләм.

— Күп кызлар белән сөйләшергә туры киләме? — Көлмәде, ләкин елмаюын саклады.

— Ифрат күп.

— Мин... болай гына... гафу итегез...

Икебез дә уңайсызланып, тынып калдык. Бераздан гына кызның китабына күз төшеп (ай, кызлар кулында була торган шул китаплар! Күпме генә егеткә ярдәм итмәгәндер алар, кемнәргә генә сүз башларга сәбәп булмагандыр!), шунда ук сүз куштым:

— Әйбәт китапмы?

— Әйбәт, искиткеч.

— Мөмкинме карарга?

Калганын, Вәкил энем, син үзең дә күз алдыңа китерә аласыңдыр инде. Күп тә үтмәде, исемен сорадым.

— Мария Алтынбаева.

— Әйбәт, бигрәк тә фамилиягез. Татарчарак та...
— Ә мин татар кызы.
— Шулаймыни? Нишләп соң үзебезчә сөйләшмибез?
— Мин белмәдем,— диде кыз. Тагын нидер әйтмәкче иде дә тукталды. Минем сүз таба алмый торганны сизеп, өстәде:
— Сез шәһәрдән түгел, ахры?
— Әйе, авылдан.
— Анда кызларыгыз сагынадыр әле.
— Монда да бар бит алар.
— Шәбрәк тәме?
— Төрлесе бар. Бушлары да күп. Үзләре ифрат вежливыйлар. Конкурс буенча киенәләр, сантыйраклары бигрәк тә нык тырыша. Шәрә күкрәк, калкып, уйнап торган арт белән җиңел хисле, күп акчалы ирләрне алдап йөриләр.
— Ә чынлап җәлеп итә алмыйлармы? — Кыз, никтер, каушагандай тоелды.
— Җәлеп итәләр, башта. Соңыннан күңелдә таш, җирәнү каладыр дип уйлыйм.
— Сезне дә... Ходаем!
— Юк, мине... сез бит алай түгел, гафу итегез...
Кыз үзенең чем-кара пальтосына, аякларына карап куйды да урыныннан торды:
— Миңа вакыт бугай.
— Юк, иртәрәк әле.
Көлмәде кыз, сүзсез генә атлап китте. Ләкин нияремә каршы килмәде. Бакча әйләнеп, шактый озак йөрдек. Иптәш малайлар искә төшеп, аларны эзләдек.
— Тиз урап киләбез дигәннәр иде.
— Аларга ышансаң...
— Сез аларны беләсезмени?
— Юк... болай...— Һәм үзалдына уйлангандай, ниндидер эчке кайгысын күңелдән кичергәндәй дәвам итте.— Кешеләр алдый, хайваннар алдамый... Алдашу әллә зиһен билгесеме икән?
— Мещаннар, төрле сорт сәүдәгәрләр, рухи гарип, булдыксыз бәндәләр... Шулар алдарга тырышалар безне. Алдашу ул — шул ук урлашу — эшләнмәгәнне бар итеп күрсәтү. Алдашу исәбенә яшәп тә була.
— Синең иптәшләрең дә шундыйлар.
— Каян беләсез сез аларны?
— Болай... алар гына да түгел...
— Ялган җир шары буйлап тәгәри, пәри арбасы кебек, тик күзгә күренми.
— Сезгә яшәү кыен булачак.
— Сез ярдәм итәрсез.
— Мин? Мин генә җитмәм бит сезгә.
— Ничек? Мин — Мөхәммәт галиәссәлам түгел ләбаса.
— Үз карашларыгызча яшәргә теләсәгез, бөтен яклап азат булу кирәк. Иң башта — материаль як. Ныклы специальность, күп акча.
— Анысы нигә?
— Чөнки... Чөнки... Ничек аңлатыйм соң? — Шунда ул русчага күчте.— Деньгами можно жить без любви, а без денег любить невозможно. Әйтеп бетерә алмадым инде. Ну, сез үзегез бөтенесен беләсез.
— Кто знает все, тот равнодушен ко всему. Ә мин омтылам әле.
— Напрасно. Аз белгәннең йокысы тәмле.
Бу инде җитди сүзләрнең бетүе иде. Елмаешып, бер-беребезгә сыендык. Мин аның йомшак рәхәтлеген тоеп:

— Бүгеннән башлап, мин бай кеше, — дидем. — Мин хәзинәгә тап булдым.

Маһирә (аның чын исеме шулай икән), әлбәттә, ни хакта әйткәнемне аңлады, ләкин эндәшмәде, елмаеп кына куйды. Сүзләремнең кабул ителгәнен сизеп:

— Менә үз карашларым белән яши торган дустымны таптым. Безгә әллә кайчан күрешергә кирәк булган,— дип өстәдем.

— Үзең килми йөрдең бит. Ә мин сине гомер буе көттем.— Кыз, аллага шөкер, тагын елмайды.

— Ник адресыңны җибәрмәдең?

Әллә үзләшү, әллә шатлыктан, кочакламакчы ук идем дә, кыз назлы гына итеп читкә этәрде:

— Күп ашасаң, аз ашарсың, аз ашасың, күп ашарсың. Не все сразу.

— Мин риза.

* * *

Икенче көнне дәрес башланыр алдыннан каршыма Габбас килеп басты:

— Я, ничек? — Авызы иләк хәтле җәелгән.

— Сезнең ташлап качуыгыз шәп булып чыкты, искиткеч кызга тап булдым.

— Кит аннан! Забавно, ей богу. Нинди кыз?

— Синең андый кызны төшеңдә дә күргәнең юк.

— Әйттем бит, аһ-һа-һа, әйттем: папаха синең, папаха кызыктыра. Безгә карамыйлар андыйлар!

— Дөрес.

Габбас тагын да тилерәк шаркылдады:

— Аһ-һа-һа! Гашыйк та булган, әй!

— Син күрсәң, акылдан ук язар идең.

— Боже! Молодец! Шә-әп! Һаһ-һа-һа! Безгәме соң андый шәп кызлар!

...Маһирә белән очраша башлагач, дөнья үзе үк үзгәреп китте. Тирә-якта котыртып, үртәп торган кешеләр дә юашландылар кебек, хәтта Габбаска да ачуланмыйм. Кара син, дөнья матурлана, көннән-көн! Кечкенә генә бер кыз йөрәктәге бозны эретте дә куйды.

Киноларга йөрибез, спектакльләр карыйбыз — гел бергәләп. Беркөнне «Тарас Шевченко» фильмын карадык...

Картинаны караганда, ирексездән, минем күзләрдән яшь бөртекләре тәгәрәде. Урамга чыккач исә, ургылган яшьне тыя алмый ук башладым һәм тыныч бер коймага сөялеп, бөтен гәүдәм, тәнем белән үксергә тотындым: сизәм, бала чактан бирле җыйналган газапларым, рәнҗүләрем, күкрәкне кысып, авырттырып торган сагышларым эреп күз яшьләренә әверелә... Бәхеткә, шатлыкка, мәхәббәткә, мәңгелек мәхәббәткә ышанам. Күңел бушап, күңел иркенәеп китә — беренче яңгырдан соң чистарып, кабарып калган, мин ташлап киткән иксез-чиксез кырлар шикелле.

Күкрәгемә ләззәтле җылылык, яктылык ургылуын тоеп, ниһаять, тынычлангандай булдым һәм үземне тегеләй дә, болай да юатырга тырышкан Маһирәгә елмайдым. Ул да, гаҗәпләнү, аптырау гаҗизләгеннән котылып, кинәт яктырып китте:

— Җүләрем син минем! Ник алай син? Ни булды?

— Мин сине яратам, Маһирә!

— Чынлап әйтәсеңме?

— Баскан төшемдә җир йотсын — яратам!

— Сөеклем минем, Исәнбәгем! Мин дә яратам! Яратам! Сөеклем! Шатлыгым минем!

* * *

Моңарчы сәеррәк гадәтле идем — дөньяда үзем өчен иң кыйммәтле дип саналган хисләремне яшерергә тырышам, күңелемнең чынларга тиеш булган иң моңлы кылларын чиртергә куркам. Авылда яшәгәндә, армиядә хезмәт иткәндә, аннан соң да — хәзергә чаклы менә — кайбер кызларга күңел тартылса да, мин бу тартылудан үзем үк оялам, беркемгә бер сүз әйтмим. Кайбер чибәр кызларны еллар буе күзәтәм, очрашырга телим, ә ялгыш очрашсак, каушап калам, сүз әйтә алмый интегүдән битләремә бөрчек-бөрчек тир чыга. Ул кызлар миңа караганда тәрбиялерәк, нәфисрәк, затлырак тоела. Мине кимсетүләреннән, кешелек дәрәҗәмне рәнҗетүләреннән куркам.

Ә Маһирәм белән бөтенләй иркен — мин аның чистарак, матуррак киенгән булуын күрмим дә шикелле, мин аның ягымлы, язгы күк йөзе төсле саф, тирән һәм зәп-зәңгәр күзләрен генә күрәм. Мин аннан бөтенләй читенсенмим, ул үзе дә. Була икән шундый да тигезлек, була икән! Әйтерсең, бер-беребезне гомер буе белешкәнбез дә язмыш кушуы аркасында гына аерым яшәгәнбез. Уку сәгатьләрен, дәрес әзерләгән чакларны искә алмаганда, хәзер менә без һәрвакыт бергә. Таныш-белешләргә дә бергә йөри башладык, төрле кичәләр, концертларны әйткән дә юк. Беркөнне мине якташлык җәмгыяте утырышына чакырдылар — тагын бергә киттек.

Хәтердә ныклап калмаган — төзүчеләр клубында иде шикелле — кызыл почмакка җыелдык. Йөзләп кеше. Якташлар дигәнебез — милләтебез кешеләре: Уфа ягыннан, Төмән, Казан, Мәскәү якларыннан. Саратовның үз кешеләре күбрәк. Гаять дәрәҗәдә оста һәм белдекле кыланып, татар мәдәнияте хакында, иң олы язучыларның һәм мәшһүр артистларның күренекле әсәрләре, иҗади уңышлары, кимчелекләре хакында фикер алышабыз. Сәнгать шундый әйбер бит инде ул — аны томаналар да «даһиларча» тәнкыйтьли ала. Күбесенчә, миңа таныш булмаган исемнәр хакында сүз барды. Ә берсе бик яхшы таныш — мин аның җырларын үзем дә көйләп йөрим һәм ул әлеге мәҗлестә дә башкарылды — Салих Сәйдәшев. Казанга барып берәр концертын тыңлау, берәр спектаклен карау хыялы күңелне кытыклый...

Бераз кәеф тә күтәрелеп (йөз илле грамм чамасы бодай аракысы күңел дигәнне болытларга менгереп утырта икән!), танцевать итә башладык. Билгеле инде — Маһирә белән. Татар музыкасы сихере белән канатланып, озын һәм киң коридор буйлап очабыз. Мондый да рәхәт, мондый да иркен бәхетне беркайчан да тойганым юк иде әле. Маһирәнең дә күзләрендә, язгы зәп-зәңгәр күкнең гаҗәеп бер кыйпылчыгында мәңгелектән килгән һәм мәңгелеккә китеп тоташачак шатлык балкый.

— Бүген минем өчен тарихи көн,— дим мин аңа ярым пышылдап,— иң бәхетле көнем!

— Минем дә шулай!

— Кигәвенгә рәхмәт, ул таныштырды бит безне.

Маһирәм, оялгандай, керфекләрен сирпеп түбән карый һәм күзләрен йома:

— Алып кит мине, теләсәң кая!

— Син миңа ышанасың?

— Җир читенә алып китсәң дә барам.

Нәкъ шушы сүзләрне ишетүгә, челпәрәмә килде хыял: кемгәдер дөпелдәп бәрелдек һәм тукталдык. Габбаска икән. Янында Сәхип. Бераз салып алганнар, кичерергә мөмкин тупаслыкларын. Ләкин моның белән генә чикләнергә чамаламыйлар, ахрысы, сүзгә, бәхәскә үк керешмәкчеләр. Әллә каян беленеп тора: безнең бәхеттән көнләшәләр.

— Маһирәне калдыр, мин үзем танцевать итәм.

— Ничек инде ул «үзең»?

— Маһирә — минем кыз. Хәзер ул кирәк, минем үземә.
— Үзеңә! Ә син аңа кирәкме икән соң? Сорадыңмы шуны?
— Анысы инде мең кабат әйтелгән.
— Маһирә! — Каушап, бөрешеп калган Маһирәгә карыйм, елар чиккә җиткән:
— Ышанма, Исәнбәк! Ышанма!
— Үзем таныштырдым, үзем...— Габбас тотлыкты, Маһирәнең кулларын әләктерде дә... каядыр өстерәмәкче.
Эшнең шактый җитдигә китәчәген сизгәнгә, мин дә кискен өзәргә булдым:
— Ал кулыңны!
— Бу ни дигән сүз? Син шундый батырмыни әле? Кайчаннан башлап, ә?
— Син нишләп безне таныштырдың? Кайчан?
— Исәнбәк! Сорама алай! — Кыз ачыргаланып кычкырды.
— Бәхәсләшмә, Исәнбәк, без таныштырдык сезне, то есть — Габбас. Аның эше бу,— дип мөгердәде Сәхип. Берни аңламыйча, дөресрәге ышанырга теләмичә, Маһирәгә, Габбаска карыйм. Габбас, җинел сулагандай, йомшаграк тонга күчте:
— Белмәгән икән шул, менә ничек! Әйтмәгән икән Маһирә. Ул минем кыз бит, минем мәхәббәт.
— Маһирә, бар әле, читкәрәк китеп тор әле. Минем сүз бар аңа.
Кыз, ике кулы белән йөзен каплаган хәлдә, читкәрәк тайпылды, сөялеп үксергә тотынды. Ә без аның хакында кычкырышабыз.
— Ни хакың бар синең бер гөнаһсыз кызны рәнҗетергә?
— «Гөнаһсыз!», «Кыз!» — диде Габбас, ике сүзнең дә оятсыз мәгънәләренә басым ясап.— Болай ук беркатлы икәнеңне белмәгән идек без. Сиңа бит аны без просто сыладык.
— Ничек инде ул «сыладыгыз?»
— Мин аның белән туйганчы йөрдем...
Бу сүз мине һушсыз диярлек калдырды. Тиле кеше шикелле тик торам. Сизәм, хәзер нинди дә булса ахмаклык эшләячәкмен.
— Шундый кыз ул,— диде Сәхип тә белгән кыяфәт белән,— аның өчен ник кычкырышып торырга? Килешегез, давай!
Аннары тегесе өстәде:
— Менә шул... Чөнки ул үзе бәйләнчек, ташлашасы килми диңкетте. Шуннан соң үзең...
— Миңа «сыладыгыз»?
— Әйе, шул, туачак колыны белән.
— Кил әле монда, кил әле, бер туйганчы карыйм әле, нинди кеше икәнсең син.— Һәм җилтерәтеп ут янынарак китердем.
— Нәрсә, күргәнең юкмы әллә? — диде Габбас кызарып.
— Мин сиңа бүтән күз белән карап йөргәнмен. Бүтән төсле итеп күргәнмен. Простой кигәвен генә түгел икәнсең син! Елан! — дидем һәм каты итеп яңагына сугып җибәрдем. Чатнап китте.
Бөтен коридор: «Ни булды да ни булды?» дип шаулаша башлагач, Габбас зәһәрләнеп елмаерга көч тапты:
— Ярый, бүгенгә бетсен,— диде ул,— бүтән урында сөйләшербез, комсомол җыелышында. Хулиган! Рабфакка килеп әләккән!
— Әләктерермен мин сиңа, кабахәт!
Кырт борылып Маһирә янына килдем:
— Әйдә, Маһирә, мин сине рәнҗеттермәм! Әйдә!
Ул һаман үксе иде. Сүз әйтә алмый торуын күреп, җитәкләдем дә өстерәп үк диярлек урамга алып чыгып киттем.
Арттыруым түгел, хулиганлык өчен тикшерүләре, шелтә һәм гайбәтләр, тагын әллә нәрсәләр — берсе дә куркытмый, мине Маһирәнең аб-

рue куркыта: ни генә сөйләмәсләр хәзер аның турында?! Бер генә хис, бер генә омтылыш: ничек аның пычранудан исемен саклап калырга?

Ким дигәндә ярты сәгать сүзсез йөрдек. Төнге һавадан тәнгә һәм җанга бераз тынычлыкка охшаган бернәрсә алгач, кызга эндәштем:

— Утырыйк әле шушында.

Үзебез танышкан эскәмиягә килгәнбез. Шул көндәге бөек яктылык һәм бу хәерсез төн... Җир белән күк арасы! Ләкин без җиңелергә тиеш түгел. Күңелдәге аптырау, өшүгә үч итеп, Маһирәне кочакладым. Ул да миңа сыенгач, яңа бер ашкыну белән иреннәренә омтылган идем, түбән иелде. Тагын сүз һәм хәрәкәтсез калдык.

— Онытыйк,— дидем, ниһаять, сүзнең ни хакында барганын аңлатырга тырышмыйча.

— Онытыйк?.. Ә бит алар хаклы... Безне чынлап та Габбас таныштырды. Шуңынчы...

Кыз әйтәчәк коточкыч сүзне туктатыр өчен мин:

— Син шул исемне телгә ала аласыңмыни әле? Юк, ул түгел, безне кигәвен таныштырды,— дидем.

— Мыскыл итүләре дөрес...

— Ялганлама! — дидем кискен һәм ачу белән, урынымнан ук сикереп тордым.— Барыбер ышанмыйм!

Нинди дә булса сүз әйтергә, нәрсә дә булса эшләргә, хәтта уйларга да батырчылык итә алмыйм. Мондый да әшәкелек башка сыймый, моңарчы уйга да килгән нәрсә түгел бу. Нинди түбәнлеккә дә сәләтле икән бу кеше дигәнең! Коточкыч! Югалдым, беттем мин, Маһирәне, мәхәббәтемне генә түгел, ниндидер тагын да зуррак нәрсә югалттым... Сизәм мин моны... Никадәр чирканыч кешеләр бар дөньяда! Ә мин аларны тәрбияләмәкче, төзәтмәкче булганмын — доклад белән, лекция белән. Күзләремне йоммакчы, күрмәмешкә салынмакчы булам. Тик күзләрем йомсам, колакларым кала — алар ишетә. Тәнем кала — ул чиркана, җанга салкын ток агыла, рәхимсез салкын...

— Башта алдадылар, ә соңыннан котылмакчы булдылармы?

— Исәнбәк! Беләсең ич инде! Җитәр инде, Исәнбәк!

Шулкадәр кызганыч итеп, шулкадәр өзгәләнеп әйтте ул бу сүзләрне — кинәт йөрәк чын авырту белән авырта, сызлый башлады һәм дөньяның зуррак сораулары да булуы, туу, үлү дигән нәрсәләр барлыгы хәтергә төшеп, әлеге гауга гаҗәп тә кечкенә нәрсәгә әйләнеп калды. Хәтта йөзләрем, күңелем яктыргандай тоелды. Бөтен нәрсә — узгынчы, бөтен нәрсә — вак; син яраткан кешеләр күңелендә, син яраткан, син бар иткән эшләр мәгънәсендә бары тик мәхәббәт кала, бары тик акыл кала... Карар — әзер.

— Син аны яратасыңмы, минеме? — дидем тыныч кына.

— Исәнбәгем, сөеклем!

— Турысын гына!

— Синең белән очрашканчы мин мәхәббәтнең нәрсә икәнен белгәнмени! Әгәр белгән булсам, шундый хәлгә тарыр идемме? Ышаныр идеммени шундый җилкуарның төче вәгъдәләренә! Ах, Исәнбәгем минем!

— Алай булгач, төкерәбез аларга.

— Ничек итеп?

— Яңадан бәхетле булабыз.

— Син мине гафу итәсеңме?

— Алай димә, Маһирә. Нинди гафу үтенү ди ул монда! Юк, синдә берниндн гаеп юк! Син — алар белән чагыштырганда, күгәрчен шикелле саф, фәрештә шикелле изге. Сиңа беркемнән пычрак йога торган түгел. Сиңа беркайчан да пычрак йокмас! Хәзер генә шуны төшендем: ничаклы да олы, чын ярату белән яратам икән бит мин сине!

— Рәхмәт, Исәнбәк. Әйбәт кеше син, чиста күңелле.
— Бүгенгә җитәр.
— Иртәгә... үкенмәссеңме?
— Бу хакта яңадан сөйләшмәячәкбез. Син ризамы шуңа?
— Риза, Исәнбәгем, риза, сөеклем минем!

* * *

Җәнҗалның ни белән беткәнлеген чамалый аласыңдыр инде, Вәкил энем. Гаепле кеше булып иптәшләр алдына бастым. «Суктыңмы?» — «Суктым».— «Ник?»

Монысын әйтсәң, Маһирә хакында, аның алдануы һәм башкалар хакында сөйләргә кирәк, бөтен шәһәргә яман атын шаулатырга кирәк. Мондый эшне Габбаслар гына эшли ала...

Мин иптәшләремне алдарга мәҗбүр:

— Салган баш белән...

— Ә син эчеп тә йөрисеңмени әле?

Фарт килмәде миңа — эт итеп сүктеләр, каты шелтә бирделәр. Һәм мин хурландым, оялдым. Үземнең алдашуымнан, җиңелүемнән. Йөрәгемә ниндидер пычрак нәрсә ябышып калгандай булды. Һәм икенче көнне укырга бармадым.

Кич коридорда Габбасны күргән идем, үзенең чагыштыргысыз зур рак икәнен күрсәтә торган мәсхәрәле көлүе белән чәнчеп:

— Укып кара инде хәзер лекцияләреңне. Кем ышаныр икән, кем тынлар! Мәгърифәтче! — диде.

Шулай, ул үч кайтарды, ә минем аңа чынлап та хәзер көчем җитәрлек түгел. Ул — җиңүче! Дошманыма төйнәлгән йодрык үз борыныма эләкте. Үз йодрыгым — үземә, бигрәк тә шунысы сызлата җанны...

* * *

Казан төрки-татар рабфагында хәлләр әйбәтрәк булып чыкты. Мещаннар күп күренми, күпчелек — авыл малайлары, мөнәсәбәтләре дә бик гади. Укытучылар дәресләрне студентларның рус телен чамалы белүләрен истән чыгармыйча, төгәл, ачык аңлаталар. Эшләрем әйбәткә китте — ул чактагы иң югары билге — «Вуд» билгесенә генә укыйм. Тик ашау-эчү, гомумән, материаль як кына начаррак иде. Монысына игътибар бирмәскә тырышам.

Театрларга, бигрәк тә татар театрына йөрергә яратам. Анда заманның иң әйбәт музыкаль әсәрләре куела, мәшһүр Сәйдәш моңнары яңгырый, артист Айдаров, артистка Рәхмәтуллинаның олы талантлары зыялылар дөньясын яктыртып, канатландырып тора. Җанга ләззәт булып агылган бу кадәр дә көчле яктылыкны үз күңелемә генә сыйдыра алмыйча, Маһирәне дә бәхетле итәсем, яп-якты зәңгәрлекнең бер кыйпылчыгын гына булса да бүләк итәсем, сөендерәсем килеп, сюрприз вәгъдә итеп, аны кунакка чакырдым.

Үзем инде ике тапкыр караган, өченче кабат караганнан соң да туймаячак спектакльгә — «Зәңгәр шәл»гә алып киттем. Ул да минем кебек үк ах-ух килер дип көтәм. Ни гаҗәптер, Маһирә бөтенләй икенче төсле кабул итте — әле булса шаккатам шуңа.

Бер пәрдә үтте, икенче пәрдә... Хәзер Мәйсәрәнең язмышы хәл итемә: кияүгә бирәләр, ишанга... Үзенең Булатка булган мәхәббәтен гомерлеккә күңеленә бикләп, кыз, алтынчы абыстайга әйләнеп, яшьлеген шул азгын карт кулына тапшырачак. Меңнәрчә мескен татар кызларының уртак язмышы... Маһирәгә үзәк өзгеч тәэсир итәргә, йөрәген тетрәтергә тиеш иде ул, минемчә. Кызлар җыры. Атаклы композитор-

нын ягымлы, нечкә музыкасы, алдагы фаҗига белән берләшеп, Маһирәнен дә күзләреннән яшь китерергә тиеш иде. Мин үзем хисләргә талып, онытылып утырам, күземдә кызгану, ачу, хәсрәт. Ә Маһирә бу минутларда сәхнә белән яшәү түгел, анда карамаган да бугай, күзләре миндә бугай... Юк, миндә дә түгел шул, түгел. Аның күзләре минем театрга махсус юдырып килгән күлмәгемдә. Каян килгән үткенлек диген; партердагы сып-сыек яктылыкта ул минем күлмәктәге кечкенә генә, нокта хәтле генә кара бөҗәкне дә күреп алган. Коты очып, кулымнан тартты:

— Исәнбәк, синең күлмәгеңдә... якаңда...

Ни хакында сөйләвен аңламыйм, вакыйгадан, музыкадан аерыла алмыйм.

— Куй әле...

— Ә беләсеңме нәрсә йөри синең якаңда?

Янда утыручылар безгә искәрмә ясарга мәҗбүр.

— Беләсеңме, нәрсә йөри синең якаңда? — диде ул бу юлы ярым пышылдап.

— Я инде, соңыннан, Маһирә.

— Синең якаңда...

Шундый сүз әйтте ки, шул секундта ук яканы капладым.

— Ни сөйлисең син?

— Үзең театрга йөрисең... бөҗәкләр таратып...— диде ул, ни өчендер елмаеп.

Мин моны мыскыллау дип аңладым. Күңелдә — рәнҗү, үземнең шакшылыкка, ә Маһирәнең... Сүз белән әйтергә куркам, ләкин бу шулай... рухи фәкыйрьлектән килә торган нәрсә булырга тиеш. Бүтәнчә ничек аңлатырга икән моны? Сүзне икенчегә бору яхшырак булмасмы — үземнең якны ачыклап үтим.

Беренчедән, ашау-эчү начар дигән идем. Иртән — өч йөз грамм ипи һәм орчык башы хәтле шикәр белән (монысы айга бер кило) кайнар су эчәбез. Төшкелектә — кәбестә ашы яки тары өйрәсе, икенчегә — тары яки арпа боткасы. Эчке киемнәрне безгә җыештыручы апа юа — начар һәм пычрак... рәтләп үтүкләү тими. Әйтсәң, бүтәнгә бирегез, минем вакытым юк, дип кенә куя. Эчке һәм тышкы күлмәкләребездән әллә нинди ачы ис килә. Кай мәлне дәрес вакытында беребезнең өстендә әлегечә бөҗәк сәяхәт итүен күрсәк, һич тә гаҗәпләнмибез, көлмибез. Ә Маһирәгә бу әллә ничек тәэсир итте... Димәк... ул... безнең тормышны аңламый, димәк ул... һаман мещанка! Әтиләре кебек үк, Габбас кебек үк... сәнгать белән мавыгып, хыял, экият, матурлык дөньясында гизәр урында — нәрсә карап утырган бит! Их, Маһирә, Маһирә!

Үзенә әйтә алмасам да, күңелдә шундый авыр хис туды... шуны җиңәргә тырышып, баягыча, сәхнәгә карап утырам. Ләкин юк инде, спектакль тәэсир итми хәзер, рәнҗешле уй көзге чебен шикелле бәйләнчек, килә дә тешли, килә дә тешли... Һәм ул менә нәрсә бызылдый: «Маһирә сиңа — чит, ул — нэпман кызы, үзе бай, үзе хаерче...» Бәхетсезлеккә каршы, бу бызылдауга мин икенче көнне тагын да ныграк ышандым.

«Бер генә кешедәге мещанлыкны да җиңәрлек булмаган килеш, нишләп соң әле мин аларның бөтен дөньясына бомба ыргытмакчы булып йөрдем? Мин бит бөтенләй көчсез алар каршында! Әйе, көчсез!»

— Сюрприз дигәнең кайда инде? — дип сорады Маһирә, поезд ишеге янында тукталгач.— Күрсәтмәскә булдыңмы әллә?

— Күрдең бит.

— Кайчан?

— Кичә.

— Кичә? — ди ул гаҗәпләнеп һәм киная белән,— я, шаяртма, мин чынлап сөйләшәм.
— Мин дә чынлап. Сюрприз дигәнем шул спектакль иде.
Дустымның иреннәре кысылгандай булды, күзләрендә үпкәләү билгесе ялтырап узды. Минем чын сүземне ул мыскыллау төслерәк кабул итте бугай.
— Шуның өчен Саратов хәтле җирдән чакырттыңмы?
Хәзер инде минем хәтер калды. «Ә сюрприз булмаса, мәхәббәт хакына, сагыну хакына ул килмәс идеме икән?»
— Сиздем инде, син үпкәләдең миңа кичәге өчен. Күрсәтмәскә булдың. Ярый, мин риза, гаеплемендер. Хәзер инде беләсем генә килә — нәрсә иде ул?
— Ә син ни дип уйлыйсың?
— Алама нәрсә түгелдер инде. Хәзер бит килеп чыккалый — кемнәрдер яшереп куйган затлы әйберләр.
— Шулай да...
— Бриллиантлы йөзек, алтын алка, браслет... Беткәнмени!
Йөрәктә әйтеп аңлата алмаслык ачу кузгалды. Күз алдымнан үзем дошман дип игълан иткән мещаннар, сәүдәгәрләр дөньясы, Габбасның олы башы һәм оятсыз йөзе, бүре күзләре төсле карап торган зәһәрле күзләр, мине тикшергәндә коточкыч җитди кыяфәт алган мәгънәсез чырайлар чагылып үтте.
— Дөрес әйттең,— дидем рәнҗүемне җиңәргә тырышып. Ләкин барыбер яшерә алмаганмындыр, чөнки шуннан соң әңгәмә өзелде.
Вагонга керер вакыт җиткәч кенә, мәзәгрәк сорау ычкынды:
— Син әллә һаман этиләрең белән торасыңмы?
— Юк, син әйткәнчә, общежитиегә күчтем.
— Алайса, син Габбас белән яңадан очраша башлагансың...
— Ни сөйлисең син, Исәнбәк?!
— Еш очрашасызмы?
Маһирәнең күзләрендә курку.
— Нишләп очрашыйк, Исәнбәк, акылыңдамы син?!
— Алайса, шушындый ук бүтән кешеләр белән.— Тагын үзлекләреннән ычкынды бу әшәке сүзләр.
Маһирә башта кызарды, аннары агарып китте, шактый вакытка телсез калды. Мин дә, әллә ачудан, әллә сүзләремнең, шикләремнең хаклыгына ышанып җитмәүдән, эндәшә дә алмыйм, сүз әйтә дә алмыйм.
Ниһаять, поезд күтәрмәсенә менәргә җыенды ул һәм әйтеп аңлата алмаслык ямансу күзләре белән карады. Тавышында чит кешеләргә карата була торган әдәп билгесе ишетелде.
— Син мине рәнҗеттең, Исәнбәк, бик нык рәнҗеттең,— диде. Һәм «иярмәскә мөмкин» дигәндәй кыяфәт белән вагонга кереп китте. Тәрәзәгә килмәсме дип, шул тирәдә йөрсәм дә, күренмәде. Поезд кузгалгач кына, тәрәзәгә капланды.
Күзләрендә яшь иде бугай...

* * *

«Хәерле көн, Исәнбәк!
Бүген, ягъни 12 июль көнне, санаторийдан язган хатыңны алдым. Рәхмәт сиңа моның өчен. Минем рухи хәлем турында язган сүзләрең белән килешмим. Чөнки миңа хәзер бернинди даирә йогынты ясамый. Акылсыз, тәкәббер, акчага бай, хискә, фикергә ярлы туганнарым, танышларым минем тормышны, холкымны, уйларымны агулый дип уйласаң, ялгышасың. Мин хәзер тулысынча ирекле кеше.

Ул тормыштан мине син аерып алдың: чын дөньяга, чын бәхеткә күзләремне ачтың. Нинди генә хәлләр булса да, мин сиңа гомер буе рәхмәтләр генә укыячакмын. Ләкин шулай ук дөресен әйтим, мин хәзер синең үзеңне дә аңлап, кабул итеп бетерә алмыйм. Әллә ничек, үзең дә шул бәндәләрчәрәк кылана башладың кебек. Моңарчы мин күреп чирканган кешеләрчәрәк — бүтәннәрдән шикләнү, кимсетү хәзер сиңа да хас...

Мин элекке сәүдәгәр кызы, син язган кимчелекләрем бардыр. Ләкин мин алар белән туктаусыз көрәшәчәкмен һәм җиңәрмен дә дип ышанам. Ә син?

Үз тәкъдимең буенча, врачлыкка укыйм. Диагнозны дөрес куярга тырышам. Үләт белән көрәшкән врач шул чирне үзенә йоктырган кебек, сиңа да куркыныч микроблар йогып калды бугай бит!

Туры сүзләрем өчен үпкәләмә, Исәнбәк, терелергә тырыш.

Ком. сәлам белән: Маһирә.

22/VII—30 ел».

* * *

Хатлар сирәгәйгән саен, бәхетем дә кими барды. Башта ямьсез нәтиҗә бутала: «Дөнья матурлыгы, кешеләр матурлыгы бары тик саташу, иллюзия генә булган, ахрысы...»

Күзләрем ачыбрак карасам, бөтен нәрсә шыксыз. Яшәү шулхәтле гади һәм мәгънәсез!

Бер генә омтылыш калды: укырга, укырга. Теләсә кем язмышымны таптап уза алмаслык, теләсә нинди җәнлек йөрәгемә үзенең саргаеп беткән тешләрен батыра алмаслык акыл, мөстәкыйльлек, ышанычлы тынычлык кирәк миңа — иҗади почмак, мәңгелек белән олы бәхәс.

* * *

Рабфак еллары — күпмедер гомер, уйланулар, бәхетсез мәхәббәт, тырышлык, арыш ипие һәм саф кайнар су,— еллар буе күңегелгән аксыл пар төсле, каядыр китте. Бары тик күңелдә калды...

Инде нишләргә, кая китәргә — кайсы институтка?

Белгечлекне үз сәләтем, физик һәм акыл мөмкинлекләремнән чыгып сайларга тырышам. Менә ничек уйлыйм:

Медицинадан ниндидер начар ис килә.

Агрономия — әнкәмне йоткан, күңелдә төзәлмәс җәрәхәт калдырган тормышка кайтарачак.

Машиностроение — белем аз, эше авыр.

Педагогика — йөрәктә невроз, мин аңа үзем ярамыйм.

Сәүдә-экономика — «сәүдә» сүзен күралмыйм, Габбас хәтергә килә.

Урман хуҗалыгы — җәнлекләр почмагы.

Исәпләү-финанс — буш һөнәр.

Химия — хатын-кыз эше...

Гомеремне багышларлык эш хәзергә күрмим икән. Ә тукталырга ярамый, сынап карарга булса да кирәк. Хәл кылам: Мәскәүгә, геология-разведка институтына китәргә. Бу тәгаен техник эш тә түгел, теләсәң — кыр, елан, табигать, теләсәң — кабинет.

Мәскәүгә юлым Уфа аша уза — анда Мәгариф халык комиссариатына гариза бирдем, институтка җибәрүләрен сорадым. Гаризага җавап көткән арада, июньнән сентябрьгә хәтле ризыклык акча өчен Осоавиахимда политик-агарту работнигы булып йөрдем.

Сентябрьдә халык комиссарлыгы разверсткасы буенча институтка киттем.

Мәскәү — минем өчен бөтенләй ят дөнья. Вокзалдан чыккач ук мине сәер шау-шуы, адаштыргыч киңлеге, баш әйләндергеч биеклеге белән һуштан яздырып, каядыр алды да китте.

Укыйбыз.

Югары математика, физика, химия, политэкономия, геология, сызымнар, палеонтология, кристаллография — барысы да табигатьтә үз урыныңны табу, дөньяда адашмау, көрәшү, җиңү өчен... Ә мин үз урынымны, киресенчә, һаман таба алмыйм әле. Әллә табып югалттыммы?.. Мөгаен, шулайдыр... Һәрхәлдә, мин эзләргә тиеш!

Институт тормышын аңларга, бәя бирергә тырышам. Күрәм, студентлар «төрле көтүдән» җыелган, йоннары — белемнәре, культура дәрәҗәләре, холыклары белән чуп-чуар... Мәскәү егетләре эчке һәм тышкы культуралары белән миннән күп өстен. Алар кыю, эшлекле, ягымлы, чиста, чибәр... Киемнәре, гадәтләре, гомумән гармонияле үсешләре — мин үземне күрергә теләгәнчә. Провинциаллар — тупас, тактсыз, кайберләре сарык шикелле. Аларга һаман нидер җитми, һаман зарланалар: квартира, ашау-эчү, акча хакында... Минем хәл дә аларныкыча да бит, ә мин сукранмыйм, күп нәрсәне үзем генә беләм, кешегә сөйләнмим. Шуңа күрә алар белән уртак сүз табылмый, ә Мәскәү егетләре бәлки минем белән шулайдыр...

Ялгызлыктан йөрәкнең авыруы көчәя: төннәрем, төшләрем коточкыч кошмарлар белән тулы, уяулы-йокылы. Иртән баш әйләнә, көндез — апатия. Шул хәлгә җиттем ки, кайда булса да хәлсез, көчсез кешеләр күрсәм, үземә охшатып сискәнәм. Бер нәрсә ачык — бирелмәскә, җиңәргә. Мин Мәскәү егетләре кебек яшәргә, алар ирешкән дәрәҗәгә ирешергә, бу дөньяның тигез тавышлы, көчле, ягымлы, шат кешесе булырга тиеш!

Ул елларда югары уку йортларында өйрәнелә торган материалларны үзләштерү өчен бригада системасы оештырылган иде. Бригадада алты кеше. Аларның өлгереше өчен бригадир җавап бирә. Безнең бригадир — унсигез яшьлек чибәр кыз — Наташа Лобанова, Мәскәү кызы. Укуы да шәп. Мин башта бүтән бригадада идем, Наташа үз бригадасына алды, билгеле, карышмадым.

Дөресен әйткәндә, мин аңа тыныч карамыйм: искиткеч матурлыгы, көчле рухы белән ул мине дулкынландыра, түзә алмагач, үзенә сизденергә тырышам, тик кыз мине я аңламаганга сабыша, я ул темага сөйләшмик әле, иртәрәк дип, укуым хакында сораштыра башлый.

Беркөнне безнең торакка килгән иде: ничек яшәвемне күрергә — бригадир бит. Сөйләшә торгач, мин аңа Маһирәнең күптән түгел язган хатын күрсәттем. Шушы хатны:

«Хәерле көн, Исәнбәк!

Синең 3/I да язган хатыңны 20/I да гына алдым. Син аны бит салмый йөрткәнсең — конвертта — 12 январь.

Гаҗәпләндем: син мине һаман да дустың дип исәплисеңмени әле? Рәхмәт сиңа моның өчен, Исәнбәк.

Үзем хакында бер-ике сүз.

Мин чын мәгънәсендә шат күңелле, тормыштан үземә тигән барлык нәрсәләрне алырга тырышам. Кеше бит эзләгәнен барыбер таба. Син дә табарга тиеш. Өметсезләккә бирелергә берничек дә нигезең юк. Ныклап уйласаң, син инде җиңүче — аяусыз бәрелештән син коры кул белән чыкмадың, ә мине алып чыктың, бер кеше язмышын саклап калу кечкенә җиңү түгел ул, минемчә. Кеше бит ул!

Янында туганнарың юклыгын, әти-әниең юклыгын, дөнья белән ярдәмчесез көрәшеп йөрүеңне мин хәтерлим. Әтиеңнең рухын имгәткән, әниеңне яшь-яшь килеш кабергә алып киткән тормыш синең йөрәктә

төзәлмәслек җәрәхәт калдырганын да беләм. Мине коткарганда, ул яра тагын ачылды... Аңлыйм, моңарчы җиңел килсәң дә, хәзер синең йөрәкне артык олы рәнҗеш хәлсезләндергән. Ләкин бит син акыллы, белемле... Син югалмаска, яшәргә тиеш. Тирә-ягыңа кара: синең кебек яшьләр бездә бармыни? Юк. Алар барысы да сәламәт, шат, бәхетле һәм тормыштан күпне көтәләр. Син дә шулар төсле булырга тиеш: дәваланырга, терелергә.

Безнең медикларыбыз дөньядагы барлык инфекцияләр белән көрәшәләр һәм зур процент яхшыруга ирешәләр. Ә менә синдәге тынгысыз авыру белән кемнәр көрәшергә тиештер, әйтә алмыйм. Мөгаен, үзеңдер...

Киңәшем чын күңелдән һәм дусларча: файдасыз тилелекләрне башыңнан чыгарып ташла да — өйлән, хатыныңны ярат, балаларың булсын...

Тормыш иптәшем Зариф сиңа дусларча сәлам әйтеп кала. Минем сүзләр буенча ул сиңа гашыйк. Ул үзе дә нәкъ синең төсле — чибәр, акыллы, усал, әйбәт. Бер өстенлеге бар — шат күңелле. Врач, педагог.

Элекке дустың — М.

P. S. Теге сюрпризны бүләк итәрлек кеше тап. Уңыш телим.

26 нчы январь, 1935 нче ел».

Хатны сак кына өстәлгә куйды Наташа:

— Кем бу кыз?

— Элек мещанка иде. Хәзер...

— Акыллы кыз!

— Мин аны чын күңелдән яраттым. Әллә ничек аерылыштык.

— Үкенәсеңме? — Наташаның күзләрендә шаян хәйлә.

— Юк, язмыш аны рәнҗетмәде. Мине дә... Тагын да гүзәлрәк...

— Стоп! — Явачак комплиментлардан котылу өчен көлеп җибәрде ул. — Тормыш гел үсешкә бара: гадилектән катлаулыга.

Ләкин ул барыбер алдый алмый, тиешлесен барыбер әйтәм мин аңа:

— Беренче дустым мещанка иде, хәзергесе — аристократка...

Наташа соңгы сүзне үз адресына кабул итте һәм ялгышмады. Өстәлдәге ап-ак бүрегенә, өр-яңа мех тунына һәм нечкә, нәфис, шул ук вакытта сәламәтлек аңкып торган буй-сынына карап сокlanуымны да сизде. Үзе дә бөтен кыяфәтемне күздән кичерде... Карашыннан сизәм мин аның: ул да ошата мине... Шуңа күрә кыенсына.

— Ә син үзең кем? — диде ул каушавын җиңәр өчен генә.

— Мин? Мещаннан узган, аристократ була алмаган.

— Гафу ит, син аристократ дигән сүзне иске мәгънәсендә әйтәсеңме?

— Юк, алла сакласын. Чын культурага ирешкән акыл һәм матурлык мәгънәсендә. Үземнең идеалым мәгънәсендә.

— Алайса, уңыш телим.

— Белмим шул, артык ерак ул миннән...

— Ә ул сине һәрвакыт көтәр...

Наташаны мин аңладым: ул минем савыгуымны, үзенә тиң булыр дәрәҗәгә җитүемне көтәргә риза. Аның тормышы, аның дәрәҗәсе — дөньяда мин эзләгән әкият. Тапсам, мин — бәхетле!

Беренче мәхәббәтне югалтудан гына кызык бетмәгән икән әле, көрәш бетмәгән. Тагы да биеккә, яктылыкка, иркенлеккә, чын тормышка һаман үрләргә мөмкин. Мәһирә алып киткән шатлыкны дистәләрчә мәртәбә кабатлап, Наташа кабат китерә, вәгъдә итә түгелме соң? Бар икән шундый мәхәббәт — бәхет белән бергә килә торган, максат белән бергә ирешелә торган мәгънәле һәм бөек мәхәббәт!

Наташа!

Катырак кычкырып җибәрдем бугай, кыз сәерсенеп калды:
— Нәрсә син?
— Юк, болай гына...
Җайсыз миңа — сизәм, Наташа иң эчтә яткан, иң кадерле сүзләремне ишетергә үк әзер түгел әле. Бу сүзләр вакытыннан элек әйтелсә, аның нечкә, чамадан тыш юка бәллүр төсле күңеленә бәреләчәк һәм авырттырачак иде. Ах, ашыксам, никадәр ялгышачак идем!
— Син нидер әйтмәкче идең.
— Юк... минем тәкъдимем бар, барыйк әле кинога.
— Кинога? Белмим шул. Әни көтәдер инде.
— Әни? Нинди бәхетле син, Наташа!
— Әйе шул, шундый әйбәт әнием бар минем.
— Өйдә генәме? Гел?
— Юк, ул врач, галим...
— Әтиең?
— Математик, профессор.
— Ә минеке... Имзасы да тамга гына.
— Борчылма. Иң кирәге — үзең кеше бул.
— Маша да шулай ди торган иде.
— Маша? Ә! Хат авторы. Карале, теге «сюрприз» дигәне нәрсә соң аның?
— Болай, мин бриллиантлы йөзек тапкан идем,— дим, янәсе, Наташаны да сынамакчы булып,— бүләк итәргә вәгъдә бирдем. Ә ачуланышкач...
— Бүләк итмәдең.
— Теләсәң, сиңа бүләк итәр идем.
— Что син,— диде ул, курыккандай,— хәзер аның белән нишлисең? Нигә кирәк ул?
— Нишләп? — дим, Наташа өчен сөенгән хәлдә,— бриллиант бит.
— Безнең бу заманда кешене бриллиантлар бизәми, дустым, иң кирәге — күңел байлыгы, күңел азатлыгы, белем, бәхет. Беркайчан да тутыкмый алар.
— Мин дә шулай уйлыйм, Наташа.
— Уйласаң, әйдә, киттек кинога.
Наташам үзенең ап-ак бүреген киде, җилкәсенә акка кара шакмак төшкән, бүреге төсле үк кабарып торган йон шарфын әйбәтләп ябынды. Тунын кияргә җыенгач, мин аның янына килдем дә кидерергәме, юкмы, дип каушап: «Минем кебек гади кешеләрнең кулы кагылырга тиешме икән» дип уйлана калдым. Тик Наташа «мөмкин» дигәндәй караш ташлагач, «Ни булса, шул булыр» дип, тунны алдым һәм кияргә тәкъдим иттем. Сүзсез генә. Бу вакыт күкрәктән нинди дә булса сүз кысып чыгару коточкыч кыен эш иде минем өчен. Тунның гаҗәп тә йомшаклыгын, гүзәл сынга тиеп торган бәхетле әйбер икәнлеген тою рәхәте,— кызның шундый ук ак, сөт шикелле пакь хисле икәнен тою ләззәте белән кушылып,— күңелне кытыклый...
Ул тунын киде дә миңа борылып көлемсерәде.
Чак кына елмайган алсу иреннәр шулчаклы матур тоелдылар ки, дөньяда мөмкин булган шул иң матур төстә һәм миңа карап торган күзләрнең тыенкы акыллылыгында, яктылыгында мин киләчәк бәхетемне төсмерләдем. Матур сүзләр әйтер өчен генә яратылган бу иреннәр, дөньяны яктыртыр өчен яратылган бу күзләр, бизәк өчен яратылган ап-ак тешләр рәвешендә (энҗе дигәнең, көмеш дигәнең, бриллиант җемелдәве дигәнең, алтын дигәнең нәрсә ул бу тешләр белән чагыштырганда!), әйе, әйе, бәя биреп бетерергә мөмкин булмаган шул камиллек рәвешендә күрдем мин үземнең киләчәгемне! Соклануымнан, яратуымнан нидер әйтәсе килеп телем тибрәнде, әйтә алмадым, каушадым.

Хәер, ана әйтәсе дә юк. Ул болай да бөтенесен аңлап, белеп тора. Югыйсә, ни өчен елмая дисең син аны! Бар бит шундый зирәк кызлар! Күңелдәге уйны үтәли күрә торган!

— Әйт, тартынма,— диде ул һәм тагын елмайды.

Бу юлы инде кызның хәйләле карашын күрәм: шаярта, янәсе...

— Ярый, икенче тапкыр,— дип кенә куям.

Димәк, иртәрәк әле, көне җиткәч, ул сүзне син үзең үк әйттерергә тырышачаксың.

— Ярый, мин түзә дә беләм.

Урамга чыгып бераз баргач та ниндидер яшьләр төркеменә туры килдек. Алар безне, дөресрәге Наташаны, урап алдылар да көлә-көлә бәйләнәләр, шаулаша, үткен сүзләр әйтешәләр. Ә мин өч сүзгә бер сүз белән генә кушылам. Киногa кереп утыргач, таныш булмаган кешеләр белән сөйләшү кыенлыгыннан котылдым һәм рәхәтләнеп экрандагы вакыйгаларны күзәттем.

Кинодан соң Наташа, минем белән хушлашып, шул танышлары белән китте. Ниндидер кимсенү, гарьләнү сизеп, тулай торакка атладым.

«Ярата алмас мине Наташа, ярата алмас!»

Бу егетләр, бу кызлар Наташаның әти-әниләре белән үк таныш һәм аралашып яшәгән дуслары икән. Кайсы университетта укый, кайсы — авиация, машина төзелеше институтында, ниндидер академияләрдә. Наташаның үзе кебек үк бөтен яктан килгән кешеләр... Мин шушы авыр хәлем, кыяфәтем, сәламәтлегем белән шул кешеләр белән ярышырга, Наташаны тартып алырга тиешме?

Сигезенче март иде бугай. Зур гына бүлмәгә озынча өстәл куелган. Ул чакта затлы дип чутланган, сезгә исемнәре килеп җитмәгән аракы һәм ширбәтләр тезелгән. Ашамлыклар да шактый мул. Ниндидер уртак вакыйгалары, таныш темалары бар — сөйләшәләр, көлешәләр. Наташаның икенче ягында (бер ягында мин) бер симез егет утыра — машина төзелеше институтында аспирант, диссертация яза икән, шуны сорашалар.

— Кандидатлыкны кайчан юабыз, Владек?

— О! Тиз түгел.

— Шулай да.

— Ким дигәндә — бер елдан! — дип Наташа җавап бирә.

Ул дә кит!

Ашап-эчкәч, гадәттәгечә — җыр, танцы. Җырга катнашам, биюгә — юк. Радиола тавышын басып, бер кыз дамский вальс дип кычкырган иде, Наташа минем янга очып килгәндәй килде:

— Күңелсез утырма, Исәнбәк, әйдә!

— Мин танцевать итмим шул.

— Шулаймыни? — Шаярта дип уйлады Наташа һәм китәргә борылды.— Кызганыч.

— Утырып кына торыйк.

— Хәзер...

Баягы симез егеткә барды:

— Ә ул танцевать итми.

Һәм икесе танцевать итә башладылар.

Әллә егет минем янга килергә үзе тәкъдим иткән инде. Була бит шундый да әдәплелек!

Бераздан шул егет, Наташа һәм ут борчасы төслерәк тагын бер кыз белән коридорга чыктык. Юк-бар сөйләшеп күпмедер йөргәч, ниндидер бүлмәгә кердек. Анда бүтән беркем дә юк, иркенләп утырырга мөмкин иде. Ләкин күп тә үтми, Наташа, йомыш тапкан булып (Галка югалткандыр, янәсе), чыгып китте. Тагы бераздан Владек Наташаны алып керәм дип китте. Әлеге ут борчасы белән икәү генә калдык. Катя исемле икән.

Сөйләшә торгач, мин аның хакында шул ук кечтә кайбер нәтиҗәләр ясарга өлгердем. Ул үз көченә, белеменә, киләчәгенә нык ышанган акыллы кыз булырга тиеш. Көнкүреш хәлләренә бәя биргәндә, тупаслык дәрәҗәсендә туры сүзле һәм чамадан тыш тар карашлы: тормышны күбрәк әдәбият аша белә һәм бүтәнчә белергә дә теләми. Мин үз хәлемне сөйләгәч, шаккатты:

— Шулай да яшәп буламыни? Сезнең исән йөрүегез дә гаҗәп.

— Сез аксөяк! — дидем мин шаярган тонда, үпкәләмәде.

— Үзегез дә шундыйга әйләнерсез әле.

— Әгәр үлми калсам.— Шулай ук шаяртмакчы булам, янәсе.

— Әйе, исән калсагыз,— шаяру исендә дә юк! — якташларыгызны аңламый ук башларсыз.

— Анысы булмас, беркайчан да.

— Иртәгә безнең эш урынына киләсезме? Киләчәк эшегезне карарга?

— Ничек алай?

— Мин сезнең институтны бетердем. Хәзер гыйльми институтта.

Тәкъдим кызык тоелды да, икенче көнне, занятие сәгате бетәрәк, барып та җиттем. Бер егет һәм ике хатын-кыз утыралар. Мине күрүгә Катя урыныннан сикереп торды:

— О! Килдегез! Менә шәп!

Эш беткәнче укый торырга дип, Катя миңа яңа газета-журналлар бирде һәм язу өстәленә яңадан барып утырды. Бүлмәдәгеләр бер-берсенә өзек-өзек сүзләр ташлый тордылар. Мәгънәләренә игътибар итмәскә тырышсам да, барыбер колакка керә.

— Иягемә күнегү ясап өлгермәдем,— диде миңа якынрак утырган хатын.

— Ничек ясыйсың аны? — диде Катя.

— Терсәкләрне менә шушылай өстәлгә куясың да, иякне уч төпләренә куеп, нык итеп кысасың. Берничә кат. Аннары авызга кечкенә таяк кабып, шул таяк белән башта бер якка, аннан икенче якка түгәрәкләр «сызасың». Аннары, иякне алга сузып, башны әле бер як кулбашка, әле икенчесенә борып сузасың.

— Катырак борып ташласаң? — диде егет җитди итеп.

— Син көлмә, яме,— диде хатын,— матурлык мәшәкатьле нәрсә ул. Үзегез бит матурларны эзлисез. Әнә бит егетләр бер дә минем янга килмәгән, Катя янына килгән.

— Муеныгызны каты ук бора белмисез, димәк.

— Әй, сине тыңласаң...

Һәм хатын күзләргә, җилкәләргә ничек массаж ясарга кирәклеген сөйләргә тотынды. Җөпләгәндәй, Катя уфтанып куйды:

— Минем парикмахерым авырый әле, нишләргә инде.

— Минекенә бар, синекеннән һич тә ким түгел,— диде хатын, ярдәм итәргә бик теләгән тонда.

...Чыктык Катя белән. Кино карадык һәм икенче тапкыр очрашырга сүз куешмыйча аерылыштык та. Берничә көннән Наташа:

— Сезнең нәрсә... барып чыкмадымыни Катя белән? — дип сорады.

Үз колагыма үзем ышанмыйча, туп-туры күзләренә карыйм: шаяртмыймы, янәсе. Юк, күзләрендә шундый җитдилек! Әйтерсең, ул — апа, миңа — энесенә карый. Ә бит болай ул үзе миңа сеңел — ун яшькә кечс. Ләкин минем белән житәкчелек итә — туры мәгънәсендә һәм акыл белән дә өстенлеген сизә, үз кешеләрчә сөйләшкәч хәтер дә калмый. Эх, Наташа, Наташа! Кирәк идеме соң миңа кайгыртуың! Миңа ни кирәген сизмисеңмени соң син! Шулай ук сизмисеңмени?! Ихтимал, мин сине артык идеаллаштырып, артыгы белән хөрмәт итеп, үз хисемне аңлата алмаганмындыр. Инде сузарга ярамый: хәзер булмаса, иртәгә соң булуы ихтимал... Курkуны җиңәргә кирәк. Шулай.

— Син нәрсә, Наташа... мине...

Тагын тукталам, сизәм, Наташа шактый борчыла, ник икәнен төшенмим.

— Минемчә, син... сез... Катяны ычкындырырга тиеш түгел идегез.— Кинәт «сез»гә күчүен кара!

— Ничек Катяны?

— Аңлыйсың бит.

— Сез мине махсус таныштырдыгызмы?

— Шулай сөйләштек бит, мин сезне үз тормышыма алып керергә вәгъдә бирдем.

— Мин ул тормышны күрдем.

— Шуннан?

— Анда да төрле кеше бар. Кайберәүләр һич тә ошамады.

— Кирәк икән, ошамау дигән төшенчә буш сүз ул.

— Наташа! Ни сөйлисең син! Мине никадәр мыскыллавыңны, хурлавыңны беләсеңме син! Күз алдыңа китерә аласыңмы? Миңа бит... нишләп аңламыйсың? Миңа бит Катя кирәкми, миңа бит Наташа...

— Шул тормышка кермичә, шунда кайнамыйча торып, син үзең еләгән кеше була алмаячаксың.

— Кирәкми миңа ул кеше, кирәкми миңа ул тормыш, әгәр...

— Исәнбәк, житте!

— Юк, туктатма син мине, бу юлы барыбер... әйтмичә калмыйм. Әгәр син булмасаң, син минем белән булмасаң, кирәкми ул тормыш миңа, бернәрсә дә кирәкми миңа, хәтта дөнья үзе дә!

— Ни сөйлисең, Исәнбәк!

— Мин сине яратам, Наташа!

Наташа сүзсез калды. Ул минем нинди хыял белән яшәгәнемне чамаласа да, карашымның бу хәтле дә житди икәнен әле генә аңлады булса кирәк. Уйга калуы барлы-юклы өметемә әз булса да жылылык өсти, мине рәнжетмәс өчен генә түгел, үзе дә ялгышмас өчен тагын да уйланырга тиеш табуы иде бугай. Димәк, әле миндә нинидер кызык нәрсә бар, бөтенләй юк түгел, димәк...

— Исәнбәк, әйдә шулай сөйләшик...— диде ул шактый атлагач.

— Ничек?

— Ярый инде, икенче тапкыр. Мин кайтып життем.

Шулай диде дә юлның икенче ягына йөгереп чыгып китте. Таныш хәрәкәт: бер кулында портфель, икенчесен миңа болгый:

— Иртәгәгә чаклы!

— Ә мин котәм.

— Беләм.— Тагын нидер әйтмәкче иде, милиционер «манипуляциясе»нә буйсынып, машиналар ташкыны гүләп кузгалды да арабызны каплады. Постовой таягының чираттагы ымы хәрәкәтне икенчегә таба борганда, Наташа юк иде инде.

Шушы төшкә хәтле мин аны көн саен диярлек озата киләм. Сүзләр бер үк тәсле тәгәлләнә:

— Ә мин котәм.

— Беләм.

Ниһаять, беркөнне юлның икенче ягына чыктым һәм болай дидем:

— Наташа, синең ишеткәнең бардыр инде... Бәлки әнием дә шулай эшлидер...

— Әнием? Ничек?

— Врачлар, галимнәр яңа төр операция үзләштергәндә, гомумән, өйрәнгәндә... шулай эшлиләр.

— Ишарәләр белән сөйләшә башладың әле син, Исәнбәк. Ничек эшлиләр? Нәрсә?

— Хайваннарга операция ясыйлар, тәжрибә...

— Ну?

— Мин туйдым бу хәлдән, гафу ит. Подопытный хәлдә булу туйдырды мине.

Елмаерга теләде Наташа, булдыра алмады, зур зәңгәр күзләрен тутырып карады һәм тукталды:

— Син шундый хәлдәме?

— Әйе.

— Нишләп?

— Син — врач, ә мин... мин бит беләм, син миннән көлеп кенә йөрисең. Дусларың белән җыелып сез миннән көләсез. Хәтта әти-әниләрегез белән дә... Провинциаллар психологиясен өйрәнәсез, миндә тәҗрибә ясап.

— Һични аңламыйм.

— Ләкин мин тәҗрибә алып барырга мөмкин булган хайван түгел, ышан. Сез юкка мине сайлагансыз.— Ни өчен шушы хәтле кызуымны үзем дә төшенмим.

— Уф!

— Синең танышларың, дусларың мине сөйләндереп, бәлки кая булса язып та бирә торганнардыр әле.

— Исәнбәк, син вөҗдансыз!

Наташаның хәлен күрерлек түгелмен, үземне белештермәслек дәрәҗәдә рәнҗегән идем бу вакытта — сәбәбен әйтә алмыйм, әллә үземә, әллә Наташага.

Ким дигәндә, биш квартал сүзсез узылды. Иң югары математика формулалары ярдәмендә дә чишелә алмаслык мәсьәләнең җавабын эзли идек. Ниһаять, Наташа телгә килде:

— Гафу ит, Исәнбәк, мин ялгыша язганмын.

— Ничек ялгыша?..

— Мин Машаның диагнозын искә алмаганмын... ышанмаган идем. Ул хаклы икән, дөрес аның диагнозы...

— Дөрес түгел.

— Ә хәзер генә син миңа әйткән шикләр?

— Син мине дә аңла.

— Аңлыйм, син чынлап...

— Әйе, мин сине чынлап яратам! Синнән башка миңа бернинди тормыш та, киләчәк тә кирәкми.

Тагын сүзсез калдык, тагын бик озак сүзсез йөрдек. Ничә кабат урап узганнан соңдыр, тагын өйләренә кайтып житкәнбез. Кыз газон читендәге карт топольгә сөялде. Әйтерсең, ул тополь ерак буыннардан килә торган киңәшен жуылдап, аңа үзенең җавабын әйтеп тора, ә Наташа бары тик кабатлый гына:

— Син әйбәт кеше, Исәнбәк. Мин сиңа ияләштем, шуңа күрәме... Юк, син, гомумән, яхшы кеше, акыллы...

Рәтле сүз әйтергә җыенмый ул. Тик үзенең гаҗәп әдәплелеге аркасында, мине рәнҗетмәс өчен җайлырак сүзләр эзли, бары тик шуның өчен генә газаплана. Сизәм мин моны, сорау да бирмим, җавап та көтмим. Тирәкнең мәңгелек төбеннән килгән сүзләре ишетелә торды:

— Үзең дә беләсең ич инде: мин сине ярата да алыр идем...

Димәк, ул мине яратмый, ә бүтән сүз инде кирәкми, әмма китә дә алмыйм, торам да торам. Ник икән?

— Син беркөнге кешене яратасың...— дидем чак кына «теге симез кешене» дип ычкындырмыйча.

— Бәлки... шулай дөресрәк тә булыр.

— Һаман акыл! Акыл сүзләре! Кайда соң синең хисләрең, кайда?

— Акылсыз хисләр азгынлыкка тоташа. Мин аларны хөрмәт итмим. Хатын-кыз, сәламәт булса, максаты белән аның мәхәббәте бергә йөри. Шушы үзе табигый хис, киләчәкне саклау хисе, җаваплылык... Кешелек туктаусыз камиллеккә омтыла. Шул камиллеккә — гүзәллеккә

алып бармаса, мәхәббәт юк, очсызлы ләззәт кенә бар. Ә безнең максат аннан югарырак. Максат — үзебездән дә бәхетлерәк, үзебездән дә тәрбиялерәк, матуррак балалар. Искедән калган барлык алама гадәтләрдән, яшертен гарип сыйфатлардан азат күңел, азат эш, азат тормыш.

— Әйе шул, минем язмыш ышанычлы түгел: канымда атамнан күчкән пигментлар... Җилер буынның ак тәненә кара таплар булып төшүем бар. Өстәвенә, үләт микроблары... Курык, Наташа, курык син миннән! Ләкин белеп тор: мин ул авыруларны эзләп йөрмәдем, гариза биреп тә алмадым. Шулай булгач, минем нинди гаебем бар монда, нинди?!

— Ә мин гаепләмим, киресенчә, борчылам.

— Син бит мине барыбер яратасың!

— Сиңа дәваланырга кирәк.

— Наташа!

— Ачуланма, Исәнбәк.

— Ах, мин сиңа ачулана алсам икән!

— Бар, Исәнбәк, кит, хуш хәзергә.

Ә мин китә алмыйм, тиле кеше төсле берни аңламыйча, һаман торам да торам. Аптырагач, үзе кузгалды...

Китте — башын иеп, салмак адымнар белән. Бераз баргач, борылды да тагын яныма килде. Сыенды. Һушыма килә алмагандай басып тик торам. Кулларымны кысты, битемнән сыйпады һәм иң ләззәтле бәхет кайнарлыгы бәрелеп торган иреннәре белән муенымны кытыклап, башта калган барлык зиһенне актарды да ташлады. Үземне дөрләп яна башлаган төсле хис иттем... Ә кыз, ак күгәрчен төсле пырхылдап, кинәт күздән дә югалды. Иреннәремдә аның иреннәреннән күчкән алсу ут кына янып калды. Бу кызыллык җуярмы берәр вакыт үзенең төсен, сүнәрме? Ихтимал, сүнәр, үзем сүнгән чакта...

— Хуш, Исәнбәк, бөтенләйгә!

* * *

Хуш, Наташа, ләкин бөтенләйгә түгел.

Хуш, Мәскәү, ләкин бөтенләйгә түгел. Хыялымда син мина гомер буе Наташа күзләре белән карап торачаксың. Барлык яшеллек дөньясы кояшка карап үскән кебек, кеше күңеле дә яктылыкка омтыла. Шуңа күрә ул күпчелек очракларда үзеннән яхшыракны сөя дә бит! Мин Наташаны яраткан кебек.

Ләкин мәхәббәтнең дуслыкка әверелүе өчен тиңлек кирәк. Югыйсә, гүзәллек усаллаша да белә — сине кабул итми. Наташа мине кабул итмәгән кебек.

Ләкин мин тереләчәкмен, кирәк булса, утта яначакмын, тереләчәкмен. Хәзер гаепләрнең, авыруларның барысыннан берьюлы котылыр, чистарыр өчен дөньяның иң изге казанында кайнарга тиеш мин, иң көчле утларда янарга тиеш.

Карар әзер минем, Наташа: беренче курсны әйбәт кенә тәгәлләгәч — эшкә!

Инде бераз хәл җыярга кирәк — Мәскәү янындагы «Аккош» санаториена ай ярымлык путевка бирделәр. Аннан Башкортстандагы Чехов исемендәге кымыз белән дәвалау артеленә җибәрделәр — «дистрофия организма» дигән диагноз беркеткәндә (Маһирә белән Наташа диагнозыннан тыш!), нервларның психикага тәэсир итәр дәрәҗәдә какшавын врачлар минем үземнән дә яшермәгәннәр иде.

* * *

Урал — ил биеклеге.
Мин шунда күтәрелдем.
Вәкил энем!

Уралда үзгән елларым турында сорашсалар, озын сөйләмә.

Чакрымнарга сузылган зәңгәр тау итәкләрендә күк төтен белән төтәсләнгән йортлар, заводлар, корым һәм ташкүмер тузаны белән кушылып яуган кар, урамнарны кысрыклаган сырынтыларны күргәнең бар: шуларның барысына безнең гомерләр кушылган. Тынлап утырсаң, сиңа кемнәрдер эндәшкән төсле тоелыр.

Шуларның берсе — мин.

Тирә-якта гудок тавышлары янгыраганда ашыга-ашыга сменаларга агылучы, дегетләнеп, майланып беткән, ялтырап торган телогрейка, киң чалбар, тупас итек яки ботинка кигән миллионнарча кешеләрнең берсе — мин.

Илдән илгә, чордан чорга: «Удар бишьеллыклар», «Комсомольск», «Магнитка», «Днепрогэс» дигән горур сүзләр янгырый. Анда сиңа бик якын бер тавыш та ишетелә торгандыр, бу — минем тавыш.

Бәлки моңарчы беркем аягы басмаган, бәлки сунарчы аяклары гына баскан, күрән аюлар кыш буе бернинди борчусыз тәпиләрен имеп йоклаган почмакларда — бөтен дөньяга ишетелгән таныш гөрелте кузгатып — аюлар йокысын качырган кешеләр... Миллионнарча кешеләрнең уртак авазы... Шул кешеләрнең берсе — мин.

Кичке бураннарда, урмандагы бердәнбер таш өй эчендә гармонь чыңлавын, яңа ритмнарны куәтләп, Алып аякларына яраклы тупас пималар идәнгә дөп-дөп баса, тәрәзәләрдән бөркелгән яктылыкка кушылып, тирә-юньгә җыр сибелә. Ух, Наташа күрсә иде бу биюне! Их, Наташа ишетсә иде бу җырларны, бу көлүне, бу тиле шау-шуны! Юк шул, килмәс ул монда, килмәс. Гаҗәеп тавышларга һәм кинәт калкып чыккан бу өйгә бары тик ераклардан үзып барышлый пошимы, әллә боланмы, белмәссең, озак итеп, сәерсенеп карап тора-тора да, мондагы тормышның мәгънәсен тәки аңлый алмыйча, үз юлы белән китеп бара.

Көндез монда динамит шартлый — һавага тау-тау балчык оча. Без шул балчыкны тачкаларга, носилкаларга салып ташыйбыз, кар һәм балчык белән буталган пычракка бата-бата котлован төбе чистартабыз. Котлован әзерләнгәч, нигез ташларын да үзебез салабыз, кирпечләрен дә үзебез тезәбез — дөнья безне күп төрле нәрсәләргә өйрәтте.

Әйе, башта кирәккә тотындык: кирәк безнең заманда, җир казып, сез яшәячәк дөньяның нигезен сала, хәзинәләр казып чыгара, самородок дип йөртелә торган бәхетләргә дә туры килә торган иде. Кирәкне кимсетмәгез.

Мастерок — кеше йөрәге төсле... Төзүченең иң изге хисләре шунда, сак булыгыз, рәнҗетмәгез. Тезәргә өйрәнеп, без кирпечләрне йөрәгебез, йөрәк каныбыз белән беркеттек... Рәнҗетмәгез.

Кирпеч — дөньяның нигезе. Юкка гына дүрт почмаклы түгел бит ул! — шәһәр мичләрендә кызарып пешкән хуш исле арыш ипие төсле. Яңа дөньяны без шул кирпечләрдән салдык.

Стеналарда — бөтен катлаулылыгы, каршылыклары, гүзәллеге, авырлыгы белән — безнең көннәр. Син алар белән сөйләшергә өйрән. Бар да син алар янына, аерып кара безнең бер көнне — аера алырсыңмы? Меңнәрчә гомерләр берегеп калган анда. Минем дә иң матур елларым шунда.

Поездан бер объект, меннән бер көн.

Ким дигәндә, өч метрлы стена. Тагын да өскәрәк күтәрелергә тиеш. Кран килгәч. Ул чактагын беләсең, краннар җитми. Ә күтәргә, һавадагы торнага, башка объекттагы кранга карап, тик ятарга риза

түгелбез. Такта баскычлар буйлап, кирпечне тачкаларда үзебез менгерәбез.

Стеналар бит агач баскычлар, ныгытмалар (русча «лес» дип кенә йөртелә) белән уратылып үсә. Йорттан йортка, цехтан цехка күчереп йөртелә торгач, алар искерә, туза, куркыныч була башлый. Яңаларын көтеп яту — шулай ук егетлек түгел безнең өчен. Юк икән, искеләрен куябыз.

Гадәттәгечә, һәркемнең үз эше — кем кирпеч, измә ташый, кем стена сала. Эчке яклап, агач күперләргә күп итеп кирпеч өелгән. Һаман ташыйлар. Без кирпеч тезәбез. Яныбыздан тачкалы ике кыз үзып бара. Тирә-якта көн дә була торган уен-көлке, тәгәрмәч дыңгырдавы, жыр. Гөнаһ шомлыгы — кинәт сүзләр дә, уйлар да юкка чыкты. Ни булганын уйлап, абайлап өлгергәнче, бөтен әйберләр, сүзләр белән бергә түбән очканбыз. Гөрселдәү колакка кереп тә өлгермәгән. Һушка килсәм — чыр-чу, елаш. Һаман аңламыйм әле. Күкрәк тинентен кирпеч арасыннан көч-хәл белән шуышып, үрмәләп чыккач, аермачык ишеттем: янда гына икән тавыш.

— Исәнбәк абый, коткар, Исәнбәк абый!

— Дядя Сережа, жаным, үләм!

Берсе — татарча, икенчесе — русча. Өсләрендәге кирпеч, измә һәм такталарны аяк белән, кул белән жан-фәрманга ыргыта башлыйм. Ә тавыш, аңны томалаган кызганыч тавыш, һаман ишетелә.

— Дядя Сережа, бүтәнчә булмый, түзалмыйм, үләм!

— Исәнбәк абый, жаным, тизрәк.

Төзелеш тулы кеше иде ләбаса, ник алар миңа гына кычкыралардыр, әйтә алмыйм. Ә бүтәннәр икенче төбәктә жыелышканнар икән! Ниһаять, актарып чыгардым. Берсе, кечкенәрәк буйлы башкорт кызы Мәрьям, үзе торып басты. Икенчесенең ярасы авыррак бугай, күтәреп алдым да киттем.

— Үзем, дядя Сережа, жәяүләп!

Үзем белмим, кая барырга тиешлегемне бүтән берәү кычкырды:

— Медпунктка!

Кулымда — бая гына уйнап-көлеп йөргән шаян кыз — Люся. Инде карышмый, бала төсле, күкрәгемә сыена:

— Дядя Сережа, арыдыңмы? Ял ит!

Ни диган сүз ул ару? Мин аның мәгънәсен үк белмим, атлавымны гына беләм. Медпунктка ким дигәндә бер чакрым! Карлы, чокыр-чакырлы кинлек буйлап — туп-туры... Күңелгә уй да керә башлады — әллә нинди буталчык сораулар: хәзер мин күтәреп барган кыз нишләп Наташа түгел икән? Ул аңа охшап та карамаган. Ник алай икән? Яшьяшь кыз язмышын кулларымда алып барам. Ник ул Наташа язмышы түгел икән?

Курыкма, шаян кыз, ят булсаң да, очраклы гына дустым булсаң да, исән-сау илтеп житкерәчәкмен, син яшәячәксең, элекке кебек үк шат, бәхетле булып яшәячәксең жирдә. Шулай да... Наташа түгел син. Наташа еракта, еракта.

Наташа!

Китәсе көнне калдырган язуда: «Дуслыгыбызның ахыры шушы димәсәң, озатырга төш», дигән идем. Килмәдең, әллә хатны тапшырмадылар инде. Китүемнең сәбәбен үзең беләсең. Шунысын гына белмисең: үпкәләшкәндәй сөйләшми йөрүебез, сөйләшкәндә дә чит кешеләр кебек «сез» дип эндәшүебез, күзләреңнең әллә нинди әйтелмәгән мәгънәләр белән ямансу карап торуы түзә алмаслык жәзага әйләнде бит. Китми нишлисең шундый хәлдә? Ләкин хатларыма үк жавап бирмәссең дип башыма да килмәгән иде. Әллә теге кешене чынлап үк ярата башладыңмы? Әллә мине бөтенләй төрелерлек түгел дип исәплисеңме? Эх, Наташа, Наташа!

Медпункт.

Безне күргә врач та, сестра да аягүрә бастылар. Кызны кушеткага куйдым да сүзсез генә ишеккә атладым, китәм, янәсе. Ләкин туктаттылар:

— Ә үзегез?

— Нәрсә «үзем»?

— Утырыгыз. Сезнең аягыгыз...

Карасам, уң аяк кып-кызыл канга манчылган. Чалбар теткәләнеп беткән...

Үземнең җәрәхәт авыррак булып чыкты. Ярты ай стационарда яттым. Люся белән Мәрьям исә, ике-өч көннән терелеп, эшкә дә чыкканнар һәм яныма хәл белергә дә килделәр. Люся егете белән иде. Елмаешып утыралар.

— Сез минем кадерле кешемне коткаргансыз, рәхмәт,— диде егет.

— Мәхәббәтемне дип әйт, курыкма,— диде Мәрьям.

Юк, елмаймасалар да, уен сүз түгел иде болар. Алар минем хәтергә гомерлеккә язылып калдылар.

Таныш түгел егет! Мин синең мәхәббәтеңне кирпеч, такта һәм таш арасыннан актарып, коткарып, кулларымда бала тоткан шикелле тотып, бәхетле язмышка илтеп тапшырдым. Ә менә үз мәхәббәтемне?!. Минем үз мәхәббәтем... Хәзер күзгә дә күренми торган, кайчандыр үзем җимерешкән иске дөнья хәрабәләре астында күмелеп калды бугай... Калды шул. Ләкин мин аны да актарып чыгарырга, коткарырга һәм үз кулларымда елларга алып китәргә тиеш.

Вакыты гына җитсен...

* * *

Ышангансыңдыр инде: эш урыннарыбыз, кайчак хәтта салынып бетә язган йортларыбыз белән бергә җимерелә-җимерелә, кабыргаларыбыз, аякларыбыз яраланды, сынды, ләкин гарипләнмәдек. Үкчәләребез, табаннарыбыз суелып бетте,— сызландык, еламадык. Вагоннарда, соңрак баракларда каныбызны кандала һәм бет суырды — үрсәләндек, бирешмәдек. Җирелмәдек. Ә менә күңелләрдәге микроблардан... Хәер, анысы соңыннан күренер.

Әллә кайда еракта без салган йортлар тезелә-тезелә шәһәргә үк килеп терәлделәр. Барлык стеналар, барлык биналарның бөтенесен бергә завод дип атадылар. Гудокларын дөньяга атаклы Морганнар, Рокфеллерларга җавап буларак яңгыраткан бу заводның үзенә хас искиткеч музыкаль исем дә табылды — аңа «Уралсталь» дигән сокландыргыч исем кушылды. Биналарын төзешкән меңнәрчә кешеләр шунда ук калдылар да — аның беренче эшчеләренә әверелделәр. Шуларның берсе — мин.

Бәхетлеме мин, бәхетсезме — әйтә алмыйм бугай, чөнки үз бәхетемнән баш тартырга, үзем өчен яшәүдән туктап, башкалар өчен яшәргә сүз бирдем инде. Сүземдә ахыргача торырмын дип уйлыйм, әгәр ялгышмасам. Минем өчен иң бөек бәхет — шул. Әйе, әйтә алам икән: иҗтимагый бәхетемне таптым, кешеләргә кирәкле мин, бик кирәкле. Наташа гына кайдадыр еракта йөри...

Башта цехта гади бер эшче булып эшләдем, бүтән цехлар өчен инструментлар әзерләүче булып. Ике-өч ай да үтмәгәндер, шул цехның начальнигы итеп куйдылар. Миннән дә кулай кандидатура юк дигәч, күндем. Тик эшли башлагач, белем җитмәве ачыкланды. Теләсәңтеләмәсәң дә, үзлегеңнән булса да укырга кирәк. Экономик, техник журналлар алам, газеталар укыйм. Ел чамасы вакыт уздымы, юкмы, баш инженер чакырып алды да:

— Ышанычлы кеше кирәк, күч управлениегә,— диде.— Берәү саботажник булып чыкты, самый кирәкле бүлектә.
— Кайсы бүлек?
— Производство-техника.
— Минем образованием житмәс бит.
— Житәр, укытырбыз.
Дөресрәге, баш инженер түгел, тормыш үзе мәжбүр итә иде укырга — куйгач, эшләргә кирәк, эшләр өчен белергә, укырга кирәк...

Шулай, үзем инженер, үзем машиналар төзелеше институтында читтән торып укыйм. Өйгә (кечкенә бүлмә) кайтсаң, өй тулы китап, журнал, сызымнар. Болар — безнең төп атрибутлар, өндә дә, төштә дә шул. Бүтәнчә яшәргә вакыт юк, искә дә керми чүп-чар.

Хәзер мин олыгайдым, басынкыландым. Мин хәзер үземне вактөяк кичерешләр белән борчымыйм, көчсезләндермим. Цехларда әйләнү тизлекләре секундына хәтле исәпләнгән машиналар, транспортерлар көче белән туктаусыз агылучы детальләр, көннәр һәм төннәр буе чыңлап торган инструментлар, мотор гуелдәве — сәгате-минуты исәпләнгән, бөтен ил, халык ихтыяры белән билгеләнгән һәм бары тик ул гына туктата ала торган шау-шулы бу тоташ агым — миллионнарча йөрәкләрнең иң гүзәл һәм иң якты өметләре, хыяллары... Бу — бүгенге һәм киләчәк шатлыкларның икенче төрле яшәве... Рухи кодрәтнең материаль көчкә әверелеше.

Производствоны, ил йөрәгенә тоташкан шул бөек агымны туктатмас өчен түгел, ә тагын да көчәйтү, тирәнәйтү, киңәйтү өчен директор яки баш инженер бүлмәсендә көн саен планеркага жыелалар — цехлар, бүлекләрнең иң җаваплы урыннарында торучы тимер холыклы кешеләр. Шуларның берсе — мин.

Көн саен бу кешеләр «стахановчылар» дигән горур исемнәр астында газеталарның күренекле урыннарына менеп елмаялар. Алар хакында радиодан сөйлиләр, китаплар, жырлар язалар, корыч күңелле дип зурлыйлар — матурлык төшенчәсе менә ничек бит ул — корыч хәзер чәчәкләрдән дә гүзәлрәк! Берсүзсез гүзәлрәк!

Бу елларда юллар мине туган якка, авылга да еш алып кайта, төрле күргәзмәләр карарга, тәжрибә уртаклашырга, яңа машиналар, модельләр, аппаратлар алырга шәһәрдән шәһәргә йөртә. Кыш һәм жәй урталарында Мәскәү көтә. Анда минем иң кадерле кешем — Наташа... Мин аны күрергә дә куркам хәзер... Ул инде ирдәдер... Институтны бетергәндер дә теге фәннәр кандидатына чыккандыр... Ә кайда яши икән? Янында без аерылышкан карт тирәк инде корыгандыр, мин аны таба алмадым. Ныклабрак эзләр идем, адрес юк...

Уйлый микән ул минем хакта? Уйласа да, минем хәтле сагынмыйдыр. Эх, Наташа, Наташа! Син очрамаган булсаң, сине яратмаган булсам, бәлки кемне дә булса очратыр һәм яратыр идем, болай ялгыз каз шикелле кангырып йөрмәс идем. Гаепле син минем каршыда, Наташа, бик зур гаепле!

Менә инде мин савыктым, сәбәбе ачык билгеле булмаган тынгысыз сагыш жиңелде. Дөнья яшь бала төсле елмая. Хәзер ни дә булса житмәсә, ул — син, Наташа! Күрешкәч, чын корыч булып чыныгуымны, йөрәгемнең таза, нык, дәртле булуын танысаң, һәм кабул итсәң — жир түгәрәк.

...Машиналар төзү институты дипломын алып чыккач, Мәскәү урамнары буйлап шулай йөргәндә, мине бер кеше туктатты:
— Исәнбәк, Исәнбәк, син бит бу?!
— Мин.

Күтәрелеп карасам, энәдән-җептән генә чыккан костюм эчендә мәһабәт гәүдә, эшләпә тулы — бәхетле чырай... Хәйләкәр соры күз-

ләр... Таныш бугай шул бу караш. Әйе, мин анын исемен дә хәтерләдем, тик әйтергә генә чирканам.

— Ә мин — Габбас. Оныттыңмыни? Дусларны алай тиз онытырга ярамый. Монысы — гөнаһ, зур гөнаһ. Кайда эшлисең?

— Заводта.

— Кем булып?

— Бүлектә, инженер.

— Гади инженер?

— Әйе.

— Син ничек алай... берүзең дигәндәй... Безнекеләр бит... ну, гафу ит. Өйләндеңме соң әле?

— Юк, вакыт җитми әле.

— Өйләнергә вакыт җитми, аһ-аһ-аһ! Нәрсә генә эшлисең соң син? Ну, алайса, кызлар белән типтерәсең! Ну, малай,* беркөнне берәү, икенче көнне — бүтән... Алай да ярый. Безгә кыенрак хәзер, менә, командировкаларда гына иркенгә чыгып алабыз, ужымга... Аһ-һа! Нишләп торабыз әле — әйдә китик — ничәдә очрашабыз? Миңа какраз иптәш кирәк. Мәскәү кызлары, ни хикмәттер, парлап йөриләр — берсе мешать итә... анысы сиңа булыр.

— Син... гафу ит...

— Нәрсә... монысына да вакыт юкмы?

— Әйе.

— Ну, син...

— Син... гафу ит — һаман да шул, бер үк кеше.

— Кем мин?

— Юк, кеше түгел, хәшәрәт!

Һәм борылып китеп тә бардым. Артымнан зәһәр тавыш куып җитте:

— Дур-рак набитый!

Ә Габбаслар — зирәк! Прагматистлар фәлсәфәсе — тулы килеш алар яклы. Арырак китсәк... Табигатьтә җиргә сыланып йөрүчеләр, сөйрәлүчеләр дигән олы бер бөтен класс бар — үз хокуклары буенча яшиләр... Ә нишләп андый төркем һәм хокук кешеләр арасында булмаска тиеш? Син аларны юк итәргә тырыштың...

Шулай, кемнәрдер күзе белән карасаң, җүләр бугай мин. Әйдә, булсын. Мин шул тилелегем белән бәхетле. Мин һаман да тормышка ашмаган мәхәббәтемне эзләп йөрим. Үзем чамалаган өйләрнең ишек алларына килеп басам да көтәм... Исемлекләрдән фамилиясен эзлим — өйдән өйгә барып.

Наташам минем, Наташам!

Сагынуым шул чиккә җитте, нидәндер гарьләнү, кимсенү хисләре белән кушылып, кинәт йөрәкне шулкадәр каты китереп кысты ки, авыртуга чыдый алмыйча, күзләрдән яшь агыла башлады. Үземне-үзем тыя алмас, белештермәс дәрәҗәгә җитеп, тиз генә гостиницага кайтып бикләндем. Бернинди шаһитсыз... Үзем һәм мәхәббәтем, бәхетсез мәхәббәтем белән бикләндем дә тотындым үксергә. Хәлдән тайганчы, күзләр яшьсез калганчы үкседем. Менә сиңа тимер йөрәк, менә сиңа корыч характер!..

Юк, болай ярамый, тизрәк заводыма кайтырга кирәк, тизрәк, тизрәк. Шунда гына минем тынычлыгым, шунда гына икән минем көчем, аерылырга ярамый икән аннан, ярамый, шунда гына минем җимерелмәс крепостем!

Илнең төрле шәһәрләренә барыгыз, төрле заводларына керегез — анда минем заводымның бер детале, бер җанлы аппараты гына булса да бар һәм ул — хәрәкәттә... Илнең иң ерак почмакларына, басуларына чыгыгыз — анда да сез безнең заводта башланган гөрелтене ишетерсез...

Хәзер инде мин юк, ләкин завод бар, ул булгач, мин бар.
Без ясаган машиналардан, без калдырган биек торбалардан һавага төтен күтәрелә. Күкнең зәңгәрлеген киметә, һаваның чисталыгын агулый дип, ямь-яшел үлән өсләренә, кызлар ирене төсле, кызлар күзе төсле чәчәкләргә корым булып төшә дип, сез тиргәрсезме ул төтенне?
Шул төтен — мин...

* * *

Үземне бар иткән туфрак белән саубуллашырга авылга кайттым. Сугыш үзенең чакыруын иң гүзәл, иң булдыклы ирләрдән башлады бит. Мин дә калышырга теләмәдем. Сиңа билгеле булган бу йөрәк белән тиз генә чакырмаслары билгеле булса да, тора-бара чират житәчәк иде. Ләкин безнең заводтагыларга бронь бирә башладылар, ә аннан кузгалам димә. Сонлаганчы, заводтан, шәһәрдән китәргә булдым, сезнең янга хушлашырга кайттым.
Дөньяда яши торгач, күп кешеләр белән очраштым, күп җирләр күрдем, бөтен илне үземнеке итеп йөрсәм дә, сугышка аны күрмичә китә алмадым. Без бит, бүтән чакта оныткан төсле гамьсез яшәсәк тә, иң авыр чакта аналарыбызны искә төшерәбез. Минем анам юк, туган җирем бар.
Кайтышлый ук ындырдан бер уч туфрак алып кәгазьгә төрдем дә сумкага салдым — аннан ул юл капчыгына күчәчәк — үзем белән мәңге бергә калачак, моннан соң туган җирдән мин мәңге аерылмаячак. Аерылу дигән төшенчә үзенең көчен җуячак: бер уч туфрак, дөньяның әллә кай почмакларына барып чыкса да, җир өстенә минем белән бергә ятачак — мәңгелек тынлык шикелле.
Ходайның хикмәте — шул фикер башта туып урнашкач, миннән үлем куркуы да бөтенләй качты — мин бөтенләй азат кеше булып калдым.
Тулысынча ирекле кеше мин!
Анам кабере белән хушлаштым. Бергә үскән апам авылына киткәндә, атам белән хушлаштым. Бичара ата! Элекке усаллык, элекке тупаслыкның әсәре дә калмаган анда. Зәңгәрсу күзләрендә яшь мөлдери, һәм алардан ул инде оялмый да. Мин сугышта югалгач, бу күзләр күрмәскә әйләнәчәк — тик мин моны белмәячәк. Мин бу кайгыдан да азат. Ак сакаллы һәм киң җилкәле карт, дөнья мәшәкатьләре кушканча, таягы һәм ак йон эшләпәсе белән генә киңәшә-киңәшә йөри торгач, үзе дә мәңгелеккә туган туфрагына ятачак. Бу кайгы да килеп житмәячәк һәм үлемнән дә яманрак авырту белән йөрәккә чәнчемәячәк. Мин бу авыртудан да азат. Әй бу Азатлык!
Туган авылым кебек үк якын тагы бер авыл бар икән — шунда туктадым. Апам әнигә охшап калган. Шушы яшендә үлгән иде әнкәм. Балалар — минем энеләрем — үскәннәр. Иң өлкәне кыз бала — бүтән авылда дөнья көтә, ике егет армиядә, ихтимал... әллә ниләр ихтимал. Унике яшьлек бала — өйдәге ир затыннан иң өлкәне — анысы син, Вәкил. Синнән башка алты-җиде яшьлек тагы ике малай гына калган. Урман ышыгында, әрекмән астына качкан куян балалары кебек, яшәп ята идегез.
Мин килеп кергәндә, өстәл янында кечкә чәй парланып тора иде. Түтәйне таныдым, сезне, балаларны, төсмерләдем: шунда ук бер хатын-кыз һәм... сискәнеп туктап калдым. Ишектән кире чыгаргамы, түргә узаргамы — ни уйларга да белмичә шаккатып тик торам. Бу кыз! Таныш, таныш ул миңа... Аксыл чәчләр, сөрмәле зәңгәр күзләр... тыныч һәм акыллы караш. Ул да мине таныды бугай. Таныды да — бу уйламаган, көтмәгән очрашудан каушап, башын иде. Шул бу, шул — Наташа! Нишләргә? Кире борылып чыгып булмый — балалар

минем жилкэгэ асылындылар — түргэ өстерилэр. Түти дэ торып исэнлэште — шатлыгы эченэ сыймый:

— Сине дэ күрер көн бар икэн! Эй, Исэнбэк. Исэнсең икэн! Рэхмэт, кайтуыңа рэхмэт, онытмавыңа. Эйдэ, уз...

— Син каян кайттың, абый? — диден син.

— Без синең белэн балыкка барабыз! — диде икенче энем.

— Эйдэ, уз инде...

Эйе, мин уздым. Өстэл янына килдем дэ русчалатып эндэштем:

— Здравствуй, Наташа.

Ул элеккечэ үк ягымлы, мэгънэле итеп елмаеп куйды. Мин аннан русча сүз көттем. Э ул татарчалап:

— Исэнмесез, кайтуыгыз белэн,— диде дэ урыныннан торып кул сузды.

Наташа түгелмени ул? Безнеңчэ, татарча сөйлэшергэ өйрэнгэнме? Ай, жүлэр, ай, мин жүлэр — каян килеп чыксын ул монда — кем янына — кемне белэ ул монда! Э шулай да күңел дигэнең бу кызның Наташа булып калуын тели.

— Сезнең исемегез бит...

— Нэркэс.

— Э! Шулаймыни! Нэркэс! Барыбер охшаган.

— Кемгэ? Сез... ымсындыгыз инде эллэ...

— Болай... Мин ялгыштым. Гафу итегез.

Ярый эле, Вэкил, син тиз генэ кулга сабын тоттырдың һэм су салаҗала юындырырга керештең. Салкын су таркау күңелне дөньяга кайтарды. Хэл керткэндэй итте. Бөтенлэй икенче күтэренке тонга күчеп, чэй эчтек. Сөйлэшэ-сөйлэшэ төн буе яттык. Нэркэс белэн лэм-мим сүз юк. Ай буе без аның белэн шушылай бер түбэ астында ничек яшэрбез икэн?

Нэркэс... Мин аның хакында уйларга да куркам. Күзлэренэ ялгыш карасам, бөтен барлыгым белэн каушап, калтырап китэм. Нэркэс! Нинди кеше син? Кешене ожмахтан кудырган алма түгелме? Бер эйттем, биш кайттым. Мин ул алмага карарга, сокланырга тиеш түгел. Башыңны жуйсаң, кешелегеңне жуйсаң, аннан ни кала туганнар каршында? Шулай да...

Шулай да, бер өйдэ торгач, сөйлэшмичэ дэ килешми. Ул яшэгэндэ өй тулы керосин, шырпы кабыз — дөрт итеп кабынырга тора дөньяң. Үзең дэ чыгып йөгерергэ өлгермэссең — пожар. Ай-яй, юкка кайттым мин монда, юкка. Ник эле мине шушы хэтле дэ яман ашкыну, курку били? Мин шундый ук тотнаксыз, бозык, вөждансыз кешеме эллэ? Мондый да түбэн төшү мөмкинме? Ул бит... Наташа түгел бугай бит! Тукта эле, мин хэлемне ачыклап карыйм эле. Һэр гөнаһның, һэр ялгышның теоретик нигезен табып акларга яратабыз бит без. Берэү эйткэн энэ: «Вөждан кешене гариплэндерэ»,— дигэн. Андыйлар өчен без гарип, э алар — безнең өчен. Телэсэ ни хакында сөйлэргэ мөмкин, эмма вөжданнан азат итмэгез мине! Вөждан — минем табигый талантым. Мин бу талантыма моңарчы һич тэ хыянэт итмэдем. Тэүбэ, тэүбэ!

Кичке авыл.

Койма янындагы урам як утыргычка утырдым да каршымдагы куакларга карап тын калдым.

Ике агач арасына аслы-өсле ике ботак һэм аларның яфраклары эллэ нинди сэер сурэт барлыкка китергэн — кыз рэсеме. Өстэн төшкэн чэчлэр астарак бөдрэлэнеп чайкала. Чигэ чэчлэре асылынып жилдэ тирбэлэ. Кашлар, күзлэр, керфеклэр... Кемнедер төсмерлим шикелле. Бу күзлэр сөрмэле бугай хэтта! Кем күзлэре соң эле бу? Хыялда гына күрергэ мөмкин булган тылсымлы иреннэр салмак кына жилдэнме, эллэ инде миңа ниндидер тылсымлы сүз эйтергэ телэпме — талгын гына селкенеп куялар. Кем сурэте икэн бу? Кемгэдер охшатам, эйтэ

генә алмыйм мәнә. Хәзер... Таптым! Таптым! Наташа бу! Әллә сәрби, әллә чаган яфраклары, шул кыяфәттә ярашып, аның төсен тудырганнар! Бу — онытылган, кайдадыр ерак калган кыз... Хәтерлим, бу — минем бәхетсез мәхәббәтем, бу — минем чая, ләкин беркайчан да сүрелми торган мәхәббәтем — Наташа! Наташа! Син дә бармыни әле! Син исәнмени! Нишләп шулкадәр озак күренми йөрдең әле син? Чынлап та шул акыллы һәм шактый сәер кыяфәтле симезеңне гомерлеккә ярата алдыңмы? Мин моның мөмкин түгеллегенә гомерем буе ышанып яшәдем. Син акылга килерсең дә, бу фани дөньяда күпләр бәхет дип атаган тыныч, ләкин мәхәббәтсез тормыштан качарсың да минем тормышыма килеп керерсең, бүген булмаса, иртәгә ишегемне кагарсың дип көттем. Инде булмады. Инде — безнеке генә, аерым кешеләрнеке генә түгел — бөтен халык өе — без үз кулларыбыз белән төзегән бөек сарайга фашистлар ут төртте, яна! Инде моннан соң да өметләнү туры мәгънәсендә җүләрлек булыр иде. Ә мин үземне бары тик бәхетсез гашыйк дип кенә йөрим.

Шулай, сөекле кешем, син миннән баш тартканнан соң, мин беркемгә дә сиңа караган кебек карый алмадым. Күзләрем синнән дә гүзәлне таба алмады, колакларым синең тавышыңнан һәм сүзләреңнән дә ягымлырак тавыш һәм сүзләр ишетә алмадылар. Еллар буе яңа мәхәббәткә үземне күндерергә дигән максатыма ирешә алмагач, мин гомумән сөюдән, гаилә тормышыннан баш тарттым. Минем бүтән максатым өстенлек алды — бөтен барлыгым белән бирелерлек бу максат — илдәге барлык кызларны да синең кебек бар яктан да гүзәл булырлык хәлдә яшәтү өчен, минем кебек, мәхәббәтләрен югалткан кешеләр синнән башка кешеләрне табарлык рух һәм тән матурлыгына ирешсен өчен — мин үземнең кечкенә бәхетемнән баш тартырга тиеш. Моңа теләсә кемнең көче җитми. Ә менә минеке җитте — корыч белән эш итә торган геройлар буыныннан идем — алар ярдәм итте. Мин дә корычка әйләндем... Мине «аскет» дип мыскыллаучылар булды. Тик, Наташа, сиңа булган коточкыч олы, ләкин тәнсез мәхәббәтем тудырган аскетизм гына бу. Ә син мине яратсаң!

Шушы көнгә чаклы газапка охшаш авыр тойгы белән таныш булмадым. Ләкин хәзер... Гади тормыш кичергән бүтән беркем дә аңлый алмаслык хис кичерә башладым. Минем хәлне ай буе бер кабым ризык төсе күрми интеккән, хәлдән тайган кеше генә аңларга мөмкиндер. Менә шул ач кеше алдында, өстәл тутырып, иң затлы эчемлекләр һәм ашамлыклар куегыз да — аңа бары тик карарга гына рөхсәт итегез. Кеше алам дип сузылса, җимешләр каядыр тәгәрәп югала, су юкка чыга — минем сөю бәхетем шикелле... әкияттәге төсле. Шул кешенең күзләренә, бөтен торышы, кыяфәте, хәрәкәтләренә карап торыгыз. Сез ул кешенең хәлен аңласагыз, бәлки минекен дә күз алдына китерә алырсыз. Гомерем буе, аңлы рәвештә үз-үземне менә нинди хәлгә куйганмын икән мин!

Менә мин аңа: язмышыма, мәхәббәтемә, ерак бәхетемә — юк аның бары тик үзем уйлап чыгарган, яфраклар берләшеп тудырган хыялый сурәтенә карап утырам. Наташа рәсеменә! Наташа! Татарча Нәркәс... Менә ничек икән! Наташа минем тормышыма Нәркәс кыяфәтендә килеп чыккан икән ләбаса! Бәлки үз законнарын танымаска тырышканга күрә табигать аны миннән үч алу, яисә сынау өчен җибәргәндер? Авылдан китеп йөргәнгә рәнҗеп, туган җирем шулай үч кайтарадыр!

Наташа!

Каян килеп чыктың әле син бу авылга, бу тормышка? Кемнәр иҗат итте сине? Уйлап карыйк әле, акыллым.

Мин бүтән язмышка таба киткән чакта син юк идең. Аңа чаклы да сине монда беркем дә күрмәгән. Каян, кайчан килеп чыктың син монда?

Син миңа болай җавап бирергә тиеш:
— Син киткәч.
— Кемнәр, ничек бар итте сине?
— Сез.
— Ничек?
— Анысын үзегез дә беләсез.

Шулай, чамалыйм мин моны. Менә болайрак чамалыйм һәм ялгышмыйм дип беләм.

Синең төсең, кыяфәтең ромашка шикелле. Тыйнак, саф, чиста, ап-ак, нәфис һәм озынча. Мондый гармонияне борын-борын заманнардан ук аңлаганнар, җырлаганнар һәм алла сыннары итеп, безнең чорга һәм аннан да арырак заманнарга таба сәяхәткә озатканнар. Кырда ат урынына сабан тартып, җилкәләрдә авыл өен тулаем күтәреп яшәгәндә андый гармония хакында уйламаска мөмкин. Моның өчен буразнага гына түгел,— йолдызларга, сәнгатькә, фәнгә, тормышка, бәхеткә, көяшка багарга кирәк. Вакыт һәм күңел кирәк. Шундый вакытны — мәктәпләр, техникумнар, институтларны, сәнгать бәхетен — сиңа без китердек. Ромашка басуда үскәндә, ул — чүп үлән. Ә бакчада кадерләп үстерсәң — җир бизәге, җыр, сөю, бәхет. Синең өчен ул бакчаны без ясадык...

Без яшәгәндә, корыч һәм чәчәк бер дәрәҗәдә гүзәл төшенчәләр иде. Без тудырган корыч басуда тракторлар гөрелтесе булып ишетелде, туфракка, җиргә тирән үтеп, аннан син үсәчәк вакыт һәм киңлекләрне актарып чыгарды.

Әйе, Нәркәс, син — безнең иҗат. Менә мин, үз әсәренә карап сокланган даһи скульптор шикелле, сиңа карап рәхәтлек хисе кичерәм — иң бөек сәнгать белән ләззәтләнәм. О, Нәркәс! Сине ничек саклап калырга? Үз иҗатын җимереп, ваткалап ташлаган тиле художник хәлендә калырмын дип куркам мин. Ай куркам!

Шулай да, ялгышам бугай. Барыбер минем бәхетем — Наташа, Наташа. Мин сүз бирәм — синең хакта уйланган кебек беркайчан да уйланмаска. Бүгеннән соң. Ләкин нишлим соң әле мин? Наташа юк — бәхет юк... Һәм Нәркәс... Наташа! Тавышларың, көлемсәрлегең, зәңгәрсу күзләрең, аксыл ефәк чәчләрең шулчаклы таныш! Ләкин бу — син генә түгел, синең матурлыкны кай ягы беләндер дистәләргә кабатлаган бу гүзәллек каршында син үзең дә югалып калдың, Наташа! Әйе, әйе, син дә мине Нәркәс чаклы сихерли алмагансың икән бит. Юк, Нәркәс син генә түгел, ул бөтенләй бүтән, бөтенләй! Мин аны үземне алдар өчен генә синең исем белән атыйм хәзер!

Юкка гына кайттым мин монда, юкка гына. Ак тәүбә, кара тәүбә: күңелемдә борынлап өлгергән кыргый кош баласын мин томаларга тиеш. Күпме генә кызгансам да. Күзләремне чытырдатып йомып.

Шушы вакытта, чәчемдә нидидер бөҗәк буталуын сиздем дә башымны сыйпадым. Бөҗәк кулга эләкмәде — төшеп китте бугай. Аның хакында оныткач, бөҗәк тагын кыймылдагандай итте, тагын эләктерергә азапландым, тагын югалды, тагын буталды, тагын юкка чыкты һәм, кинәт хатын-кыз җорлыгы белән кемдер койма артыннан рәхәтләнеп көлеп җибәрде. Менә кем икән ул — «бөҗәк». Койма аркылы үлән белән шаяручы — Нәркәс! Тиле! Ни дип көләсең шулхәтле — тургай сайраган шикелле? Көләсең, кызый. Көлүнең азагы күз яше икәнен беләсеңме соң син?

— Сезмени әле бу?! — дидем гаҗәпләнүемне сиздермичә һәм шактый тыныч. — Әйдә, чыгыгыз алайса, сөйләшеп утырыйк.

Ул чыкты да утырырга теләмәде. Мин дә бастым. Ә ул һаман елмая.

— Сез һаман көләсез,— дим мин.
— Еларгамы әллә?

Шулай диде дә утырды. Мин дә. Сүз сөрешен югалтмыйча, тагын сорадым:

— Тынлыктан туйдыгызмы? Сезнең монда...

— Ерак планетадагы шикелле...

— Кояштан иң ерак планета — карангылык патшасы. Исеме дә шуннан килә — Плутон. Мәңгелек караңгы. Кояш анда ай төсле генә күренә. Сезгә ай гына житми, кояш та кирәк. Шулай бит?

— Ә нәрсә, гаепме әллә? Без барыбыз да кояш балалары.

— Кояшка телескоп аша караганда каралткыч прибор аша гына карарга мөмкин — яндыра, югыйсә, күзне. Кояш белән шаярмыйлар.

— Янса янар иде әле.

— Сез чынлапмы?

— Мин каян белим.

— Ә мин беләм.

— Нәрсә?

— Агач югарыга омтыла, җимеш — аска.

— Һәр җимешнең — үз вакыты,— дип тә өстәгез,— диде ул баягы тавышы, тургай тавышы белән көлеп.

— Бал корты чагуын татымаган кеше бал тәмен белмәс,— дип сез миңа әйтә аласыз.

Кинәт аның көлүеннән җилләр исте. Наташа күзләре төсле зур зәңгәр күзләре зур булып ачылдылар. Бу карашта: «Мин бит шаярып кына сөйләшәм, ә сез житдигә борасыз», дигән мәгънә сүзгә әйләнмичә тукталып калган иде. Ә мин чынлап сөйләшәмме?

— Мин берсекөнгә районга барам,— диде Нәркәс шактый сүзсез утырганнан соң, нәрсәгәдер үкенгәнрәк, нәрсәнедер жәлләгәнрәк кыяфәт белән.

— Җәяүме?

— Җәяү шул. Каян килсен хәзер ат.

— Әйдә, үзем алып барам.

— Күтәрепме? — Ул тагын көлеп җибәрде. Бу минутта аның белән бары тик шаярып кына сөйләшергә мөмкин иде.

— Нәрсә сез, күтәрә алмас дип беләсезме?

— Я төшереп җибәрерсез.

— Кулга күтәргәнне ычкындырмыйм мин алай.

— Батыр!

Шактый тирәнгә китүе ихтимал булган әңгәмә, аллага шөкер, өзелде — өйдән, Вәкил энем, син чыктың да без теләсә нинди вак-төяк сөйләшеп утырдык. Һава чак кына болытлы. Җил дымлы, янгыр вәгъдә итә. Югартын, ниндидер бәрән тавышы чыгарып, күзгә күренми торган сәер аваз әйләнә.

— Күк кәҗәсе,— дип аңлаттың син моны. Ярканат иде бугай ул.

— Ишеткәнем юк,— дидем мин.

— Минем дә,— диде Нәркәс.

— Тартайны ишеткәнегез бармы? Арбалары бата да гел «тарт, тарт!» дип кычкыралар.

— Тагын нинди кошлар бар?

— И-и! — дидең син, нәрсәгәдер сөенгәндәй,— чуты-исәбе юк. Еrak-тарак гөрләгән тавыш ишетәсезме?

— Ишетәбез.

— Кыр күгәрчене. Шуның төсле итеп көртлекләр дә гөрләшә. Урман тутырып йөриләр. Көйгәләкләр чырылдый. Көндез әнә теге каеннарга ышыкланып, ботакта карчыга утыра — тавык-чебеш аңдып.

— Тота дамы?

— Килеп тә төшә, ялт итеп күтәреп тә кача. Әнә теге саз артындагы тауда — нарат... Мең яшьлек. Шунда аларның оялары. Балаларын менеп алабыз.

— Шулхәтле биеккә! Курыкмыйсызмы?
Нәркәскә гаҗәпсенеп карадым:
— Нәрсәдән?
— Егылудан.
— Бер малай егылды, чигәсе тишек калды.
— Ә сез һаман да менәсезме? — дидем мин дә гаҗәпләнеп.
— Менмичә, менәбез!
Адәм балалары! Без барыбыз да шулай!..
Ярты төнгә кадәр утырдык. Син безнең яннан китмәдең. Минем өчен шулай хәерлерәк иде.
Икенче көнне Нәркәснең район үзәгенә җыенуын күреп, вәгъдә буенча, велосипедны урамга чыгарып, аны капка төбендә каршыладым. Башта «утырмаса ярар иде» дигән уй. Мин бит аңа күңел чынлыгы өчен генә тәкъдим иттем. Юк, баш тартмады. Кая ул! Иртәнге көн төсле елмайды да руль алдына килеп тә утырды.
— Ексам, үпкәләмәгез,— дидем «әллә төшәсезме?» дигәнрәк тавыш белән.
— Егылсаң, яхшы аттан егыл,— диде Нәркәс, җавапсыз калмас өчен генә.
Һәм киттек.
Миңа Нәркәс белән күңелле, мин аны аңлыйм. Үземне басынкы тотарга тырышкан хәлдә, район үзәгенә көн саен диярлек илтә торган булдым һәм бу сәфәр икебез өчен дә бәйрәмгә әйләнде. Бәйрәмне мон белән бизәр өчен мин аңа мандолина алып бүләк иттем.
Әйе, аның ни уйлавын, нәрсә ишетергә теләвен мин бик яхшы сизәм, шулай да җавап бирмим: ничек кенә үземне алдарга тырышсам да, ул барыбер Наташа түгел бит һәм... ир хатыны... Аны мин тиргәргә, оялтырга тиештер. Тик көчем җитми — кайда ул көч! Юк. Алай гына да түгел, шушы тиле караштан исерткеч шатлык, юаныч алам — бу бит инде соңгы юанычым, соңгы... чак мәхәббәтем дип ычкындырмадым. Әллә шулай ухмы? Миңа инде дөнья бүтән бернинди дә мәхәббәт вәгъдә итми — ул бары тик шушы тилелекне генә тәкъдим итә һәм бу да гаҗәп кыска вакытка... Теләсәң нишлә — сөю шатлыгының нәрсә икәнен белми үк китәргә мөмкин дөньядан... Теләсәң нишлә, теләсәң нишлә... Күзләремне чытырдатып йомып... юк, булмый миннән, кабул итә алмыйм... Юк! Юк!
— Ах, Наташа, нинди яхшы син! — дидем мин бер чакны Нәркәснең чәчләреннән сыйпап,— Наташа! Сине табигать ялгыш бүтән кеше белән бутаган, мәңгелеккә бутаган, Наташа! Мин икебезнең дә кешелек дәрәҗәбезне рәнҗетмәслек, кимсетмәслек, гаепсез ярату белән, ак мәхәббәт белән яратам.
— Мин яратам!..
Вакыты җиткәч, җаным сездән еракта булыр, еракта. Мәңгелек тәмугта, һич булмаса хыялда, хәтердә, тынгысыз өермәләр очырып йөрткән Паоло һәм Франческа[1] янында тагын бер пар — акылга һәм йөрәккә хыянәт иткән ике күләгә барлыкка килсә, аларның исемнәрен белегез — Наталия һәм Исәнбәк!!!

* * *

...Күпме кешеләр, яшерен мәхәббәт белән янып, гомер буе татлы газаплар кичерәләр... Ә мин моңа сәләтле кеше булып чыкмадым. Яшерен мәхәббәт миңа ләззәт китермәде, әйтерсең, үз йөрәгемә хәнҗәр кадаганмын да хәзер аны тартып чыгарырга көч табалмыйм — үзем исән, хыялга да китерергә мөмкин булмаган авырту, җәрәхәт...

[1] Паоло һәм Франческа — Данте Алигьеринын «Иланы комедия»се персонажлары.

Үзем — судья, үзем — гаепләнүче...

Инде беләм, бәхетем минем бер генә канатлы булып чыкты, икенчесен мин аның таба алмадым — гаебем шунда. Ә бер бәхетсезлек икенчесен тудыра. Бәхеткә ирешү — кешенең үз эше генә түгел, ә социаль бурычы. Мин шул бурычны үти алмадым, сыңар канат белән дә очарга мөмкин дип ялгыштым. Дөньяда бәхеткә өметен җуйган кеше — таң бүресе...

Ишетегез, туган җирләрем, якташларым!

Мин үземнең гаебемне үлемем белән кайтардым, соңгы минутымача тынгы бирмәгән бәхетсез мәхәббәтне үз үлемем белән үтердем, җиндем...

Мин сезнең өчен дә үлдем — сезнең балаларыгыз, бүгенгегез, киләчәгегез өчен.

Хәтерләрдә, кинохроника пленкаларында — экраннарда сугышчылар күрсәгез, белегез, шуларның берсе — мин.

Хәтерләрдә, экраннарда терелеп, солдатлар атакага күтәреләләр, разведкага баралар, кышкы салкын окопларда, буран уртасында яталар, походларга китәләр. Шуларның берсе — мин.

Хәтерләрдә, саргайган газета битләрендә, кино тасмаларында мәңгелеккә калган коточкыч картиналар — чәнечкеле тимер чыбык белән уратылып алынган лагерьларда — әсирлектән, ачлыктан, кыйналу, җәрәхәт, хәлсезлек, үлем авыруыннан битрәк, коллык гарьлегеннән кимсенеп, күзләрен, керфекләрен күтәреп күккә кагарга көчләре җитмәгән меңнәрчә корбаннар сакланыр. Шуларның берсе — мин.

Хәтерләрдә Бухенвальд, Майданек, Дахау дигән сүзләр яңгырар — набат шикелле, чакыру тавышы, чаң, кыңгырау тавышы шикелле. Аларга минем тавышым да кушылган.

Утын әрдәнәләре рәвешле өелгән гәүдәләр күрсәгез, вәхшиләр мичләргә өстерәп барган меңнәрчә мәетләр күрсәгез, белегез, шуларның берсе — мин.

Зәп-зәңгәр күк йөзендә, кояш яктысында җилпенгән кара күбәләкләр күрсәгез, курыкмагыз — мичләрдә мәңгегә калырга теләмичә, шул күбәләкләр кыяфәтенә кереп булса да, без өскә күтәрелдек. Туган җирләребездә сез бодай чәчәсе, күмер төсле туфрак өсләренә төшсәк, ак каен яфракларына, чәчәкләр өстенә кунсак, тиргәмәгез. Кырау да түгел, кабынырга торган очкыннар да түгел — төтен генә бит ул, төтен генә!

Шул төтен — мин...

Кыңгырау төсле чылтырап, тургайлар безнең теләкләрне кабатлар:

— Бәхетле булыгыз!

1968.

Рәис Сабиров

# НЕФТЬ ҺӘЙКӘЛЛӘРЕ[1]

*Шәһәр салыначак бирегә.*
**А. С. Пушкин.**

— Димәк, Җәлилгә сәфәр тотабыз? — Машинабызның хуҗасы яше әллә ни зур булмаса да күпне күргәнгә, күпне белгәнгә охшаган чая егет шулай дип сорады да диңгез дулкыны төсендәге өр-яңа «Волга» иртәнге чык кибеп тә өлгермәгән юеш асфальттан җәһәт кенә кузгалып китте.

Эшлекле ыгы-зыгысы, машиналар һәм тепловозлар шавы белән Бөгелмә артта калды. Элек өяз үзәге булган бу шәһәрдә искелек белән яңалык әле янәшә яши. Кызыл кирпечтән салынган, тимер рәшәткә куелган зур-зур тәрәзәле купец йортлары белән бер үк урамда заманча эшләнгән якты өйләр калкып чыккан. Элекке тар, караңгы урамнарны киң проспектлар кисеп үтә. Бөгелмә халкы үзенең яшәреп килүче бу шәһәрен ярата, аның революцион традицияләре белән, авыр көрәш елларында, гражданнар сугышы, коллективлаштыру елларында тоткан роле белән хаклы горурлана. Бөгелмәгә барсагыз, сезгә андагы музейны күрсәтми калмаслар, төрле вакытларда шәһәрдә булган вакыйгаларны бәйнә-бәйнә сөйләп бирерләр, анда оештырылган беренче кызыл комендатурада комендант ярдәмчесе булып атаклы чех язучысы, Совет иленең чын дусты коммунист Ярослав Гашек эшләгәнлеген дә искә алмый калмаслар. Биредәге рус драма театрын күрсәтерләр, аның шактый кызыклы үз иҗат йөзе, талантлы артистлары, традицияләре булган коллективы белән таныштырырлар.

Татарстанның нефть чыга торган иң бай районнарыннан бераз гына читтәрәк торса да, Бөгелмәнең, шәһәр буларак, шактый әһәмиятле транспорт төене буларак, культура һәм фән учагы буларак һәм, ниһаять, промышленность үзәге буларак бөтен тормышы нефть белән аерылгысыз бәйле. Бу шәһәрнең механика заводы һәм нефть аппаратлары заводы Әлмәт, Лениногорск, Азнакай промыселларын төрле машина һәм механизмнар белән тәэмин итеп тора. Биредәге Татарстан фәнни-тикшеренү нефть институты (ТатНИИ) нефть геологиясе, сыек ягулык ятмаларын эзләү, аны рациональ эксплуатацияләү, скважиналар бораулау проблемалары, нефть һәм газ чыгару өлкәсендә уңышлы гына эш алып бара. Хәзер ул үз профилендәге фән үзәкләреннән иң әһәмиятлеләренең берсенә әверелде. Анда берничә фән докторы, уннарча фән кандидатлары эшли. Бөгелмәдә оештырылган «Татнефтепроект» институты һәм «Татнефтегеофизика» тресты да республиканың нефть промышленностен үстерүгә шактый зур өлеш кертәләр.

Бөгелмә нефть промыселларына һәм бораулау предприятиеләренә килгән күп

[1] Ахыры. Башы 9 санда.

төрле йөкларне кабул итеп торучы транспорт капкасы булып та хезмәт итә. Нефть районнарына самолет белән килүчеләр дә Бөгелмә аэропортына төшәләр. Республикабызның башкаласы Казаннан гына да мәшһүр ИЛ-14 ләр биргә көненә унаруникешәр рейс ясый.

...Бөгелмә артта калды. Уктай туры сузылган асфальт юл буйлап төньякка барабыз. Күзгә урман эченнән атылып килеп чыгабыз да кинәт түбәнгә ыргылабыз. Пейзаж да кинәт үзгәрә. Юл кырлар буйлап сузыла. Күз аларны тыныч, йомшак буяуларга буяган. Бер якта кара-кучкыл масса булып яңа сөрелгән җир сузылып кала. Юл буена тигез рәт булып алтын сыман сары салам эскертләре тезелгән. Әмма бу тирәдәге җир кешегә ризык биреп, икмәк биреп кенә калмый. Биредә авыл хуҗалыгы һәм промышленность пейзажы бергә кушылган. Әлеге салам эскертләре янында нефть скважиналарының көмеш сыман буяуга буялган үлчәгечләре һәм траплары, товар паркларының зур-зур резервуарлары, нефтьне комплекслап әзерләү установкаларының (УКПН) түм-түгәрәк шарлары күренеп китә. Әнә олы юлга якында гына утыз метр биеклектәге бораулау вышкасы калкып тора. Без анда кичә генә булып, бригаданың кешеләре, эшләре белән танышкан идек. Бу установкада республиканың атаклы мастеры Александр Подберезный җитәкли торган коллектив «Җир тишә». Буровойдан аз гына арырак без тагын бер танышыбызны күрәбез. Монысы монтажчылар бригадиры, Татарстан нефтьчеләре арасында шактый атаклы кеше — Ильяс Кәримов. Ул бөтен тирә-юньне моторлар гөрелтесенә күмеп, салмак кына алга баручы унлап трактор алдына баскан да, оркестр белән идарә итүче дирижер төсле, тракторчыларга әллә нинди ишарәләр ясый. Тракторларның берничәсе буровой вышкасын алга тарта, икенчеләре, ул авып-нитеп китмәсен өчен, аны арттан һәм ике яктан тарттырып киләләр.

Юл шактый биек калкулык итәгеннән бара. Карабаш тавы дип йөртәләр аны бу тирәләрдә. Тау дигәч тә тау ук түгел инде ул — тигез җирдәч күп булса йөз-йөз илле метрга калкурактыр. Бу якларның хуҗалары — нефтьчеләр — Карабаш түбәсенә менәргә яраталар.

Аннан бөтен тирә-як уч төбендәге төсле күренә: бу төбәкне пәрәвез җепләредәй куе челтәр белән каплап алган тип-тигез юллар да, авыллар-поселоклар да, газ эшкәртү заводының күккә чөелгән колонналары да, колхоз басулары да, инешелгалар да...

Тауның нәкъ итәгендә, шакмак-шакмак кварталларын җәйлы һәм пехтә генә тезеп, Карабаш эшчеләр поселогы сузылып яткан. Янында гына — шундый ук исемле ясалма сусаклагыч. Халык телендә аны хәтта «Карабаш диңгезе» дип тә йөртәләр.

Үзенә күрә тарихы да бар ул «диңгез»нең. Моннан унике-унбиш ел чамасы элек Тимәш-Ромашкино нефть ятмасын чын-чынлап торып «эшкә җигү» иң кызып барган чакта чын мәгънәсендә суга сусаган нефтьчеләр теләге белән, алар акчасына булдырылган дәрья ул. Нефтьне җирнең аскы катламында ясалма басым тудыру юлы белән тизрәк өскә кудырып өчен бик күп су кирәк. Ул елларда яңгырдан соң үсә торган гөмбәләр төсле күзгә күренеп калка барган поселоклар һәм шәһәрләр өчен шулай ук бик күп су кирәк. Каян алырга ул суны? Язгы ташкын вакытында гына, күперләр-басмалар агызып, болын-басуларны басып киткән булып, бер «холыксызланып ала» да яз узгач яңадан юашланып ярларына кайта торган Зәй елгасы суы гына җитми моның өчен. Кара исәп белән генә булса да, чамалап карагыз: нефть промыселларына бер катламга кудыру өчен генә тәүлегенә ярты миллион кубометр су кирәк. Үзе бер диңгез бит бу! Дөрес, Татарстанның үз җире буйлап шактый мул сулы Кама елгасы агып үтә. Ләкин еракта бит ул: нефтьнең төп чыганакларыннан йөз илле-ике йөз чакрым чамасы. Аңа тикле җир астыннан трубалар сузганчы никадәр вакыт, моңа ни тикле металл кирәк.

Менә шунда туа инде бу фикер. «Вакыты җиткәч, Камага да җитешербез, торабара ансыз барыбер булмас,— диләр нефтьчеләр,— ә хәзергә шул Зәйне буа белән буарга да ясалма сусаклагыч ясарга кирәк». Әйткән сүз — аткан ук. Әнә бит тау итәгендә ничек дулкын уйната хәзер алар ясаган диңгез! Поселокларга һәм калаларга су бирә, якын тирәдәге насос станцияләрен «туендыра». Нефтьчеләр өчен бик тә әйбәт ял урыны да ул. Җәйге челләдә аның яр буйларында аяк басар да урын булмый: бар дөньясын онытып балык чиерттереп утыручы хозур-ләззәт табучы ир-

ат, кояшта кызынырга, су керергә яратучы хатын-кыз, бала-чага, спорт белән шөгыльләнүче яшь-җилкенчәк шунда палаткалар корып, мәш килеп яталар...

Безнең машина алга чаба. Олы юл буендагы авыллар бер-бер артлы артка кагалар.

Бу авыллардагы кысык тәрәзәле, салам башлы, җиргә сеңәргә торган өй-алачыклар кая киткән соң? Ул урамнарында көзен-язын ерып чыккысыз пычрак ничек кипкән? Әгәр бүген ул авылларның уртасыннан соры тасма булып асфальт юл сузылган икән, әгәр анда яшәүчеләр бүген үзләренең тормышын электр утыннан башка, радиоалгычтан, телевизордан башка күз алдына да китерә алмый икән, авыл абыстайлары, берсеннән берсен уздырып, газ плитасында алсуланып пешкән гөбәдия турында мактанышалар, ә малайлар безнең илдә чыгарыла торган барлык телевизор маркаларын яттан белеп, аларның кайсысы өчен нинди антенна кулайрак булуы турында бәхәсләшәләр һәм Лениногорск телестудиясенең дулкыны ничә километрга кадәр җитүен сезнең белән бездән күбрәк беләләр икән, әгәр болар барысы да әкият түгел, ә күз алдында ярылып яткан чынбарлык икән — болар барысы да биредә нефть табылуның, нефть промышленносте үсүенең нәтиҗәсе бит!

Әле без санап киткән нәрсәләрне үз күзең белән күрсәң дә ирексездән Максим Горькийны искә төшерәсең. Бөтен Россияне диярлек җәяүләп йөреп чыккан бөек язучы революциягә кадәрге нефть промыселларын: «Караңгы тамугның даһиларча эшләнгән картинасы»,— дип атаган. «Тәртипсез урнашкан вышкалар арасында эшчеләр өчен кызгылт сары һәм соры төстәге шомартылмаган ташлардан ашык-пошык салынган озын һәм тәбәнәк казармалар җиргә елышканнар, алар тарих башланганчыга кадәрге кешеләрнең торакларын хәтерләтәләр», дип яза Горький, Баку нефть промыселларында булганнан соң.

Без татар авылларыннан үтәбез. Исемнәре — Карабаш, Миңнебай, Габдрахман. Бу тирәләрдәге халык телендә еш кына ишетергә мөмкин булган легенда искә төшә. Явыз көчләргә каршы кыю тора алган, халык өчен көрәшүдән үзенә тәм тапкан курку белмәс Габдрахман батыр турында ул. Имеш, ул явыз көчләр игенчеләрнең кыр-басуларын юкка чыгаручы сазгак-баткаклар рәвешенә кергәннәр дә кешеләрне ачлык белән азапларга ниятләгәннәр. Уңдырышлы бик күп җирләр сазга әверелгән. Тәмам интеккән халык бу явыз көчкә каршы көрәшкә Габдрахман батырны чакырган. Озак еллар көрәшкән пәһлеван баткак-сазлар белән. һәм җиңеп чыккан. Ә изгелеккә изгелек белән җавап бирергә күнеккән халык шул батыр-пәһлеванның исемен мәңгеләштерергә булган — ул яулап алып биргән җиргә авыл салып, аңа Габдрахман исемен биргәннәр.

Ә хәзер Габдрахман батыр исемен шунда яшәүчеләр генә түгел, бу риваятьне ишетеп тә белмәгән йөзләрчә нефтьчеләр дә көн саен телгә ала. Тимаш-Ромашкино нефть ятмасының бер мәйданын — әйтергә кирәк, нефтькә иң бай булганын — шул ук исем белән: Габдрахман мәйданы дип йөртәләр. Бу мәйданнан «кара алтын» чыгаруны үзләренә гомерлек кәсеп итеп алган, әле кичә генә җир сөреп, бүген «нефтьче» дигән исемне горур йөртүче күп санлы операторлар, тезүчеләр, техниклар, транспортчылар шушы авылда яши. Авыл белән шәһәр, промышленность белән авыл хуҗалыгының бергә үрелүе менә шунда инде бик ачык чагыла: һәр өйдә диярлек промыселчы-эшче белән игенче-колхозчы бергә яшиләр. Семья башлыгы шундагы «Ярыш» колхозында комбайнчы яисә терлек караучы булса, аның хатыны яисә улы «Иркеннефть» промыселлар идарәсе предприятиеләренең берсендә эшли. Әле бер дә өйрәнелмәгән, социологларның ныклап уйлануын көтә торган социаль күренеш бу.

Без телгә алган Габдрахман батыр турындагы риваятьнең тагын бер ягы бар бит әле. Ул халыкның үз батырларына карата, үз каһарманнарының исталегенә никадәр турылыклы булуы турында сөйли. Геройлар исемен мәңгеләштерү турында сүз барганда, халыкның ни дәрәҗәдә юмарт һәм киң күңелле булуын дәлилли ул.

Биредә Маяковскийның «Нетто иптәшкә, пароходка һәм кешегә» дигән шигырен хәтерләү урынлы:

«Су түгел,
кан — безнең тамырларда.

Революерлар
лаңгелдәве аша
барабыз
һаман бергә.

Үлгәч, пароходларда,
җырларда
һәм башка
мәңгелек эшләрдә
гәүдәләнергә».

Тарихка билгеле һәм билгесез күпме каһарманын халык авыллар һәм калалар, пароходлар һәм заводлар, урамнар һәм мәктәпләр исеме итеп гәүдәләндергән, аларга таштан һәм граниттан, бронзадан һәм корычтан күпме һәйкәл салган!

Менә бүген шул халык үзенең тагын бер батыр улына, гражданины һәм шагыйренә, сугышчысы һәм әдибенә, — Муса Җәлилгә, бөтен кешелек дөньясының явыз дошманы булган ерткыч фашизмга каршы кулына мылтыгын һәм каләмен тотып соңгы сулышына кадәр көрәшкән кешегә тагын бер һәйкәл куя, аның үлмәс исеме белән атап тагын бер кала — Җәлил шәһәрен сала. Менә без бүген шунда барабыз. Дөресен әйткәндә, ул яңа кала безгә күптән таныш иде. Без аны шәһәрдә булачак кварталлар, бакчалар, йортлар һәм җәмәгать бинадары архитекторлар ватманына төшкән вакыттан ук беләбез. Ләкин бу тирәләрдә, нефть районнарына, килгән саен шунда барасы, күтәрелеп килүче Җәлилгә тагын бер тапкыр күз төшерәсе, анда яшәүче нефтьчеләр белән, аны төзүчеләр белән сөйләшәсе, андагы матур үзгәрешләр һәм яңалыкларны күреп алар белән бергәләп шатланасы килә.

Дөрес, Җәлил шәһәре әле үзенең мәһабәтлеге, зур масштаблары белән беркемне дә шаккатыра алмый. Анда әле берничәшәр километрга сузылган киң-киң проспектлар да, көне-төне халык өзелми торган зур вокзаллар, трамвай яисә троллейбус тукталышлары да юк. Поселокның бер башыннан икенчесенә ун-унбиш минут эчендә барып җитеп була. Ләкин эш зурлыкта гынамы соң? Җәлил үзенчә матур, игътибарны үзенчә җәлеп итә. Аның ерактан ук үзенә чакырып торган, зәвык белән эшләнгән капкасы, матур итеп ирекле планлаштырылган кварталлары, барак тибындагы вакытлы өйләрнең бөтенләй булмавы үзе генә ни тора! Җәлил барча яктан камап алган куе яшеллеге белән дә, үзенең яшьлеге белән дә матур.

Чыннан да, биредә һәр нәрсә яшь. Ул әле карталарга да төшерелмәгән. Поселокта урнашкан «Җәлилнефть» промыселлар идарәсе дә Татарстандагы промыселлар идарәләренең иң яшьләреннән берсе. Аның начальнигы Татарстан АССРның атказанган фән һәм техника эшлеклесе Галимҗан Әхмәдиев үзе дә яшь кеше. Нефтьчеләрнең өлкән буыныннан эстафетаны кабул итеп алган һәм аны уңышлы гына алга илтүче операторларның, инженерларның, техникларның күпчелеге яшьләр. Аларның эшләрендә, үз-үзләрен тотышында, тыелгысыз энергияле, темпераментлы, зирәк булуларында күренә бу яшьлек. «Җәлилнефть» идарәсе промыселларының берсендә Социалистик Хезмәт Герое Павел Федорович Савельев җитәкләгән участок бар. Бердәм, тату коллектив бу. Якын-тирәдәге авыллардан килгән дистәләрчә егетләр һәм кызлар бу участокта нефтьче-оператор һөнәренә өйрәнде. Участокның эше искитәрдәй ритмлы булуы белән аерылып тора. Биредә планнан тыш сыек ягулык алынмаган бер генә атна да, бер генә ай да юк. Тагын шунысы характерлы: участок кешеләре куелган максатны гамәлгә ашырмыйча калмыйлар. Савельев участогындагы операторлар, мәсәлән, үз алларына тик торучы, нефть бирмәүче скважиналар фондын бөтенләй бетерергә дигән бурыч куйдылар. Һәм республика нефтьчеләре арасында беренчеләрдән булып максатларына ирештеләр. Бер-бер хәл булып, берәр скважина сафтан чыкса, аның язмышын участоктагы барлык операторлар бергәләп кайгыртлар. Менә нәтиҗә: юбилей алды елында гына Павел Федорович участогы дәүләт заданиесеннән тыш мең тонна чамасы «кара алтын» бирде.

Җәлил шәһәре әле салынып кына ята. Анда әле хәзергә кешеләр тора башлаган күп катлы йортлар саны берничә дистәдән артмый. Ул әле поселок кына. Поселокта әле күп нәрсә җитешми. Ләкин нефтьчеләр инде аны, Әлмәтне, Лениногорскины, Азнакайны, Баулыны, Шөгерне, Карабашны, Актүбәне яраткан кебек яратәлар, аны мактап, анда яшәүләре белән горурланып сөйлиләр. Алар үз Җәлилләрен

яшьлеге өчен, гүзәллеге өчен, анық нәкъ менә шундый исем белән аталган булуы — Җәлил булганы өчен яраталар.

Инде хәзер Татарстанның нефть башкаласы дип йөртелә торган Әлмәт каласына күз салыйк.

Казаннан Бөгелмәгә очканда ул самолеттан бик ачык күренеп кала. Карталарда Дала Зәе (Степной Зай) дип аталып йөртелә торган елга буена сыенып ук урнашкан ул. Шәһәрнең төп магистрале — Ленин исемендәге проспект беренче булып күзгә ташлана. Җентекләбрәк карасаң, ул проспекттагы аерым зур биналарны да төсмерләргә мөмкин. Беренче чиратта, әлбәттә, мәһабәт колонналы Техника йорты. Аның каршындагы зур матур мәйданга күптән түгел генә куелган бөек Ленин һәйкәле, Ленин орденлы «Татнефть» производство берләшмәсе һәм «Әлмәтнефть» промыселлар идарәсе урнашкан административ бина...

Кубәүләр Әлмәтне акташ кала дип йөртәләр. Чыннан да ул шундый. Бәхете шул ак таштан булды инде ул шәһәрнең. Нефтьчеләрнең яңа шәһәрен төзү турындагы мәсьәлә куелгач һәм анық нәкъ менә элекке район үзәге булган Әлмәт авылы урынында салыначагы тәмам хәл ителгәч, төзүчеләрдә бик җитди бер сорау туды: нәрсәдән салырга соң әле бу Әлмәт каласын? Кирпеч заводы корыргамы? Әйе, бердәнбер шул юл. Тик бу бит бик озакка сузылачак. Кирпечне бүтән шәһәрдән китертсәк? Алай итәргә дә мөмкин. Төзүчеләр баштарак шулай эшләргә мәҗбүр булдылар да. Ләкин һәр кирпечең алтын бәясенә төшә бит алай иткәндә. Менә шул вакыт кемдер Әлмәттән ерак түгел Чупай тирәләрендә крестьяннарның күптән-күптәннән үз ихтыяҗларына ак таш чыгаруларын искә төшерде. Белгечләр моны тикшереп карыйлар да шаккаталар: чыннан да, булачак шәһәрнең капка төбенә куелган чын хәзинә ләбаса бу! Һәм берничә айдан Чупайда төзелеш өчен ак таш чыгару карьеры эшли башлады. Ә тагын бераздан Зәй буенда төзелеп ята торган яңа шәһәргә зур-зур кирпеч итеп киселгән, берминди өстәмә эшкәртү, тыштан штукатурлауны таләп итми торган менә дигән төзелеш материалы — Чупай тавы килә башлый. Хәзерге Әлмәтнең күпчелек биналары әнә шул таштан салынган да инде.

Шактый нәрсә салынган инде бу шәһәрдә. Төгәл саннары кирәксә, аларны шәһәр Советында әйтә алалар. Анда кермәсәң, Усман Закиров дигән агайны очратып сорашырга мөмкин. Пенсиягә чыккан бу иптәш шунда яши, шәһәр эшләре белән нык кызыксына ул. Әлмәт шәһәр Советы башкарма комитеты председателе булып озак еллар торгангамы, аннан соң шактый вакыт «Татнефть» производство берләшмәсенең начальник урынбасары сыйфатында еш кына шәһәр эшләре белән шөгыльләнергә туры килгәнгәме, Әлмәт турында күп кенә саннарны күңелдән белә Усман Закиров. Менә ул китергән кайбер саннар: 1859 елда үткәрелгән халык санын алу мәгълүматларына караганда, Әлмәт авылында 214 крестьян хуҗалыгы булып, аларда 1518 кеше яшәгән. Шуннан соң үткән чирек гасыр эчендә авылдагы кешеләр саны тагын 441 кешегә арткан. Ә хәзер Әлмәт шәһәрендә 80 мең чамасы кеше яши. Шәһәрдәге мәктәпләрдә һәр ел саен 2 меңнән артык нәни граждани беренче тапкыр парта артына утыра. Әлмәт шәһәрен салуга инде дәүләт 90 миллионнан артык акча тоткан.

Биредә, билгеле, аеруча җылы сүз — төзүчеләр турындагы сүз булыр. Шәһәрдәге йортларны һәм клубларны, мәктәпләрне һәм бала тудыру йортларын, магазиннарны һәм больницаларны, балалар бакчаларын һәм китапханәләрне, заводларны һәм фабрикаларны үз куллары белән салучы, салкын ташка йөрәк җылыларын кушып эшләп кешеләргә көн саен, сәгать саен сизелеп торган шатлык бирүче осталар турында мактау сүзе әйтмәскә һич мөмкин түгел.

Шәһәр салына башлауның беренче көннәреннән ук Әлмәттә яшәүче бер кеше бар. Аның исемен яшьләр дә, картлар да белә.

Рәшит Саттар улы Саттаров, Социалистик Хезмәт Герое — менә кем ул бөтен Әлмәт халкына билгеле кеше. Күпләр аны Рәшит абый дип кенә йөртәләр. «Татнефтестрой» комбинатында комплекслы төзү бригадасын җитәкли. Аның биографиясе — биредә, нефть краенда эшләүчеләрнең күбесенекенә охшаган биография. Яшүсмер чагында ук язмыш Рәшитне Урта Азия якларына илтә. Шунда, эссе якларда үсә, башлы-күзле була, балалар үстерә башлый. Кәсебе бик шәп аның — йортлар сала. Шул якларда гомергә торып калырга да күңелен күндергән була инде ул. Әгәр

туган яклар, яшел шәл ябынган каеннар, яңа өлгергән арыш саламының балачактан таныш тәмле исе бик сагындыра икән, туган авылның яшел болыннарыннан чикерткәләр сайравын тыңлый-тыңлый, ялан аяклап бер үтәсең, әле генә савылган җылы сыер сөтен эчәсең килә икән,— чираттагы ялыңны алып самолетка утырдың да киттең дә бардың.

Исәпләре шундый була Рәшит Саттаровның. Ләкин менә искиткеч куанычлы яңа хәбәр: Татарстанда нефть тапканнар! Ә зур нефть булган җирдә — Саттаров моны яхшы белә — яңа калалар, яңа поселоклар, яңа заводлар салырга кирәк. Шундый хәбәр ишеткәннән соң үз эшен яраткан, өстәвенә тагын үзенең туган җирләрен сагынган тезүченең күңел кошы ничек җилпенүен күз алдына китерү кыен түгел.

Һәм менә егерме еллап инде Рәшит Саттаров Әлмәт шәһәрен төзүдә катнаша. Аның куллары инде ничәмә-ничә миллион кирпеч, ничәмә-ничә миллион данә киселгән таш салган. Ничәмә-ничә йөз кешене ул йөрәк юмартлыгы белән төзүче һөнәренә өйрәткән. Меңләгән кеше аңа чын йөрәктән чыккан бик гади, ләкин бик ягымлы сүзне — «рәхмәт» сүзен әйткән. Ә үзе ул һаман да әле моннан егерме еллар элек ашык-пошык оештырылган беренче бригадасы белән Әлмәт авылы читендә беренче җыелма йортларны салып йөргәндәге төсле тиктормас, тыңгы белмәс кеше, нәкъ ул вакыттагы төсле, һаман яңалыкка атлыгып тора. Менә ничә ел инде Әлмәт халкы аны шәһәр Советына үзенең депутаты итей сайлый. Рәшит Саттаровның сайлаучылар белән очрашкандагы сүзе һәрвакыттагыча гади, тыйнак, эшлекле һәм кыска була:

— Рәхмәт, якташлар, ихтирамыгыз өчен. Мин аны көчемнән килгәнчә акларга тырышырмын...

Әлмәт тә әле яшь шәһәр. Моннан берничә ел элек кенә үзенең уньеллык юбилеен билгеләп үтте. Ул тиелгысыз яшьлек ярсуы белән зурая, киңәя. Һәм, әйтергә кирәк, аның өлгергәнлек аттестаты да бар инде. Бу өлгергәнлек һәрнәрсәдә үзен сиздерә. Барыннан да бигрәк анда яшәүче нефтьчеләрнең эшендә. Шәһәрдә хәзер дүрт промыселлар идарәсе бар: «Әлмәтнефть», «Елховнефть», «Әлкинефть», «Ямашнефть». Болардан тыш «Әлмәтбурнефть» тресты, газ эшкәртү заводы, «Татнефтестрой» комбинаты, «Татнефтегаз» тресты, шиннар ремонтлау заводы һәм башка зур һәм ваграк предприятиеләр эшли. Алар барысы да теге яки бу күләмдә нефть чыгаруга бәйләнгән, Татарстан нефтьчеләре куйган төп максатка — бөек юлбашчыбыз В. И. Ленинның тууына 100 ел тулу елында «кара алтын» чыгаруны 100 миллион тоннага җиткерү максатына хезмәт итәләр. Нинди символик саннар: юлбашчының йөз еллыгына — йөз миллион тонна! Бик җитди бу бурычны үтәүнең төп авырлыгы Әлмәттә урнашкан предприятиеләр җилкәсенә төшә. Бу исә, иске ятмаларда ягулык чыгаруны интенсивлаштыру белән беррәттән, яңа ятмаларны да эксплуатациягә кертүне таләп итә. «Татнефть» берләшмәсе составында әле күптән түгел генә оештырылган һәм Ромашкино ятмасыннан көнбатышкарак урнашкан чыганакларны үзләштерергә тиешле «Ямашнефть» промыселлар идарәсе нәкъ менә шул бурычны үтәргә тиеш тә. Якын киләчәктә «Ямашнефть» идарәсенең елына 5 миллион тонна ягулык бирүе көтелә. Әлмәттәге иң яшь предприятиенең мөмкинлекләре шундый булгач, башкаларың өлкәнрәкләре турында әйтеп тә торасы юк. Шулай да тагын ике сан китермичә һич мөмкин түгел: «Әлмәтнефть» идарәсе илнең нефть эшкәртү заводларына һәм «Дуслык» нефтьүткәргече буйлап Европадагы социалистик илләргә ел саен 20 миллион тоннадан артыграк «кара алтын» озата. «Әлмәтбурнефть» тресты бораулаучылары промыселчыларга елына ким дигәндә 650—700 мең метр яңа скважина тапшыралар.

«Бишьеллык планны — бөек Октябрьның 53 еллыгы көненә үтәргә!» — Бу лозунг Әлмәттә көннән-көн популяррак була бара. Шәһәр хезмәт ияләре КПСС Үзәк Комитетының, СССР Верховный Советы Президиумының һәм Министрлар Советының Истәлек Байракларының «Әлмәтнефть» промыселлар идарәсендә һәм Газ эшкәртү заводында мәңгегә калдырылуы белән хаклы рәвештә горурланалар.

Нефть тудырган шәһәр кызыклы, бай тормышта мәгънәле итеп яши: укый, спорт белән шөгыльләнә, әдәбият, музыка, рәсем сәнгате, театр белән кызыксына. Әлмәтләр Россия Федерациясенең стадионнарында һәм бозлы мәйданчыкларында шәһәр даны өчен көрәшүче «Буровик» футбол командасының һәм хәзер иң популяр спорт төрләреннән булып киткән хоккей осталарының уенын зур игътибар белән күзәтеп

баралар. Алар шәһәрнең стадионына, спорт залларына бик теләп йөриләр, ял көннәрендә күмәкләшеп чаңгы белән шәһәр читенә чыгарга, туристлык походлары оештырырга яраталар, балык тоту белән мавыгалар.

Әлмәт шәһәрендә академик Губкин исемендәге Мәскәү Нефть институтының кичке факультеты, Лениногорск нефть техникумының филиалы, бораулау кадрлары мәктәбе эшли. Нефтьчеләрнең Техника йорты, культура сарайлары һәм клублары теләсә кайсы шәһәр өчен бизәк булырлык. Әлмәтнең үз театры да бар. Бу талантлы иҗат коллективы составында Татарстан АССРның халык артистлары Зәкия Тунишева, Раисә Гобәйдуллина, республиканың атказанган артистлары Ләлә Садыйкова, Әгъзәм Галиуллин, Габделбари Гатауллин, Рамазан Ихсанов кебек бөтен республикага танылган сәхнә осталары эшли. Театр үз авторларын, үз репертуарын булдырырга омтыла, татар драматургиясенең күренекле әсәрләрен үз алымнары белән, үз традициясенә хас образлар белән сәхнәдә гәүдәләндерергә тырыша.

Нефть краеның башкаласы үзенең язучы һәм шагыйрьләрен, художник һәм җырчыларын, композитор һәм скульпторларын үстерә, аларны олы иҗат юлына чыгара. Биредә менә берничә ел инде Татарстан язучылары союзының бүлеге уңышлы эшләп килә. Аның хәзер 9 члены бар, бүлек тирәсенә уннарча яшь язучылар, үз каләмнәрен беренче кат сынап карарга омтылучылар тупланган. Рафаил Төхфәтуллин, Әдип Маликов, Гамил Афзал, Саҗидә Сөләйманова, Шамил Бикчурин, Сәет Кальметов, Энҗе Мөэминова кебек каләм осталарының повестьлары, шигырь-поэмалары, драма-хикәяләре белән Татарстан хезмәт ияләре генә түгел, бөтенсоюз укучысы да таныш.

— Безнең Әлмәт шундый инде ул,— дип шаярта КПССның Әлмәт шәһәр комитеты секретаре В. В. Ермаков.— Магнитлы шәһәр — бөтен кешене үзенә тарта. Инженерын да, төзүчесен дә, язучысын да...

Бу сүзләр, әлбәттә, беренче чиратта әдипләрдән Гариф Ахунов белән Рафаил Төхфәтуллинга кагыла. Аларның беренчесе Казанда, икенчесе Кенәрдә яши, повестьлар, хикәяләр яза иделәр. Шуннан тоттылар да Әлмәткә китеп бардылар. Биредә кайнап торган чын тормыш, нефтьле яклар романтикасы, кайчандыр артта калып килгән бу районнарны берничә ел эчендә бөтенләй танымаслык иткән кешеләрне якынданрак белү теләге, алар турында язу теләге чакырды аларны. Аларга адресның болай үзгәртелүе өчен үкенергә туры килмәде: «Хәзинә», «Хуҗалар» романнары, берничә пьеса, хикәя һәм очерклар — шактый зур багаж бит бу Гариф Ахунов өчен. Хәер, бу әйтелгәннәр бер Ахуновка гына кагылмый. Ә Рафаил Төхфәтуллин, Әдип Маликов иҗатлары нинди мул уңыш бирә! Ә алар тәрбияләп, өйрәтеп үстерә торган әдәби алмаш әдәбиятка нинди бай тормыш материалы белән аяк баса!

Нефть районнарында, аерым алганда, Әлмәттә яшәүче художниклар да рәсем сызу, күргәзмәләрдә катнашу белән генә чикләнмиләр. Үз тирәләренә яңача зәвыклы, уйлый белүче актив туплап, алар шәһәр урамнарының, бакча-стадионнарның, клуб-китапханәләрнең яңача оформлениесен эшләделәр, рәсем сәнгатен халык арасында киң пропагандалауны оештырдылар.

Моннан берничә ел элек ачылган балалар художество мәктәбе Әлмәт рәссамнары өчен зур җирлек булып тора. Аны ачу турында беренче тапкыр сүз чыкканда шик белдергәннәр иде: мәктәп кадәр мәктәп өчен җитәрлек кадәр укучыны каян табып бетерербез?! Анда укыр өчен бер теләк кенә җитми, талант дигән нәрсә дә булырга тиеш бит әле. Ә хәзер уку елы башланыр алдыннан шундый конкурс була ки, Әлмәттәге барлык бала рәссам булырга җыена икән дип белерсең. Мәктәпне оештыручылар уку бинасы табу, укытучыларның штатын ачыклау кебек мәсьәләләрне хәл итәргә өлгермәде, рәсем ясарга өйрәнмәкче нефтьче агайлар үпкә белдерделәр:

— Бу ничек килеп чыга инде, әллә без балаларыбыздан калышырга тиешме?

Бер нишләр хәлең юк, балалар мәктәбе каршында зурлар өчен кичке студия ачарга туры килде. Хәзер илледән артык оператор, бораулаучы, төзүче, газ чыгаручы сәнгать тарихы, композиция, скульптура, нәгыш сәнгате буенча шунда «сабак тыңларга» йөриләр. Дәресләрне Әлмәт художниклары нигездә җәмәгать эше тәртибендә алып баралар.

Әлмәт предприятиеләренең берсендә токарь булып эшләүче Григорий Маляров-

ка инде илле яшьтән артык. Ләкин чәчене чал кергән бу кеше яшьләрчә бер мавыгу белән мәктәпкә йөри, бер генә дәресне дә калдырмый. Аның этюдлары авторның туган табигатькә мәхәббәте, хезмәттәшләре — нефтьчеләргә ихтирамы турында сөйлиләр. Художество мәктәбенең үзендә быелга кадәр шактый сәләтле яшүсмер Михаил Вотяков укып йөрде. Ул быел мәктәпне тәмамлап чыкты һәм укытучылары аңардан киләчәктә әйбәт кенә рәссам чыгачак диләр. Михаилдан ике ел соңрак шул мәктәпкә, аның кечкенә студиясенә икенче бер Вотяков йөри башлады. Тиздән мәсьәлә ачыклана: студиягә кереп укырга Варфоломей Ильичка улы Михаил киңәш биргән икән.

Һәр шәһәрнең үз тарихы, үз бүгенгесе һәм үз киләчәге, бүтән беркайда да кабатланмый торган үз йөзе һәм, ниһаять, үзенә генә хас гүзәллеге була. Бу хакыйкать Татарстан нефтьчеләренең зурлыгы һәм әһәмияте ягыннан икенче шәһәре булган Лениногорск өчен дә хас.

...Биредә, шау-шулы зур юллардан, зур шәһәрләрдән читтә, яшь имәннәр үсеп утыра торган шактый биек калкулык итәгенә сыенып, зур вакыйгалардан читтә, даншөһрәт артыннан кумыйча, яңа Писмән исемле кечкенә генә бер рус авылының йортлары тезелешеп торган. Аксакаллар сүзенә караганда, авылга бу исем «письмо» («хат») дигән сүздән алып бирелгән, имеш. Риваятьләр сөйләвенчә, борын-борын заманнарда, власть башында патшалар утырып, илдә хаксызлык хөкем сөргән вакытларда, бу авылга властьлар каршында нидер гаепләре булган, кыю фикерле кешеләр килеп урнашкан. Билгеле, үз теләкләре белән түгел, ә сөрелгән кешеләр булганнар алар... Алар үз авылларында гына түгел, бөтен тирә-юньдә бердәнбер укый-яза белә торган кешеләр булганнар. Күрше авылларда яшәүче рус һәм татар крестьяннары волостьтагы янсә өяздәге түрәләргә гариза яздыру өчен, ә кайберләре еракта патшага хезмәт итүче солдат улына хат сырлап бирүне үтенеп, алар янына еш килә торган булганнар. Әлеге исеме дә, имеш, менә шуннан киткән: «письмо», «письмянка», «Новая Письмянка»...

Совет власте урнашып, район үзәге булып киткәч тә, Новая Письмянка гади бер авыл булып кала килгән, административ учреждениеләр урнашкан берничә биегрәк бинасы гына булган.

Авылның киләчәк язмышын Новая Письмянкадан берничә генә чакрым ераклыктагы, Шөгергә бара торган олы юл өстендәге Тимәш авылы читендә 1948 елда борауланып, моңа кадәр илдә күрелмәгәнчә бай нефть ятмасы ачылуны хәбәр итүче тарихи 3 номерлы скважина хәл итә. Шуның аркасында бу тирәләргә, чал Уралның шаукымы барып җиткән эреле-ваклы калкулыклар төбәгенә, зур илебезнең барлык почмакларыннан халык агыла башлый. Берничә йөз кеше яшәп килгән, шуларны түендырып, киендереп торырга гына күнеккән Новая Письмянкада кинәт урын кысаная башлый. Письмянка дигән авыл гомере буе йөрткән исеменнән ваз кичәргә, исеменнән генә түгел, гомумән авыл булуыннан ваз кичәргә, зур-зур йортлы, киң-киң урамлы, электрлы-радиолы, автобуслы-машиналы шәһәр булып үсәргә тиеш була. Безгә иң якын кешенең, безгә социализмны ачып биргән, коммунизмга юл күрсәткән, шуңа илтәчәк партиябезне оештырып биргән һәм, ниһаять, Идел буенда «кара алтын» эзләүне чын фәнни нигезгә кую турында беренче күрсәтмәләрне биргән кешенең — Ленинның исемен кушарга булалар яңа шәһәргә. Менә шуннан бирле ул шәһәр Лениногорск дип йөртелә.

Аңа, Лениногорскига, әле унбиш кенә яшь тулып килә. Ул үзендәге ун мәктәпне быел бетереп чыккан һәр укучысыннан берничә елга яшьрәк. Ул Казагыстанның һәм Алтайның чирәм җирләрендә беренче палаткалар барлыкка килүдән бер ел соңрак Лениногорск исемен йөртә башлады. Бу кала Җирнең беренче ясалма иярчennәреннән дә ике елга соңрак туа. Россия Федерациясенең Татарстан АССРдагы Новая Письмянка эшчеләр поселогын Лениногорск шәһәре итеп үзгәртү турындагы Указы 1955 елда кабул ителде.

Шул унбиш ел чамасы вакыт эчендә шәһәр көнләп түгел, сәгатьләп үсте. Шундый гына яшьтәге шәһәр өчен 50 мең чамасы халык — бу аз түгел инде.

Лениногорск үзенең өлкән агасы Әлмәткә караганда ике яшькә яшьрәк. Ләкин үзләренең эшләре ягыннан, өлгергәнлек дәрәҗәләре ягыннан алар — яшьтәшләр,

замандашлар, берүк шартларга куелганнар, бер үк бурычларны хәл итү өчен ярышалар. Бу, әлбәттә, аларның һәр икесенә беренче булырга омтылырга, кирәк урында үз шәһәреңнең уңышлары белән мактанып алырга, алай гына да түгел, аның бөтен яктан әйбәтрәк булуына чын күңелдән ышанырга һәм бүтәннәрне дә ышандырырга тырышырга комачауламый. Лениногорск кешеләре дә шундый. Алар Ромашкино-Тимәш нефть ятмасының нәкъ алар шәһәрендә төзелгән предприятиеләр тарафыннан эксплуатацияләнә башлавы, республикадагы иң өлкән промыселлар идарәсе — «Лениногорскнефть»нең һәм иң өлкән, иң зур бораулау тресты — «Татбурнефть»нең алар шәһәрендә булуы белән горурланалар. Татарстанда беренче автоматлаштырылган Зәй-Каратай промыселы кайда булдырылды? Лениногорскида. Нефть трубаларына парафин утырмасын өчен аларны эчтән юка пыяла каплау ысулы беренче тапкыр кайда кулланыла башлады? Лениногорск промыселларында. Ул трубаларны пыялалау өчен беренче предприятие кайда төзелде? Лениногорскида. Бу шәһәрдә яшәүче һәм эшләүче нефтьчеләр белән ныклап торып сөйләшеп китсәгез, алар сезгә мондый сорауларны һәм ул сорауларга бер сүздән торган кыска горур җавапларны бик күп китерерләр. Юк, шапырыну, мактану түгел, ә эш кешесенең үз хезмәт җимешләре белән горурлануы, аларның кан саен ишәя баруын күреп шатлануы бу.

Әйе, Әлмәт белән Лениногорск, бер-берсе белән ярышып, тәҗрибә алышып, булганнарын уртаклашып, бер-берсеннән калышмаска тырышып яшиләр. Аларның һәркайсының үзенчәлеге бар. Бу нәрсә шәһәрләрнең тышкы күренешләрендә дә сизелә. Аларда урамнарның, кварталларның планлаштырылуы, архитектура ягыннан башкарылыш үзгә. Әгәр Әлмәт (аның патриотлары үпкәли күрмәсеннәр тагын!) күп кенә урамнарының, кварталларының һәм бигрәк тә торак йортларының бер-берсенә охшаш булуы белән бераз оттырса, бу хәлне Лениногорскида күрмәссең. Мондагы ансамбльләр бер-берсен һич кабатламый, йортлар бер-берсеннән аерылып тора. Димәк, шәһәрдә архитектор фикере кыюрак эшләгән һәм кыюрак тормышка ашырылган.

Лениногорск шәһәре һәм анда яшәүчеләр өчен тагын бер нәрсә характерлы. Сез анда җәй көне барсагыз, барыннан да элек урамнарда яшелләкнең, аерата чәчәкләрнең бик күп булуына, аларның нинди зур мәхәббәт, нинди нечкә зәвык белән үстерелүләренә игътибар итәрсез. Чәчәк үстерүнең — аерата шәһәр урамнарында чәчәк үстерүнең — үзенә бер сәнгать төре икәнлегенә тагын бер тапкыр ышанырсыз. Юк, Лениногорск шәһәрендә бу эшкә махсус өйрәтелгән, шуның өчен акча алып ятучы чәчәк үстерүчеләр штаты юк. Болар барысы да җәмәгатьчелек эше, энтузиастлар эше. Кар эреп, җир кибү белән меңләгән шәһәр халкы, көрәк, тырма тотып, урамнарга чыга. Чәчәк утырту, аларга су сибеп тору, аларны саклау — мәктәп балаларыннан алып, пенсионерларга кадәр бөтен кеше эшенә әверелгән. Лениногорск халкының бу тырышлыгы инде үзенең чагылышын рәсми документларда да таба башлады. Россия Федерациясе шәһәрләре арасындагы ярышта алар мактаулы урыннарның берсен алып киләләр.

Шәһәр җәмәгатьчелеге, нефтьчеләр үзләре яшелләкне урам-скверларда булдыру турында гына кайгыртмыйлар. Алар торган өйләрен генә түгел, эш урыннарын да үзләре тәпләнеп утырган йорт итеп саныйлар. Промыселчыларның участокларында, культбудкаларында булсаң — бу сүзләрнең дөреслегенә ышанасың. «Лениногорскнефть» һәм «Иркеннефть» идарәләре промыселларындагы скважиналар, нефть җыю пунктлары, төбәк насос станцияләре яшелләккә, чәчәккә күмелеп тора.

Лениногорскида булсагыз, сез, әлбәттә, аларның стадионнарына бармый калмассыз. Гаҗәеп бер корылма ул. КПССның Лениногорск шәһәр комитеты секретаре Леонид Максимович Смагин аның турында бик күпне сөйләп бирер. Ник дисәң, ул үзе бу эшкә турыдан-туры катнашкан, алай гына да түгел, бу эшкә «җан өргән» кешеләрнең берсе. Сөйләгәндә үзен катнаштырмаса да, яшь операторларның, бораулаучыларның, төзүчеләрнең, инженерларның һәм техникларның, җитәкчеләрнең һәм гади эшчеләрнең — спорт белән кызыксынган, аның белән шөгыльләнергә теләге булган йөзләрчә кешенең шәһәрдә стадион булдыру идеясе белән чын мәгънәсендә янып йөрүләре, аны проектлаштырганда яшь «архитекторларның» төннәр буе тамак карлыкканчы бәхәсләшүләре, аннары һәр көнне кичләрен, хезмәт көне тәмамланганнан соң, йөзләрчә егетләрнең һәм кызларның, бернинди административ басымсыз һәм

үгетләүсез, стадион булачак мәйданга эшкә җыелулары турында әйтми калмас ул. Ә моннан соңгысын — 1966 елның кыш башында, ниһаять, әле төзелеп тә бетмәгән стадионда спорт уеннары, аерым алганда, хоккей өчен яраклы чын каток әзер булган көнне монда булган чын тантананы, яшьләрнең, бөтен шәһәр халкының ничек шатлануын,— без үзебез дә күрдек. Әле хәзер дә, стадион инде чын мәгънәсендә стадион булып җиткәч тә, аның турында кайгырту дәвам итә. Шул ук Леонид Максимович үзе, «Татбурнефть» трестының управляющие, ярышларда катнашучы Лениногорск спортчылары өчен, аерата шәһәрнең хоккей командасы өчен чын күңелдән «авыручы» Николай Михайлович Куликов, «Лениногорскнефть» промыселлар идарәсе начальнигы Николай Дмитриевич Сергеев физкультура һәм спортка кагылышлы һәр нәрсәдә ярдәм кулларын сузарга әзер торалар.

Лениногорскилыларның җәмәгать активлыгы турында сүз кузгалган икән, бер-ике генә сүз белән булса да тагын бер нәрсә турында — Татарстан нефте музее турында әйтми булмый. Республикабызда нефть чыгару промышленностеның барлыкка килүе һәм үсүенә кагылышлы бар нәрсәне — документларны, ветераннарның истәлекләрен, мемуарларын, шул заманнардан сакланып калган фоторәсемнәрне, газета-журналларда басылган хәбәрләрне, берәмтекләп, бөртекләп эзләү, җыйнау, системага салу, халыкка тәкъдим итәр хәлгә китерүнең ни дәрәҗәдә авыр, четерекле булуын әйтеп аңлату гына түгел, күз алдына китерү дә кыен. Ләкин бит шул эшләр барысы да эшләнде, бик әйбәт итеп эшләнде. Һәм барысы да әлеге дә баягы шул җәмәгатьчелек көче белән. «Лениногорскнефть» промыселлар идарәсенең техника бүлеге работниклары, КПССның һәм ВЛКСМның шәһәр комитеты работниклары көче белән эшләнде. Тырыша торгач, бинасы да табылды, стендлары да булдырылды, кирәкле җиһазлары да куелды. Халык аны рәхәтләнеп карый. Музей ел саен тулылана, байый.

Лениногорскида, әйтеп үткәнебезчә, «Лениногорскнефть» һәм «Иркеннефть» исемле ике промыселлар идарәсе, «Татбурнефть» тресты бар. Аларның еллар буе тупланган матур традицияләре, теләсә нинди катлаулы техник бурычларны хәл итәргә сәләтле квалификацияле инженер-техник кадрлары бар. Ничәмә ничә матур башлангычка, киң колачлы ярышка нигез салган коллективлар болар. Хәзер, юлбашчыбыз В. И. Ленинның 100 еллык юбилее алдыннан, «Лениногорскнефть» промыселлар идарәсе коллективы: «Бәйрәм елында 100 миллион тонна нефтьне тизрәк чыгару өчен»,— дигән девиз белән бик кыйммәтле ярыш ялкынын кабызды. Патриотик инициативага республикабызның барлык нефтьчеләре кушылдылар. Ә «Татбурнефть» тресты коллективы! Аның кешеләре күрсәткән матур эш үрнәкләрен саный башласаң, үзе бер китап булыр иде. Скважиналарны тизләтелгән ысул белән бораулауның пионерлары— шул трест кешеләре, нефть скважиналарын бораулаганда балчык измә урынына чиста су кулланып ничәмә-ничә мең сумга экономия ясаучылар — шул трест кешеләре. Бораулау установкаларын индустриаль ысул белән, эре блоклар ярдәмендә монтажлау ысулын табып, производствога кертүчеләр һәм шуның аркасында вышкалар төзү эшен бернича тапкырга тизләтүчеләр — шул трест кешеләре. Соңгы ике ел эчендә генә тирән девон скважиналарын тиз бораулау буенча бөтенсоюз рекордын гына бернича тапкыр яңарткан, бу тизлекне станок-айга 8 мең метрдан да арттырып җибәргән танылган осталар: Социалистик Хезмәт Герое Мөгалим Гыймазов, Богдан Гриник, Матвей Гриньнар — шул трестта үскән, шунда эшләүче кешеләр. Даннары бөтен илгә танылган вышкачылар бригадирлары Социалистик Хезмәт Геройлары Александр Тимченко һәм Гәрәй Баһманов та — «Татбурнефть» тресты тәрбияләгән белгечләр. Бу мәшһүр трестның Совет властеның илле еллык юбилее уңае белән КПСС Үзәк Комитеты, СССР Верховный Советы Президиумы һәм СССР Министрлар Советы Байрагы белән бүләкләнүе һич тә очраклы түгел...

Татарстан җиренә нефть алып килгән барлык яңалыклар турында, кайчандыр артта калган Кама аръягының йөзен танымаслык иткән барлык үзгәрешләр турында бәйнә-бәйнә сөйләп чыгу өчен бик күп язарга кирәк булыр иде. Моннан егерме биш ел элек Шөгердә беренче нефть ятмасы ачылудан соң үсеп чыккан эшчеләр поселокларының исемлеге генә дә бөтен бер дәфтәр бите тулырлык.

Нефть тудырган шәһәр һәм поселоклар күп алар. Ләкин аларның язмышлары

уртак: барысында да тормыш кайнап тора, барысы да нефтьчеләргә, кыен, ләкин кызыклы профессия кешеләренә хезмәт итәләр, барысы да күзгә күренеп көннән-көн матураялар, яктылыкка, культурага омтылалар.

Кыска гына итеп булса да, тагын бер шәһәр-һәйкәл турында берничә сүз әйтик.

Нефть тудырган башка шәһәрләргә охшамаган ул. Тегеләренең һәркайсы тирәсендә очрый торган детальләр — нефть вышкалары, нефть саклау резервуарлары биредә юк. Шәһәрдә син нефтьче дип күкрәк сугып әйтә торган бер генә кешене дә очратмассың. Шулай да шәһәрнең нефтькә турыдан-туры катнашы бар. Әлмәтне һәм Лениногорскины тудырган кебек үк, аны да нефть тудырган. Сизенгәнсездер инде, сүз мул сулы гүзәл Каманың сул як ярында калкып чыккан Түбән Кама шәһәре турында бара.

Хәзерге заман химиясен безнең көндә нефтьтән башка һәм аның аерылгысыз юлдашы булган нефть газыннан башка күз алдына да китереп булмый. Һәм ул, зур химия, Татарстанда инде күптән туды. Безгә таныш ак ташлы Әлмәттән ерак түгел, күп санлы биек-биек колонналарын күккә чөеп, Миңлебай газ эшкәртү заводы калкып чыкты. Ул тәүлек саен промыселларда нефть белән бергә җыелган 8 миллион кубометр чамасы газны эшкәртә. Зур химиянең икенче карлыгачы Казан органик синтез заводы фенол белән ацетоннан башлап полиэтиленга кадәр уннарча төр продукциясен илебезнең барлык почмакларына озатып тора. Һәм менә Кама буенда 1961 елда яңа нефтехимия комбинатының беренче ташы салынды. Ул ясалма каучук эшләп чыгару буенча дөньяда иң эре промышленность комплексы булырга тиеш. Предприятиедә каучукның бик күп төрле сортларыннан тыш аның мономерлары, автомобиль шиннары һәм органик синтезның бүтән продуктлары эшләп чыгарылырга тиеш. Предприятие өчен төп чимал — әлеге шул нефть газы.

Узган 7 ел эчендә Кама буенда шактый зур эш эшләнде. Төзелеш мәйданына тимер юл һәм шоссе юлы китерелде. Комбинатта күп кенә объектлар сафка кертелде. 1967 елда сыек газ эшләп чыгаруга җайланган Үзәк газ фракцияләү установкасы эксплуатациягә бирелде. Предприятиене пар һәм электр энергиясе белән тәэмин итүче Түбән Кама җылылык электр станциясе эшли башлады.

Ә химия гигантыннан якында гына, елга буенда, яңа гүзәл шәһәр — Түбән Кама туып килә. Яшьлек шәһәре дип йөртәләр аны. Шәһәрдә инде йөзләрчә биш һәм тугыз катлы йортлар, мәктәпләр, магазиннар, клублар бар. Анда инде илле меңнән артык кеше — химиклар һәм төзүчеләр яши. Шәһәрдә трамвайлар йөри, иртәләрен тепловоз кычкырткан тавышлар ишетелә. Түбән Камада чын шәһәр өчен кирәкле бөтен нәрсә дә бар. Шулай да Түбән Кама — ул әле киләчәк шәһәре. Аның төзелеп беткәннән соң нинди булачагын шәһәрнең проекты белән танышканнан, аны төзүчеләр белән сөйләшкәннән соң гына тулысынча күз алдына китерергә мөмкин. Ә ул, бер Татарстанда гына түгел, бөтен Кама буенда иң матур шәһәрләрдән булачак. Республикабызның Казаннан кала иң зур промышленность һәм культура үзәге булып әверелачәк Түбән Камада 250 меңнән артык кеше яшәячәк.

Түбән Кама шәһәренә килгән һәр кеше андагы тугыз катлы матур-матур йортларга игътибар итми калмый. Менә шул йортлардан берсенең, дөресрәге, беренчесенең тарихы кызыклы. Трест комсомолларының бер җыелышында кемдер шундый тәкъдим кертә: «Үз көчебез белән, эштән соң эшләп, шәһәргә тугыз катлы йорт һәм бер балалар бакчасы салырга!» Каршы килүчеләр табылмый. Фикерне трестның барлык яшьләре яклап чыга. Күп тә үтми, трестта җәмәгатьчелек тәртибендә эшли торган Төзү-монтаж идарәсе барлыкка килә. Аны яшь инженер Александр Рогов җитәкли. Ә тиздән шәһәрдә беренче тугыз катлы йорт булачак мәйданда эш кайный башлый һәм ул ике елда өлгерә.

Чәчәк атучы яклар бу. Бу сүзләр безнең республикабызга, үзенең 50 еллыгына баручы совет республикасына, нефть һәм химия республикасына карата бик туры килеп торалар. Аның экономикасы үсә, анда яңа шәһәрләр, эшчеләр поселоклары туа, авыллар үзләренең йөзен үзгәртә. Аның кешеләре яңа үрләр яулау өчен көчләрен кызганмыйлар. Чөнки безнең бүгенге тормышның диалектикасы шундый.

**Флүн Мусин**

# РЕАЛИЗМ ЮЛЫННАН

*Соңгы елларда, Бөек Октябрь социалистик революциясе белән бәйле рәвештә, илебез халыкларының төрле-төрле өлкәләрдә үткән тарихи үсеш юлларына игътибар бермә-бер артты. Замандашларыбыз, бу юлларга борылып карап, аларны зур канәгатьләнү һәм горурлык хисләре белән янә бер күздән кичерәләр.*

*В. И. Ленинның 100 еллык юбилеен һәм ленинчыл милли политиканың күркәм бер җимеше булган Татарстан автономияле республикасының данлы 50 еллыгын каршылау көннәрендә без дә туган халкыбызның иҗтимагый-политик һәм культура өлкәләрендә үткән гүзәл үсеш юлына борылып карыйбыз, аны тирән дулкынлану һәм горурлану белән күз алдыннан үткәрәбез. Әйе, искә алырлык, горурланып сөйләрлек нәрсәләребез күп безнең. Аерым алганда, тарихи 50 елда татар әдәбияты һәм сәнгате зур үсешкә иреште.*

*Журналыбызның бу санында без тәнкыйтьче Флүн Мусинның прозага багышланган мәкаләсе белән туган әдәбиятыбызның совет власте елларында үткән юлы турында юбилей алды сөйләшүләрен башлап җибәрәбез.*

*РЕДАКЦИЯ*

## 1. КӨРӘШЛӘРДӘ ЧЫНЫГЫП

Татар совет прозасы социалистик революция утында туды. Күренекле немец шагыйре һәм фикер иясе Иоганнес Бехерның күпләргә мәгълүм сүзләре белән әйткәндә, яңа сәнгать бервакытта да яңа формалардан башланмый, яңа сәнгать һәрвакыт яңа кеше белән бергә туа. Мәгълүм ки, революциядән соң гына барлыкка килгән кайбер милли әдәбиятлардан аермалы буларак, татар совет прозасы үткәндәге демократик прозабызның бай традицияләренә таянып атлый башлады. Аның яңа тип әдәбият буларак формалашуы исә илебездә яңа кеше — социализм кешесе туу белән бәйләнгән иде. Һәм аның 50 еллык тарихы да билгеле бер дәрәҗәдә илебездә яңа кеше тәрбияләү өчен барган дәвамлы көрәшнең әдәби елъязмасын тәшкил итә. Ул шушы кеше белән бергә үсте, чыныкты.

Яшь татар совет прозасының, тиз арада аякка басып, әдәбиятның олы юлына чыгуы байтак дәрәҗәдә аның нигезләрен салучылар арасында Г. Ибраһимов, Ш. Камал, М. Гафури кебек өлкән һәм тәҗрибәле язучыларның булуы белән аңлатыла. Бу әдипләр Октябрь революциясен инде житлеккән сүз осталары төсендә зур тормыш

һәм иҗат тәҗрибәсе туплап каршыладылар. Аңлашыла ки, бу тәҗрибә, бигрәк тә тормыш тәҗрибәсе, аларның революциядән соңгы иҗатына да шактый эз салды. Ягъни алар совет чорында да үткәндәге чынбарлыкны гәүдәләндерү өлкәсендә эшләрен дәвам иттерделәр. Әмма язучыларның бу чынбарлыкка мөнәсәбәтләрендә, аны тасвирлау принципларында инде зур гына үзгәрешләр туган иде. Әйтик, Г. Ибраһимовның «Безнең көннәр», «Казакъ кызы», «Татар хатыны ниләр күрми», Ш. Камалның «Таң атканда» романнарында, М. Гафуриның «Кара йөзләр» һәм «Шагыйрьнең алтын прискасында» повестьларында үткән тормыш күренешләре һәм кешеләре яңа иҗтимагый-эстетик карашлардан чыгып сурәтләнәләр. Патша самодержавиесе шартларында хезмәт ияләренең авыр һәм караңгы тормышы, аларның сыйнфый аңы үсә бару егерменче елларда тагын Ф. Сәйфи-Казанлы, Х. Кәрим, А. Таһиров һ. б. өлкән язучыларның әсәрләрендә дә чагылыш тапты. Г. Ибраһимов, Ш. Камал һәм М. Гафури кебек әдипләр иҗаты революциягә кадәрге проза белән совет чоры прозасы арасында үзенә бер күпер хезмәтен үтәде. Шул ук вакытта бу язучыларның әдәби эшчәнлеге татар прозасының яңа социаль шартларда идея-эстетик яктан үзгәрүен, үсүен дә чагылдыра. Бу үсеш-яңарыш процессы Г. Ибраһимов иҗатында барыннан да тулырак һәм ачыграк гәүдәләнә.

Бөек Октябрь һәм иҗтимагый-политик, һәм идея-эстетик яктан Ибраһимовны нык-лап чыныктырып һәм җитлектереп, аның иҗатында мөһим үзгәрешләр тудыра. Алар беренче чиратта чынбарлыкны һәм геройны гәүдәләндерүдә чагылалар. Мәгълүм ки, үз иҗатының беренче адымнарыннан ук Ибраһимов капиталистик чынбарлыкны катгый рәвештә кире какты, яңа тормыш һәм яңа кеше турында хыялланып, бу хыялын сәнгатьчә гәүдәләндерергә омтылып яшәде. Революциягә кадәрге әсәрләрендә ул шул чор чынбарлыгын фаш итүдә, аның үз сүзләре белән әйтсәк, «явыз вә караңгы тормышның мөһлик[1] бер кисәген тәмам җимереп ташларлык мәртәбә һөҗүм» итүдә көчле реалист иде. Ә инде яңа тормыш һәм яңа кеше турындагы хыялларын, аларга әле чынбарлыкта җирлек таба алмау аркасында, язучы ул чорда күпчелек иллюзор планда һәм абстракт романтизм чаралары белән гәүдәләндерде.

Октябрь революциясе язучының яңа чынбарлык һәм яңа герой турындагы хыялларын тормышка ашырырга киң мөмкинлекләр ача. Ягъни хәзер ул бу тормышны һәм геройларны үз күзләре белән күрү бәхетенә ирешә. Мәгълүм ки, Ибраһимовның совет чорында иҗат ителгән беренче әсәрләрендә, аерым алганда «Кызыл чәчәкләр» повестенда, яңа чынбарлык һәм геройларны гәүдәләндерүдә романтик сурәт чаралары өстенлек ала. Бер Г. Ибраһимов иҗатына гына түгел, бәлки шул чордагы бөтен әдәбиятка хас булган бу хәлнең төп сәбәбе шунда: автор күз алдында, каты көрәшләрдә туып килгән сокландыргыч яңа чынбарлыкны һәм яңа кешене, әйтергә кирәк, берьюлы һәм киң колачлап алырга, аларны революцион пафос белән һәм калку итеп тасвирларга омтыла. Аңлашыла ки, бу омтылышны тормышка ашыру өчен романтик сурәт чаралары сорала иде.

Әмма Г. Ибраһимовның 20 еллар башы иҗатындагы романтизм үзенең табигате буенча аның революциягә кадәрге романтизмыннан инде шактый аерыла иде. Хәзер ул элекке абстрактлык, иллюзорлык сыйфатларыннан арынган, конкрет революцион мәгънә белән сугарылган хәлдә яңа реализмга киң юл ача иде. Шунлыктан, язучының революциядән соңгы беренче әсәрләрендә без романтизмны яңа реализм сыйфатлары белән бергә үрелгән хәлдә күрәбез.

Нәтиҗәдә хәзер Ибраһимов иҗатында романтизм, аның революциягә кадәрге әсәрләрендәге кебек, реализмнан аерылып тормый, бәлки киресенчә, аңа якыная төшә, аны баета. Шундый яңа реализм, ачыграк әйткәндә, социалистик реализм үзенең тулы чагылышын Г. Ибраһимовның «Тирән тамырлар» романында таба. Бирелә язучы зур революцион процессларны тирән реалистик анализ аша үткәреп һәм гомумиләштереп гәүдәләндерә, Фәхри, аның хатыны Гайшә, кочегар, Садыйк кебек геройлар образларында социализм кешеләренең үзенчәлекле характерларын күз алдына бастыра.

Татар совет прозасының беренче адымнары турында сөйләгәндә Г. Ибраһимов иҗатын алга чыгаруыбызның икенче мөһим сәбәбе шунда: революциядән соң әдәбиятка килгән күп кенә яшь прозаиклар үз иҗатларын шушы әдипнең көчле йогынтысы астында башладылар. Бу уңайдан тәнкыйтьче Г. Нигъмәти болай язды: «Г. Ибраһимов-

[1] һәлакәткә дучар итә торган.

ның Октябрьдан соңгы әдәбияттагы роле... Октябрьдан соң күтәрелгән күп яшь язучыларга әдәби үрнәкләр бирел, шул юлда тәрбияче хезмәтен үтәвендә дә иде. Байтак яшь хикәячеләр иске әдәби мирастан файдалану, өйрәнү моментын Г. Ибраһимовтан башладылар һәм аның тирәсендә күбрәк әйләнделәр».

Егерменче елларның беренче яртысында яшь каләмнәргә Г. Ибраһимовның романтизмы якынрак иде. Яңа тормыш төзү өчен барган дәһшәтле көрәшләрдә үзләре үк катнашкан яшь язучыларның күпчелеге игътибарны гражданнар сугышы кырларына юнәлтте. Алар бу көрәшләрдә бөтен халык күрсәткән гомум батырлыкка сокландылар, аңа дан җырларга теләделәр. Шуңа күрә алар үз әсәрләрендә әле яңа формалашып килгән социалистик чынбарлыкны, аны иҗат итүче һәм шул процесста үзе дә үзгәрә баручы халыкны берьюлы кочаклап алырга омтылдылар. 1924 елда татар әдәбиятының торышын билгеләп, Г. Ибраһимов болай язды: «... революционер каләмнәр... киң массаны алалар, зур иҗтимагый коллективларның көрәшләрен, халык эчендә эш, хезмәт моментларын мәйданга чыгаралар.

Һәрбер әдәби кисәк, бер шигырь, бер хикәя, бер драма, комедия, һәрбер поэма бездә хәзер менә шул киң көрәш, тормыш яланнарын ала, моны сыйнфый рух белән сугара, тарихның үзәгендә туып килгән киләчәк мәгънәне — иҗтимагый азатлыклар юнәлешен сукыр күзләргә дә күрсәтергә тели: хезмәт, тормыш моментлары, иҗтимагый коллективларның кузгалышлары, бәрелешләре, боларның икътисади тамырлары!» Сүз уңаенда ул чорда мондый тасвирның шактый дәрәҗәдә берьяклы булуын билгеләп үтәсе килә. Эш шунда ки, яңа чынбарлыкны һәм революцион массаларны киң колач белән сурәтләүне яшь прозаиклар әле еш кына тасвирланган вакыйгаларга җентекле анализ ясау белән бәйли алмадылар. Моның нәтиҗәсе буларак, күп кенә әсәрләрдә очерклык һәм эскизлык шактый сизелде.

Революциянең кайнар эзләреннән язылган беренче әсәрләрдә еш кына искене җимереп яңаны төзү идеясе лозунг рәвешендә алгы планга куелды. Яшь авторлар шушы гомум идеяне лирик геройлардан зур пафос һәм көч белән әйттерделәр. Прозада бу хәл лирик хикәя — нәсерне алга сөрде. Егерменче еллар башында нәсер өлкәсендә иң актив эшләгән язучы Мәхмүт Максуд иде.

Икенче төр яшь язучылар революцион массаларның үзләренә мөрәҗәгать иттеләр. Ш. Усмановның гражданнар сугышына багышланган «Легион юлы» дилогиясенең 1921 елда чыккан беренче өлеше — «Кызыл байрак астында» тормышны һәм геройны сурәтләү үзенчәлекләре ягыннан рус язучыларыннан А. Серафимовичның «Тимер ташкын» романына, А. Малышкинның «Данрның җиңелүе» һәм Вс. Ивановның «Бронепоезд 14-69» повестьларына якынрак тора. Бу әсәрләрдә тимер ташкын булып дошманга каршы баручы революцион масса образы алга баса. Гражданнар сугышы күренешләрен сурәтләгәндә кырыс реализм белән романтик күтәренкелек һәм революцион пафос үзара үрелеп бирелә. Автор монда тышкы нәфислек турында уйламыйча, буяуларны эре-эре салып рәсем ясаучы художникны хәтерләтә. Шуна күрә автор сурәтләгән тормыш күренешләрендә төсләр гармониясенең эзе дә юк, киресенчә, алар ничектер тупасрак, ятышсызрак булып чыгалар.

«Кызыл байрак астында»ның үзәгендә ак казакларга каршы көрәшүче кызылармеецлар массасы тора. Автор дошман тылында калып көрәшкән интернациональ легионның көндәлек тормышын кырыс реализм белән, төрле яклап сурәтли. Әсәрнең һәр юлыннан революция биргән азатлыкны саклап калу өчен канга-кан көрәш рухы аңкып тора. Бөтен легион бер уй, бер омтылыш белән яши: бернинди авырлыкларга, кыенлыкларга карамастан дошманны җиңәргә.

Гомум массаны гәүдәләндерергә омтылу К. Нәҗминең беренче хикәяләренә дә хас иде. Аның «Чыныгу», «Кырлар буенча», «Иң соңгысы», «Шобага» һ. б. хикәяләрендә, Г. Нигъмәти сүзләре белән әйткәндә, «гражданнар сугышының конкрет типларын, аерым кешеләр психологиясе белән бәйләп җентекләп бирелгән күренешләрен күрсәтүдән бигрәк, масса — күпчелек катнашкан күренешләрен бирә».

Шул ук вакытта яшь прозаикларның егерменче еллар башында язылган кайбер әсәрләрендә аерым шәхесләрне игътибар үзәгенә алып сурәтләргә дә омтылышлар булды. Әмма аларда еш кына революцион аскетизм идеясе калкып чыга. Геройлар халык бәхете өчен көрәшкә шәхси тормышны корбан итәргә чакыралар. Революцион көрәш хисе белән мәхәббәтне бергә бәйләп карый алмый алар. Бу яктан, мәсәлән, Ш. Усмановның «Ил кызы» һәм «Краском мәхәббәте» хикәяләре игътибарга лаеклы

«Ил кызы»нда кызылармеец Әхмәт партизан кыз Раузага, «Краском мәхәббәте»ндә кызыл командир Хафиз госпитальдә яткан-да медсестрага гашыйк була. Алар икесе дә сөйгән кызларына саф мәхәббәтләрен бел-дерәләр. Әмма кызлар егетләрнең тойгыла-рын, шундый киеренке заманда урынсыз нәрсә дип карап, катгый рәвештә кире кага-лар.

Егерменче еллар башы прозасында рево-люциядән соңгы авылга да беркадәр игъти-бар бирелде. Бу өлкәдә яшь язучылардан Г. Толымбай шактый актив эшләде. Үз хикәяләрендә ул яңа авыл өчен көрәшүче каһарманнарны сурәтләргә омтылды, сыйн-фый дошманнарның чын йөзен ачып салды.

Егерменче еллар уртасына таба әдәбият күптән түгел булып үткән дәһшәтле вакый-галарны, күз алдында туып килә торган яңа чынбарлыкны ныклабрак өйрәнергә то-тына. Үткән елларда байтак кына тормыш һәм иҗат тәҗрибәсе туплаган яшь язучы-лар хәзер тормышны һәм кешеләрне якын-нанрак һәм җентеклэбрәк сурәтли башла-дылар. Шулай проза акрынлык белән чын-барлыкка конкретрак анализ ясауга күчә барды. Бу хәл прозаның форма ягына да йогынты ясады. Моңа кадәр язучылар-ның әдәби арсеналында нигездә хикәя үзәк урынны алып торса, хәзер алар эрерәк формаларга — повесть һәм романга мөрәҗә-гать итә башлыйлар. Шулай гражданнар сугышы вакыйгаларын җанландырган кү-ләмле әсәрләр — К. Нәҗминең «Яр буенда-гы учаклар», А. Шамовның «Днепр буенда» һ. б. повестьлар дөнья күрә. К. Нәҗми по-вестенда «революциянең беренче дулкынна-ры белән уянып, хәзер инде бөтенләй йөрәктән ташып чыккан яшьлек дәртенә» бирелгән авыл егете Тимербулатның кызыл-армеецлар сафына басуы, шушы процесста аның политик һәм рухи яктан чыныгуы шактый нигезләнеп сурәтләнә. Шул ук вакытта автор Тимербулатның сөйгән кызы Айбикәгә булган саф мәхәббәтен дә җанлы детальләр аша гәүдәләндерә.

А. Шамовның «Днепр буенда»сында да яшь геройлар сурәтләнә. Гомумән, бу чорда күп кенә яшь язучылар иҗатында яшьлек темасы үзәк урын алды һәм бу табигый хәл иде. Чөнки авторлар әдәби образларда давыллы еллар аша үткән үз яшьлекләрен, уй-хисләрен, кичереш-омтылышларын чагыл-дырырга теләделәр. Шунлыктан әсәрләрдә еш кына автор белән герой уйлары аваздаш яңгырый.

А. Шамов үз повестенда төп игътибарны мәхәббәткә юнәлтә. Бу нәрсә беркадәр 20 еллар башындагы революцион аскетизм идеясе белән полемика төсен ала. «Днепр буенда» повесте кызылармеец Хәлим белән медсестра Рахиль мәхәббәтен тасвирлый. Биредә автор теләсә нинди киртәләрне һәм кыенлыкларны җиңеп чыга торган көчле мәхәббәткә дан җырлый. Бу хисне ул кешенең рухын, дәртен күтәрә, яшәүнең мәгънәсен тирәнәйтә торган көч итеп карый һәм моның белән прозага яңалык алып килә иде.

А. Шамовның «Рәүфә» исемле повесте дә шул еллар прозасы өчен яңалык иде. Рәүфә йөзендә автор революциядән соң татар хатын-кызының язмышы үзгәрү ту-рында гына сөйләп калмады, бәлки яңа социаль шартларда татар авылының рухи үсешен, аның күп гасырлык рухи изелгән-лектән, йомыклыктан рухи активлыкка күчә баруын гаҗәп тормышчан итеп күрсәтә алды. Кайнатасы кулак Шәмгун карт семья-сындагы кыргый тәртипләр, киленгә бары җанлы эш көче итеп карау әкренләп рухи яктан бик тә изелгән һәм пассив булган Рәүфә күңелендә протест хисе, мондый шартларга каршы баш күтәрү теләге туды-ралар. Героиня күңелендә кеше горурлыгы хисе уяна. Ул үзен мыскыл иттереп яшәргә теләми һәм ире йортын ташлап чыгып китә.

Җыеп әйткәндә, 20 елларда яшь татар совет прозасы Г. Ибраһимов, Ш. Камал һәм М. Гафури кебек өлкән әдипләрнең иҗади йогынтысы астында яңа чынбарлыкны сән-гатьчә гәүдәләндерүдә беренче, әмма ыша-нычлы адымнарын атлый.

## 2. ЗАМАНГА ЙӨЗ БЕЛӘН БОРЫЛЫП

30 еллар башы илебез тормышының бөтен өлкәләрендә социализм һөҗүме баш-лану белән характерланды һәм бу хәл шул чор прозасы үсешенә мәгълүм эз салды. Язучылар алдына әдәбиятны халыкның хезмәт фронтындагы көндәлек көрәшенә якынайту, аны «бүгенге төзелеш бурычлары белән бәйләү» бурычы куелды. 1930 елда ТАПП секретариаты «Матур әдәбиятны производствога йөз белән!» лозунгысы астында әдәбиятка ударниклар призывын игълан итә. Шул ук елда чыга башлаган «Атака» журналы үзенең хәбәрчеләренә «завод-фабрика һәм эшчеләр тормышы белән бәйләнгән язмалар — хикәяләр,

шигырьләр, очерклар» язарга чакырып мөрәҗәгать итә. Язучылар завод-фабрикаларга беркетеләләр, яки авылларга дәвамлы командировкаларга җибәреләләр. РАПП хәрәкәтендә «демьянлашу» лозунгысы күтәрелә. Бу лозунг язучыларны рус шагыйре Демьян Бедный кебек иҗат итәргә, «бүгенге көн һавасы белән сулап, бүгенге көн теле белән сөйләп, чын мәгънәсендә бүгенге көн бурычлары өчен» көрәшергә чакыра иде. Шул ук вакытта әдәбиятның максатына төрле карашлар да ачыкланды. Кайберәүләр алгы планга аның идея ягын куйдылар. К. Нәҗми, мәсәлән, болай дип белдерде: «Реконструкция өчен көрәштә промфинпланны большевиклык темпы белән арттырып үтәү юлында пролетариат әдәбияты киң массаларны тупларга, капитализм калдыкларына каршы барган кискен көрәшнең бөтен тармакларында җиңүебезне оештыручы коралларның берсе булырга тиеш»[1]. Икенче берәүләр исә әдәбиятның идея яңгырашы белән бергә, аның сәнгатьчә танып-белү сыйфатына да игътибар итәргә кирәклеген күрсәтеләр. Бу уңайдан Һ. Такташ болай язды: «Пролетариат язучыларының кыйммәте, аларның кирәклеге сыйнфый көрәш һәм бүгенге социализм экономикасы тудырган яңа хисләрне, яңа уйларны оештыра, бер формага кертә белүе белән, шул теләкләрне массаның йөрәгенә сеңдерә алуы белән үлчәнергә тиеш»[2].

Бу чорда әдәбият үзенең төп игътибарын яңа экономиканы тудыру, социалистик хуҗалык төзү өчен барган киеренке хезмәтне, бу юлда сыйнфый дошман белән кангакан көрәшне тасвирлауга юнәлдерде. Герой да беренче чиратта шушы күзлектән чыгып сурәтләнде һәм бәяләнде.

Язучылар чынбарлыкның безнең проза өчен чагыштырмача яңарак өлкәләренә күз сала башладылар, укучыны промышленность кешеләре тормышы белән якыннанрак таныштырырга теләделәр. Шулай И. Газиның завод-фабрика тормышына багышланган «Бригадир кыз» һәм «Көмеш сулы Нурминкә» повестьлары чыга. И. Туктар Урал эшчеләре тормышын яктырткан хикәяләр циклы һәм шахтерлар турында «Сиксән беренче штольня» повестен яза. Донбасс шахтерлары тормышы М. Сөндекленең «Донбасс ударниклары» исемле очеркл җыентыгында чагылыш таба. Р. Ильясны күп санлы хикәяләрендә исә Баку нефтьч ләренең авыр үткәне һәм хәзерге ка көрәшле тормышы гәүдәләнә. Бу әсәрл арасында И. Гази һәм И. Туктар повес лары геройларның күркәм характер сыйфа ларын киеренке хезмәт сынавы аша үткәр һәм калку итеп сурәтләүләре белән аерыль торалар. Шунлыктан «Бригадир кыз»да Галия, «Көмеш сулы Нурминкә»дәге Фәр дә, «Сиксән беренче штольня»дагы Гәр күпчелек хезмәт фронтында очраган һә төрле кыенлыкларга каршы үз-үзләре аямыйча көрәшеп яшәгән хәлдә күрсәтел ләр.

Яна социалистик хезмәтне, аның кешел аңында һәм психологиясендә күркәм үз решләр тудыруын чагылдыру ягынн 30 еллар прозасында М. Галәүнең «Кабу сай» романы игътибарга лаеклы. Ур Азиядәге бер совхоз тормышын тасвирлаг бу романда бер яктан, яшь специалистл Асия, Икбал, Фатих образларында я совет интеллигенциясе вәкилләре гәүдәлә дерелсә, икенче яктан, Туктамыш ка образында крестьянның искелек калдыкл рыннан арына баруы күрсәтелә.

Икенче төр әсәрләрдә, аерым алган авыл темасына багышланганнарында, гер сыйнфый бәрелешләр мохитында тасвирл на. Биредә инде шушы процесста геройнь дөньяга карашы, рухи үсешен чагылдыру омтылыш көчәя. Бу яктан К. Нәҗмин «Якты сукмак» повестендагы укыту Мәдинә һәм «Кояшлы янгыр» повестенда авыл кызы Гөлнур образлары кызыкл Һәр ике очракта да астыртын эш ит сыйнфый дошманнарның явызлыкларын жилкәләрендә татып, героинялар яңа то мыш хакыйкатен аңлауга киләләр. Акл тарафыннан үтерелгән большевик е Булатны ярату, элегрәк дус булып йөрг Әнвәрнең соңыннан яңа тормыш дошманы әверелүен күрү Мәдинәнең дөньяга кар шында кискен үзгәреш тудыра. Ул дөресле нең большевиклар ягында булуын аңл һәм, авылга укытырга килеп, Совет влас дошманнарына каршы килешмәүчән көрә кә күтәрелә. Гөлнур исә авылның көрәш тормышында Мәдинә кебек турыдан-ту катнашмый, ул көрәшче түгел. Үзен тәрҗемәи хәле буенча ул А. Шамовн Рәүфәсенә тартымрак. Гөлнур образын яңа чынбарлыкның җиңүле адымнар бел кешеләр тормышына, аңына үтеп кер чагылдырыла. Ул да ахырдан дөреслекн

---

[1] «Атака» журналы. 1930 ел. 8—9 саннар. 7 бит.

[2] «Атака» журналы. 1930 ел. 2 сан. 17 бит.

үзенең ире — кулак малае Хәнәфиләр ягында түгел, бәлки колхоз ягында, колхоз төзү өчен көрәшүчеләр — әтисе Ситдыйк абзый, яшьлек дусты Сирай кулында булуын аңлый.

Авылны коллективлаштыру темасына шулай ук Ф. Сәйфи-Казанлының «Өч нарат» романы, Г. Толымбайның «Түбән Елгада», М. Әмирнең «Безнең авыл кешесе» повестьлары, күп санлы хикәяләр һәм очерклар багышланды. Аларда авылда барган көрәшнең кызыклы гына күренешләре тудырыла, бу көрәшне әйдәп баручыларны, крестьян психологиясе үсешен гәүдәләндерергә омтылышлар ясала. Шул ук вакытта бу әсәрләрдә әле еш кына хроникальлек һәм схематизм үзен сиздерде, геройларның күп кырлы характерлары тиешенчә ачылып җитмәде.

М. Әмирнең «Агыйдел» повесте һәм Ш. Камалның «Матур туганда» романы яңа авыл чынбарлыгын, аның кешеләрен сәнгатьчә дөрес сурәтләү юлында бер адым алга атлау булдылар. «Агыйдел»дә коллективлаштыру алдыннан авылда барган сыйнфый көрәш гаҗәп тормышчан детальләр аша, геройлар арасындагы киеренке конфликтларда ачыла. Шәһәрдән каникулга кайткан комсомоллар Гаяз һәм Ильяс, авыл яшьләре Артыкбикә, Күчәрбайларны, ярлылар Имәли, Ибрай һәм башка крестьяннарны үз тирәләренә туплап, кулак Тәкъвә Сахәү төркеменә каршы кискен көрәш башлыйлар. Шушы процесста геройларның рухи дөньясы, характеры алар тормышының төрле яклары белән якыннан кызыксынып сурәтләнә.

Яшь геройны тасвирлау ягыннан Л. Гыйльминең «Чын мәхәббәт» исемле романы кызыклы. Шәхси тормыш тәҗрибәсенә нигезләнеп язылган бу әсәрдә автор ятим малай Рәшитнең гыйбрәтле язмышын, аның социализм шартларында яңа җәмгыятьнең алдынгы вәкиле булып җитлегүен ышандырырлык итеп сурәтли.

30 нчы еллар прозасының иң әһәмиятле әсәрләреннән берсе Ш. Камалның «Матур туганда» романы булды. Анарда егерменче еллар башы авылының бөтен катлауларына бердәй игътибар ителә, кеше характерларының тулы бер галереясы тудырыла. Авылны, аның кешеләрен яхшы белгән һәм зур иҗат тәҗрибәсенә ия булган Ш. Камал тормышны һәм геройларны бөтен барлыгы белән, һәрьяклап һәм бөртекләп сурәтли. Нәтиҗәдә Кигәвенле авылы активистлары Каюм, Мостафа, Мәдинә, Чуртан Халикъ, Һидият һәм башкалар авылча табигый булып һәм үзләренә генә хас характер сыйфатлары белән алга басалар. Иң әһәмиятлесе, язучы коммунада эшләү дәвамында кешеләрдә коллективлык һәм үзара теләктәшлек рухы тәрбияләнүне гәүдәләндерә. Шул ук вакытта автор Садыйк хаҗи, аның улы Әмирҗан, кулак Хөснулла, аның нярчене Нәгыйм кебек Советка каршы килешмәүчән көрәшкә күтәрелгән дошманнарның тормышчан һәм үзенчәлекле образларын тудыра. Шундый дошманнар белән канлы көрәштә коммунарларның дуслыгы ныгый, характерлары чыныга.

Яңа чынбарлыкның социаль-политик мәсьәләләрен яктырту белән бергә, проза утызынчы елларда мораль-этик мәсьәләләр белән дә якыннан кызыксына башлый. Ф. Хөсни, Г. Кутуй, А. Расих һәм башкаларның хикәяләрендә совет кешеләренең олы эшләре, матур уйлары, каршылыклы кичерешләре зур симпатия белән тасвирланалар. Бу өлкәдә 30 еллар татар прозасының иң күренекле әсәре булып Г. Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар» повесте тора. Әсәрнең үзәк геройлары — врач Галия һәм артист Искәндәр образларында безнең прозада беренче мәртәбә диярлек яшәүгә ике төрле карашның, ике төрле тормыш фәлсәфәсенең, ике әхлакның кискен бәрелеше зур художество көче белән күрсәтелде. Семья, мәхәббәт мәсьәләләрен язучының саф коммунистик мораль өчен компромиссыз көрәшүче гражданин буларак һәм сугышчан публицистика рухы белән сугарып яктыртуы әсәрнең укучыларга тәэсир көчен тагын да арттыра иде. Врач Галияне автор совет яшьләренең типик вәкиле итеп сурәтли. Героиняның типик сыйфатларын ул беренче чиратта аның тормышка гашыйк булуында, тирән оптимизмында, саф мәхәббәткә турылыклы булуында, тормыш каршылыкларын кыю рәвештә җиңеп яшәргә омтылуында күрә.

Заман тормышының төрле-төрле өлкәләрен һәм мәсьәләләрен вакыйгаларның кайнар эзеннән яктыртып бару белән бергә, утызынчы еллар прозасында тарихи-революцион темага да игътибар көчәя. Бер төркем язучылар иҗатында революциягә кадәрге чынбарлыкны сурәтләү киң урын ала. Шулай М. Галәүнең «Болганчык еллар» һәм «Мөһаҗирләр» романнары дөньяга чыга. «Канлы тамгалар» исеме астында дүрт китаптан торырга тиеш булган тарихи эпопеяның беренче ике китабын тәшкил иткән бу романнар татар җәмгыятенең XIX йөз

урталарыннан башлап рус-япон сугышына кадәрге чорын эченә алган киң тарихи панорамасын күз алдына бастыралар. Шушы чорда татар халкы тормышын бөтен барлыгы белән һәм төрле яклап сурәтләгән бу әсәрләр безнең прозада тарихи роман жанры өлкәсендә нигездә уңышлы тәҗрибәләрдән булдылар. Революциягә кадәрге татар тормышын киң план белән һәм аның төрле катлауларына игътибар итеп сурәтләү К. Тинчуринның «Мәрҗәннәр»енә дә хас. Патша Россиясендә татар хезмәт ияләренең авыр тормышы тагын Х. Садриның «Тимерче малае», «Ил батырлары», «Безнең таң», Г. Рәхимнең «Чишмә буенда» повестьларында чагылыш тапты.

Г. Ибраһимовның «Безнең көннәр» романының төзәтелгән яңа варианты чыгу 30 еллар татар прозасы өчен зур вакыйгага әверелде. Аның мөһим идея-эстетик әһәмияте, бер яктан, татар халкының беренче рус революциясендә катнашуы, революция һәм интеллигенция кебек зур мәсьәләләрне сәнгатьчә дөрес һәм тулы гәүдәләндерүдә булса, икенче яктан, безнең прозада тарихи-революцион роман жанрын үстерүдә җитди бер адым ясауда иде. Тарихка да ул шушы жанрның иң матур үрнәкләреннән берсе булып керде.

Кайбер яшьрәк язучылар иҗатында исә утызынчы елларда гражданнар сугышы темасына игътибар ителә. Ш. Усманов «Легион юлы» дилогиясенең соңгы өлешен язып бетерә, аңарда, әсәрнең 20 еллар башында чыккан беренче кисәге белән чагыштырганда, авторның каләме шомара, сәнгатьчә фикерләве тирәнәя төшкәне күренә. Бу елларда А. Шамовның «Бер мәхәббәт турында» һәм Г. Бәшировның «Сиваш» повестьлары дөнья күрә. Элегрәк чыккан «Днепр буенда» исемле әсәрендәге кебек, бу повестенда да А. Шамов геройларның шәхси тормыш мәсьәләләрен, интим уй-хисләрен ачуга күбрәк игътибар бирә. Кавалерист Нуруллинның медсестра Рабигага мәхәббәтен сурәтләп, автор бу хиснең кешене теләсә чиксез бәхетле итүче, теләсә аның күңеленә төзәлмәс яра салучы зур илаһи көч булуын ача. Г. Бәширов повестенда да Перекопны яулап алуда катнашкан батыр сугышчыларның үзенчәлекле характерларын, уй-хисләрен гәүдәләндерергә омтылыш сизелә. Ләкин әсәр авторны канәгатьләндерми, аларның «уй-тойгыларын, эчке дөньясын күбрәк отып калырга» теләп, 50 елларда ул бу повестена янадан әйләнеп кайта.

Гәрчә кайбер әсәрләргә, Г. Ибраһимов әйткәнчә, схематизм һәм лакировка зур гына зыян китерсә дә, тулаем алганда, утызынчы елларда татар прозасы чынбарлыкны сәнгатьчә танып-белү һәм гәүдәләндерү, яңа әдәби жанрларны үзләштерү юлында кызыклы гына адымнар ясады.

### 3. СЫНАУЛАР ҺӘМ СЫНАЛУЛАР АША

Шул хәлдә проза Бөек Ватан сугышына килеп керә. Беренче көннәрдән үк күп кенә язучылар үзләре теләп фронтка китәләр. Берләре каләмне коралга алыштырып турыдан-туры алгы сызыкта көрәшәләр, икенчеләре татар телендә чыга торган фронт газеталарында редакторлар, әдәби сотрудниклар, хәрби корреспондентлар булып эшлиләр.

Сугыш язучылар иҗатында кискен үзгәрешләр тудыра. Прозада хәрби тема үзәк урын ала. Әдипләр алдына социализм җирлегендә үскән совет кешесенең яңа характер сыйфатлары, уй-омтылышлары һәм идеалларының дәһшәтле сугыш сынавын үтүләрен чагылдыру бурычы баса. Беренче әсәрләрдә туган илебезгә хыянәтчел төстә басып кергән явыз дошманга чиксез нәфрәтне, Ватан азатлыгы өчен канга-кан көрәш идеясен зур пафос белән чагылдыру өстенлек алды. Биредә кабат нәсер жанры калкып чыга. Г. Кутуй, М. Максуд, Г. Бәширов, М. Әмир һәм башкаларның нәсерләрендә совет кешеләренең әлеге уй-хисләре зур тәэсир көче белән гәүдәләндерелделәр. Тора-бара, сугышның үзендә катнашып, аның авырлыкларын үз җилкәләрендә татыган язучылар әсәрләрдә чынбарлыкны һәм кешеләрне конкретрак сурәтләүгә күчәләр. Хикәяләрдә солдат тормышының төрле-төрле яклары күтәрелә. Язучылар еш кына бер мәсьәләгә — совет сугышчысының физик һәм рухи ныклыгын сынауга игътибар итәләр. Г. Бәширов, М. Әмир, Г. Әпсәләмов, И. Гази, Ә. Еники, А. Расих, Г. Галиев һәм башкаларның хикәяләрендә бөтенләе белән тыныч тормыш кешесе булган солдатның — кичәге колхозчының, эшченең, студентның сугыш кырында зур рухи ныклык, кыюлык һәм геройлык үрнәкләре күрсәтүләре гәүдәләндерелә. Әсәрләр үзәгенә еш кына разведчиклар куела һәм аларның легендар батырлыклары калку итеп тасвирлана. Бу яктан Ф. Кәримнең «Разведчик язмалары» һәм «Язгы төндә» повестьлары аеруча игътибарга лаеклы иде. Фронт чынбарлыгын һәм

геройларын тормышчан итеп һәм реалистик сурәт чаралары белән күрсәтүләре сәбәпле, Ф. Кәрим повестьлары сугыш чоры прозасының иң күркәм битләрен тәшкил итәләр. Бу елларда маҗаралы жанрга беркадәр игътибар арта. Аерым алганда Г. Кутуйның «Рөстәм маҗаралары» һәм А. Расихның «Бәхет орлыклары» повестьлары иҗат ителә.

Геройларның легендар каһарманлыкларын калку итеп тасвирлау белән бергә, язучылар дәһшәтле сугыш шартларында да совет кешесенең бай рухи тормыш белән яшәвен күрсәтүгә дә игътибар бирәләр. Сугыш геройның интим хисләрен ярлыландырмый гына түгел, киресенчә, тагын да тулыландыра һәм тирәнәйтә генә.

Гомумән алганда, бу елларда иҗат ителгән күп санлы хикәяләр, әйтерсең, киләчәктә туачак зур эпопеянең, сугыш турында язылачак олы китапның аерым битләрен, штрихларын тәшкил итәләр иде. Сугыш чынбарлыгын эпик планда, киң идея-эстетик гомумиләштерүләр ясап сурәтләү эшенә язучылар сугыштан соңгы елларда тотындылар. Бу эш хикәядән эре формаларга — повесть һәм романнарга күчүне сорады. Г. Әпсәләмовның «Ак төннәр» повесте бу өлкәдә күләмлерәк беренче әсәрләрдән булды. Повестьта совет разведчикларының батырлыгын, кыюлыгын, тапкырлыгын сурәтләү максат итеп куела. Геройларның мондый сыйфатларын калкурак һәм күркәмрәк итеп гәүдәләндерү өчен автор әледән-әле романтик тасвир чараларына, кайчак хәтта маҗаралы әсәр алымнарына да мөрәҗәгать итә.

Моннан соң язылган «Алтын йолдыз» һәм «Газинур» романнарында Г. Әпсәләмов сугыш чынбарлыгының киң картиналарын, геройларның тулы бер галереясын тудырды. Биредә ул сугыш еллары прозасының үзәк проблемасын — социализм чорында үскән совет кешесенең характеры һәм рухының бөтен ил өстенә төшкән зур тарихи сынау аша үтүен — киң планда, эзлекле һәм дәвамлы рәвештә яктыртты. «Алтын йолдыз» кичәге унынчы класс укучылары — Урманов, Мөнирә, Ләлә, Хаҗәр һәм башкаларның сугыш утында характеры, рухы чыныгуын гәүдәләндерә. «Газинур» романында бу гомум идея бер герой — Газинур образында чагылдырыла. Газинур әсәрнең буеннан-буена Матросов батырлыгын кабатларга әзерләнә. Романдагы һәр образ, һәр деталь шушы үзәк максатка — геройның әлеге героик адымын ясарга килү юлын яктыртуга буйсындырылган. Нәтиҗәдә роман битләрендә гади совет кешесенең данлы тормыш һәм көрәш юлы, якты образы алга баса.

Г. Әпсәләмов әсәрләреннән аермалы буларак, Г. Бәшировның «Намус» романы геройлары сынауны тыл тормышында, сугыш чоры колхозы кырларында үтәләр. Романның вакыйгалары сугышның иң киеренке көннәрендә, дошман Иделгә, Сталинградка якынлашкан көннәрдә бара. Геройларның характеры, физик һәм рухи көчләре авылның шул чордагы авыр хезмәтендә, гаять кырыс тормыш-көнкүрешендә сынала. Нәфисә, Айсылу, Тимери абзый, Карлыгач, Сөмбел, Мәүлиха түти фронтка икмәк җитештерү өчен киеренке хезмәттә күрсәтеләләр. Шушы процесста аларның хезмәт сөючәнлек, физик һәм рухи ныклыгы, тирән оптимизм, туган ил азатлыгы өчен үз-үзеңне аямау кебек гүзәл сыйфатлары бөтен күркәмлеге белән ачыла. Әсәрнең буеннан-буена зур күтәренкелек һәм яктылык рухы хөкем сөрә.

Г. Бәширов совет кешеләренең иҗтимагый һәм шәхси уй-хисләрен органик бердәмлектә, иҗади хезмәт поэзиясе белән сугарып сурәтләде. Шул нигездә ул әдәбиятта уңай герой образын гәүдәләндерүнең матур үрнәкләрен бирде.

М. Әмирнең «Ялантау кешеләре» һәм «Саф күңел» романнары бер үк вакытта фронт һәм тыл тормышын үз эчләренә алалар. Бу әсәрләргә чынбарлыкны масштаб белән, киң колачлап сурәтләү сыйфаты хас. Шул ук вакытта биредә геройларны тасвирлауда М. Әмирнең үзгә максатлары да бар. Мәгълүм булганча, Г. Әпсәләмов башлыча совет кешесенең ил алдындагы иң изге бурычын канлы сугыш кырында үтәве, бу эштә зур батырлык һәм ихтыяр көче күрсәтүе белән кызыксынды. Г. Бәшировка килсәк, ул төп игътибарын совет кешесенең туган илгә бирелгәнлеген, халык алдындагы бурычын үтәүгә карашын хезмәткә мөнәсәбәт аркылы, иҗади хезмәттә чагылдыруга юнәлтә. М. Әмир романнарында боларның икесен дә очратырга мөмкин. Шул ук вакытта язучы Г. Әпсәләмов һәм Г. Бәширов әсәрләрендә артык күзгә чалынып тормаган яки беркадәр үтеп барышлый гына искә алынган кайбер мәсьәләләрне алгы планга куеп һәм калку итеп яктырта. Ягъни М. Әмир сугыш елларында кешенең мораль йөзен, әхлак мәсьәләләренә мөнәсәбәтен сынауга аеруча басым ясый. Ул геройларның шушы дәһшәтле көннәрдә иҗтимагый планда да,

әхлак өлкәсендә дә бердәй намуслы һәм принципиаль булырга тиешлеге, аларны бер-берсеннән аерып карарга ярамаганлыгы турында җитди сүз алып бара.

Сания, Фәрдәнә, Рифгать һәм башкалар, тылда һәм сугыш кырында зур батырлык һәм фидакарьлек үрнәкләре күрсәтү белән бергә, иң кыен очракларда да үз мәхәббәтләренә тап төшермиләр, аңа турылыклы булып калалар. Бу киеренке көннәрдә алар мәхәббәтнең мәгънәсен тагын да тирәнрәк аңлыйлар.

Геройларны иҗтимагый планда күрсәткәндә язучы аларның туган илгә бирелгәнлеген, тарихи оптимизмын, рухи ныклыгын һәм ихтыяр көчен гәүдәләндерүгә басым ясый. Боларның гүзәл чагылышын ул коммунистларда күрә.

Бөек Ватан сугышында совет халкы тарихта тиңдәшсез батырлык күрсәтте һәм шуның белән бөтен дөньяны таңга калдырды. Әдәбият бу батырлыкның тарихи чыганаклары белән кызыксына башлады. Моның өчен язучылар халыкның революцион үткәненә мөрәҗәгать итәләр. Шулай сугыштан соңгы елларда К. Нәҗминең «Язгы җилләр», Ә. Фәйзинең «Тукай» романнары, И. Газиның «Онытылмас еллар» повесте һ. б. дөнья күрә. Бу әсәрләрдә татар халкының революциягә кадәрге авыр тормышы, хезмәт кешеләренең әкренләп яңа җәмгыять төзү өчен актив көрәшкә күтәрелә башлаулары тасвирлана.

Сугыштан соңгы проза, тарихи үткәнне һәм Бөек Ватан сугышы вакыйгаларын гәүдәләндерү белән бергә, табигый, заман тормышы белән дә якыннан кызыксына. 50 елларның беренче яртысында гадәттәгечә күп кенә язучыларның игътибар үзәгендә сугыштан соңгы авыл чынбарлыгы тора. Шулай Ф. Хөснинең «Җәй башы» һәм «Авыл өстендә йолдызлар», Ә. Еникинең «Рәхмәт, иптәшләр!», И. Газиның «Алмагачлар чәчәк ата» повестьлары чыга. Шул ук вакытта язучылар тормышның башка өлкәләренә дә игътибар итә башлыйлар. А. Шамов, М. Максуд, З. Нури, С. Сабиров һәм башкаларның очерклары нефтьчеләргә, мехчыларга, төзүчеләргә, эшчеләргә, елгачыларга багышлана. Соңрак проза чынбарлыкның бу өлкәләрен күләмле әдәби формаларда — романнарда яктыртуга күчә. И. Газиның «Гади кешеләр» романы безнең прозада Татарстан нефтьчеләренә багышланган беренче күләмле әсәрләрдән исәпләнә. Әмма романның әһәмияте тема яңалыгында гына түгел, барыннан да бигрәк тормыш дөреслегенә турылыклы булуында иде. Моңа басы[м] ясауның сәбәбе шул. Илленче елларны заман темасын яктырткан кайбер әсәрләрен дә шул чор тормышы бөтен дөреслеге белә[н] күз алдына бастырылмады, ул бер[к]адә җиңелләйтеп, ясалма матурайтып күрсәтел[ә] де. «Гади кешеләр» романы менә шунды[й] тасвирга полемика булып яңгыраган берен[че] әсәрләрдән иде. Автор нефтьчеләр тормы[]шын төрле яклап, каршылыклы үсеш про[]цессы итеп гәүдәләндерә. Шул нигездә у[л] геройларын да, аерым алганда, бурмасте[р] Мансур Габитовны И. Гази тормышча[н] ситуацияләрдә, реаль каршылыклар, кыен[]лыклар белән бәрелешләрдә күрсәтә, бире[д]ә[] әзер схемалардан, декларатив чишелешлә[р]дән уңышлы рәвештә котыла ала. Кыры[с] тормышчанлык, кабатланмас характерлар[] үзенчәлекле кеше типлары тудырырга омты[]лу шулай ук контора директоры Гыйльма[]нов, парторг Камышев, баш инжене[р] Алмаев, бораулаучы Николай, Соня һә[м] һәм башкаларның образларын иҗат иткән[]дә дә чагыла. Болар барысы әсәрдә реали[]стик анализның тирәнәюе турында сөйли[]ләр.

Г. Әпсәләмовның «Сүнмәс утлар» рома[]ны укучыны завод һәм аның кешеләре тор[]мышына алып керә. Бирегә Г. Әпсәләмов күп планлы һәм күп геройлы роман язуда нәтиҗәле адымнар ясый. Әсәрнең үзәгенд[ә] өлкән эшче Сөләйман Уразметов семьяс[ы] тора. Бөтен сюжет җепләре шушы семьяг[а] барып тоташа. Сөләйман образында автор өлкән буын татар эшчесенең авыр, әмма данлы хезмәт юлын зур художество көче белән чагылдыра, геройның күп кырлы характерын, бай рухи дөньясын ачып сала.

Романның иң әһәмиятле ачышларыннан берсе — ул завод директоры Хәсән Мортазин образы. Биредә автор гаҗәп каршылыклы кеше язмышын чагылдыра. Мортазин гомер буе ниндидер зур эш башкару, «яшендәй бер яшьнәү» теләге белән, «кеше үзеннән биек сикерергә тиеш һәм сикерәчәк!» — дигән ышаныч белән яши. Ул хезмәтне д[а] хөрмәт итә, аны барыннан да өстен куя. Әмма эш турында күп уйлап, ул аны башкаручылар белән бик аз кызыксына. Б[у] нәрсә аны коллективтан, кешеләрдән аера, тар юлга этәрә. Нәтиҗәдә ул шактый көчле тормыш фаҗигасенә дучар була.

Г. Әпсәләмов романда төрле буын совет кешеләренең үзенчәлекле һәм тормышчан образларын тудыра. Шулай кабатланмас характерлары, каршылыклы уй-кичерешләре

белән укучы алдыннан карт эшче Матвей Погорельцев, Айнулла бабай, Гаязов, Надежда Николаевна, Назиров, Илшат, Акчурин, Иштуган, Гөлчирә һәм башкалар узалар. Алар кешеләр күңелендә Бөек Октябрь кабызган сүнмәс утны буыннан-буынга тапшырып һәм укучыларның да күңелләрен яктыртып, матурлап үтәләр. «Сүнмәс утлар»ның төп фәлсәфи фикере дә шуннан гыйбарәт.

## 4. ЯҢА ҮРЛӘР ЯУЛАГАНДА

Мәгълүм булганча, партиянең XX съезды карарлары, илебез тормышының төрле-төрле өлкәләрендә жанлану тудырып, әдәби хәрәкәткә дә зур этәргеч ясадылар. Нәтиҗәдә илленче елларның икенче яртысыннан әдәбиятта зур җанлану башлана, язучыларның тормыш белән бәйләнешләре ныгый, иҗат активлыгы һәм кыюлыгы үсә. Шушы шартларда татар прозасында әһәмиятле ике күренеш хасил була. Бер яктан, элеккерәк елларда беркадәр пассивланып киткән кайбер өлкән буын язучылар хәзер күркәм бер иҗат активлыгы күрсәтә башлыйлар. Икенче яктан, инде 50 еллар башында ук каләмнәрен сынап башлаган бер төркем яшьләр, әйтик алганда Р. Төхфәтуллин, Н. Фәттах, А. Гыйләҗев, Г. Ахунов һәм башкалар 60 елларга инде шактый җитлеккән һәм әдәбиятта үз юлларын ачыклаган язучылар булып килеп керәләр.

Алтмышынчы елларда без менә шушы гомум җанлануның, иҗат активлыгының җимешләрен күрә башлыйбыз. Бу чорда татар прозасы чынбарлыкны сәнгатьчә гәүдәләндерү юлында яңа үрләр яулый.

Язучыларның тормыш белән бәйләнешләре ныгый бару сәбәпле әдәби иҗатта аналитик башлангычның һәм тарихилык рухының көчәюе прозада туган халкыбызның социаль-рухи үсеш юлын тарихи аспектта, аның төрле этапларын сәнгатьчә гәүдәләндерү теләге үсүгә китерде. Әсәрләрдә бу үсеш юлының әһәмиятле өч этабы үзәк урын ала. Г. Бәшировның «Туган ягым — яшел бишек», Г. Гобәйнең «Без үскәндә», И. Газиның «Онытылмас еллар» (икенче китап) һәм «Канатланыр чак», Ә. Еникинең «Вөҗдан» повестьларында, А. Расихның «Ямашев», И. Туктарның «Ике егет», Ф. Хөснинең «Утызынчы ел», С. Рафиковның «Беренче яз», Э. Касыймовның «Гомер ике килми», Г. Әпсәләмовның «Мәңгелек кеше» романнарында, Н. Дәүлинең «Үлем белән яшәү арасында» һәм «Җимерелгән бастион» әсәрләрендә, Ш. Рәкыйповның «Геройлар эзеннән» исемле документаль повестенда татар халкының социаль-рухи үсеше төрле яклап яктыртыла. Әлеге әсәрләрдә без татар хезмәт иясе массаларының 20 йөз башында иҗтимагый активлашып, революцион көрәш юлына басуларын, Беренче рус революциясе, бөек Октябрь, гражданнар сугышы һәм Бөек Ватан сугышы ялкынында чыныгуларын, 20—30 елларда яңа тормыш төзүләрен күрәбез. Шушы гомум процессны чагылдыру белән бергә, бу әсәрләрнең һәркайсы аерым кызыклы мәсьәләләрне дә яктырта. Г. Бәширов повестенда, мәсәлән, туган халкыбызның рухи ныклыгының һәм оптимизмының тарихи чыганаклары зур осталык белән ачыла. А. Расих романында хәзерге әдәбиятта аеруча актуаль төс алган мәсьәлә — тарихи шәхес образын гәүдәләндерү нигездә уңышлы хәл ителә. Сүз уңаенда соңгы елларда безнең прозаның бу мәсьәләне яктырткан тагын бер әсәр — Ш. Маннурның «Муса» романы белән баюын әйтеп үтәргә кирәк. И. Гази һәм Ф. Хөсни әсәрләрендә 20—30 елларда яңа кеше туу процессы зур осталык һәм ышандыру көче белән чагылдырыла.

Тулаем алганда, санап үтелгән әсәрләрдә татар халкының тарихи-революцион үткәне катлаулы социаль-рухи үсеш процессы итеп гәүдәләндерелә.

60 еллар татар прозасында актуаль төс алган икенче мәсьәлә — ул сугыш елларындагы һәм сугыштан соңгы авыл мәсьәләсе. Хәзерге язучылар иҗатында бу мәсьәләгә игътибар артуның объектив сәбәпләреннән берсе партиянең сугыштан соңгы авыл хуҗалыгындагы кыен хәл турында бөтен халыкка әйтеп биреп, бу хәлнең җитди сәбәпләрен Ленинча кыюлык белән ачып салуыннан гыйбарәт. Ә инде бу мәсьәләнең башлыча урта һәм яшь буын әдипләр иҗатында яктыртылуы шул чор авылында үзләренең балалык һәм яшьлек елларын үткәргән ул прозаикларның әлеге елларда шәхси күргәннәре һәм кичергәннәре турында арттырмыйча да, киметмичә дә бер сүз әйтергә теләүләре белән бәйләнгән. Нәтиҗәдә күп кенә повестьларда үзәккә яшь герой образлары куела һәм ул образларда авторлар башлыча шәхси тормыш тәҗрибәсен чагылдыралар. Мондый әсәрләр рәтенә Р. Төхфәтуллинның «Полдызым» һәм «Тамчылар ни сөйли», А. Гыйләҗевның «Берәү», Ә. Баяновның «Яшьлегемне эзлим», Н. Фәттахның «Артта калган юллар», М. Шәрифуллинның «Еллар үткәч»

повестьлары һ. б. керә. Әмма аерым очракларда язучыларның бары шәхси тормыш тәҗрибәсенә генә таянып эш итүләре, халык һәм тарих тәҗрибәсен искә алмаулары кайбер әсәрләрдә әлеге чор авылы турында шактый берьяклы һәм субъектив фикернең өстенлек алуына китерде.

Тулаем алганда исә бу повестьларның күпчелегендә авылның мәгълүм чордагы тормышы шактый объектив чагылыш тапты. Сүз уңаенда хәзерге прозада аналитик башлангычның көчәюе гомумән чынбарлыкның каршылыклы үсешен, бу үсешнең кыен моментларын тирәнрәк аңларга һәм чагылдырырга омтылыш артуга китерде. Мондый әсәрләр исәбенә тагын Ә. Еникинең «Рәшә» һәм «Әйтелмәгән васыять», С. Батталның «Сигезенчесе кем?», А. Гыйләҗевның «Өч аршын җир» повестьларын кертергә була. Аларда сугыштан соңгы тормышның кайбер гыйбрәтле күренешләре шундый ук гыйбрәтле герой язмышлары аркылы шактый дәлилле чагылыш табалар.

Икенче төр әсәрләрдә игътибар партиянең мәгълүм карарларыннан соңгы авылга юнәлтелә. Андый әсәрләр арасында иң әһәмиятлесе — А. Расихның «Язгы авазлар» романы. Биредә әлеге карарлардан соң авыл хуҗалыгын үстерү өчен башланган киеренке көрәш уңай һәм тискәре геройлар арасындагы принципиаль конфликтларда бөтен барлыгы белән күрсәтелә. Г. Минскийның «Язның беренче көне», Н. Фәттахның «Мөдир Сажидә», Х. Сарьянның «Әткәм һөнәре» повестьларында исә төрлесендә төрле уңыш белән хәзерге авыл тормышының мораль-этик мәсьәләләре, беренче чиратта, авыл яшьләренең мораль йөзе, тормыштагы юллары яктыртыла. Соңгы елларда авыл турындагы әдәбиятның тормыш географиясен киңәйтүгә омтылыш сизелә. Ачыграк әйткәндә, казакъ далаларын үзләштерүне чагылдырган ике күләмле әсәр — И. Салаховның «Күкчәтау далаларында» һәм Н. Фәттахның «Бала күңеле далада» романнары дөнья күрде.

Алтмышынчы еллар прозасында өченче мөһим момент туган халкыбызның бүгенге тормышын сурәтләүгә карый. Әсәрләрдә еш кына гаять әһәмиятле бер процесска — татар халкының Совет власте шартларында тормыш офыгы киңәюен, аның профессиональ-техник үсешен чагылдыруга игътибар бирелә. Нәтиҗәдә безнең прозага үз уйхыяллары һәм шатлык борчулары белән үзенчәлекле профессия ияләре — нефтьчеләр һәм төзүчеләр, галимнәр һәм медицина әһелләре, энергетиклар һәм зур химия кешеләре, укытучылар һәм елгачылар килеп керделәр һәм әдәби геройлар галереясында үзләренә лаеклы урын яуладылар. Аларны без А. Расихның «Ике буйдак» һәм «Каһарманнар юлы», Г. Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр» һәм «Яшел Яр», Г. Ахуновның «Хәзинә» һәм «Хуҗалар», Э. Касыймовның «Томан аша», М. Хәсәновның «Юллар, юллар» романнарында, А. Гыйләҗевның «Зәй энҗеләре», Р. Төхфәтуллинның «Агымсу» повестьларында, С. Сабиров хикәяләрендә һ. б. күрәбез.

Мондый персонажларны элеккерәк елларда да аерым очеркларда һәм хикәяләрдә очратырга мөмкин иде. Ләкин ул вакытта еш кына геройның исеме җисеменә туры килмәде. Хәзерге әсәрләрдә исә үзенчәлекле хезмәтнең, профессиянең герой рухына һәм психологиясенә мәгълүм эз салуы күрсәтелә. Бу хәл роман-повестьларда күп кенә кызыклы мәсьәләләрнең яктыртылуына сәбәпче була. А. Расихның «Ике буйдак» һәм Г. Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр» романнарында, мәсәлән, галимнәр тормышы, фәнгә төрле-төрле карашлар бәрелеше чагылдырыла. Биредә А. Расих романы авторның геройлар тормышын һәм хезмәтен тирәнтен белеп сурәтләве, әсәр идеясен персонажлар арасындагы динамик конфликтта нигезләп һәм эзлекле рәвештә ачуы белән аерылып тора.

Г. Ахунов, А. Гыйләҗев һәм Р. Төхфәтуллинның роман-повестьларында республикабыз халык хуҗалыгындагы яңа мөһим күренешләрнең — нефть промышленносте барлыкка килүнең, электростанцияләр төзелүнең кичәге крестьян тормышында һәм язмышында зур үзгәрешләр тудырулары конкрет герой образлары белән дәлилләп ачыла.

Күренә ки, прозаның тормыш белән бәйләнешләре ныгу аның жанр үсешенә дә йогынты ясый. Халкыбызның үткәндәге һәм хәзерге иҗтимагый-рухи үсешен тирән анализ аша үткәреп һәм гомумиләштереп чагылдырырга омтылу алтмышынчы еллар татар прозасында күләмле әдәби формаларның — роман белән повестьның аеруча әһәмиятле роль уйнауларына китерде. Бу жанрларның үз эчләрендә дә кызыклы гына үзгәрешләр бара. Повесть еш кына үзенең сюжет-композициясе буенча романга якыная. Романның үзенә килгәндә исә, соңгы елларда без аның төрле-төрле формалары белән очрашабыз. Алар арасында социаль романны да, тарихи-революцион романны да,

психологик романны да һ. б. күрергә мөмкин. Хикәя исә, гәрчә ул әдәби иҗатның иң актив жанрларыннан берсен тәшкил итәргә тиеш булса да, хәзерге прозада роман белән повестьтан шактый калыша. Бу жанрга гомум игътибар кимегән бер вакытта Ф. Хөсни, Г. Галиев, С. Сабиров, А. Гыйләҗев, Б. Камалов, Г. Мөхәммәтшин кебек прозаикларның хикәя өлкәсендә ярыйсы гына актив һәм нәтиҗәле эшләп килүләрен аеруча билгеләп үтәсе килә. Тулаем алганда исә, тормыш белән бәйләнешләре ныгый бару аркасында, 60 елларда татар прозасы һәм идея һәм эстетик яктан үсә, житлегә төште. Туган халкыбызның XX йөз башыннан безнең көннәргә кадәр үткән тарихи үсеш юлын чагылдыру кебек гаять зур һәм катлаулы бурычны сәнгатьчә хәл итү дәвамында хәзерге проза реалистик анализның һәм конфликтлылыкның көчәюе, геройны мөхит белән диалектик бәйләнештә сурәтләү һәм тарихилык принцибына игътибар арту шикелле әһәмиятле эстетик сыйфатларга баеды. Болар барысы милли прозабызның нык адымнар белән социалистик реализм юлыннан баруы турында сөйлиләр.

* * *

Күренә ки, Совет власте елларында татар прозасы житди эзләнүләргә һәм күркәм ачышларга бай булган данлы үсеш юлы үткән. Үз алдында торган олы бурычларны хәл итү өчен киеренке иҗат дәвамында ул һәм идея һәм эстетик яктан чыныга һәм житлегә барган Республикабызның данлы юбилеен да язучыларыбыз тынгысыз эзләнүләр һәм кызыклы табышлар белән, иҗат юлында яңа үрләр яулаган хәлдә каршылыйлар.

Энҗе Мөэминова

# «БӘХЕТЛЕ БУЛЫРСЫҢ ДИГӘН ИДЕ...»

ОЧЕРК

Камы-Исмәгыйл авылын халык телендә «Камы» дип кенә йөртәләр. Табигать матурлыгына бай түгел бу авыл: урманы ерак, зур суы, әрәмәлекләре юк. Бар булганы — тау да чокыр, тау да чокыр. Таулары да әле аның яшел куаклар белән капланып алынган матур таулар түгел, ә тиресе сыдырылган терсәк кебек, ташлары тышка чыгып, тырпаеп торган шәрә таулар. Ә менә кешеләренә килгәндә инде — менә дигән, кешеләре бик әйбәтләр! Эчкерсез, киң күңелле, эшчән һәм кунакчыл кешеләр. Син аларга авылыгыз матур түгел дип әйтеп кара әле! Алар хәзер синең белән бәхәскә керешеп, аның тау итәкләреннән челтерәп аккан чишмәләренең матурлыгын, «Капитан тавы», «Чатыр тавы» дип исемләнгән тауларының Пугачев восстаниесе белән бәйле тарихларын сөйли башларлар. Аннары зур итеп салынган яңа мәктәп, яңа клуб, яңа магазин, китапханә, медицина пункты биналарын күрсәтерләр.

Минем Камыда беренче генә булуым түгел. Кунак булып та, үзләрендә сигезьеллык тәмамлагач, безнең авылга — Габдрахманга килеп укучы балаларның әти-әниләре белән очрашып сөйләшер өчен дә — кыскасы, күп мәртәбәләр булырга туры килде миңа анда. Һәм менә, ни гаҗәптер, Камыны искә алу белән үк, һәрвакыт минем күз алдыма, иң элек, тау итәгендә кояш күзенә карап, тәгәрәп үскән кавыннар һәм яшел суган түтәлләре килә. Кечкенә вакытымда кунакка баргач ашаган ул кавыннарның татлы тәмен мин әле дә авызымда тотам төсле.

Ә бүгенге килүем бөтенләй башка. Мине бу юлы зур бер тантанага кунак итеп чакырдылар.

* * *

Без килеп кергәндә, халык җыелып беткән иде инде. Өстәл түрендә Гаян апа үзе, аның ике ягына кызы һәм улы белән килене утырганнар. Кунаклар белән исәнләшеп, үз урыныма үткән арада табынга күз төшермичә булдыра алмадым. Ризыкларның матурлыгы һәм күп төрлелеге таңга калдырды мине. Нинди генә азык юк бу табында! Авылның барлык аш-су осталары җыйналып «Иң оста пешекче» дигән исемне алу өчен конкурс оештырганнармы әллә диярсең! Һәр өстәл үзенчә матур һәм үзенчә бай! Минем кызыксынуым шул дәрәҗәгә җитте ки, янәшәмдә утыручы ягымлы гына бер кыздан шыпыртлап кына: «Табынны шушы кадәр матур итеп кемнәр әзерләде икән?

Монда ничә төрле ризык барын беләсе иде!» — дип әйтмичә түзмәдем. Күршем миңа бераз текәлеп карап торды да: «Ризыкларның төре кунаклар санынннан өч-дүрт мәртәбә артыграк булыр. Ә әзерләүчеләре — кунаклар санынча. Бу табын — кучтәнәчләр табыны. Кучтәнәч хуҗалары — кунаклар. Кунакларның күбесе Гаян апаның балалары. Калганын соңрак белерсез әле»,— диде, серле генә елмаеп.

Тантананы башларга вакыт икәнлекне белдереп, тынлы оркестр тынуга, партком секретаре сүз алып: «Гаян апабыз хөрмәтенә багышланган юбилей тантанасын ачык дип белдерәбез»,— диде һәм мәҗлесне ачып җибәрде. Гөрләшеп кул чаптылар. Һәм шул вакытта ишектән берсе егерме биш-утыз, ә икенчесе егерме-егерме биш яшьләр тамасындагы сөйкемле генә ике хатын-кыз килеп керде. Аларның берсе кулына зур поднос белән чәкчәк күтәргән, ә икенчесе, ак салфеткага салып, шишара (пич төбенә тәмләп салынган кечкенә ипи) тоткан. Керүчеләр кунаклар белән очраштылар да, өстәл өстәлнең ике ягыннан үтеп, Гаян апа янында туктадылар. Халык гөр килеп, шаулашып алды.

— Хөрмәтле Гаян апа! Моннан нәкъ 32 ел элек якты дөньяга килүчеләрнең беренче шаһите дә Сез булгансыз, бүген дөньяга килүче сабыйларның беренче авазларын да сез ишетәсез. Менә бирегә җыйналган барлык аналарның да, балаларның да җаннан җан аерылган иң авыр минутларында Сез, ана һәм бала гомерен саклап калу өчен, үзегезне аямыйча тырышкансыз. Бүген үзегезгә 50 яшь, хезмәтегезгә 31 ел тулган көндә, сез беренче булып үз кулыгызга алган «сабыегыздан» шушы кучтәнәчне кабул итеп алсагыз иде!..

Көтелмәгән бу чыгыштан халык бик канәгать булып, гөр килеп кул чапты. Гаян апа артык дулкынланудан дерелдәгән куллары белән кучтәнәчне алгач, кипкән иреннәрен чак-чак кыймылдатып: «Рәхмәт!» дип кенә әйтә алды. Оркестр тагын, халыкның шау-шуыннан өстенлек итеп, тантананы күтәреп җибәрде. Керүчеләрнең икенчесе, оялчанлыгы йөзенә үк чыгып торган яшьрәге, болай дип сүз башлады:

— Татар халкында элек-электән бәби әбисе иң хөрмәтле кеше саналган. Һәм халыкта шундый бер гадәт яшәгән: һәрбер бәби тудырган ана ипи салган саен, бәби әбисенә атап шишара сала һәм шуны салфеткага төреп аңа илтә торган булган. Шулай эшләмәгәндә, бәбинең дә, әнинең дә эче авыртулы була, янәсе. Әгәр шул гадәт буенча, әниләр һәр баласы өчен, һәр ипи салганда, Гаян апага шишара китерә торган булсалар, үзебезнең Чатыр тавыннан да биегрәк шишара тавы өелгән булыр иде. Менә мин бүген шул гадәтне яңартып, Гаян апаның юбилеена, быел үзе кабул иткән иң яшь сабыйның әнисе буларак, кучтәнәч итеп үзенә атап салынган шишара китердем...

Яшь ананың бу сүзләреннән соң залда туган җанлылыкны һәм күңелле шау-шуны җиңәргә оркестрның да көче җитмәде.

Гаян апа хөрмәтенә тост тәкъдим ителде. Залны салют залпларына охшаган шампан бөкеләре шартлавы һәм бокаллар чыңлавы, күңелле шау-шу тутырды. Бәйрәм кызганнан-кыза барды. Юбиляр исеменә бик күп мактау сүзләре, котлаулар әйтелде. Соңгы сүзне Гаян апаның үзенә бирделәр.

— Чистай медицина училищесын тәмамлап, сезнең авылга эшкә килгәндә, миңа нибары унтугыз яшь иде. Хәзер илле! Утыз бер ел гомерем минем сезнең күз алдыгызда һәм сезнең белән бергә үтте. Авыр вакытларда сез минем ышанычлы таянычым булдыгыз. Кайгыларымны да, шатлыкларымны да тигез уртаклаштыгыз. Өйләренә килен булып төшкәндә, мәрхүм ирем миңа: «Бер дә икеләнмә, Гаян, син бездә бик бәхетле булырсың»,— диган иде. Аның әйткән сүзләре рас килде. Бүген мин дөньядагы иң бәхетле кеше! Моның өчен сезгә рәхмәтемне ничек кенә итеп әйтсәм дә аз булыр төсле.

Шул вакытта кемдер: «Ә сез аны, Гаян апа, җыр белән әйтегез, җыр белән!» — дип әйтеп куйды. Аның бу тәкъдимен халык дәррәү күтәреп алды: «Дөрес!», «Җырлагыз әле бер, Гаян апа!», «Теге үзегез яраткан җырны!», «Сорыйбыз!» — дигән сүзләр залны тагын бер гөрләтеп алдылар.

— Гафу итүегезне үтенәм, иптәшләр! Бик теләсәм дә, мин бүген сезнең алда җырлый алмыйм. Җырлар чакта җырлый идем бит. Хәзер тавышым юк...

— Өйдәгез кызын — Риманы сорыйбыз! Риманы!

— Дөрес, дөрес!

Рима ялындырып тормады. Әнисенең олы бәйрәмендә, үзе баянда уйнап, әнисенең иң яраткан җырын, ягымлы тавыш белән, җырлап та җибәрде.

Таулар ватып, ташлар актарганда,
Сез булырсыз минем уемда.
Эштән арып, яллар иткән чакта,
Сез булырсыз минем күңелемдә.

Халык тын да алмый тыңлады. Җыр тәмамлангач, гөр китереп кул чаптылар.

Бәйрәм тантанасы тәмам булганда, ярты төн авышып килә иде инде.

Төн. Күктә чекерәеп йолдызлар яна. Айның зәңгәрсу салкын нурлары кар кристалларын, үтә кечкенә йолдызларга охшатып, җемелдәтәләр. Аяк астында кар шыгырдый. Мондый көннәрдә аның шыгырдавы урамның аргы башына кадәр яңгырап ишетелеп тора.

Без, әкрен генә сөйләшә-сөйләшә, Гаян апаларга юл тотабыз.

— Менә кайтып та җиттек. Балалар бездән алдарак өлгергәннәр — өйгә ут алынган. Яшьләр шул,— диде Гаян апа, урамга яны белән салынган матур гына өй турысына килеп җиткәч.

Ишек алдында җыйнаклык, пөхтәлек күзгә ташлана. Үз урынына, матур һәм уңайлы итеп урнаштырылган һәрбер каралты хуҗаларының акыллы һәм план белән эш итә белүләре турында сөйли.

Без өйгә үтәбез. Гаян апаны өендә дә сюрприз көткән икән әле. Балаларының тантаналы мәҗлестән шактый иртә киткәнлекләрен исбатлап, өйгә яңа гына пешеп чыккан бәлеш исе таралган. Яшьләр безне түр бүлмәгә чакырдылар һәм өстәл янына утыруыбызны үтенделәр.

— Кадерле әниебез, сине олы бәйрәмең белән котлыйбыз! — дип, улы әнисенең кулын кысты, килене тыйнак һәм матур итеп әзерләнгән табынның өстен ачты, ә кызы һәр өчесе исеменнән әнисенә атап алынган бүләкләр төргәген тапшырды.

Ананың шатлыгы эченә сыймады.

— Рәхмәт инде сезгә, балалар. Гомергә рәхәт күрегез! — дип әйтеп бетерүенә, йөзе буйлап шатлыклы күз яшьләре тәгәрәп төштеләр.— Әтиләре үлгәндә, кызыма нибары биш яшь, ә улыма унике яшь иде. Тормышның бөтен авырлыгын үз җилкәмә алып, гомеремне шушы ике балам бәхете өчен багышладым инде мин,— диде Гаян апа, миңа карап.— Улымны, әтисе кебек, гармунчы итәсем бик килгән иде. Өйрәнәсе килмәде. Ә менә кызым көтмәгәндә генә гармун белән мавыкты да китте. Балаларым үземне кеше арасында ким-хур итмәделәр инде. Рәхмәт. Улым Марлис әйбәт кенә эшли. Эш урынында бик яраталар үзен. Киленебез Рима — укытучы. Кызым Риманы, бергә эшләгәч, үзегез яхшы беләсез инде,— дип, Гаян апа балалары турында горурланып сөйләп китте.

Үз исеме чыгуга, Рима сүзне икенчегә борып җибәрде:

— Әни, үзең яраткан теге матур җырның әти сугышка киткәч үзең чыгарган куплетын җырлап күрсәт әле. Мин уйныйм,— дип, тиз генә баянын кулына алды да сыздырып җибәрде. Аңа Гаян апаның моңлы тавышы кушылды.

Агыйделкәй алкын, суы салкын,
Идел аша кошлар сайраша.
Онытмагыз безне, китүчеләр,
Еш-еш сәлам язгыгыз хат аша.

Бу җыр безнең барыбызның да күңелләрен кузгатты. Гаян апа җырлап туктау белән үк: «Әле бүгенгедәй хәтеремдә»,— дип, моннан утыз елга якын элек булып узган вакыйганы сөйли башлады.

— 1941 елның кышы. Сугышның иң кызган чагы. Әтиләре Казанда укуда. Улымның тугыз ае яңа тулып кына килә. Һәр таң саен олау-олау ирләрне, кан-яшь белән, сугышка озатабыз. Һәр көнне берәр авылдашыбызның үле хәбәрен ишетеп, зар елыйбыз. Шундый көннәрнең берсендә минем үземә, бер тәүлек эчендә җыенып, авылдан чыгып китәргә кушылган повестка килде. Бу хәбәрне алу белән мин бары бер нәрсәне генә уйладым: «Ә балам нишләр? Кем янында калыр? Аны кем карар? Кем имезер?

Юк, юк, бу бит мөмкин була торган хәл түгел. Бәлки, военкомат хәлне аңлар. Бик үтенеп сорасам, сабыем хакына калдырырлар. Һич булмаса, улыма яшь тулганчы, күкрәк сөтеннән аерылганчы гына кичектереп торырлар. Тиз генә җыендым да, шундый уйлар белән, бөтен көчкә чапкан ат алдыннан йөгерердәй булып, Әлмәткә военкоматка киттем. Юлда барганда, военком белән ничек сөйләшәчәгемне күз алдыма китердем.

— Сезгә сугыш вакытында медицина хезмәткәрләренең никадәрле кирәклеге турында сөйләп тору кирәкмәстер дип уйлыйм мин... Балагыз өчен бер дә борчылмагыз. Аны сезнең үзегездән дә әйбәтрәк итеп карарлар, тәрбияләрләр. Сезне бит госпитальләрдә йөзләр, меңнәр тилмереп көтәләр...

Озатырга бөтен авыл халкы җыйналды.

Тавышлар ишетелмәслек ераклыкка китеп, авыл үзе инде тәмам күренмәс булгач та, баламның шәүләсе күз алдымнан китмәде. Өстенә кигән кызыл блузкасының ак сәдәфләре, йодрык чаклы зурлыкта булып, каршымда торды...

Алты ай буе Казан госпитальләрендә хезмәт итеп авылга кайтканда, улым яшь ярымлык булган иде инде. Кайтасымны ишеткәч, авыл халкы улымны арбасы белән тартып, юл тутырып, каршы килде. Шулай итеп, аерылу кайгысын бергә кичерешкән авылдашларым күрешү шатлыгын да уртаклаштылар. Алар улымны үстерешергә дә әбисенә ярдәм итешкәннәр. Миннән башка гына иремне сугышка озатып калганнар...

Әтиләре сугышка киткәнче, мәктәптә директорлык вазифасын алып бара иде. Сугыштан ул яңадан яраткан эшендә — мәктәптә эшли алмаслык булып, каты авыруга әйләнеп кайтты. Һәм озак вакытлар урында ятып авырып, газапланып дөнья куйды.

Сез миңа: «Чәчләрегез бигрәк иртә агарган»,— дидегез. Минем хезмәтемдә дә бит бер минуты чәчләреңне агартырлык хәлләр булып кына тора. Утыз бер ел буе бер авылда фельдшер-акушерка булып эшләү дәверемдә, кыл өстендә торган кеше гомерен саклап калу өчен, үземә бер минут эчендә берничә мәртәбә үлеп терелергә туры килгән вакытлар бик күп булды.

Бер вакытны шулай, өйгә кайтып өстемне чишенүем булды, күңелем нәрсәдәндер шомлана башлады. Һәм, күп тә үтмәде, үз янымда эшләүче санитаркамның ашыга-ашыга безгә таба килгәнлеген тәрәзә аша күреп калдым. Аны-моны уйлап тормастан, тизрәк өйдән чыгып йөгердем. Санитарканың борчулы йөзеннән үк хәлнең әйбәт түгеллеген аңлап алдым.

— Канны туктатып булмый! — диде ул, хәлсез тавыш белән.

Тудыру йортына килеп керү белән, ананың йөзенә күз салдым. Һәм шундук мин күрсәткән беренче ярдәмнәрнең генә файда итә алмаячагын аңлап, авыл Советына телефонга йөгердем. Авыл Советы тудыру йортыннан шактый ерак. Мин бөтен көчем белән йөгердем. «Тизрәк, тизрәк! Мондый вакытта бер минут та хәл итә бит!» — дигән уй, миңа көч өстәү урынына, тез буыннарымның хәлен алды. Өйалды баскычыннан үрмәләп менеп, көч-хәл белән ишекне ачтым. Телефон трубкасына үрелергә кулларымның хәле җитми.

— Тизрәк шалтыратып, «Ашыгыч ярдәм» машинасын чакыртыгыз әле! Кеше үлә бит!..— дип, чак-чак кына әйтә алдым. Машинаны көтеп алып, ананы врачлар кулына тапшыргач сузылган мондый вакытның бер минуты бер ел кебек тоела бит аның!..

Монысы әле аның бер хәл. Ә менә сугыш вакытында, дөньяга туарга тиешле һәр җан иясен саклап калу өчен дәүләт алдында, закон алдында бик зур җаваплы булган бер чорда, яшерен абортлар шикелле җинаятьле эшләр китергән фаҗигаләрне сөйләве дә авыр...

Без утны сүндереп йокларга яттык. Ләкин керфекләремә йокы кунмады. Урынында әле бер якка, әле икенче якка әйләнеп ятуына карап, мин Гаян апаның да йоклый алмаганлыгын сиздем. Шулай да, күпмедер вакыттан соң, мин йокымсырап киткәнмен. Шыгырдап капка ачылган тавышка кабат күзләремне ачтым. Моны ишетеп, Гаян апа тиз генә урыныннан торды да, мине «уятмас» өчен аяк очларына гына басып, алгы якка чыкты. Ишек төбендә әкрен генә сөйләшкән ир-ат тавышы ишетелде. Гаян апа берничә минутта киенеп бетеп, килүче белән бергә өйдән чыгып та китте. «Берәр сабый дөньяга киләдер, күрәсең. Ул халыкның шул синең белән хисаплашып торырга вакыты юк»,— дип уйлап куйдым мин. Һәм үзебезнең мәктәптә булган бер вакыйганы искә төшереп, ихтыярсыз елмайдым. Болай булган иде ул хәл.

Беренче баласына йөкле булган бер иптәшебез класстан авырып чыгып, директор янына кергән. Һәм үзенең, иртәдән башлап, ялга китәргә тиешлеген белдергән. «Ярар, хәл итәрбез. Тик берничә көн генә сабыр итеп торсагыз, әйбәт булыр иде. Мин иртәгә үк РОНОга шалтыратып сөйләшермен дә, урыныгызга кеше китертербез»,— дип җавап биргән аңа директор. Тик менә дөньяга киләсе сабыйның да, әнисенең дә сабыр итәр хәле калмаган. Берничә сәгатьтән директорга, РОНО рөхсәтен көтеп тормыйча гына, бер малай дөньяга килгәнен хәбәр иткәннәр. Шул вакыйгадан соң шактый еллар коллективта РОНО рөхсәтеннән башка дөньяга килгән бу малай турында кызык итеп сөйләп йөрделәр.

Мин, йоклап китеп, Гаян апаның кайчан һәм ничек кайтканлыгын сизмичә дә калганмын. Күземне ачып җибәргәндә инде өй эче яп-якты, ә Гаян апа өстәлгә иртәнге чәйне әзерләп йөри иде.

— Хәерле иртә. Йоклый алдыгызмы? — диде Гаян апа, миңа ягымлы гына карап.

— Рәхмәт. Бик әйбәт йокладым. Тик менә сезгә генә йокы эләкмәде.

— Зарар юк. Мин өйрәнгән инде. Бер хатын бозылган ит ашап агуланган булган, ашказанын юдырдым. Хәле яхшырып калды,— диде Гаян апа.

— Андый очракларда да сезгә мөрәҗәгать итәләрмени? Әллә авылыгызда фельдшерларыгыз юкмы?..

— Барын бар да, электән өйрәнгән гадәт буенча, үз итеп, һаман шулай миңа килгәләп торалар алар. Кешене кире борып җибәреп булмый бит.

— Шулай шул,— дип куйдым мин дә, аның сүзен хуплап.

Иртәнге чәйдән соң, Гаян апа белән тудыру йортын карарга киттек.

Өч кенә койкалы бер йортта, нәкъ шәһәрдәге кебек, ана һәм бала өчен кирәк булган бөтен шартлар да бар. Яшь аналарга консультация пункты хезмәтен дә үти икән әле ул.

— Сигез ел инде менә безнең авылда балалар үлеме булганы юк. Ана карынындагы чорыннан башлап, ундүрт яше тулганчы балалар безнең күзәтү астында торалар. Авылыбызның бала тудыру йорты республикада үрнәк санала. Әле күптән түгел генә бездә семинар үткәрелде. Килүчеләр эшебезне бик яратып киттеләр,— диде Гаян апа, үзенең утыз бер еллык хезмәтенә йомгак ясагандай.— Улым белән киленем шәһәргә күчик диләр. Алар яшьләр шул әле, торган нигезне ташлап китүнең никадәр авыр икәнен белмиләр. Сагыну хисе дә таныш түгел аларга. Ә менә мин аларны үз башымнан кичереп беләм. Үземнең алдагы тормышымны шушы авылдан, шушы авыл кешеләреннән башка күз алдыма да китерә алмыйм. Алардан башка бәхетем тулы булмас төсле тоела минем. Әтиләре, мәрхүм, «Син бездә бәхетле булырсың, Гаян»,— дигән иде бит.

Кайту юлында да уем Гаян ападан аерылмады. Кичәге матур тантананы мин өр-яңадан күз алдымнан кичердем.

Әйе, Гаян апа, сез бүген бик-бик бәхетле! Сезне бөтен авыл халкы олылап: «Үзебезнең Гаян апа»,— дип кенә йөртә. Ә бит хезмәт кешесе өчен халык тарафыннан үзенекедәй кабул ителүдән дә зуррак бүләк юк дөньяда! Халык бит кешеләрне бик сайлап кына үз итә.

**Рим Кәримов**

# КИҢ КОЛАЧЛЫ ИҖАТЧЫ

Фоат Халитов Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында 1937 елдан башлап эшли. Эшләвенең беренче елларында ук аны күреп алалар, аңа өмет баглыйлар. Чөнки ул олы сәхнәгә инде канат чыгарып килгән яшь көчләрнең берсе була. Әле Вахитов исемендәге Жиркомбинатта эшче яшьләрнең үзешчән сәнгать түгәрәгендә катнашып йөргәндә һәм Казан эшче театрында артист булып эшләве дәверендә үк Фоат җаваплы гына сәхнә образларын ярыйсы ук камил башкарып чыга. Мәсәлән, А. Островскийның «Гаепсездән гаеплеләр» әсәрендә Григорий Незнамов ролен башкарган яшь артист Фоат Халитов турында 1936 елда «Кызыл Татарстан» газетасы болай дип язды: «...Буржуа мохитында ялгыз калып, шул ук буржуа тарафыннан кимсетелүче, җәберләнүче артист тибын бөтен тулылыгы белән бирә алды. Незнамовның ялгызлык трагедиясе көчле бирелде».

Профессиональ сәхнә иҗатының беренче адымнарында ук уйламыйча сүз әйтү түгел, төгәл мәгънә салмыйча хәтта кул хәрәкәте ясарга да мөмкинлек бирми торган җитди образлар белән очрашу зур театр мәктәбе үтмәгән яшь артистта әдип сүзенә игътибарлы, җаваплы мөнәсәбәт тәрбияли, персонаж фикеренә тормыштан килергә, Фоат аганың үзенчә әйтсәк, тормышны укырга өйрәтә.

Тормышны уку. Беренче карашка гади генә яңгыраган бу тәгъбир артист өчен гаять дәрәҗәдә әһәмиятле һәм тирән мәгънә белдерә. Сәхнәгә чыккан саең яңадан-яңа кеше характерларын тудыру өчен, артист тормышны, кешеләрне күзәтә белергә, яңа буяулар, яңа төсмерләр таба торырга тиеш. Башкарган образың шул ук вакытта ышандырырлык гади дә, табигый халәтендә дә булсын. Менә шушы сыйфат артист Фоат Халитов иҗатында туктаусыз рәвештә үсә, камилләшә барды.

Ул башкарган рольләрнең йөреш-торыш, килеш-килбәтендәге, уй-сүзендәге һәм интонацияләрендәге табигыйлек Фоат Халитовның артистлык осталыгыннан, тәҗрибәсеннән генә түгел, бәлки аның, кеше буларак, характерыннан да килә. Билгеле булганча, артист үз герое кичерешләренең, холкы-фигыленең тиңдәшен тормыштан эзли. Фоат ага Халитовның кече күңелле, танышлыкта талымсыз, сөйләшү-киңәшүдә эчкерсез, гади табигатьле булуы исә моңа бик нык ярдәм итә, күрәсең. Аның характерындагы бу сыйфат гомер-гомергә тормыш белән тату булып, кулыннан килгәнне һаман кешеләргә биреп яшәргә тырышуыннан да килгәндер. Шушы уңай белән язучы Фатих Хөснинең 1941 елда «Кызыл Татарстан» газетасында басылган бер фикеренә мөрәҗә-

гать итик: «Халит белән Мамай, ике җиңел егет, ике дус егет, кайчандыр бөтен эстрадаларны тутырып, республика буйлап шаулап йөриләр иде. Эшчеләр клубында, кызыл почмакларда, колхоз станнарында, ашханәләрдә, кыскасы, сөйләргә, җырларга, такмак әйтергә мөмкин булган бөтен җирдә бу егетне очратып була торган иде. Алар урын, публика талымлап торуны белмәделәр, алар бернәрсәдән дә тартынмыйча, халыкка матур сүз, сәнгать азыгы ташып йөрделәр. Менә шул ике егетнең берсе Фоат Халитов хәзер, Татар дәүләт академия театрының артисты буларак, гаҗәп зур энергия белән үсеп килә. Яшьлек энтузиазмы белән давыллана белү, шигъри җиңеллек һәм тормыш дөреслегенә таба омтылу менә бу сыйфатлар — яшь артист Халитовны башкалардан аерып торалар»,— ди ул.


Моннан 30 еллар чамасы элек язылган бу сүзләргә өстәп, Фоат Халитовның артистлык иҗатына тагын эзлэнүчәнлек хас, ул башкарган образлар гаять табигый һәм эзлекле төстә үсә дә баралар, дип әйтәсе килә. Менә Николай Погодинның «Мылтыклы кеше» пьесасы буенча эшләнгән спектакльдән солдат Иван Шадрин образы. Шадрин-Халитов белән беренче мәртәбә очрашканда, без аны империалистик сугыш, окоп газапларыннан йончыган гади бер солдат итеп күрәбез. Аның кыяфәте боек, революцион Петроградтагы һәр вакыйга һәм һәр кешегә ул бераз шикләнебрәк карый. Халитов аны тирә-юньдә булган хәлләр белән әллә ни кызыксынмый, үзе белән кызыксынучыларга да теләмичә генә җавап бирә торган кеше итеп уенга кертә. Шуның белән бергә, сер итеп кенә саклый торган бер уе барлыгын сиздереп, аның акылы, үз башы белән эш итәргә ярата торган кеше икәнен, белер-белмәс башкалар артыннан ияреп китүче беркатлы аумакай булмавын тамашачыга җиткерә. Шушы минуттан тамашачы, нык ышанып, үз итеп һәм зур теләктәшлек белдереп, Шадрин-Халитовның революциягә килүен күзәтә башлый.

Халитов Петроградтагы революцион вакыйгалар уртасында калган Шадринны тигез, табигый үстерә. Аның сәхнәгә килеп керүе дә акрын, берникадәр кыюсыз. Һич тә алга чыгып, күзгә ташланып тормый. Скульптор сынны акрынлап, сылап-сыйпап, чын яратып ясаган шикелле, Халитов та бу образын зур саклык белән, сөеп, аның характерына, җае чыккан саен, игътибарлы күз генә күрә ала торган ниндидер кирәкле бер деталь өстәп, тулыландыра, матурлый, бөтенәйтә бара.

Инде күп еллардан бирле театр тәнкыйте Фоат Халитовны киң диапозонлы артист дип бәяләп килә. Ягъни ул характерлары белән бер-берсеннән нык аерылган яки капма-каршы булган, яшь ягыннан, тормыш шартлары, омтылышлары белән бер-берсенә охшамаган, төрле чор, төрле сыйныф кешеләренең образларын бер үк дәрәҗәдә уңышлы башкарып килә. Ул рус, татар һәм көнбатыш классиклары әсәрләре буенча эшләнгән спектакльләрдә дә, драмада, комедиядә һәм трагедия жанрында да бер үк дәрәҗәдә уңышлы уйный.

Ләкин Фоат Халитов нинди генә образ өстендә эшләмәсен, аның барлык образларына хас бер сыйфатны аерып күрсәтергә була. «Кызыл Татарстан» газетасының 1945 елгы бер санында «Каюм Насыйри» спектакленә багышланган рецензиягә игътибар итик әле. Анда: «Халитов иптәш башкаруында Каюм Насыйри шәхси тормышта йомшаграк, җәмагать эшендә көчлерәк гәүдәләнгән», диелгән. Биредә генә түгел, Халитов башкарган һәр рольдә персонаж характерының ниндидер бер сыйфаты аерылып тора. Ул һәрвакыт образның асылын билгеләүче сыйфатын, теге яки бу эшне башкарудан нинди мәгънә эзләвен ахырынача ачыкларга тырышучы артист. Менә бүген, хәзер бу герой нәрсә хакына яши, нинди көч аны киләчәккә канатландыра? Фоат Халитов образдан иң элек шуны эзли һәм таба. Шунлыктан булса кирәк, ул башкарган образлар һәрвакыт кайсыдыр бер ягы белән калкурак булып хәтердә калалар.

Әйтик, солдат Шадринның бөтен максаты — авылга кайтып сыер алып, тыныч, тук тормышка ирешү. Шадрин-Халитов һәрвакыт шушы уй белән яши һәм тыныч, тук тормышка социалистик революция аша гына ирешү мөмкин булачагына ышанганның соңында ул инде революция солдаты булып китә. Җиргә тартылу, җир турында сөйләгәндә янып, дәртләнеп китү, үзенең крестьян булуын мөмкин кадәр ныграк, калкурак итеп сиздерергә тырышу Шадрин-Халитовны күрәштә көчлерәк, уйда-сүздә матуррак итә төшә.



Ф. Халитов К. Насыйри ролендә.

Яки менә Фоат Халитов башкаруында Хөснетдин маклерны алып карыйк. Шәриф Камалның «Хаҗи әфәнде өйләнә» комедиясе буенча эшләнгән бу спектакльнең 1944 елда куелган булуына карамастан, әле күп театр сөючеләребез хәтерли торганнардыр. Чөнки ул театрыбызның «Хуҗа Насретдин» белән рәттән торырлык зур уңышларыннан берсе. Мәгълүм булганча, әсәрдә хатыны өстеннән яшь кәләшкә өйләнергә йөрүче азгын Юныс хаҗи көлкегә калдырыла. Беренче карашка, Хөснетдин маклер да, алдынгы карашлы яшьләр Җәләл, Габделхак, Камиләләр белән берлектә, Хаҗины изге ният белән көлкегә калдырырга йөри дип уйларга мөмкин. Ләкин Халитов Хөснетдинне бурныкын урларга йөрүче карак итеп уйный, аның яхшы ниятле булып күренүе ничек тә маклерлык акчасын кулга төшерү өчен эшләнгән хәйлә-ялган икәненә басым ясый һәм образның төгәл социаль яңгырашына ирешә.

Юныс хаҗи шикелле үк, Хөснетдин-Халитов — паразит элемент. Һәм ул аны яшермичә дә, Фоат Халитов Хөснетдинне ул чор тормышы өчен гадәттән тыш бер күренеш итеп уйнамый. Чат саен, базар саен очрый торган, ялган булган җирдә үзенә күрә табигый һәм зарури бер кеше итеп уйный. Шуның белән тамашачыны ул заман шартларына, заман мохитына алып керә, алып-сатарлар чорының ачык гәүдәләнгән бер тибын иҗат итә.

Алда Фоат Халитов һәр рольнең ниндидер характерлы бер асыл сыйфатын калку итеп сурәтли дидек. Мисалга солдат Шадринны, маклер Хөснетдинне китердек. Шул хакта сөйли торган мисалларның тагын берсе төсендә драматург Кәрим Тинчуринның «Зәңгәр шәл»еннән ат карагы да бик отышлы булыр кебек. Ат карагы Миңлегали белән Хөснетдин арасында зур уртаклык бар. Чөнки алар икесе дә караклар: алар өчен намус, вөҗдан дигән төшенчәләр бөтенләй ят. Шулай булгач, артистның бу ике образны бер үк материалдан оештыруы мөмкин.

Әмма Фоат Халитов, үзен һич тә кабатламастан, аларның һәр икесен гаять оста индивидуальләштерә. Һәр ике каракның үз сүзе генә түгел, үз төсе, үз карашы, үз омтылышы, үз йөрәге, сөйләү манерасы бар.

Хөснетдин — реалист карак, урлашу аның төп хезмәте һәм кәсебе. Миңлегали исә — романтик карак. Ат урлауның шигърияте, тәмен татыган кеше. Ул аттан башка нәрсә урламый да. Чөнки аны, малдан битәр, атны урлау моменты, ялмышыңны куркыныч астына куеп ихтыярыңны сынап карау, аннары атны алып чыккач, өермә куптарып иреккә очу ләззәтен тату, йөрәкне бер җилкендерү үзенә тарта. Бу турыда сөйләгәндә

Миңлегали-Халитов онытылып-онытылып китә, аның иреннәре калтырый, күзләре бер очкынлана, бер дымлана, борын тишекләре киңәеп-киңәеп куя, тыны кысыла:

**МИҢЛЕГАЛИ. Белмисез, егетләр, ат урлауның рәхәтен, ләззәтен белмисез. Менә караңгы төн, ди, ындыр аркылы корсак өстеннән килеп, сырт капканың алдына туктыйсың. Йортта эт әрә башлый, син тынычны чыгармыйча, күләгә төсле тын торасың. Шул арада аргамак җаныем абзарында пошкырып куя, йөрәкләр тиздән кавышуны сизгәнгә кытыкланып китә, сулышлар кысыла башлый. Капка астын казып керәсең дә, салават укып, агуланган икмәк, ит кисәкләрен этка ташлый торасың. Бер ярты сәгатьтән аллага тапшырып эт тончыга. Аргамакның ишегендә чабата хәтле бикләнгән йозак була. Бисмилла әйтеп, отмычка белән келт итеп бер борасың да, йозак шылт итеп борынын күтәреп куя. Абзар ишеге ачылуга, кара бодай басуындагы төсле хуш исләр аңкып китә. Аргамак җаныем, кеяз кызлар төсле, кызыл билле прәннек кимергән кебек, шыгыр-шыгыр печән кимереп ята, сылу кызлар көлгән төсле кеязләнеп пошкырып куя. Барып ялыннан тотып сыйпагач, бәгырем килдеңме дигәндәй пуф итеп бер сулап ала. Шуннан иренен боргычлап, акрын гына сырт капкадан чыгарасың да, әгүзе бисмилла әйтеп атланып, әйдә... Тфф!!! Менә шул чагында рәхәтне әйтәм, кыз куенына керүләрең бер якта кала шул. Калтырап, дерелдәп торган нык гәүдәсен аякларың белән шундый итеп кочаклыйсың, Таһир Зөһрәсен дә алай кочаклый алмагандыр. Йөрәкләрең оҗмах рәхәтләрен сизә инде шул чагында.**

...Фоат Халитов башкарган рольләрнең исемлеген карасаң, аларның күплеге һәм төрле характерда булуы таңга калдыра. Мәшһүр Шекспирның «Король Лир» трагедиясеннән үзенең трагик бөеклеге белән тетрәткеч Кент һәм Таҗи Гыйззәтнең «Чаткылар» драмасыннан атай малын катай дип эчеп йөри торгач, тәмам бөлеп юкка чыккан Мочтак, Нәкый Исәнбәтнең «Гөлҗамал» драмасыннан үзенең эчке куәте, кайнар темпераменты, психологик тирәнлеге белән хәтергә сеңеп калган Хафиз һәм шул ук авторның «Хуҗа Насретдин» комедиясеннән байлыгына карап акылын, яшь кызларга карап сабырын җуйган Бики бай, Мирсәй Әмирнең «Миңлекамал» драмасыннан сугыш чоры тудырган авырлыкларны үзенең пычрак максатларында файдаланырга тырышучы вак җан Кылый Хәлим һәм Нәкый Исәнбәтнең «Муса Җәлил» трагедиясеннән Ватаныбызның, заманабызның горурлыгы, үзенең эчке гайрәте, таланты белән мәһабәт Муса Җәлил һәм башкалар, һәм башкалар. Күрәсез, никадәр сәхнә образлары иҗат ителгән. Алар арасында кечкенәсе бар, зурысы бар, берсе белән артист сине көлдерә, икенчесе белән тормыш, яшәеш турында тирән уйга сала, өченчесендә исә тарихның тетрәүле чорларе белән очраштыра. Ә образлар уйлану, уку, эзләнү нәтиҗәсендә туганнар.



Халитов — Хуҗа Насретдин.

Мәгълүм булганча, күп еллар буена Фоат Халитов Нәкый Исәнбәтнең «Хуҗа Насретдин» комедиясеннән Бики бай ролен уйнап килгән иде. Бер үк спектакльдән үзләренең социаль табигатьләре, темпераментлары, тышкы кыяфәтләре белән капма-каршы булган ике образ иҗат итүгә артист, әлбәттә, бик теләп алына. Ләкин бу очракта Фоат Халитовны үзенең артистлык осталыгын сынап карау мөмкинлеге генә кызыктырмый. Халык хыялында инде ничә гасырлар яшәп, турылык, тапкырлык символына әверелгән Хуҗа Насретдинның талантлы язылган сәхнә образын иҗат итү — артист өчен зур ышаныч

бөлдерүне күрсәткән мактаулы, җаваплы хезмәт.

Фоат Халитовның эш алымы турында сөйләгәндә өлкән артист Хәким ага Сәлимҗановның «Совет Татарстаны» газетасының 1959 елгы 10 март санында басылган фикерләренә тукталып үтик. Ул болай яза: «Фоат Халитов рольне тирәнтен аңлап, өйрәнеп эшләргә ярата. Образның эчке кичерешләрен ачуга зур урын бирә. Кечкенә генә, хәтта сүзсез рольне дә сокландыргыч җитди хыял белән башкара. Аның тагын бер уңай ягы шунда ки, ул кулына роль алган текст белән генә канәгатьләнми, эзләнә, шуның нәтиҗәсендә образның характерын тулырак ачуга ирешә».

Ә бит кулдагы текстка таянып кына образның характерын ачу артист өчен гомумән мөмкин эш микән?.. Әгәр дә ул мәгълүм тарихи шәхес образы да булса. Шуның өстенә трагик шартларга куелган шагыйрь дә булса. Муса Җәлил образы турында сүз башлавымны төшенгәнсездер.



«Соңгы корбан». Халитов — Флор Федулович.

Матбугатта Фоат Халитов башкаруындагы Муса образы өлгергәнлек, үзенә ышанучанлык сыйфатларына ия дип яздылар. Бу шулай һәм шулай булырга тиеш тә. Чөнки Халитов инде кырык яшькә җитеп килә торган Мусаны — көчле ихтыярлы, тормышка, көрәшкә карашлары тәмам төпләнгән, нык характерлы ил батырын уйный. Аның Мусасы — Ватанына, идеалына кул күтәргән дошманга каршы, Гитлермы ул яки сатлык Бәкерме, һич икеләнүсез көрәшкә ташланырга әзер торган арслан йөрәкле ир. Артист характерның шушы сыйфатына басым ясый. Ләкин Муса-Халитов дошманның күзләренә туры карап үрә каткан таш солдат түгел. Киресенчә, аның Мусасы гаять мөлаем. Бигрәк тә беренче пәрдәдә аның интонацияләре тыныч, йомшак, җанлы һәм берникадәр сагышлы.

Менә икенче пәрдә. Әсирлек. Муса аз сүзле, ул бераз каушаган, ләкин фикерләре таркау түгел, иптәшләренә карата элеккечә үк игътибарлы. Әсирлектәге һәр сәгать газаплы, куркыныч көрәш булуга карамастан, иң зур сынауның алда булачагын сизенгәндәй, Муса-Халитовның хәрәкәтләре ышанычлырак, тавышы ныклырак, фикерләре ачыграк була бара. Муса үзен һәм иптәшләрен дошман белән соңгы тапкыр алышуга әзерли. Тик ул шундый шартларга куелган ки, көрәш юлларын сайлаганда, берничә кыяфәткә кереп, ике Муса булып яшәргә тиеш. Чөнки дошман аңа бары ике генә юл тәкъдим итә. Беренчесе үлем, икенчесе хыянәт. Ә өченче юл бармы соң? Хәзер спектакльдән бер эпизодка тукталыйк. Ул икенче пәрдәдән Муса монологы. Муса-Халитов нәкъ әнә шул, өченче сорауга җавап эзли.

Ак эмигрант Зәбихулла Альбиков (бу рольдә Хөсәен ага Уразиков) Мусага дошман газетасында эшләргә тәкъдим ясый. Өстәлдә гариза язу өчен кәгазь, каләм калдыра һәм үзе чыгып китә. Тышта быргы тавышы ишетелә. Әгәр Зәбихулла тәкъдименә риза булмаса, өченче быргыдан соң ул асылырга тиеш. Сәхнәдә Муса-Халитов ялгызы. (Монолог бераз кыскартып алынды.) Ул ачулы, аптырашлы кыяфәттә, хәрәкәтсез. Сабыр, ярым шыпырт тавыш белән сүз башлый: «Нинди кеше ул? Нәрсә әйтте? Ул мине көчләми, бары тик ...икенең берсен генә сайларга тәкъдим итә». Муса-Халитовның беренче карашка басынкы күренгән уйлануларының киеренкелеген күз карашларыннан гына укыйсың: «Ләкин бу икенең кайсын гына алып карасаң да, берсе икенчесенә торырлык: берсе үлем, икенчесе — х-ы-я-н-ә-т!» Муса-Халитов соңгы сүзне басым ясап, әүрүчә кичереп әйтә. Ә кайчакта ул бу сүзне кабатлап та әйтә торган иде. Аның өзе кырыслана, тавышы көчәя, шелтәле яңгыраш ала башлый. Ләкин бу очракта

аның ачуы, шелтәсе үзенә юнәлтелгән булуын сизәсең. Сөйләү тизләтелә, кискенләшә, герой бер карарга якынлаша кебек: «Я, соң монда миңа сайлап торырлык нәрсә бар? Мин түгелме шигырь уты белән ант итүче канлы сугышта: үлемгә дип, ачы нәфрәт белән елмаермын соңгы сулышта! Я мин соң аны моңарчы да елмаеп каршы алган кеше түгелмени?»

Быргы тавышы Муса-Халитовның уйларын бүлә. Ул берничә адым янга атлый, тәрәзәдән тышка карый. Аның хәрәкәтләре басынкы, сөйләме монолог башындагы сабыр ритмда. Ул күзәтә. «Бөтен лагерь аякта. Әнә ул — өрлеккә тагылган берничә бау... Дар агачы. Аста басып торган Гөлгенә! Әйе, ул! Нинди пакь, нинди балкый аның йөзе. Палач аның муенына бау төшереп тигезләп карый... Янында ук Илстан! Низаметдин абзый, хәтта Янгир... Ул да китерелгән. Ул да, күрәсең, кача алмаган. Уртада бары тик бер генә бау буш тора. Нәрсә ул? Ник бар да шунда борылып карады? Ах, әйе... Аны палач шулай селкетеп җибәрде. Мине көтәләр! Ул — минем бавым!» Берниндибүленешсез артист тавышын күтәрә һәм катгый карар рәвешендә әйтеп куя: «Мин дә хәзер шунда барырга, мин дә шул иптәшләрем янына басарга тиеш».

Муса-Халитовның шушы урында тавышы киселә. Үлем алды минутында ул кинәт кенә нәрсәнедер хәтеренә китерде. Яшьсез елаган кешенеке шикелле йөзе чытылды. Бу секундта аның бөтен әрнүле уйлары эченә бикләнгән. Артист йөзендә әрнешүнең шәүләсе генә уйный. Герой, үзе дә сизмәстән, акрын гына алга берничә адым ясый, шул ук вакытта аның буе үскән кебек күренә, карашы тамашачылар өстеннән кайдадыр еракка юнәлтелгән. Пауза. Ул катып калган хәлендә иреннәре белән генә нәрсәдер әйтте. «Хуш, Әминәм!» Хәзер аның сүзләре аермачык аңлашыла. Ләкин алар серле, кайдандыр ерактан ишетелгән кебек. «Баламны кулларына күтәреп торган Әминәм! Соң сулышта синең мәхәббәтең җиңеләйтер үлем газабын; Илемне һәм сине сөюемне каным белән җиргә язармын!»

Ул кискен борылып ишеккә юнәлә. һәм өстәл өстенә яткан кәгазьгә күзе төшә. Муса-Халитов туктап кала. Кәгазьне кулына алып йомарлый. Әйтерсең лә, җирдәге бөтен әшәкелекнең башы шушы кәгазьдә. Герой нык катгый тавыш белән сөйләп китә. Бу урында Халитовның берникадәр карлыккан тавышы гаять көчле яңгырый. Җыйнак гәүдәсе мәһабәт булып күренә. Тамашачы каршында артист бөтенләй югалып, бары батыр Мусаның гына басып калуы хәрәкәтнең трагик тетрәткеч булуы һәм фикер олылыгы аны шулай итә.

Муса-Халитов, кулына утлы күмер тоткан шикелле, зәһәрләнеп, кәгазьне җиргә ташлый. «Син сүнәрсең, әмма бу якты кояш сүнмәс әле. Бу мөкатдәс син залимның өмеренә күнмәс әле». Муса-Халитовның тәне аша электр тогы үттемени? Ул калтыранып туктап калды,ниндидер бер көтелмәгән фикер кинәт аның башына китереп сукты сыман. Намусны саф, вөҗданны пакь саклаган хәлдә, көрәшчеләр сафында калу мөмкин түгелме соң? Муса-Халитов кабалана, аны фикерләре ашыктыра, тизрәк-тизрәк уйлап тап. Югыйсә, өченче быргыда сине дә, иптәшләреңне дә асачаклар. Әһә, менә бит. Тукта, тукта, Муса!

**«Чапаев та яраланган, соңгы бомбасын да аткан, ләкин бит ул дошман кулында пассив кына үләргә риза булмаган, суга сикереп төшкән дә Җаекның арьягына йөзәргә тотынган. Ә монда... Монда Гитлер миңа корал тәкъдим итә! Үзе! Соң шулай булгач! Мин ул коралны алырга да үзенә үк төзәргә тиеш түгелме соң! Димәк!.. Тукта, тукта!»** Муса-Халитов тамашачыга аркасы белән калып, түр стенада эленеп торган Гитлер рәсеменә карап каршы баса. Аның тавышы тыныч, тигез, хәтта берәз шатлыклы-тантаналы да. Ул көрәшчеләр сафында калды. Үлә калса, аңа барыбер үлемсезлек киләчәк. **«Ул миңа ике юлның берсен тәкъдим итте. Ләкин монда минем өченче юл бар. Күрик!!!»**

Монолог шулай тәмамлана.

«Муса Җәлил» трагедиясенең соңгы, үзе режиссерлык иткән постановкасында Халитов Муса ролен башкармады. Аны яшь, талантлы артист Ренат Таҗетдиновка тапшырды. Еллар узу белән таушалмый, искерми торган рольләр шулай буыннан буынга күчә киләләр. Талантлы язучы һәм талантлы театр тәнкыйтьчесе Гадел Кутуй әле 1940 елда ук Татар дәүләт академия театрының «Ромео һәм Джульетта» спектакленә язган рецензиясендә болай дигән иде: «Спектакльнең әйтеп китәргә тиешле

тагын бер уңышлы ягы бар. Бу — Ромео һәм Джульетта рольләрендә театрның яшь буыны — Халитов, Миңлебаева иптәшләрнең чыгуы. Үсү юлында иҗат ияртүдән курыкмый. Хәзер ияреп уйнаучылар килачәктә үзләре иҗат итәчәкләр».

Язучы Әмирхан Еники үзенең артист Шакир Шамильский турындагы зур бер мәкаләсендә «Нур», «Сәйяр» да ук уйнап килгән Шамильскийның сәхнә иҗатына хас табигыйлек, ягымлылык, фикернең тигез агышы, бөтенлек Фоат Халитов иҗатында уңышлы дәвам иттерелә, дигән фикерне әйткән иде. Бу — татар профессиональ театрының тууыннан бирле килә торган тирәнтен реалистик традицияләр, заманча яңгыраш алып, бүген дә сәхнәбездә яши дигән сүз. Хәзер инде Фоат Халитов, Мәрзия Миңлебаева кебек күренекле артистларыбыз, үзләре яшьләр белән бер сәхнәдә уйнап, аларга сабак бирәләр, үзләре артыннан ияртәләр. Кәрим Тинчурин, Таҗи Гыйззәт, Шакир Шамильский, Зәйни Солтанов кебек сәхнә осталарыннан алганнарын зур саклык белән яшьләргә тапшыра киләләр.



«Миләүшәнең туган көне».
Халитов Әһлиулла ролендә.

Татарстанның һәм РСФСРның халык артисты Фоат Халитов 1930 еллар башында, культура күтәрелеше елларында, хезмәт иясенең әдәбият, сәнгатькә ныклап якынаю, иҗатчы буларак үсүе чорында тормышның җанлы чалымнарын үзендә туплап, эшче яшьләр арасыннан сәхнәбезгә килгән иде.

Сәхнә сәнгатебездә социалистик реализм алымының камилләшә баруы чорында Фоат Халитов артист буларак үсте, аның иҗат үзенчәлекләре ачыкланды, ныгыды. Бүген ул — үзенең талантлы, җитди уены белән театр сәнгатебезнең халыкчанлыгын, профессиональ яктан камил һәм замандаш булуын раслаучы төп иҗат көчләренең берсе.

# ҮЛЕМСЕЗЛЕК ҖЫРЧЫСЫ

Менә җиде ел инде Каракитә белән Мунчәли арасындагы көмеш чишмә тагын да салмакланып, моңсурак ага сыман. Чишмә буендагы күксел бөдрәле талларда, Мунчәли мәктәбенең шәфәкъ алсулыгында янган зур тәрәзәләрендә, хәтта Чүпрәле районында кояшлы иртәне беренче булып сәламли торган Бизнә тауларында да ниндидер сагыш бар кебек. Алар ничә ел инде, җәйләрен Казаннан кайтып, үзләрен Тукай сүзләре белән сәламләүче нечкә хисле шагыйрьне күрмиләр. Шәрәф Мөдәррис туган якка кайтып төшүгә Тукайның «Туган җиремә» шигыреннән шушы өзекне укырга ярата иде:

**Ул таныш кырлар, болыннар тартты әүвәл хиссеми,**
**Тарта торгач, куймады, кайтарды ахыр җисмеми.**



Бу — шагыйрьнә як. Ш. Мөдәррис аны гомер буе йөрәгендә йөртте, аның белән горурланды. Бу якларның бер үзенчәлеге шунда, аңа Казан белән Сембер яктысы гомер-гомергә тигез төшкән. Мәйданга киләчәк яңа әдәбияттан узган йөздә үк аваз биреп куйган Г. Кандалый, соңрак XIX йөзнең күренекле укымышлыларыннан шагыйрь В. Алкаев-Чүпрәле шушыннан чыккан.

Мөдәрриснең: «Ленин — безнең якташ»,— дип горурланырга хакы нигезле иде. Чөнки ул — дөнья өстенә Сембердән күтәрелгән шушы кояш шифасында бөреләнгән талант. Шагыйрь үзен юксына торган туган ягын җырларына кертеп калдырды, Хәзер инде ул үзе — шушы якның горурлыгы.

Аңа 50 яшь. Мондый юбилей көнендә хөрмәт, мәдех фейерверкы күзләрнең явын алучан була. Ләкин юбилярның арттырып мактаулардан тыйнаклык белән баш тарту мөмкинлеге бар. Безнең юбилярыбыз исә соңгы сүзне әйтү мөмкинлегеннән мәхрүм.

Социалистик җәмгыять художникның гомерен озайтты. Ләкин ашкын чор, икә дөньяның кискен көрәше, шул көрәшнең бер тарафын тәшкил иткән тормышыбыз яңу сорый, фидакарьлек сорый. Шагыйрь гомере гадәттә «бәйгеләрдә йөрәге ярылып ауган ат сыман» көрәш мәйданында өзелә һәм үзе артыннан әллә ничаклы үкенеч, сагыш, сагыну калдырып китә.

Президиумда дуслары уртасында утырган бәхетле юбилярга күбрәк тыңларга, әйтелгәннәрне мыекка урарга туры килсә, ни хикмәт, мәрхүм юбилярыбыз үзе генә сөйли. Ул өйрәтә, чакыра, әйди, кисәтә. Һәм без аны тыңлыйбыз.

Шәрәф Мөдәррис шигъриятенең лейтмотивы — үлемсезлек. Аның геройлары моңа еш кына үзләренең үлемнәре аша киләләр. Ләкин батырлык халык гомерен озайта, җырларга көчә, якты оптимизм юлдашына әверелә.

Шагыйрь поэзиянең бурычын, Максим Горькийча, «батырларның шашкынлыгына дан җырлауда» күрә һәм үзенең иң яхшы әсәрләрендә халкыбызның сугышчан батырлыгына дан җырлый.

Аның беренче әсәрләре үк, үзләре аерым кыйммәткә ия булсалар да, зур күләмле, җитди әсәрнең эскизларын хәтерләтәләр. Кыргыз егете «Җанбатыр турында җыр» (1935) һәм татар, украин егетләренең гражданнар сугышындагы туганнарча дуслыгын, шул дуслыктан туган уртак батырлыгын җырлаган «Разведка» (1938) шигырьләрендә булачак зур әсәрләренең яралгысын абайлау читен түгел.

Менә аның Ватан сугышы чоры иҗатына йомгак ясап «Тупчы Ваһап» поэмасы (1943) туа. Шулай итеп, «Көмеш чишмә» шигырендәге: «Очсын хыял эпос киңлегенә»,— дигән теләге тормышка аша. Шагыйрь биредә Ватан сугышында сыгылмас батырлык күрсәткән татар халкының мәһабәт сынын һәйкәл итеп алга бастыра:

Бите явыз, агыза-агыза харам канын —
Күкрәгендә утлы пычак, кызыл саплы.
Һәм тупчы да, текәп күккә карашларын,
Яткан килеш мәңгелеккә тынып калды.

Чулпан бата. Шунда көзге вакларыдай
Җемелдәтеп җиргә яткан көмеш чыкны,—
Көнчыгышта, Алып батыр калканыдай
Матурланып түм-түгәрәк кояш чыкты.

. . . . . . . . . . . . . . . .

Ян син, әй җыр, ялкын телең сузылдырып,
Ядкәр булып, айлар-еллар, заманнарга! —
Ян син дулап, йөрәкләргә нурың сызып,
Гомер биреп Ваһап кебек каһарманга!

Шагыйрь үзенең иҗатында бу теманы эшләүне, үстерүне дәвам иттерә. Ниһаять, монументаль образлары белән мәһабәт шигъри симфониянең эпик киндере мәйданга килә. Халкыбызның сугышчан батырлыгы темасын үрдән-үргә үстерә барып, шагыйрь үзе дә гаять зур иҗат батырлыгы эшли. Иҗат йомгагы булып дөньяга туган «Үлемсезлек» поэмасында (1959) батырлык темасы, киң иҗтимагый-әхлакый планда чишелеп, тирән фәлсәфи мәгънә, халыкларның тарихи язмышы, урыны һәм җирдәге хакы турында уйланулар төсен ала. Шагыйрь гражданлык, ватандарлык хисләрен, халыклар дуслыгын бөтен талант көченә җырлый. Ватан хакына рус һәм татар халкы уллары эшләгән батырлыкның тарихи һәм социаль мотивларын ачып бирә. Менә әсәр каһарманнарыннан Тимербулат Рахмановның иҗтимагый һәм әхлакый йөзен тасвирләткән бер өзек:

Сүз — аткан ук, үлсәм, бергә — сүзем белән,
Үлгәндә дә бушка үлмәм, Захар иптәш!
Сөям, дустым, көмеш йөзле Казан күген,
Таңын шунда сыерчыклар очкан чагын;
Тукай ташын, көзге төсле Кабан күлен,
Башларында утлар янган Ослан тавын.
Туган әнкәм — горур халык, батыр халык,
Фриц әле белер Казан татарларын!
Антка тугры, дуска юмарт, сабыр халык
Төшендерер татар барда хәтәр барын!
Һәлак булып, каным сыгып, җиргә аусам,
Кичке яшь ай туган кырга хәбәр итсен.
Сүзем, антым, вөҗданымны җилгә атсам,
Әнкәм-ватан гүр комын да харам итсен!

Поэмада шагыйрьнең киң эрудициясе һәм югары шигырь культурасы җемелдәп тора.

Шәрәф Мөдәррис — иҗатка гомумән кырыс таләпчәнлек белән караган шагыйрь. Үз иҗатына шундый таләпчән булганга, ул яшьләргә дә, өлкәннәргә дә тәнкыйть сүзен туры һәм ярып әйтүчән иде. Бер вакыт Хәсән ага Туфан яшь шагыйрьләр семинарына ике кулына ике китап тотып керде.

— Менә сезгә шигырь техникасы ягыннан үрнәк алырлык, әйбәт рифмалар өлгесе булырлык ике китап,— диде ул.

Аларның берсенә: «Шәрәф Мөдәррис», икенчесенә «Зәки Нури» дип язылган иде. Алар икесе дә бер районда туып-үскән, бер мәктәптә укып чыккан кешеләр.

Шәрәф Мөдәррис иҗатының соңгы дәверендә сонетка мөрәҗәгать итте. Бу очраклы түгел. Шагыйрь бөтен иҗаты буенча нигездә традицион формаларга таянды. Аның зур киндерле эпик әсәрләре поэзиябезнең күп гасырлык юлын билгеләп килгән калыпларга корылган. Ш. Мөдәррис һәр сүзен үлчәп куллана, сүзнең бәясен, әһәмиятен күтәрә һәм шулай итеп классик шигырь формасын мәгънә белән эчтән соң чиккәчә тыгызлый. Шагыйрьне дөнья поэзиясенең сонет кебек камил жанрына алып килгән иң беренче сәбәп — аның гомумән классикага мәхәббәте. Аңа сонетның туплаучан кырыслыгы ошый. Шул ук вакытта моның поэзиябез үсешендә зарури мәгънәсе дә бар. Ул мәгънәне күренекле немец шагыйре Иоһаннес Бехерның шушы сонеты ачса кирәк:

**Когда поэзии грозит разгром,**
**И образы над пропастью повисли,**
**И тщетно бьешься над порожняком**
**Летящих строф, пренебрегая мыслью.**

**Когда в переизбытке впечатлений**
**Теряет остроту усталый взгляд,**
**И в судорогах смерти и рождений**
**Меняет мир привычный свой уклад,**

**Когда не знает форма чувства меры**
**И выпирает, затрещав по швам,**
**Когда поэзия сошла на нет,**

**Тогда со строгою своей манерой,**
**Как символ стойкости являясь нам,**
**Выходит из забвения сонет.**

Бездә, илебезнең башка әдәбиятларындагы кебек үк, шигъри традицияне гомумән инкарь итү, шагыйрьне осталык җаваплылыгыннан тугару, таркау формалар белән мавыгу тенденцияләре күренеп үтте. Мөдәрриснең сонетка мөрәҗәгать итүе шуңа принципиаль иҗади җавап иде. Шигырьне таркаулыкка илтү Көнбатышның модернистик агымнарыннан башланса, аңа каршы сәламәт җавапны (бәлкем артык кискен) да шагыйрь шул ук поэзиянең классикасыннан алды.

Ш. Мөдәрриснең инглиз һәм немец телләрен яхшы белүе бу эштә нык ярдәм итте. Сүз уңаенда шуны әйтергә кирәк, мәрхүм гомере буе телләр өйрәнде. Гарәп теленнән гаять грамоталы булу өстенә, соңгы елларда тырышып латин телен үзләштерде. Ул Шекспир сонетларын инглизчәдән тәрҗемә итеп, поэзиябез өчен изге эш эшләде.

Шагыйрь үзенең сонетларында да үлемсезлек турында фәлсәфи уйлануларын дәвам итә, бу теманы социаль-гуманистик планда чишә. Монда сүз кешелекнең үлемсезлеге турында бара. Үлемсезлек биологик өзлексез һәм иҗтимагый күчемле бер күренеш булып баса. Шагыйрь балага кешенең төсен, исемен, нәселен килачәккә илтүче итеп кенә түгел, илен сөюче, идеяләрне дәвам итәчәк эстафетачы итеп карый:

**Туп кебек тәгәрәп, кечкенәң туды,**
. . . . . . . . . . . .
**Чикләнсә бер заман юлында офык,**
**Юл ачар ераграк синең яшь оның**

һәм атлар чорларга синең үзеңсез...
Нәрсә бар дөньяда туудан бөек! —
Ул яшәр тормышны, ватанны сөеп,—
һәм, димәк, мәңгегә син дә үлемсез!

Без хезмәт җыры дибез. Ә фидакарь, дәртле хезмәттән соң ләззәтле, хаклы ялны җырда истән чыгарабыз. Ә бит ул да чынлыкта хезмәт җыры. Менә Мәдәррис-нең бер сонеты:

Син, туган, сорадың, сүзләрем бүлеп:
— Әйтеп бир, нәрсә,— дип, синең рәхәтең!
— Көндәлек эшемнән канәгать булып,
Йокларга дип яткан төнге сәгатем!

Йөрелгән. Арылган, башкарып зур эш.
«Ял, ял» дип, сорый күк бөтен халәтең.
Нинди зур бер бәхет — үтәлгән бурыч!

Яткачтын, учлап син тузгыган чәчең,
«Бик әйбәт көн бу» дип, уйлап торасың,
Кайдадыр бер читтә мыраулый мәчең,
Рәхәткә чолганып, күзең йомасың...

Барасың, шәм сыман, сүнеп бер заман;
Җәелә күк, киң булып, синең колачың,
Ыргыйсың тирәнгә, тирәнгә һаман...

Бу сонет психологик картинаны гаять төгәл һәм сиземле тасвирлый. Тасвирда художник гадәттә штрихлар белән дә мәсьәләне оста хәл итә. Бу — тәҗрибәле, талантлы художник эше. Ләкин Мөдәррис тулы, киң тасвирга, төгәл сурәткә омтыла.

Шагыйрь үлгәндә дә үлемсезлек турында җырлап үлә. Аның кабатланмас матурлыкка һәм җуелмас кыйммәткә ия «Язгы октавалар» циклы (1962) иҗатының оптимистик бөтенлеген төйнәп куя. Монда якты яз мотивлары, яшәү ихтыяры, тормыш сөю, зирәк нәтиҗәләр. Цикл сабыр-салмак уйланулардан, бай тәҗрибәгә ия өлкән кешенең тормыштагы һәм табигатьтәге нечкә күзәтүләреннән тора, ул аллегорик мәгънә, тирән фәлсәфә белән сугарылган. Лирик герой тыныч тормышның рәхәтен, хезмәт һәм хаклы ял ләззәтен тоя. Ләкин ул, гражданин буларак, гамьсезлектән ерак:

Ерак калды инде безнең яшьлек,
Дәшеп булмый кулың изәп тә...
Тик һаман да «запас — беренче» мин,
Торам әле дә хәрби исәптә.

(«Хәрби билет». 1961)

Шагыйрь тормыштагы барлык гади нәрсәләрне ярата, үтә гади күренешләрнең, хәтта «прозаик» әйберләрнең шигъриятен таба.

Ш. Мөдәррисгә матурлыкны аңлау үтә гуманистик. Ул материалистик эстетиканың «тормыш үзе матур» дигән тезисын шагыйрь генә күрә алган детальләрдә, гаять гади һәм кешелекле итеп раслый. Кеше тормышын урап алган күренешләрдә, аның яшәеш юлдашы булган барлык «прозаик» ваклыкларда ул матурлык күрә, шуның белән матурлыкның кырын киңәйтә. Менә аның бер октавасы:

Карасам базга: аптырап калам,
Кайда бәрәңгем! — Ак җеп җәтмәсе.
Суган, кыяклап, йомшаган тәмам,
Калмаган да күк ашар нәрсәсе.

**Фонарем йөртеп тагын күз салам:**
**Кишер, чөгендер — үргән һәммәсе.**
**Караңгы базда сизәләр диген,**
**Язның сулышын, басулар җилен!**

Шушы баздагы бәрәңгеләрдә моңарчы кем соң шигърият күргән? Ә ничаклы матур! Шушы бәрәңгеләрнең язга тартылуы, яшәү омтылышы матур.

Иҗаты һәм гомере турында мондый йомгакны ясарга шагыйрь бик хаклы:

**Гомер таңымда дәртләнеп яндым**
**Тиле яшьлекнең ләззәте белән.**
**Утлар аркылган илларда бардым**
**Илемнең ачы хәсрәте белән.**
**Рухым сынганда янә көч алдым**
**Батыр йөрәкле халкымнан гелән.**
**Бөтен тормышым, эшләгән эшем —**
**Дусларым белән җиңгән җиңешем.**

Гел мактау гына язганга хөрмәтле укучы безне, бәлкем, шелтәләр дә. Бу — шагыйрьнең юбилее икәнен онытмыйк. Ә тәнкыйть аңа исән чакта артыграк та эләкте. Без әле монда аның ялкынлы публицистикасына һәм сатирасына туктала алмадык. Ш. Мөдәрриснең тугандаш чуваш әдәбияты белән бәгләнышларны армый-талмый ныгытуы үзе аерым тәкъдир ителергә хаклы. Ул чуваш халкына, аның теленә, әдәбиятына зур мәхәббәт белән карады. Иделдәге якын күршебез поэзиясе белән без иң әүвәл чуваш шигыре классигы Константин Ивановның Ш. Мөдәррис тәрҗемәсендәге «Нарспи» поэмасы аша таныштык. Поэманың тәрҗемәсенә сокланмый мөмкин түгел.

Бернича айдан республикабызның ярты гасырлык юбилеен билгеләп үтәчәкбез. Бәхетле йолдыз астында республика белән бергә диярлек дөньяга килгән шагыйрь — аны илһамланып җырлаган, татар халкының милли һәм социаль бәхетенә тукынучыларга, башка халыклар белән аның дуслыгы турында Көнбатыштагы гайбәт сатучыларга ачы ирония белән караган кеше. Аның актуаль мәгънәсе ачыла гына барган якты иҗаты һәм классикага юлдаш таланты — азат республика җимеше.

**Нурмөхәммәт ХИСАМОВ.**

Хуҗи Мәхмүтов

# «КОМАН МӘҖМУГАСЫ»НДАГЫ ТАБЫШМАКЛАР

Венеция шәһәрендәге китапханәләрнең берсендә 1303 ел датасы куелган һәм латинча-фарсыча-команча сүзлекне, коман теленең кыскача грамматикасын, шушы телгә тәрҗемә ителгән христиан дине догаларын, шулай ук халык иҗаты әсәрләренең кайбер үрнәкләрен эченә алган бер кульязма җыентык табыла. Тюркология фәнендә аны «Кодекс куманикус» дип йөртә башлыйлар. Татар әдәбияты тарихына багышланган хезмәтләрдә ул «Коман мәҗмугасы» исеме белән телгә алына.

Мәҗмуганың кайда һәм нинди максат белән язылуы турында төрлечә фараз итүләр бар. Немец профессоры В. Банг фикеренчә, ул Россиянең көньягында, изге Иоанн монастырендә; ә Д. Расовскийча — Кырымда, Италиянең Кара диңгез буендагы колониясе урнашкан Солхат шәһәрендә язылган[1]. Тарихчы М. Г. Сәфәргалиев аны Алтын Урда белән сәүдә итүче Венеция купецларына кулланма төсендә Италиядә язылган дип саный[2]. Т. И. Грунин мәҗмуганың язылу сәбәбен италия һәм немец миссионерларының XIV йөз башында Галиция чикләрендә яшәгән команнар арасында христиан дине таратырга омтылулары белән аңлата[3].

«Коман мәҗмугасы» беренче мәртәбә (өлешчә) 1828 елда Парижда басыла. Ә тулы басмасы 1880 елда Будапешттә Геза Кун дигән галим тарафыннан чыгарыла. Шул вакытлардан бирле мәҗмуга төрле илләрдәге тюркологларның игътибар үзәгендә тора.

Команнар үзләре төрки телдә сөйләшүче күчмә халык булганнар. Аларны половецлар һәм кыпчаклар дип тә атыйлар. «Половецлар җире XI гасырның азагында һәм XII гасырда Дунай белән Идел арасындагы Кара диңгез буе далаларын алып торган. Аның составына шулай ук Кырым далалары һәм Азов диңгезе буйлары да кергән. Половецлар тагын Кавказ алды далаларында һәм Түбән Идел һәм Җаек арасында күченеп йөргәннәр»[4]. Хуҗалыкларының нигезен терлек асраучылык тәшкил иткән.

«Коман мәҗмугасы»на фольклор әсәрләренең дә кертелүе очраклы хәл булмаска тиеш. Кайбер чыганаклардан күренгәнчә, бу халыкның көнкүрешендә музыка һәм

---

[1] Н. А. Баскаков. Тюркские языки. Издательство Восточной литературы. Москва. 1960 ел. 57—58 битләр.

[2] М. Г. Сафаргалиев. Распад Золотой Орды. Саранск. 1960 ел. 36 бит.

[3] Документы на половецком языке XVI в. Транскрипция, перевод, предисловие, введение, грамматический комментарий и глоссарий Т. И. Грунина. Москва. 1967 ел. 106 бит.

[4] К. В. Кудряшов. Половецкая степь. Москва. 1948 ел. 124 бит. (Рус һәм немец телендәге хезмәтләрдән алынган өзекләр безнең тәрҗемәдә китерелә — Х. М.)

җыр әһәмиятле урын алып торган: «Команнар башка күчмә төркиләр шикелле сугыш кылып торалар, ләкин тыныч чакларда хозур кылырга да сөяләр иде. Зур сугышлардан кайткач, хан батырлар белән мәҗлес ясый, алларына кымыз килә, батырлар исерешәләр, кыллы музыкада чиртеп уйный башлыйлар, кызлар-кәнизәкләр бииләр; шул вакытта халык җырчылары мәйданга чыгып, саз чиртеп, борынгы батырларны, борынгы заманнарны искә төшерәләр иде»[1].

XIII гасырның беренче яртысында монгол яулап алучылары тарафыннан буйсындырылганнан соң, команнарның бер өлеше Алтын Урда кулы астында яши башлый. Дәүләт берләшмәләре таркалуга карамастан, алар әле шактый вакыт үз телләрен саклап киләләр. Кыпчак теле Алтын Урдада нигездә дәүләт теле булып тора.

Инде сорау туа: кыпчак телендә язылган «Коман мәҗмугасы»ның безнең татар теленә һәм фольклорына нинди мөнәсәбәте бар!

Бу сорауга җавап, барыннан да элек, мәҗмуганың үзендә. «Аның 70 процентка якын сүзләре борынгы татар әдәбиятында кулланылган һәм файдаланылган сүзләрдән тора дияргә ярый. Аларның күбесе хәзерге көндә дә татар телендә яки аның аерым диалектларында шул мәгънәләрендә йөртеләләр... Сүзләрнең грамматик формаларында да шундый ук хәл сизелә»[2].

Проф. М. Зәкиев «Туган тел үсеше» исемле хезмәтендә татар сөйләменең бербер сенә якын булган болгар һәм кыпчак сөйләмнәренең кушылмасыннан барлыкка килгәнлеге турында яза, «XIV—XVI йөзләр эчендә ул инде аерым бер халыкның теле буларак оешып җитә һәм... гасырлар дәвамында зур үзгәрешләргә дучар ителмичә, безнең чорларга кадәр әкренләп үсеп, шомарып килә»,— ди[3].

Кыпчаклар һәм болгарлар арасындагы тел, фольклор мөнәсәбәтләре турында Н. Исәнбәтнең фикерләре кызыклы. «Борынгы Болгар — Казан — Кыпчак территориясе бик киң булып,— дип яза ул,— төрки кавем-кабиләләрнең конгломераты (катнашмасы) булган. Боларда гадәт-йола уртаклыгы зур булган кебек, мәкальләрнең (табышмакларның дип тә өстик — Х. М.) тел структуралары да якын һәм бер-берсеннән әзер килеш алырга мөмкин булганга, мәкальләрнең бер-берсенә күчүләре җиңелрәк, күбрәк була. Шул рәвешчә, территориаль яктан да, тел, гореф-гадәт, тормыш һәм кара ышанулар ягыннан да, шулай ук мәкальләрнең төзелеш алымнары буенча да уртаклыгы зур булган. Андый мәкальләрнең мирас юлы белән безгә килгәннәренең күбесе хәзер асылда безнекеме, әллә анысы монысыннан алынганмы икәнен дә билгеләве кыен мәсьәлә»[4].

Бу әйтелгәннәрдән «Коман мәҗмугасы»ның борынгы бабаларыбызның телен, поэтик иҗатын, тормыш-көнкүрешен өйрәнүдә, башка төрки халыклар белән бергә, татар халкы өчен дә кыйммәтле мирас булып торуы ачык аңлашылса кирәк.

Мәҗмугадагы текстларның күбесе дини эчтәлекле. Ләкин тәрҗемәченең халыкның образлы сөйләменнән киң файдаланганлыгы күренеп тора. Мәрьям анага мактау җырлаучы түбәндәге юлларга күз салыйк:

Ave, кимниң тотаклары
бал-шәкәрдән тир көп татлы,
алардан бизгә төгүлдү
тын азыкы, тәңри сөзү.

Ave, кимниң сөзләмәки
әрир кумушнең ауазы...[5]

---

[1] Г. Газиз, Г. Рәхим. Татар әдәбияты тарихы. Беренче җилд. Борынгы дәвер. Икенче бүлек. Казан. 1923 ел. 43 бит.
[2] Борынгы татар әдәбияты. Татарстан китап нәшрияты. Казан. 1965 ел. 68 бит.
[3] М. Зәкиев. Туган тел үсеше. Татарстан китап нәшрияты. Казан. 1967 ел. 23 бит.
[4] Н. Исәнбәт. «Татар халык мәкальләре»нең беренче томына кереш мәкалә. Татарстан китап нәшрияты. Казан. 1959 ел. 48 бит.
[5] W. Radloff. Das türkische Sprachmaterial des Codex Cumanicus. Memoires de L'Academie Imperiale des Schiences de St.-Petersbourg. VII serie. Tome XXXV. №0. 6. Немец телендә. 1887 ел. 93 һәм 100 битләр.

«Тотаклары» сүзен Радлов «иреннәре» дип тәрҗемә итә. Ягъни, иреннәре бал-шикәрдән татлы, сөйләшүе — көмеш авазы... Бу чагыштырулар «шикәрләрдин шкрин, балдан татлы тел тибрәтеп әйткән сүзләре» кебек җырларыбызга бик аваздаш яңгырыйлар.

Халык иҗаты әсәрләреннән мәҗмугада 47 табышмак китерелә. Венгр галиме Дьюла Немет, немец профессоры В. Банг, академик В. В. Радлов, күренекле совет тюркологы С. Е. Малов һ. б. бу табышмакларны өйрәнүгә багышлап махсус хезмәтләр яздылар [1]. Көнчыгышны өйрәнүчеләрнең 1960 елның августында Мәскәү шәһәрендә үткәрелгән 25 халыкара конгрессында Лос-Анжелос галиме Андре Титце «Коман табышмаклары» дигән темага доклад белән чыкты.

Шундый күренекле тюркологларның хезмәтләре бар өстенә, коман табышмаклары хакында яңадан сүз кузгату урынсыз булып күренергә мөмкин. Шуны искәртеп үтик: бу тикшеренүләр нигездә текстологик характерда. Табышмак текстлары чагыштырмача әйбәт саклanса да, байтак сүзләр танымаслык хәлгә килгәннәр. Бу бер. Икенчедән, кайбер борынгы сүзләрнең нинди мәгънә аңлаткан булулары анык түгел. Ниһаять, команча текстны латин хәрефләре белән язганда (язучысының италияле яки немец булуы ихтималын да өстәсәк), теге яки бу хатаның китүе дә табигый хәл. Менә шуңа күрә исемнәре аталган галимнәр төп игътибарны текстларны дөрес итеп укуга һәм аңлатуга юнәлткәннәр. Табышмакларның жанр үзенчәлекләренә алар аерым очракларда гына кагылып үтәләр.

Мәсьәләнең тагын бер ягы бар. Бу тикшеренүчеләр үз хезмәтләрендә башка төрки халыклар фольклорыннан байтак үрнәкләр китерсәләр дә, бер-ике фактны исәпкә алмаганда, аларның татар табышмакларына мөрәҗәгать итүләрен күрмибез. Ягъни безне иң кызыксындыра торган өлкә яктыртылмый кала.

Дөрес, татарча хезмәтләрдә мәҗмугадагы кайбер табышмаклар телгә алына. «Татар әдәбияты тарихы»нда Г. Газиз һәм Г. Рәхим мондый дүрт табышмакны китерәләр: «Тап-тап тамасык, тама дырган тамасык. Ул — күбәләк»; «Бити-бити битедем, биш агачка битедем, күнә суын йөгерттем, бәкин-бәкин чормадым. Ул — кынадыр»; «Ултырганы уба йир, басканы багир чамат. Ул — өзәнге»; «Бу барды, эзе юк. Көймәдер». Әмма авторлар бу мисалларны В. Радловның: «Коман теле безгә татар теленең биш йөз ел элек булган бер халәтен күрсәтеп, шушы биш гасыр эчендә татар теленең алмашу тарихын ачып бирә», дигән фикерен раслау өчен генә файдаланалар. Табышмакларны өйрәнүне исә «халык әдәбиятын тикшерүчеләргә махсус эш» дип искәртү белән чикләнәләр [2].

Өзәнге һәм көймә турындагы табышмакларны, бу төр әсәрләрнең озак вакытлар саклана алу сәләтен күрсәтү өчен, Н. Исәнбәт тә искә ала [3]. «Борынгы татар әдәбияты»нда алдагы хезмәтләрдә китерелгән дүрт табышмак янына тагын дүртәү өстәлә: «Ап-пак арты ябулы, алтын башлы чукмарлы. Ул — торнадыр»; «Языда яулы туқмак ятыр. Ул — керпедер»; «Языда яулы каеш ятыр. Ул — еландыр»; «Эчәр, йиәр, энена керер. Ул — пычактыр». (182 бит.)

Хәмит Ярми «Кодекс куманикус»тагы табышмаклар буенча безнең борынгы табышмакларыбызны да беркадәр күз алдына китерергә мөмкин» икәнлеге, аларның «безгә бик аңлаешлы табышмаклар» булуы турында яза [4]. Ләкин ул да өстә күрсәтелгән текстлар белән генә эш итә.

Шулай итеп без татарча хезмәтләрдә мәҗмугадагы 47 табышмактан тик 7—8енең генә фәнни әйләнештә йөрүен күрәбез. Мондый чикләнгәнлекнең сәбәбе шул: автор-

---

[1] Бу хезмәтләрдән без нигездә Д. Немет һәм С. Е. Малов мәкаләләрен файдаландык:

Julius Nemeth. Die Rätsel des Codex Cumanicus. Zeitschrift der Deutschen Morgenländischen Gesellschaft. 67 Band. IV Heft. Немец телендә. Лейпциг. 1913 ел. 577—608 битләр. Алга таба: Д. Немет хезмәте.

С. Е. Малов. К истории и критике Codex Cumanicus. Известия АН СССР. Отделение гуманитарных наук. 1930 ел. 347—375 битләр. Алга таба: С. Е. Малов хезмәте.

[2] Г. Газиз, Г. Рәхим. Татар әдәбияты тарихы. 48 һәм 50 битләр.

[3] Н. Исәнбәт. Табышмаклар. Татгосиздат. Казан. 1941 ел. 11—12 битләр.

[4] Х. Ярми. Татар халкының поэтик иҗаты. Татарстан китап нәшрияты. Казан. 1967 ел. 169—171 битләр.

лар табышмакларны бер чыганактан — В. Радловның «Das türkische Sprachmaterial...» исемле хезмәтеннән алалар. Ә анда 17 табышмак кына тикшерелә.

«Коман мәҗмугасы»ндагы табышмаклар хакында тулырак тәэсир тусын өчен, без аларның эчтәлегенә һәм кайбер художество үзенчәлекләренә тукталып узыйк.

Тематик яктан бу табышмакларны якынча дүрт төркемгә бүлеп булыр иде:

1. Күк җисемнәре, ел вакыты.
2. Җиләк-җимеш, яшелчә, үсемлекләр.
3. Хайваннар һәм кош-корт.
4. Төрлеләр: торак, транспорт, кораллар, бизәнү әйберләре.

Болардан тыш тагын сәүдәгәр һәм кол кеше турында ике табышмак бар.

Беренче төркемгә керүче табышмаклар күп түгел. Аларда кояш, ай, йолдызлар, яңа ел тууы, кояш һәм ай нурлары сурәтләнә. Кыпчак кешесенең хыялында төнге күк зур ук савыты, ә йолдызлар хисапсыз-сансыз уклар булып гәүдәләнә. Яңа ел килүе аңа бия колынлавын хәтерләтә. Нурларны ул кояштан һәм айдан килүче илчеләр дип кабул итә:

Көн астыннан илче килер,
Көмеш быргыдан килер.
Ай астыннан илче килер,
Алтын быргыдан килер.
**Ул — кояш һәм ай нурлары** [1].

Калган төркемнәрдәге табышмаклар исә кыпчакларның тормыш-көнкүреше турында сөйләүче җанлы шаһитләр булып торалар. Барыннан элек аларда терлек асраучылыкның тәэсире ярылып ята. Бу башка әйберләрне еш кына хайваннар аша метафоралаштыруда да күренә. Әйтик, кавын — бәйдә симерүче кәҗә бәтие итеп сурәтләнә. Табышмакларда сыер, куй, бия, колын, кучкар, тәкә, дуңгыз, айгыр кебек терлек исемнәре телгә алына.

Художество үзенчәлекләренә килгәндә, иң башлап, күпчелек табышмакларның шигъри строфалар төсендә төзелгән булуларын әйтергә кирәк. 47 табышмактан бары 13 е берьюллы булып, калганнары арасында 12 икеюллыклар, 10 дүртюллыклар бар. Ике табышмак 6 шар юлдан һәм берсе 8 юлдан тора.

Строфалар эчендә 7—7, 8—7, 8—8, 5—5, 4—4 иҗекле үлчәмнәр кулланыла. Моның шулай икәнлеген түбәндәге табышмаклардан күреп үтәргә мөмкин [2]:

Тау үстиндә талашман,
Тайаги бар беш батман.
Ол: түлкү...

Силәүсин йаги силкип болмас,
Сырма тонум бүгүп болмас.
Ол: йумуртка.

Бучу кыш кышлар,
Бучу йәй йәйләр.
Ол: сирик [3].

Сыер сырты,
Кой коңакы.
Ол: (җавабы танылмый).

Шушы ук мисалларга таянып, рифмалар хакында бер-ике сүз әйтик. Күрәсез, «талашман — беш батман» кебек шактый матур яңгыраучы рифмалар да, рәдифләр дә (силкип болмас — бүгүп болмас) очрый. Соңгы табышмакта рифма юк, ләкин, аның каравы, монда аһәңне арттыручы икенче чара — аллитерация һәм ассонанс бар. Язуда аны болай күрсәтергә була:

с-ы-р | с-ы-р
к-о | к-о| к-ы

---

[1] Текст С. Е. Малов хезмәте буенча (357 бит) бүгенге орфография нигезендә китерелә.

[2] Табышмаклар Д. Немет хезмәте буенча бирелә. 590, 581, 593 һәм 591 битләр.

[3] Бу табышмакта В. Банг һәм Д. Немет «яртысы суда, яртысы һавада» дигән мәгънә күрәләр һәм «сирик»не кармак таягы дип тәрҗемә итәләр.

Авазлар чиратлашуы кайчакта эчке рифма дәрәҗәсенә күтәрелә. Мәсәлән:

Сарайдаги сары айгыр
Савалатып кишнәмиш [1].

Шигырьне нәфисләү чараларыннан мәҗмугадагы табышмаклар анафора, эпифора һәм кабатлауларга бай.

Узун-узун сыргалак,
Учуна дейре сыргалак;
Кызга-кызга сыргалак,
Крыена дейре сыргалак.
Ол: бычак билә белеү [2].

Сурәтләү чаралары арасында еш һәм зур тапкырлык белән кулланылганы — метафора. Биш бармак — биш агач, тырнак — күк ефәк, елан — яулы каеш, керпе — яулы тукмак һ. б. Метафоралар гадәттә гиперболалаштырыла. Торнаның башында — чукмар, төлкенең койрыгы — биш батманлы таяк... «Биш»нең элек, конкрет санны белдерүдән тыш, «күп» дигән мәгънәне аңлатуын да хәтергә төшерик. Бу мәгънә кайбер идиомаларда хәзергәчә сакланган. Әйтик, «биш былтыр» — бик күптән, бик озак.

Сурәт ясау, әйбер турында читләтеп әйтү өчен башка төрле алымнар да файдаланыла. Менә мәҗмугадагы 13 нче табышмак:

Узун агач башында
Ургув атлы куш олтрур...

Монда нинди кош, нинди «ургув» турында сүз бара! Бу сорауга Немет табышмак жанрының үз табигатеннән чыгып җавап бирергә омтыла. «Икенче юлдагы беренче сүзнең чын кош исеме түгеллеге ачык»,— ди ул һәм бу «әкәмәт сүзне» «ор-ку» яки «ор-куыл» дигән боерык фигыльләрдән ясалган булырга тиеш, дип исәпли [3]. Табышмакта карга турында сүз бара. Ә аны һәрвакыт оралар да куалар.

Чыннан да, мондый әкәмәт исемнәр ясау табышмак өчен хас сыйфат. Менә бүгенге фольклор җыентыкларында йөрүче бер табышмак: «Ил ятса да, Иләмән ятмас». Хикмәтенә төшенмәсәң, Иләмәнне ниндидер бер баһадир итеп күз алдына китерергә мөмкин. Ә монда сүз... сыер мөгезләре хакында бара. Сыер — ил, мөгезләр — аның әманәтлеген саклаучы. Сыер үзе ятса да, мөгезләре гел басып тора...

Күренә ки, «Коман мәҗмугасы»ндагы табышмаклар шигъри төзелешләре, телсурәтләү чаралары ягыннан бүгенге табышмакларга якын торалар. Инде мондый сорауга җавап эзләп карыйк: бу борынгы табышмаклар икенче юл белән — телдәнтелгә күчү юлы белән безнең көннәргәчә килеп җитә алмадылармы икән! Аларның халык арасында хәзер дә әйтелеп йөри торганнары юкмы!

Борынгы текстларны бүгенге фольклор җыентыкларындагы табышмаклар белән чагыштыру нәтиҗәсендә, бу сорауга уңай җавап бирү мөмкин булды. Менә дәлилләр.

Акча кайда кышламыш?
Канлы йердә кышламыш;
Каны нечик йукмамыш?
Кап ортада кышламыш.
Ол: карын йавудыр [4].

700 ел диярлек элек теркәп калдырылган бу текстта хәзерге татар кешесе өчен аңлашылмый торган бер генә сүз дә күренми. Шуны гына искәртик: монда «акча» ак әйбер дигәнне аңлата. Берәр төс белдерүче сүзгә «ча-чә» кушымчасы ялганып, исем ролендә йөрүче мондый сүзләр бүгенге табышмакларда да очрый. «Ары да очар карача, бире дә очар карача...» дип башланучы мәгълүм табышмакта «карача» сүзе кара әйберне — борчаны аңлата.

Бу табышмакның җавабы тирәсендә үз вакытында бераз бәхәс булып алды. В. Банг аны «карын явы» — терлекнең эч мае дип аңлый. Д. Немет исә «карның яуы»

---

[1—2] Д. Немет хезмәте. 607 һәм 600 битләр.
[3] Д. Немет хезмәте. 587 бит.
[4] Д. Немет хезмәте. 589 бит.

Х У Җ И Н  М Ә Х М У Т О В ◆ «КОМАН МӘҖМУГАСЫ»НДАГЫ ТАБЫШМАКЛАР ◆

мәгънәсен күрергә тели. Әмма бу фикерендә ул ялгыз кала. Радлов та, Малов та немец тюркологы тәрҗемәсенә кушылалар [1].

«Карын» сүзе бездә «эч» мәгънәсендә хәзер дә кулланыла. «Яу» сүзе исә «күз явы» дигән идиомада гына очрый. Инде «күз мае» дип сөйлиләрме, дигән шик туса, моңа да җавап бар шикелле. Телебездә «күзен майландыра» дип әйткәнне еш ишетергә мөмкин. «Майлы күздә ягым булмый» дигән мәкаль дә бар.

Күрәсез, бу табышмакны без шушы борынгы варианты буенча гына да үзебезнеке итеп саный алыр идек. Тикшерә башлагач, шул ачыкланды: аның әле хәзер дә телебездән төшкәне юк икән. Исәнбәт җыентыгының 146 нчы битен ачып, 1383 нче табышмакны укыйк:

— Кани кайда кышладың?
— Агиделдә кышладым.
— Каны ничек тимәде?
— Уртасында кышладым.
Җилек.

Мәҗмугадагы тексттан төп аерма шунда: «канлы йердә» — «Агиделдә» дип үзгәртелгән. Бу исә табышмакның яңа җавап алуы белән бәйләнгән. Җилек — сөяк эчендә. Ак сөяк — Агидел. «Ак сыер торып китәр, кара сыер ятып калыр» табышмагындагы кебек, метафора төсләр уртаклыгына нигезләнгән (ак кар — ак сыер, кара җир — кара сыер, ак сөяк — Агидел).

Инде җавап алмашынуга килсәк, монысы табышмак жанры өчен гайре табигый нәрсә түгел. Төрле сәбәпләр аркасында (я иске җавапта күздә тотылган әйбернең көнкүрештән төшеп калуы, я табышмактагы сурәтнең икенче бер әйбергә тагын да тапкыррак туры килүе һ. б.), табышмакларның яңа җавап алып яши башлаулары еш күзәтелә. «Кайчысыз киселә, җепсез тегелә» дигән табышмак элек «пилмән ясау» дип чишелә иде. Хәзер аның «электросварка» дигән яңа җавабы да бар. Яки менә шул ук «Коман мәҗмугасы»ндагы «Бурунсуз буз тешер. Ол: кой богу» [2] дигән табышмакны байтак еллардан бирле «Борынсыз чыпчык боз тишә.— Тамчы» вариантында очрата киләбез.

Мәҗмугадагы кайбер табышмаклар әле дә шул ук образларын һәм җавапларын саклаган хәлдә әйтелеп йөриләр. Аларда аерым архаик сүзләр генә алмашкан булырга мөмкин.

| | |
|---|---|
| Йазда йаулы каеш йатыр.<br>Ол: йыландыр [3]. | Юл өстендә майлы каеш.<br>Елан [4]. |

Борынгы табышмак еланны «йаулы каеш», ә бүгенгесе — «майлы каеш» дип атый. «Йау»ның элек «май»ны аңлатуы турында сүз булган иде инде. Хәмит Ярми бу табышмакта «йаулы» сүзе «кораллы», «чәнечкеле» (сөңгеле) мәгънәсендә түгел микән! — дигән фикер әйтә [5]. Ләкин, күрәсез, бүгенге вариант моны расламый. Башка чыганакларда да «каеш» метафорасы «майлы» эпитеты белән кулланыла. Мәсәлән, «Заятүләк белән Сусылу» легендасында:

Кыска койрык, шәм колак
Куяны күп Балкан тау.
Майлап салган каештай
Җыланы күп Балкан тау [6].

«Йаз» сүзе борынгы телебездә «тигезлек», «дала» дигән мәгънәне белдергән. Хәзер ул кайбер топонимик исемнәрдә генә очрый. Дөбьяз — төп дала, Олыяз — олы дала һ. б.

---

[1] С. Е. Малов хезмәте. 360 бит.
[2] Д. Немет хезмәте. 596 бит.
[3] Д. Немет хезмәте. 595 бит.
[4] Н. Исәнбәт. Табышмаклар. 58 бит.
[5] Х. Ярми. Татар халкының поэтик иҗаты. 171 бит.
[6] М. Гафури. Заятүләк белән Сусылу. Яңалиф. Казан. 1927 ел. 28 бит.

**Хәзерге текстта «йаз» һәм «йау» сүзләренең алмашынган булуы, ихтимал, мондый сәбәптәндер: алар бүгенге телебездә бөтенләй икенче мәгънәдә (яз айлары, дошман явы) йөриләр. Текст үзгәрешсез калса, буталчыклык килеп чыгар иде. Юкса табышмак үз тукымасына кереп урнашкан кайбер архаик сүзләрне сакларга һич тә авырсынмый.**

...Улагим көгендә семирер.
Ол: ковун [1].

**Башта текстның эчтәлеген аңлап китик. Радлов сүзлегендә «улак» сүзенең ике төрле мәгънәсе күрсәтелә: 1) Йөк күчерү өчен хезмәт итүче теләсә нинди йорт хайваны. 2) Бер яше тулмаган кәҗә бәтие [2]. Табышмакны тәрҗемә иткәндә, В. Банг шулардан беренчесен, Д. Немет — икенчесен сайлый. Монда Неметның хаклы икәнлеге ачык, чөнки йөк хайванын симереп ятучы итеп күз алдына китерү читен. Немет текстын татарчага күчерсәк, болай була: «Кәҗә бәтием бәендә симерә. Ул — кавын».**

**Ә менә табышмакның Исәнбәт җыентыгындагы варианты (87 бит):**

Күк ылагым күк үләндә ятып симерде.
Карбыз.

**Ике текст арасында кайбер үзгәлекләр булса да, төп метафора элеккечә калган. «Ылак» сүзенең чыннан да «кәҗә бәтие» мәгънәсендә йөргән булуын башка чыганаклардан да күрергә мөмкин. «Йосыф вә Зөләйха» поэмасында мондый юллар бар:**

«Йосыфның кардәшләре әвә дүнде,
Берисе бер углак тотып бугазлады...»

**Шагыйрь Утыз Имәни поэманың үз кулы белән күчергән нөсхәсендә бу строфа кырыена «Углак — кәҗә баласы» дип язып куя [3]. Билгеле булганча, поэманы ул 1824 елда күчергән. Димәк, шундый аңлатмага мохтаҗлык сизелгәч, «углак» моннан 150 еллар чамасы элек үк архаик сүз булган. Бу исә үз чиратында бүгенге табышмакның чыннан да борынгы заманнардан бирле яшәп килүен күрсәтүче бер дәлил булып тора.**

**Фольклор жанрлары арасында табышмакларга иң якын торучысы — мәкальләр. Бу ике күрше арасында, Исәнбәт әйтмешли, кунакка киткәндә узара йортта калып торулар була торган хәл. Ягъни, кайчакта табышмак мәкаль урынында йөри ала һәм киресенчә:**

Аузум ачсам өпкәм керүнир.
Ол: ешик ачса от керүнгәндир [4].

**«Коман мәҗмугасы»ндагы менә бу табышмак та хәзер мәкаль буларак әйтелеп йөри: «Авызын ачса, үпкәсе күренә» [5].**

**Югарыдагы мисалларда без борынгы текстларның артык зур үзгәреш кичермәгәнлекләрен күрдек. Һәрхәлдә, табышмакларның композициясе, образлар системасы өчен тотрыклылык хас. Шул ук вакытта аларның, художестволы әсәр буларак, өзлексез камилләшә баруы да табигый күренеш. Бу хакта теоретик фикергә дәгъва итмичә, бер борынгы табышмакның «Коман мәҗмугасы»ннан алып соңгы вакытларга кадәр булган эволюциясен күздән үткәрик.**

Бу барды, изи йок.
Ол: кемәдер [6].

**Текстны тәрҗемә итүдә тюркологлар арасында каршылык юк. Тик А. Н. Самойлович кына аерым караштა тора. Аңа «бу» алмашлыгы ошамый, һәм ул, көймә**

---

[1] Д. Немет хезмәте. 592 бит.

[2] В. В. Радлов. Опыт словаря тюркских наречий. Издательство Восточной литературы. Москва. 1963 ел. 1 том. 2 кисәк. 1678—1679 баганалар.

[3] Борынгы татар әдәбияты. 70—72 битләр.

[4] Д. Немет хезмәте. 602 бит.

[5] Татар халык мәкальләре һәм әйтемнәре. Төзүчесе Х. Ярми. Казан. 1960 ел. 208 бит.

[6] Д. Немет хезмәте. 601 бит.

турындагы якут табышмагына таянып [русчага тәрҗемәсе: Кобыла пробежала и следа не оставила], коман табышмагында да «бу» берәр җан иясен, әйтик, шул ук бияне [бей] яки боланны, пышины [бугу] белдерүче сүз булырга мөмкин, дип исәпли[1].

Гәрчә Малов мондый мөмкинлекне кире какса да, Самойлович бер яктан хаклы: чыннан да күрсәтү алмашлыгы табышмак өчен ятышып бетми. «Бу» дип төртеп күрсәткәч, ул әйберне эзләп торуның кирәге калмый ич.

Табышмакны без икенче мәртәбә М. Ивановның 1842 елда басылган «Татарская хрестоматия» дәреслегендә очратабыз [191 бит]: «Әнә бара, эзе юк». Текст әйтү өчен җиңеләеп, шомарып китсә дә, анда барыбер баштагы аңлашылмаучылык хәл ителми. [Әнә — шулай ук күрсәтү алмашлыгы.]

Ниһаять, «әнә» сүзе соңга табарак «үзе» дип алмаштырыла. «Үзе» логик басым ала һәм табышмакта чишелергә тиешле «конфликт» калкулаиып китә. Ничек инде алай! Бара торган әйбернең эзе калырга тиеш ләбаса! Шушы сәерлекне тагын да көчәйтү өчен, табышмакка «маңгаенда күзе юк» дигән яңа юл да өстәлә. Ягъни, эзе калмавы бер хәл, ул әле күрмичә дә бара ала икән. «Үзе — эзе — күзе» рифмалары әсәрнең ритмын бизәп, нәфисләп җибәрәләр. Шушыларның барсы нәтиҗәсендә, табышмак гаҗәп камил бер дәрәҗәгә килә:

Үзе бара, эзе юк,
Маңгаенда күзе юк[2].

«Коман мәҗмугасы»ндагы табышмаклар белән бүген бездә әйтелеп йөрүче табышмаклар арасындагы бәйләнеш кайчакта артык күзгә бәрелеп тормый. Соңгыларына еш кына яңа бизәкләр, башка сурәтләр өстәлгән булырга мөмкин. Ләкин барыбер аларның тамырлары бер икәнлеге шик тудырмый.

| | |
|---|---|
| Былтырдагы беш кувлук<br>Беши биле кулунламыш.<br>Сарайдаги сары айгыр<br>Савалатып кишнәмиш[3] | Сакмардагы сары айгырым<br>Сагындырып кешнидер.<br>Мишәрдәге биш биям<br>Бишесе дә колынлый.<br>Колыннары сары ала һ. б.[4] |
| Чапчачык өстендә<br>чапчачык.<br>Ол: камышдыр[5]. | Тустак өстендә тустак,<br>Иң өстә песәй койрыгы.<br>Җикән камыш[6]. |

Камыш турындагы борынгы табышмак метафорасы белән дә, композициясе буенча да бүгенге вариантның беренче юлына охшаш. Аерма «чапчак» дигән диалекталь сүздә генә. Ул «кисмәк» дигәнне белдерә һәм кайбер җырларыбызда да очрый:

Чапчак кына чапчак балларны
Ялгызың, анакай, башладың...[7]

Бер үк табышмакның төрле диалектларда шулай үзгәртелеп әйтелүе киң таралган күренеш. «Тәбәнәк күктән кар ява», «Кат-кат тунлы, карыш буйлы» дигән табышмаклар, мәсәлән, Омск өлкәсендә болай әйтеләләр: «Алаша һавадан кар ява», «Кат-кат тунлы, сәррә буйлы».

Шулай итеп, без «Коман мәҗмугасы»ндагы табышмакларны берничә ноктадан карап күзәтеп чыктык һәм аларны бүгенге табышмакларыбызның борынгы үрнәкләре итеп санау өчен тулы нигез барлыгын күрәбез.

---

[1] А. Н. Самойлович. К истории и критике Codex Cumanicus. Доклады Российской Академии наук. Серия В. Ленинград. 1924 ел. 88—89 битләр.

[2] Шушы вариантында табышмак беренче мәртәбә Т. Яхинның «Сабый вә сабыяләр өчен мөргуб булган хикәяләр вә мәкальләр...» җыентыгында күренде. Казан. 1902 ел. 111 бит.

[3] Д. Немет хезмәте. 607 бит.

[4] Н. Исәнбәт. Табышмаклар. 35 бит.

[5] Д. Немет. хезмәте. 594 бит.

[6] Н. Исәнбәт. Табышмаклар. 49 бит.

[7] Татар халык җырлары (лирик җырлар, йола җырлары). Төзүчесе И. Надиров. Татарстан китап нәшрияты. Казан. 1965 ел. 247 бит.

Әкрам Сафин

# МУСА—ТАТРАБФАК СТУДЕНТЫ

Без 1923—1925 елларда Татрабфакта Муса белән бергә укыдык. Ул минем яшьтәшем дә, шәриктәшем дә иде. Аның белән бер бүлмәдә яшәгән чагыбыз да булды. Бу истәлегемдә мин әнә шул Татрабфакта укыган еллар хатирәсен язарга булдым.

1923 елның август аенда Казанда татарлар өчен махсус рабфак оештырылды. (Аның рекламасы Татрабфак иде.) Әмма анда татар яшьләреннән башка, башкорт, казакъ, кыргыз, үзбәк кызлары һәм егетләре дә укыдылар. Татар яшьләре арасында Оренбург ягыннан килгән Муса Җәлил дә бар иде.

Татрабфак вакытлы рәвештә Кабан күленең сул ягындагы зур ак таш бинага урнашкан иде. Без килгәндә инде Муса, рабфак җитәкчеләренең кушуы буенча, кайбер җәмәгать эшләренә дә керешкән иде. Аңа рабфакка укырга килүчеләрне каршылау, рабфакка керү шартларын һәм аларны торак урыннарына урнаштыру вазифасы йөкләнгән. Бүгенгедәй хәтеремдә: без, бер төркем авыл яшьләре, Татрабфак йортына килеп кереп, инде нишләргә, кемгә мөрәҗәгать итәргә, дип аптырашып торганда, кечерәк кенә гәүдәле, кара чәчен маңгаена кыек салган бер чибәр егет килеп, безнең белән исем-фамилиясен әйтеп исәнләште. Ул безнең кайсы яклардан килүебезне сораша башлады. Кулына кәгазь, карандаш алып, безнең исем-фамилияләрне язганнан соң, безгә рабфакка керү өчен нинди фәннәрдән имтихан бирергә кирәк икәнлекне аңлатты да безне торак бүлмәләренә урнаштырды. Мин Муса үзе тора торган алты кешелек бүлмәгә туры килдем.

Ләкин аның белән бер бүлмәдә өч ай чамасы гына тордык. Татрабфак, Кабан күле буендагы уку-укыту биналарын калдырып, Черек күл урамына күченгәннән соң, Мусаның шагыйрь икәнен искә алыпмы, яисә җәмәгать эшләрендә актив катнашкан өчен булгандырмы, аны ике кешелек бүлмәгә урнаштырдылар. Әмма без, аерым бүлмәләрдә яшәсәк тә, һәрвакыт бер-беребезгә йөрешеп тора идек. Чөнки ул күп кешелек зур бүлмәләргә еш кына кереп, студентларга үзенең яңа язган шигырьләрен кычкырып укырга ярата иде.

Муса белән бергә торган чорны искә алып, шуны әйтәсе килә: гаҗәп тырыш кеше иде ул. Төннәрен китап укып, яисә шигырь язып бик озак

утыра иде. Шуңа карамастан, иртәгесен бик иртә тора. Тору белән һәркөн гимнастика ясап ала. Аннары юынып киенә дә, тизрәк укырга яки язарга керешә.

Китап укуга һәм язу эшләренә күп вакыт сарыф итү белән берргәттән, Муса көндәлек дәресләрен дә вакытында хәзерләргә өлгерә. Укуда ул бик сәләтле. Әле үзе әйбәт уку белән бергә, кайбер йомшаграк студентларга да ярдәм итә иде. Бигрәк тә рус телен авыр үзләштерә торган татар-башкорт яшьләренә булыша. Шунлыктан аны укытучылар да, студентлар да ярата иде.

Мусаның тагы бер әйбәт ягын искәртеп китәсе килә. Татрабфак ачылган елны, завод-фабрикалардан, шахталардан, авыллардан, укырга теләп, бик күп яшьләр килде. Аларның байтагы, хәтеремдә калганча, йөздән артык татар һәм башкорт яшьләре, рус теленнән, математикадан кабул итү имтиханнарын уңышлы тапшыра алмаулары сәбәпле, рабфакка керә алмадылар. Рабфак каршында хәзерлек курслары ачылачагы да билгеле түгел иде әле. Шул көнне Муса рабфак каршындагы партия һәм комсомол ячейкасы секретарьлары белән сөйләшеп, безнең мәсьәләне РКСМның өлкә комитетына җиткергән иде. Шуннан соң күп тә үтмәде, рабфак каршында хәзерлек группалары ачылып, әлеге йөздән артык татар-башкорт егетләре һәм кызлары рабфакта калдырылды һәм аларга шунда уку хокукы бирелде. Муса ярдәме нәтиҗәсендә хәзерлек группаларында калып, соңыннан югары белем алган партия эшлеклеләрен, галимнәрне, агрономнар, зоотехниклар, инженер һәм башка төрле белгечләрне әле күп очратырга мөмкин. Алар барысы да Мусаның ул чактагы яхшылыгын зур хөрмәт белән искә алалар.

Мусаның кайбер башка үзенчәлекле яклары да бар иде. Яше ягыннан безнең белән замандаш булса да, аның күзләре алданрак ачылган булса кирәк. Ул рабфакка килгәндә инде башка яшьләр арасында белеме күбрәк булуы белән дә, кием-салымының пөхтәлеге белән дә аерылып тора иде. Дөресен әйтергә кирәк, ул елларда әле күп кенә авыл яшьләре рабфакка киндер күлмәктән, киез эшләпәдән һәм чабата киеп киләләр иде. Ә Мусаның өстендә чем-кара сатин күлмәк, бик яхшылардан булмаса да, кара костюм, башында кара кепка, аягында кара ботинка иде. Ләкин безне аның кием-салымы түгел, бәлки зур мәгълүматлы булуы гаҗәпләндерә иде. Ул татар телен дә, рус телен дә яхшы белә. Рабфакта төрле җәмәгать эшләрендә эшли, студентларның яисә комсомолларның җыелышларында докладлар ясый. Рабфакта чыга торган стена газетасының редакторы да, комсомол ячейкасының бюро члены да, яңалиф ячейкасының секретаре да — ул. Үзешчән түгәрәк белән дә ул җитәкчелек итә иде. Шул ук вакытта ул студент та, шигырьләр һәм пьесалар да яза иде. Мусаның тагын бер үзенчәлекле ягы шунда, ул яңа язган шигырьләрен безнең студентлар группасында укып, аларның «яхшы» дигән бәясен алмыйча торып, аларны кичәләрдә укымый һәм матбугатка басарга бирми иде.

Муса үзе язган шигырьләрен рабфак студентлары кичәсендә генә түгел, бәлки татар коммунистлар университетының, педтехникум студентларының кичәләрендә дә укырга өлгерә иде.

Муса театрга йөрергә һәм театрда үзе уйнарга бик ярата иде. Рабфак сәхнәсендә куела торган пьесаларда нинди дә булса бер рольне башкармыйча калмый иде.

Муса ул елларда безнең кебек үк авыр шартларда укыды. Революциядән соң гражданнар сугышы, төрле бандаларга каршы көрәш, шулар өстенә ачлык еллар булуы илебезгә бик зур авырлыклар китергән иде. Рабфак ачылганга инде дүрт ай үткән булса да, мәсәлән, әле студентларга стипендия бирү-бирмәү мәсьәләсе дә хәл кылынмаган. Шунлыктан материаль хәлебез гаять авыр иде. Булды шундый көннәр: Печән

базары янсә Кабан күленең бу башындагы Болак күпере янындагы бәрәңге-яшелчә базары таралуга, без шунда барып, сатучылардан коелып калган бәрәңге, кишер, чөгендерләрне җыйнап кайта идек. Беркөнне шулай шәриктәшем Мәҗитов Әшрәф белән яшелчә калдыкларын җыйнап алып кайтып пешердек тә ул ашны Муса белән бергәләп өч кашыктан ашадык. Ашап бетергәч, Мусаның: «Бу бик шәп булды әле, егетләр», дигән сүзе бүгенгедәй күңелемдә саклана. Шуны да әйтергә кирәк, рабфакта уку шартлары бик авыр булуга карамастан, бер генә студент та укуын ташлап китмәде, барысы да тырышып укуларын дәвам иттеләр.

1923 елның азакларында Казанга А. В. Луначарский килде. Аның Татрабфакта да булачагы безгә алдан ук билгеле булды. А. В. Луначарскийны каршы алу комиссиясе дә төзелде. Студентлар вәкиле итеп, комиссия составына без Мусаны тәкъдим иттек. Әйтелгән вакытта безнең рабфакка килеп, А. В. Луначарский студентларның тормыш, көнкүреш хәлләре белән танышты. Шуны да әйтергә кирәк, А. В. Луначарский безнең курста озаграк тукталды. Чөнки безнең курс укучылары аңа бик күп сораулар бирделәр. Безнең курста шахталардан килгән студентлар да бар иде. Шуларның берсе — 30—32 яшьләрендәге, зур гәүдәле, тубал чәчле Зиганшин рабфакта укыр өчен тиешле шартлар булмау турында да әйтте. Аның сорауларын А. В. Луначарскийга Муса Җәлил тәрҗемә итеп торды. (Кечкенә буйлы Мусаның зур гәүдәле А. В. Луначарский янында басып торганы әле дә күз алдында.) А. В. Луначарский Зиганшинга студентлар тормышының кыенлыгы вакытлы хәл икәнлеген әйтеп, киләчәктә тормышыбыз яхшы булачагын аңлатты да, безнең белән бик җылы гына хушлашып, укуыбызда зур уңышлар теләп китте.

А. В. Луначарский рабфакта булып киткәннән соң озак та үтмәде, безнең тормыш шартларында кинәт үзгәрешләр булды. Айга сигез сум стипендия бирелә башлады һәм кием-салымнар да бирелде. Стипендия узган айлар өчен дә бирелүе нәтиҗәсендә, безнең көнкүрешебез сизелерлек яхшырып китте. Аннары рабфак каршында махсус ашханә ачылып, студентларга көнгә ике мәртәбә аш, кара икмәк тә җитәрлек итеп бирелә башлады. Студентларның кием-салымы бөтенәйде. Киндер күлмәк, киез эшләпә, янсә чабата киеп йөрүчеләр калмады. Болар барысы да А. В. Луначарскийның Татрабфак тормышын яхшырту буенча тиешле чара күрүе нәтиҗәсе иде.

Менә шушы үзгәрешләрдән соң, Муса «Луначарский килде» исемле шигырен язды һәм аны стена газетасында бастырып чыгарды.

Рабфакта атнага бер мәртәбә студентлар өчен политкичә үткәрелә, анда политика һәм әдәбият мәсьәләләренә кагылышлы сорауларга җавап бирелә, соңыннан концертлар була торган иде. Ул кичәләр дә Муса Җәлил җитәкчелегендә үткәрелә иде. Әнә шундый кичәләрнең берсендә, сорау-җаваплар тәмамланып, концерт башлангач, Муса бик күңелсез кыяфәт белән сәхнәгә чыкты да: «Иптәшләр! Бик күңелсез хәбәр алдык, безнең даһи юлбашчыбыз Владимир Ильич Ленин үлгән, бүгенге кичәне шуның белән бетерәбез»,— диде.

Бу хәбәр кичәдә катнашучы барлык студентлар өчен бик авыр булды. Кичә таралды. Студентлар арасыннан кайберләре, аптырашып: «Ничек болай булды икән соң? Әле узган атнада гына Муса Ленин турында сөйләгәндә, В. И. Ленинның гомумән хәле яхшыра башлаган, үзе тора торган бинаның баскычыннан төшеп-менеп йөри башлаган икән, дигән иде бит»,— диделәр.

Шул сәгатьтән безнең рабфакта кайгы көннәре башланды. Икенче көнне студентлар һәм укытучылар катнашы белән үткәрелгән митингта Муса В. И. Ленин турында кайгы речь сөйләде. В. И. Ленинны мавзо-

лейга куйган көнне безнең рабфак коллективы, зур оешканлык белән Казанда ясалган кайгы демонстрациясенә катнашты. Муса да, рабфак житәкчеләре белән бергә, демонстрация колоннасының алгы башында барды. Ул башына малахай бүрек, өстенә солдат шинеле, аягына киез итек кигән иде. Аннары шул ук көнне В. И. Ленинга багышлап, Муса Жәлил житәкчелегендә, рабфакта махсус стена газетасы чыгардык. Ул газетада Мусаның «Ленин турында» дигән шигыре дә басылды.

**Ленин турында**

Ленин бабайның үлеме
Бик әрнетте йөрәкне,
Безне батыр көрәшергә
Ленин бабай өйрәтте.

Ленин сүзләрен өйрәник,
Укучылар, килегез!
Ленин бабай өйрәткәнчә
Төзелә безнең илебез.

Ленин юлы — җиңү биргән
Иң туры юл — безнең юл.
Ленин төсле көчле бул,
Ленин төсле сизгер бул!

Ленин бабайның сүзләрен
Син чыгарма исеңнән,
Син укуда алдынгы бул,
«Ленинчы бу!» дисеннәр.

Муса ул шигырен соңыннан студент кичәләрендә дә берничә тапкыр укыды.

# ШАГЫЙРЬ КҮҢЕЛЕНДӘ НИЛӘР БАР?

Равил Фәйзуллинның яңа китабы чыккан икән. Гади генә — суратсез, чәчәксез, төссез. Карага ак белән язган тышлык — «Мәрмәр».

Фәйзуллинның шигырьләренә бәя бирүе кыен. Болар «яхшы» дип әйтер идең — нәрсәсе белән яхшы, шуны исбат итәргә тиешсең. «Начар» дип әйтер идең, начар шигырьне газет-журнал битләрендә теләгәнчә күреп торабыз, «Тозсызны күзсез дә белә» дигәндәй, начарны гына таныйбыз. Фәйзуллинда андыйлар юк кебек. Әйткәнебезчә, Фәйзуллин шигырьләренә бәя бирү җиңел эш түгел. Хөер, мин укучы буларак кына язам. Алай теләгән сүзләреңне әйтүе җиңелрәк була, үзеңне иркенрәк тотасың. Мин — укучы.

Фәйзуллин шигырьләрен хәреф таныган, әзмы-күпме китап караштырып барган бәрлык кеше дә аңлыймы? Мәсәлән:

**Ах, тау юклыклар!**
**Кыя юклыклар!**
**Үзән, калкулыклар**
**Күз текәмә кая...**

**Бөркетләр түмгәктә**
**Канатларын кага...**
**Тырнаклары чумган...,**
**Ә күзләре яна!**

Менә мондый эчке мәгънәле шигырьләр бу китапта теләсәң никадәр. Әдәбият белән яхшы ук таныш булмаган кеше, айһай, моны аңлармы икән?..

Бөтен кеше дә аңлый торган булмагач, шагыйрьмени ул?.. Себер, Урал татарлары арасында йөргәндә күзәткәнем бар. Җырчы сәхнәгә чыга да «Китмә, сандугач»ны җырлый, «Раушания»мне җырлый. Зал болай әйбәт кенә кабул итә, игътибар белән тыңлый. Менә бер заман берәү чыга да «Ай, Сафа, вай, Сафа»ны җырлый. Зал ду күтәреп кул чаба, аяк тибәләр, сызгыралар. Кыскасы, җырчыны кабат сәхнәгә чакыралар. «Китмә, сандугач» та, «Раушания» дә икенче планда күмелеп кала...

Шагыйрь «элементар укучының» дәрәҗәсенә яраклашып язарга тиешме, әллә **сан ягыннан алай ук массовый булмаган**, әдәбиятны **таный торган укучылар** өчен язарга тиешме? Бу — принципиаль мәсьәлә.

Шагыйрь нәкъ «элементар укучы» уйлаганча уйларга, аныңча сөйләшергә, **ул аңлаганча гына** язарга тиешме, әллә аңардан югарырак торырга, аны уйландырырга, ул белмәгән мәсьәләләрне, шигъри образлар аша яктыртып, аның каршына китереп бастырырга тиешме? Бу — заманында Галимҗан Ибраһимов күтәргән мәсьәлә. «Шалт» итеп рифма-сугып, «ялт» итеп эчтәлек биргән шагыйрьне аңлавы, әлбәттә, кыен түгел. Ә менә мәгънәсе эчкәрерәк яшерелгән булса? Әнә бит Дәрдмәнднең «Кораб»ы нинди язмышка очрады... 1908 елдан бирле — Г. Ибраһимовтан башлап Г. Сәгъдигә кадәр, Г. Нигъмәтидән башлап М. Гайнуллин, Г. Халит, И. Нуруллинга кадәр — бу шигырь турында ничәмәничә төрле фикер әйтмәделәр? Инде соңгы елларда «Кораб» тулысы белән реабилитацияләнгән дип йөри идек, әле күптән түгел генә, культура мәсьәләләренә багышланган гыйльми конференциядә галимнәрдән берәү «Кораб»ка тагын һөҗүм итеп карады. Ә «Кораб» төн вә көндез һаман йөзә бирә...

Инде Равил Фәйзуллин шигырьләренә килик. Бу китаптагы күзгә ташланган иң беренче сыйфат — шагыйрьнең җәмгыятьтә тоткан урыны, кешелек алдындагы катлаулы, җапаплы бурычы турында уйланулар. Китап бу фикерне кычкырып тормый, ләкин, минем аңлавымча, бу җыентык нәкъ әнә шул мәсьәләне үзәккә куйган (шигырь китабы өчен «җыентык» никадәр ямьсез сүз. «Сборник» мәгънәсен бирә торган берәр сүз ясыйкмы әллә?). Шагыйрь вәгазь укымый, үгет-нәсихәтчелек белән шөгыльләнми. Ул куәтле сүз белән шагыйрьнең һәм аның замандаш буынының кешелек җәмгыятендәге урынын раслый. Заман аның буыны алдына олы эшләр куйган. Шагыйрь әнә шунда нишләр? Замандашлар нишләр? Шагыйрьне шул борчый. Шагыйрь өчен байрак — гаделлеккә турылыклы булу. Гаделлек — кешелек җәмгыятенең киләчәге — коммунизм. Әнә шул юлда көрәштә:

**Шәхесен ватмаган,**
**хаклыкны сатмаган,**
**вөҗданны саклаган,—**

кешеләр генә җиңеп чыга, ди ул.

Шагыйрь үз әсәрләренең буеннан-буена турылыкка гимн җырлый. Турылык, саф күңеллелек — безнең җәмгыять кешеләренең төп сыйфаты.

**Яз гына Рухыңнан,**
**Син — беттең!**

Туган ил, безнең җәмгыять турында язганда шагыйрь шапырынулардан, фанфара бәрүләрдән ерак тора. Ватан икән, димәк, шатлыгы, яме, матурлыгы янында аның кайгы-хәсрәте, кырыс хакыйкате дә бар. Җәмгыять икән, димәк, әле монда барысы да ал да гөл түгел. Әле анда шагыйрьне борчый торган күренешләр бар. Фәйзуллинның Туган иле дә без гел ишетеп өйрәнгән чишмәле, болынлы, урманлы, сандугачлы гөлбакча түгел. Ул — рәхәт тә, михнәтен дә күргән җир. Гел рәхәт кенә күргән җирнең кадере буламыни аның! Әнә шуңа күрә Фәйзуллинда ул бөтенләй халыкча (шагыйрьләрчә генә түгел) сыйфатлары белән алга килеп баса.

Бу китапка шагыйрьнең солдат лирикасы кертелгән. Монда да шул ук хәл: кулына автомат алып горур рәвештә ракета янында басып торучы солдат урынына Фәйзуллин тоткан да тере кешене биргән. Карасак — солдат дигәнебез барлык уй-кичерешләре, шатлыгы, кайгы-хәсрәте белән яши торган бер адәм баласы икән. Бу адәм баласын Иле, Анасы, Яры сакчы итеп куйганнар. Аның алар алдында бурычы зур. Ләкин ул бурычны, ихтимал, «пилотка белән генә бәреп ташлап» үтәп булмый торгандыр. Солдат булу шагыйрьдән бик күп авырлыклар кичерүне таләп итә. Дөрес, бүгенге солдатның баш очыннан пуля выжылдап узмый. Янында снаряд та шартламый. Ләкин син — солдат. Солдат тормышы рәхәт дисәләр, ышанмагыз. Бик кырыс тормыш ул. Әмма:

**Кеше сабыр. Түзә, күнә,**
**Иялänә күз дә, тел дә.**

Солдат тормышы авыр, чөнки:

**Ут яна табаннар,**
**балтырлар — таш...**
**Итекләрне салгач, пар чыга.**
**Пилотканы кыскач — тамчылар.**

Шагыйрьнең солдат җырлары әнә шулай туганнар.

Ярты минут буш арасы булдымы, солдатның уена сөйгәне килеп керә. Ул аны кырыс казарманың тимер караватына авып йокыга ятканда да уйлый, аның белән бергә постта да тора, аның белән бергә бәрәңге дә әрчи. Ул — солдатның газизе, аңа беркемнең дә тияргә хакы юк. Солдат үзе хезмәттә вакытта аның сөйгәненә кул салу — дөньяда иң зур хыянәт. Иң зур мәкер.

Мин, сөйгән кызының икенче берәүгә кияүгә чыгарга җыенуын ишеткәч, постны ташлап өенә качып кайтып киткән яшь бер матросны беләм. Аңа хәрби трибунал суд ясады. Җылап шешенеп беткән теге кызый судта чыгыш ясады, гаепне үз өстенә алды, егеткә миһербанлы булуларын сорап ялынды...

Мин «хатының хыянәт итте» дип, ялган хәбәр алгач бер төн эчендә акылдан шашкан офицерны беләм, без аңа күчтәнәчләр алып больницага күрешергә йөри идек. Фәйзуллинның солдат лирикасын укыйм да шулар искә төшә.

**Ярлар күчәр, дулкын бәрсә,**
**Тик... торсыннар безнекеләр!**
**Тимәгез җанкайларга!**

**Ут өстенә ут өрмәгез!**
**Болай да ялкында без.**
**Тимәгез җанкайларга!**

**Исән булып бер кайтырбыз,**
**Ничек тә бер юатырбыз...**
**Тимәгез җанкайларга!**

Пейзаж — һәр шагыйрьнең юлдашы. Фәйзуллинда да бу шулай. Тик ул аны язмый, сурәтләми. Ул аңа дәшә, аны кузгата, аның турында хөкем чыгара, яки син җавап таба алмаслык фәлсәфәгә алып керә. Шагыйрьнең күңеле һәрвакыт дулкынланып тора. Аның «монашкадай чем-кара» җәйге төнен чишендереп аҗаганнар уйный. Аның диңгез буена килгән кешесе дә диңгезнең мәһабәтлегенә соклану өчен түгел, ә «дулкынның ак ярасына» карар өчен килгән.

**— Кешенең ни эше дә, күбекнең**
**кешедә ни эше!**
**— Ярама иш яра күргәч,**
**нишлим мин — кеше!**

Сандугачлы алсу таңнар бик күп шагыйрьләрнең күңелен җилкетте. Фәйзуллинның күңелен аҗаганлы җәйге төннәр җилкетә. Аның лирикасында аҗаган — кеше язмышы, ил язмышы. Табигатьнең бу серле күренеше шагыйрьнең әсәрләрендә еш телгә алына. Аҗаган безгә нәрсәдер сөйли, нәрсәгәдер чакыра, нәрсәнедер кисәтә. Аны тик аңлый гына бел...

Соңгы елларда яшьләрнең иҗатында ана образы бик активлашып китте. Әниләрне калдырып без шәһәргә укырга киттек, укып бетергәч, алар янына кайтмадык. Тегеләй иттек, болай иттек, шигырь, мәкалә, комедия, роман яза башладык, яхшы фатирлар алгач, аналарны үзебез белән торырга шәһәргә чакырдык, нигезләрен ташлап алар килмәделәр... Сугыш елларының бөтен авырлыгын үз җилкәсендә татып, түкми-чәчми, сыкранмыйча гына безне үстереп, безне кеше иткән аналарга карата хәзер безнең күңелләребез нечкәрде, аларга багышлап җырлар чыгардык, хикәяләр, повестьлар яздык. Аналар нигезләрендә калдылар, без исә күчтәнәч алып елына бер алар янына кайта торган булдык. Ел узган саен аналар бөкерәя төштеләр, ел узган саен безнең чәчләргә дә ак бертекләр өстәлә барды. Без дә үсеп җиттек. Табигатьтә, тормышта әллә ни үзгәреш юк кебек — кыр казлары да элеккечә түбәбездән үтә, сабантуйлар да элеккечә тау башында була... Тик...

**Менә без дә үсеп җиттек, әни!**
**Син әллә ни үзгәрмәгәнсең,**
**Элеккедәй мөлаемсың.**

**Күзләр гел шул,**
**Яшьләр генә менә...**

**Бар да әйбәт, әни,**
**Моңсу гына менә...**

Бала һәм ана мөнәсәбәтен Равил Фәйзуллин әр-яңа бизәкләр белән безнең алга бастырган да куйган! Беркемне кабатламаган, нәкъ менә үз тавышы белән, үз фәлсәфәсе белән әйткән. Күңелеңнең иң нечкә кылларына күбәләк канаты белән генә кагылган да узган...

Китапта тагын ниләр бар?

Картлык, гомер узу, тол хатыннар язмышы, кеше язмышы...

Чегән карчыгы... Я шул булдымы инде поэзиягә кертерлек образ? Йорты-җире, туган җире юк, кешегә фал ачып, алдалап гомер итә. Шагыйрьгә дә ул фал ача. Бәхет сырын таба, ак юл ача, сөйгән ярын күрсәтә. Болай гына булганда шигырь сине дулкынландырмас иде. Ләкин шагыйрь багучы карчыкка кулын сузып торган обыватель түгел. Ул үзе — философ — бу карчыкның маңгаенда адәм баласының авыр язмышын күрә. Аның фаҗигасенә шагыйрьнең җаны тетри.

**Ә мин аның**
**ярганланган маңгаена карап тордым.**
**Бәхетсезлек сызыклары,**
**азаплы юл сызыклары,**
**ялгызлык сызыклары...**

Фәйзуллин дөньяны яшьләр күзлегеннән чыгып кына түгел, гомере узган өлкәннәр күзлегеннән чыгып та күрә белә. Аның шигырьләрендә, гадәттә, вакыйга юк. Анда Дәрдмәндчә фәлсәфә бар. Аның дөньядан китеп баручы картлары «ил хакын аклауны» яшьләргә мирас итеп калдыралар. Алар пессимистик җылау белән дөньядан китәргә җыенмыйлар, шулай ук тынычлык белән дә түгел. Ә бүгенге яшьләр өчен борчу хисләре кичерәләр. Алар гомер узганына шашынып, күңелләре кузгалып, эшләгән эшләренә йомгак ясыйлар, яшьләргә дәшәләр.

**Әй сулар, ярсу-ярсу!**
**Эчләрдә ялкын, ялкын...**
**Без китәбез, кала өмет,**
**акларсызмы ил халкын!.**

**Шәфәкъләр алсу-алсу.**
**Дөньялар ямансу.**

Яшьләр кала. Картларның васыятен йөкләп яшьләр кала. Ләкин гомер — объектив күренеш. Ул бөтен кешедән дә уза. Шагыйрь моны нәкъ Дәрдмәнд поэзиясендәгечә нечкәлек белән кисәтә.

**Бүгенге көн нинди матур!**
**«Кемнәр бар да, кемнәр юк!»**

**Моны бүген мин пышылдыйм.**
**Иртәгә кем!**

**...Кемнәр бар да кемнәр юк...**

Дәрдмәнд дигәннән, поэзиябездәге бу өлкән остазның аһәңе Фәйзуллинның күп кенә шигырьләрендә яңгырап-яңгырап китә. Бу, әлбәттә, Дәрдмәндне кабатлау түгел. Бу — традиция. Фәйзуллинда ул традиция поэтик бизәкләр, фикер йөртү алымнары белән генә түгел, иҗек, сүз тәзелеше ягыннан да дәвам иттерелә. Дәрдмәндтә «бу», «ул» алмашлыклары еш кына бик матур бер поэтик функция үтиләр. Башка шагыйрьләрдә моны очратуы кыен.

**Бу ул матур, бу ул күркәм,**
**Бу ул,**
**Бу ул — хуш исле яз!**
**Бу ул — хуш исле таң җиле...**

(Дәрдмәнд. Бу ул матур...)

**Исәнме, улым!**
**Син гел мин дә,**
**Мин дә түгел.**
**Бу күз-кашлар — ул син.**
**Бу аяк-кул — ул син.**

(Р. Фәйзуллин. Алмазга.)

Яшь шагыйрьнең ил язмышы турындагы шигырьләрендә дә без Дәрдмәнд поэзиясендә урын алган фәлсәфи тирәнлекне күрәбез:

**Ни яу булса да илгәдер,**
**афәте тигез иңгәдер.**

Р. Фәйзуллинның моннан берничә ел элек шау-шу куптарган «өчьюллык»лары да бик матур икән бит! Юкка курыкканбыз! Азмыни өлкән язучыларда, классик шагыйрьләрдә поэмаларга, шигырьләргә кертелми калган аерым-аерым шигъри асылташлар! Кечкенә, сүзе аз, өч кенә юл, ә никадәр картина! Никадәр фәлсәфә...

**Таз эчендә орчык малай**
**Пар эчендә ата елмаюы:**
**«Арка ышкырга кеше бар!»**

Моңа бүтән бер сүз дә кирәкми! Моны сузасы юк. Бу — Еникичә әйтсәк, «әйттем — бетте». Яки көзге яңгыр турындагы өчьюллыкны алып карыйк. Торналар киткән вакыт. Көн болытлы, вак яңгыр сибәли. Көзге яңгыр. Бик ямансу вакыт — күңел үзенә урын тапмый, сагыш баса. Озын итеп сөйләсәң менә шул. Фәйзуллинча менә болай, тугыз сүз белән генә:

**Торналар китеп бара.**
**Кош канатлары орынгач,**
**болытларның күңеле тулды.**

Болытларның гынамы? Әллә кешенеке дәме? Монысын инде үзеңчә кабул ит. Шуның өчен ул — шигырь. Ул төрле кешенең күңеленә төрлечә тәэсир итә.

Ирексездән бер күренекле рус әдибенең түбәндәге фикерләре искә төшә: «Өсте ачык рояль торган бүлмәгә керегез дә, кулыгызны кулга бәреп карагыз. Тирбәнү ешлыгы сезнең кул хәрәкәтләрегездән чыккан тавышның тирбәнү ешлыгы белән бер булган кыл сезгә тавыш белән җавап бирер».

Фәйзуллин шигырьләре, чыннан да, шулай...

Талантлы шагыйрь булу, минемчә, бик авыр эштер. Халык кайгысын, ил кайгысын кайгырткан шагыйрьнең көне дә, төне дә мәшәкатьледер. Шулай булмаса, югыйсә, Равил Фәйзуллин гел шатланып кына яшәр иде. Менә болай борчылмас иде:

> **Башны салларга салып**
> **Китәсе иде агып...**
>
> **Бер күңел булыр иде!**
> **Шатлыгым ургыр иде,**
> **я сыкрап сулгыр идем.**

...Шигырь язучы — күп. Чын шигырь — сирәк. Шигырь тарихның үзе кебек өлкән. Шагыйрьлек дәрәҗәсенә антик заманнарда ук патшалар, императорлар көнләшеп, кызыгып караганнар. Хәтта шигырь язып шөгыльләнүче тираннар да булган. Патшалар, ханнар сарайларда шагыйрьләр тотканнар. Алтын-көмеш сарайлар гына, яулап алган илләр генә җитмәгән — шигырь дә кирәк булган.

...Сиракузы тираны Дионисий (безнең эрага кадәр IV гасыр) шигырь язгалый икән. Олимпия уеннарына ул да үзенең шигырьләре белән катнашырга булган. Олимпиадага ул иң яхшы декламаторлар җибәргән. Ләкин начар шигырьләр укыган өчен ачуы килгән халык (ә борынгы греклар начар шигырьдән яхшыны аера белгәннәр!) аларның чатырларын җимереп ташлаган. Декламаторлар Сицилиягә кайтып киткәннәр һәм юлда штормга очрап аларның кораблары ватылган. Моны ишеткән греклар фаҗигането сәбәбен начар шигырьләр белән халыкны мәсхәрәләгән өчен, дип аңлатканнар. Ә Рим императорларыннән берсе начар шигырь язучы шагыйрьләргә, укучыны мәшәкатьләмәсеннәр өчен, алдан ук гонорар түләп куярга кушкан. Александр Македонский исә походларда йөргәндә һәраакытта да кыйммәтле сандык эчендә Гомернең поэмаларын йөрткән. Хәер, Тукай шигырьләре Бөек Ватан сугышы елларында солдат капчыгында Берлингача барып җитмәдемени!

Равил Фәйзуллинның кечкенә генә бу җыентыгын дулкынланып укыйсың. Шөкер, начар шигырьләр кермәгән. Әлбәттә, барысы да бертигез дәрәҗәдә түгел. Мәхәббәт фәлсәфәсендә ул үзен әле көчсезрәк сизә. Ниндидер яңа сүзләр ясарга омтылуы да күзгә ташлана, калькалар да очрый. Ләкин Фәйзуллин — талантлы шагыйрь. «Талант — я бар, я юк,— ди Рәсүл Гамзатов.— Аны бирәү дә бирә һәм бирәү дә тартып ала да алмый».

«Мәрмәр» дигән шигырьләр китабын укып чыккач моның шулай икәнлегенә ышанасың. Р. Фәйзуллинның поэзиядә берәүне дә кабатламый торган үз юлы бар. Кыен, җаваплы, ләкин мактаулы юл...

**М. МӘҺДИЕВ.**

**МИРГАЗИЯН ЮНЫС. Тимер фил. Диңгезче язмалары. Казан. 1968 ел**

Соңгы вакытта Татарстан китап нәшрияты яшь язучыларның аерым җыентыкларын бастырып чыгаруга шактый зур игътибар бирә башлады. Быел беренче китаплары басылып чыккан яшь каләмнәр арасында без Миргазиян Юнысны да күрәбез. «Тимер фил» дип аталган җыентыгына аның җиде хикәясе һәм «Янар таулар», «Зәңгәр дөнья кочагында», «Ямәнгә сәяхәт» исемле очерклары тупланып бирелгән.

Миргазиян Юныс күп еллар буе диңгезче булып хезмәт итте. Атна-айлар буена сузылган озын рейслар вакытында аңа төрле илләрдә һәм дөньяның зур-зур портларында булырга туры килгән. Менә шуңа күрә дә аның күпчелек язмаларында диңгезче хезмәтенә бәйләнешле кызыклы һәм гыйбрәтле вакыйгалар, ул үзе күргән илләрдә яшәүче халыкларның тормыш-көнкүреше, гореф-гадәтләре тасвирлана. «Тимер фил», «Әти оҗмахка киткәч», «Харара җиле искәндә» һәм «Румба Негра» хикәяләрендә без илбасарлар коллыгы астында бер сынык икмәккә тилмереп көн итүче, әмма киләчәккә булган якты өметләрен, үзләренең кешелек горурлыкларын югалтмаган көчле ихтыярлы яшүсмерләр белән очрашабыз. «Харара җиле искәндә» хикәясендә, мәсәлән, «Стелла» пароходында кочегар булып эшләүче испан егете Верхильо Ремореснең язмышы турында сөйләнә. Совет солдатларының фашистларга каршы көрәшен чагылдырган рус фильмын караган өчен Верхильоны эшеннән куалар. Туган җиренә кайтып җиткәнче булса да пароходта калдыруларын сорап, ул ничаклы гына ялынмасын, пароход капитаны үзенең боерыгын үзгәртми. Җир өстендә төнге караңгылык җәелгәндә Верхильо Кызыл диңгез буендагы портларның берсендә үзенә бөтенләй таныш булмаган причалга төшеп калырга мәҗбүр була. Ләкин аның күңелендә яшәү дәрте, Испания җирендә дә таңнарның якты булып туачагына ышану хисе сүрелми. Шомлы диңгез яры буйлап шәһәр ягына атлаганда аның колак төбендә пароходның өченче механигы әйткән сүзләр яңгырый:— Үзеңне ирләрчә тот, Верхильо. Ихтыярыңны, көчеңне ныгыт... Испания гомергә тиран олтаны астында яшәмәс әле... Көрәшче булып кайт. Тиздән илебезгә көрәшчеләр кирәк булачак!

«Румба Негра» хикәясендәге музыкант һәм җырчы Джузеппино да укучы күңелендә җылы тәэсир калдыра. Ярлылыгы ничаклы көчле булмасын, Джузеппино акчага сатылмый. Бер төргәк кәгазь акча тәкъдим итүләренә дә карамастан, ул матрос киемендәге исерек янкилар теләгән көйне уйнаудан баш тарта. «Китегез моннан, сасы дуңгызлар! Мин җырымны сатмыйм, сугыш чукмарлары!» — дип җавап кайтара ул аларга. Хикәя бәйсезлек һәм тынычлык сөюче кешеләрнең рухи бөеклекләрен сурәтләүгә багышланган. «Безнең өй өянке астында иде» хикәясендә автор туган җиреннән аерылып, чит-ят туфракта гомер кичергән татар карчыгының сагышлы тормышын, аның уй һәм кичерешләрен һәркемнең күз алдына китереп бастыра алырлык картиналар аша ачып бирә. Туган илгә, Ватанга булган мәхәббәт тойгысы җыентыкның ахырында урнаштырылган «Ямәнгә сәяхәт» очеркында да үзенең матур чагылышын тапкан.

Миргазиян Юнысның хикәя һәм очеркларын укыганда лирик геройның көтелмәгән хәлләр эчендә дә югалып калмавын, тормышны, табигатьне һәм аларга бетмәс-төкәнмәс ямь бирүче кешеләрне чиксез яратуын тоясың. Җыентыктагы язмаларның кайсын гына алып карама, андагы вакыйгаләрнең берсе дә сине үзләренә карата битараф калдырмый. Алар сине уйланырга, үзең яшәгән мөхиткә айнык күз белән карарга мәҗбүр итә.

Миргазиян Юныс әсәрләренең теле җиңел, һәркемгә аңлаешлы. Олы һәм урта яшьтәге мәктәп балаларына адресланып чыгарылган булса да, бу китапны, һичшиксез, өлкән яшьтәгеләр дә кызыксынып укыячаклар.

**НИЛ ЮЗИЕВ. Сәнгатьчә матурлык һәм осталык. Казан. 1969 ел**

Укучылар, бәлки, хәтерлидер: моннан берничә ел элек «Казан утлары» журналында Нил Юзиевның рәттән диярлек 2—3 мәкаләсе чыккан иде. «Музалар туганлыгы» дигән гомуми баш астында басылган ул мәкаләләр шул чагында ук шактый зур кызыксыну уяттылар. Моның, билгеле, үз сәбәпләре бар иде.

Сәнгатьнең төрле төрләре һәм жанрлары арасындагы бәйләнеш мәсьәләләренә игътибар итүчеләр элек тә булган. Әмма татар галимнәре арасыннан бу мәсьәләгә

ныклап тотынган беренче кеше Нил Юзиев булды диярга мөмкин.

Әдәбият һәм музыка сәнгате, әдәбиятның композиторларга, музыканың әдипләр иҗатына булган тәэсире; матур әдәбият һәм рәсем сәнгате; театр һәм поэзия; татар әдәбияты һәм кино... Авторның «Әдипнең эрудициясе һәм сәер остазлары», «Кино һәм татар әдәбияты», «Кино күзе. Полимерлар белән уйлау...» исемле мәкаләләрендә әнә шул мәсьәләләр карала, әдәбият белән чиктәш сәнгать төрләренең татар язучылары иҗатына ясаган уңай йогынтысы хакында сөйли торган кызыклы мисаллар китерелә. Нил Юзиевның Татарстан китап нәшрияты чыгарган яңа җыентыгында да төп урынны әлеге мәкаләләр алып тора.

Дөрес, Н. Юзиевның музалар туганлыгы хакындагы барлык фикерләрен дә бәхәссез хакыйкать төсендә кабул итәргә ярамыйдыр. Арада житәрлек дәлилләнмәгән аерым тезислар очрый, күтәргән тема белән кирәгеннән артык мавыгып киту күренешләре дә шактый. Әмма авторның кыю төстә кызыклы мәсьәләләр күтәрүен һәм татар язучыларын әдәбият белән чиктәш сәнгать төрләрен өйрәнергә чакырып чыгуын хупламый булмый.

Китапның беренче бүлегендә урын алган «Ирекле форма бөтенләй үк ирекләме?», «Конфликт һәм характер» исемле мәкаләләр дә кызыксыну белән укыла һәм уңай тәэсир калдыра. Аларда соңгы елларда иҗат ителгән татар совет романнарының сюжет-композиция төзелеше, конфликтлары һәм характерлары тикшерелә.

Икенче бүлеккә төрле юбилейлар уңае белән язылган мәкаләләр һәм рецензияләр тупланган. Бу бүлеккә урнашкан әйберләре арасында да кызыклылары, мавыгып укырлыклары байтак. Шуның белән бергә, җыентыкны нык кына чуарлый торганнары, китапка кертми калдырырга ярардайлары да юк түгел. Н. Баян һәм Ф. Бурнаш юбилейлары уңае белән язылган мәкаләләр, мәсәлән, шундыйрак тәэсир калдыра...

**ГАЗЕТДИН ФӘРХЕТДИНОВ. Солдатлар. Хикәяләр. Казан. 1968 ел.**

«Солдатлар» — Газетдиннең беренче китабы. Яшь авторның беренче китабын исә гадәттә сагаю һәм кызыксыну хисләре белән кулга аласын. Әдәбиятка нинди рәк яңа кеше килә? Үзе белән нинди үзенчәлек, монарчы очрамаган нинди яңа образлар, нинди яңа материал алып килә? Өметлеме, сәләтлеме ул?..

Билгеле, «Солдатлар»ны укып чыгу белән әлеге сорауларның барысына да тулы һәм төгәл җаваплар табарсыз дип булмый. Хикмәт, яшь авторның иҗаты хакында төпле фикер йөртү өчен, җыентыкка кергән хикәяләрнең бик аз санда — нибары ике бөртек булуында гына түгел. Әнә шул ике бөртек хикәянең дә әдәби эшләнеш һәм язылышлары, шулай ук стильләре ягыннан бер-берсеннән нык аерылып торулары, хатта капма-каршы характерда булулары аптырашта калдыра.

«Рота юлга чыга» исемле беренче хикәядә автор бөтен бер взвод, хәтта рота солдатларының бердәм ныклы коллектив булып оешуларын, гел артта калып килгән подразделениенең «яхшы» билгесе алырлык дәрәҗәгә кадәр үсеп житүен күрсәтергә тырыша сыман. Максатның зурлыгы тормыш материалын да киңрәк, колачлырак итеп алуны сораган. «Рота юлга чыга» күп санлы эпизодлардан тора. Хикәя зур күләмле әсәрнең кыскача конспектын хәтерләтә. Рядовой Бараташвили хакында хикәяләүдән башланып киткән әсәрнең «авырлык үзәге» әледән-әле алмашынып тора, беренче планга әле лейтенант Александров, әле өлкән лейтенант Җаббаров яки капитан Әмирханов, я булмаса бөтен бер коллектив язмышы калкып чыга.

Автор төрлесе төрле кеше язмышына багышланган эпизодларны туплый, бер үзәккә җыярлык ситуация таба алмаган. Әмма хикәядә бүгенге солдатлар тормышын җанлы итеп күз алдына китерергә ярдәм итәрдәй тормышчан детальләр бик күп. Алар авторның күзәтүчәнлеге хакында сөйлиләр, тышкы яктан шактый таркау күренгән әсәрне укылырлык итәләр.

«Затвор» исемле икенче хикәя бөтенләй башка характерда. Көннәрнең берендә сержант Доронин автоматының затворы югала. Автор бөтен вакыйганы әлеге югалган затворны эзләү һәм табу тирәсенә кора. Хикәя үзенең бөтенлеге белән аерылып тора. Ләкин ул тышкы бөтенлек кенә. Автор әлеге вакыйганың үзе, тышкы ягы белән мавыга, җанлы кешеләргә, аларның уйхисләренә, кичерешләренә якынлаша алмый. Әнә шуңа күрә дә, затворны бөтенләй уйламаган-көтмәгән кеше яшергәнлеге беленгәч, без бөтенләй аптырап калабыз, иннәрне җыерырга мәҗбүр булабыз. Автор үзенең бу хикәясе белән нәрсә димәкче, нинди идея уздырмакчы булды икән?.. Укучыларга мәсьәләнең әнә шул иң кирәкле ягы аңлашылмый кала.

Җыентык яшь авторның күзәтүчән булуы, тырышканда кызыклы гына характерлар бирә алуы хакында сөйли. Әмма хәзергә язучының үз йөзен чамалавы бик кыен әле.

**КИМ ӘХМӘТҖАНОВ. Шигърият иленә сәяхәт. Башкорт телендә. Уфа. 1969 ел.**

Без, татар укучылары, Башкортстан галимнәренең әдәбият фәне һәм тәнкыйть өлкәсендәге хезмәтләрен даими рәвештә күзәтеп торабыз. Аларның куанып һәм горурланып сөйләрлек уңышлары күп. Соңгы берничә ел эчендә генә дә әдәбият галимнәре һәм тәнкыйтьчеләрнең дисталәгән хезмәте дөнья күрде. Ул хезмәтләр арасында башкорт әдәбиятының үткәне һәм бүгенгесе хакында язылган фундаменталь тикшеренүләр, әдәбиятның теге яки бу мәсьәләләренә, шулай ук аерым язучылар иҗатына багышланган зур монографияләр бар. Баш-

корт галимнәре сафына югары белемле, совет әдәбият фәненең бүгенге казанышлары белән ныклап коралланган, әдәбият-сәнгать әсәрләренең үзенчәлекле табигатен тирәнтен анлый, сиземли торган сәләтле һәм эшчән яшьләр килеп кушылды. Ким Әхмәтҗанов — шундыйларның берсе.

Быел Башкортстан китап нәшрияты аның «Шигърият иленә сәяхәт» исемле чираттагы китабын бастырып чыгарды. Җыентык ике бүлектән тора. «Шигърият узаманлары» дип исемләнгән беренче бүлеккә Шәйхзадә Бабич, Рәшит Нигъмәти, Галимов Сәләм, Мостай Кәрим, Назар Нәҗми һәм Тимер Арслан кебек күренекле шагыйрьләр иҗатына багышланган мәкаләләр тупланган. Төрлесе төрле кешегә караган һәм төрле югарылыкта эшләнгән ул мәкаләләр гадәттә без укып иялэнгән иҗат портретларыннан нык кына аерылалар. Ким Әхмәтҗанов һәр шагыйрьнең бер генә үзенчәлеген, әмма иҗатының төп асылын, төп характерларын билгели торган үзенчәлеген тотып алырга тырыша. Ахырдан, әлеге шул үзенчәлек ноктасыннан торып, әдипнең бөтен иҗатына күз ташлый. Ш. Бабич иҗатын өйрәнгәндә, мәсәләп, аны беренче чиратта «ышанычсызрак адымлы, әмма югары карашлы» бу шагыйрьнең романтиклыгы кызыксындыра. Р. Нигъмәтинең әдәби детальләрдән файдаланудагы осталыгы, Г. Сәләм поэмаларының сюжет-композиция төзелешендәге көтелмәгәнлек, Н. Нәҗминең «табигать телен шигърият теленә — кеше теленә күчерүдәге» осталыгы алгы планга чыгарылып, икенче төрле әйткәндә, үзәккә куеп тикшерелә...

«Традиция һәм шигърият» дип исемләнгән бүлеккә күләмле ике мәкалә урнаштырылган. Аларның беренчесе, нигездә теоретик характерда булып, фольклор һәм әдәбият, аларның үзара йогынтысы, мирас һәм әдәби йогынты, традиция һәм новаторлык кебек мәсьәләләрне тикшерүгә багышланган. Авторның принципиаль позициядә торып, югары таләпләрдән чыгып язылган соңгы мәкаләсе «Поэзиянең сугышчанлыгы һәм шигърият» дип атала. Кайбер бәхәсле урыннары булса да, анда соңгы еллардагы башкорт поэзиясенә шактый киң һәм тулы күзәтү ясала.

**МАКСИМ ГЛУХОВ. Не молот железо кует. Рус телендә. Казан. 1969 ел.**

Һөнәрчелек — кешелек җәмгыяте тормышында гаять әһәмиятле урын алып тора. Чөнки һөнәрчелек әйберләре, беренчедән, халыкның көнкүреш кирәк-яракларына булган ихтыяҗын канәгатьләндерсәләр, икенчедән, шул әйберләрнең формалары һәм алардагы бизәк-рәсемнәр кешеләрнең эстетик зәвыкларына да җавап бирәләр. Шуңа күрә һөнәрчеләр, кул осталары борын-борыннан үзләре ясаган әйберләрне ничек тә булса матуррак итеп эшләргә омтылганнар. Һөнәрченең аңында файдалылык төшенчәсе белән янәшә үк матурлык дигән төшенчә дә яшәгән. Ә матурлык төшенчәсе инде кешеләрне сәнгатькә, иҗади эзләнүләргә этәргән. Халык арасында кул осталарын юкка гына «алтын куллы кешеләр» дип атамыйлар, күрәсең.

Безнең Татарстан җирләрендә, аеруча Казан шәһәре тирәсендә яшәүчеләр борынборыннан һөнәрчелек белән дан тотканнар. Без инде татар читек-кәвешләренең бүгенге көндә дә дөнья базарында бәясе югары булуын беләбез. Соңгы елларда Татарстан һөнәрчелегенең башка төрләренә дә игътибар итәлә башлады. Һәм менә күптән түгел Татарстан китап нәшриятында бу темага багышланган беренче китап та басылып чыкты. **М. Глуховның «Не молот железо кует»** дигән җыентыгын югарыда әйтеп үтелгән игътибарның матур бер чагылышы дип карарга кирәк.

Китапта нибары биш очерк тупланган. Шулай да автор Татарстандагы байтак төр һөнәрчелекнең тарихын һәм бүгенге көндәге торышын шактый төгәл ачып бирә алган. Без монда татар тальян гармунының тууы, Казандагы бай бизәкле тимер коймаларны, төрле биналарга тимер бизәкләр һәм башка бик күп тимер әйберләр койган Чебакса тимерчеләре, Дөбьяз ягындагы читекчеләр, башмакчылар, чүвәкчеләр, Питрәч чүлмәкчеләре һәм Балтач районындагы атаклы тимерче Сәрвәр апа Нафикова белән очрашабыз. Фәнни-популяр китап буларак, очерклар фәнни нигезләүләргә бик бай. Автор кирәк урында гаять кызыклы фактлар һәм документлар китереп куя. Тарихилык белән берräттән, автор һөнәрчелек төрләренең бүгенге торышы белән дә кызыксына, һөнәрчелекне үстерү буенча бүгенге көндә эшләнәсе эшләргә, үтәлергә тиешле бурычларга туктала.

Ә бу инде китапны киң катлам укучыга якынайта һәм китапта әйтелгән фикерләр җәмәгатьчелек фикеренә килеп кушыла. Шуңа күрә М. Глуховның бу китабы халык һөнәрчелеген үстерүдә практик яктан да әһәмиятле.

Дөресен әйтергә кирәк, халык һөнәрчелеге, кустарьчылык, кул осталары байтак еллар буе онытылып тордылар. Ләкин соңгы елларда халык һөнәрчелеген үстерү буенча Татарстанда байтак кына эш башкарылды инде. Республикабызның газета-журналлары да әледән-әле бу темага мөрәҗәгать итеп торалар. Шушындый күтәрелеш чорында Татарстан китап нәшрияты халык һөнәрчелегенең берничә төренә багышланган бу җыентыкны чыгарып бик файдалы һәм кирәкле эш эшләгән. Киләчәктә мондый китапларның күбрәк чыгуын гына телисе кала.

**ФЛҮН МУСИН. Тормыш сынавы аша. Казан. 1969 ел.**

Партиябезнең егерменче съездыннан соңгы чор илебез тормышының барлык тармакларында барган тирән үзгәрешләр белән характерлы. Съездан соң урнашкан иҗади атмосфера әдәбият һәм сәнгатьнең үсеше өчен дә күп уңай шартлар тудырды, иҗат кешеләре өчен киң мөмкинлекләр, яңа горизонтлар ачты. Бу — үзебезнең татар

әдәбияты мисалында да бик ачык чагылды. Соңгы ун ел эчендә әдәбиятыбыз туктаусыз үсте. Язучыларның әдәби осталыклары артты, чынбарлыкны фәлсәфи танып-белү куәтләре көчәйде. Алар бөтен ил күләмендәге проблемаларга багышланган, зур иҗтимагый конфликтларга корылган әсәрләр иҗат итү югарылыгына күтәрелделәр.

Татар совет әдәбиятында барган сыйфат һәм сан үзгәрешләре проза жанрында аеруча нык гәүдәләнде. Әйе, прозабыз бик нык үсте, камилләште. Моңарчы безнең әдәбиятта авыл темасы гына тулырак яктыртылып килә иде. Бүгенге прозада күтәрелгән, хәл ителгән, чишелгән проблемаларны санап кына чыгу өчен дә зур урын, күп вакыт кирәк булыр иде. Хәзер безнең фән һәм вузлар, интеллигенция һәм эшчеләр тормышына, семья, әхлак, мораль һәм башка темаларга багышланган әсәрләребез күп. Типик образ иҗат итү принциплары тагын да яңарды, баеды, төрләнәнде. Әгәр тәнкыйтьчеләребез һәм әдәбият галимнәребез башка жанрлар белән чагыштырганда прозага күбрәк игътибар бирәләр икән, моны, беренче чиратта, проза жанрының нык алга китүе, тикшеренүчеләр өчен бай материал бирүе белән аңлатырга кирәк. Ф. Мусинның «Тормыш сынавы аша» исемле яңа китабы да асылда әнә шул соңгы ун ел эчендә иҗат ителгән проза әсәрләренә багышланган.

Әдәбиятның төп өйрәнү объекты — кеше, аның эчке дөньясы, хис-кичерешләре. Язучы кеше турында яза, шуның белән укучының игътибарын яулый. Шуңа күрә дә герой мәсьәләсе әдәбиятның иң мөһим, иң актуаль проблемаларыннан санала. Үзенең яңа китабында Ф. Мусин соңгы еллар прозасының герое, аны иҗат итү принциплары хакындагы уй-фикерләре, уйланулары, күзәтүләре белән уртаклаша. Сүз башлыча 1960—1965 елларда матбугатта чыккан күләмле әсәрләр — повесть һәм романнар тирәсендә бара.

Бүгенгене яхшырак аңлар өчен үткәнне белергә кирәк. Шуңа да, алтмышынчы еллар прозасы турында сүз башлаганчы, автор әүвәл аңа кадәрге чорга кыскача гына әдәби-эстетик күзәтү ясый.

Хезмәт материалга байлыгы, кызыклы күзәтүләре белән игътибарны җәлеп итә. Авторга төрлесе төрле характердагы гаҗәеп күп сандагы повесть-романнар белән эш итәргә туры килгән. Әмма ул югалып калмаган: үзе өйрәнгән әсәрләрне мәгълүм бер төркемнәргә аера, системага сала алган. Һәм шактый төзек, эзлекле фәнни хезмәт язып чыккан. Тик авторның 60 еллар прозасы үсешенә сизелерлек өлеш керткән аерым язучыларны, аларның әсәрләрен юри күрмәмешкә салышуы, аларны читләтеп узуы гына күңелдә ризасызлык хисләре уята. Кирәкмәс иде...

# ДӘРДМӘНД

(1859—1921)

Энҗе-алмазлар югалмас
Һәм ятып калмас, үтәр.

Дәрдмәнднең гаять мәгънәле бу ике юллыгы аның үз иҗат мирасына да тулысынча туры килә. Аның энҗе-алмазлар сыман аз һәм энҗе-алмазлар сыман нурланып, җемелдәп торган фәлсәфи-лирик шигырьләре татар укучыларының һәм шагыйрьләренең инде ничә буынын үзенә җәлеп итеп, әсәрләндереп килә. Поэзиябез титаны Муса Җәлил яшьлегендә Көнчыгышның Хәйям, Сәгъди, Хафиз кебек бөек шагыйрьләре белән янәшә Дәрдмәнд шигырьләрен яратып укуын язган. Хәсән Туфан һәм Сибгат Хәким әсәрләрендә Дәрдмәнд осталыгының тәэсирен абайлау читен түгел. Кыскасы, Дәрдмәнднең шигъри казанышы күптән инде поэзиябезнең аерылгысыз өлеше булып киткән.

23 ноябрьда Дәрдмәнднең (Закир Садыйк улы Рәмиевнең) тууына 110 ел тулды. Шагыйрь Оренбург губернасы, Эстәрлетамак өязе, Җиргән авылында сәүдәгәр гаиләсендә туган. Әтиләре 1862 елда Орск өязенең Юлык авылына килеп алтын прискасы ачып җибәргән. Миллионер Рәмиевләр тарихы асылда шуннан башлана.

Булачак шагыйрь агасы Шакир Рәмиев (соңыннан нәшир) белән бергә Муллакай авылы мәдрәсәсендә укый, гарәп һәм фарсы телләрен өйрәнә. Мәдрәсәне тәмамлагач, 1880 елда Төркиягә китеп, Истамбулда хосусый рәвештә төрек телен һәм әдәбиятын өйрәнә, әдипләр, шагыйрьләр белән аралаша. Солтан реакциясеннән интеккән бу чор төрек әдәбиятында төшенкелек мотивлары көчле була. Күрәсең, моның Дәрдмәндкә тәэсире булмый калмагандыр.

Шагыйрьнең иҗат эшчәнлеге Россиягә кайткач башлана. Ул балалар өчен төрекчәдән кечкенә күләмле хикәяләр тәрҗемә итә. Аның беренче әсәрләре 1902—03 елларда «Тәрҗеман» газетасында басыла.

Дәрдмәнд иҗатының активлашуы 1905—07 еллардагы беренче рус революциясе чорына туры килә. «Каләмгә хитап» шигыренең беренче юлындагы фикер шагыйрьнең бөтен иҗатын характерлый, ягъни шагыйрь күңелдәгене укучыга ихлас сөйләп бирүне аклый:

**Каләм! Кальбеңдә ни сер бар, гаян ит...**

Дәрдмәнд Көнчыгыш һәм Көнбатышның культура хәзинәләреннән үтә хәбәрдар була. Аның рус телен һәм әдәбиятын әйбәт белүе поэзиябезне матур тәрҗемәләр белән баетуда ярдәм итә. Дәрдмәнд Пушкинның «Кышкы кич»ен, «Салтан патшә турында әкият»еннән өзек тәрҗемә иткәндә оригиналдагы мәгънәви байлыкны, ритм һәм башка шигъри чараларны татар укучысына да тегәл җиткерергә омтыла.

Шагыйрь беренче рус революциясен мәгърифәтчелек позициясеннән чыгып, буржуаз демократ буларак каршылый. Ул матбугат, сүз иреге, «явочный порядок ачылуга» өметләнә. Ләкин ул беркатлы кабынып, сокланып китүдән ерак тора. Аның өмет һәм ышанычларында саклык бар. Иҗтимагый тормыштагы күренешләргә үзенең мөнәсәбәтен белдергәндә аллегориягә мөрәҗәгать итүе дә шуннан килә. Ул русчадан тәрҗемә иткән саф табигать шигырьләренә дә иҗтимагый мәгънә салырга ты-

рыша. Мәсәлән, Тютчевтан тәрҗемә ителгән «Тал чыбык» шигыренең астына: «Ислах сораган шәкертләргә тартамын», дип искәрмә бирә.

Шагыйрьнең үз чорында киң иҗтимагый яңгыраш тапкан әсәрләреннән иң күренеклесе «Кораб» (1908) шигыре була. Дәрдмәнд хәвефле юл ерып барган мәһабәт кораб образында, Россиянең киң иҗтимагый хәрәкәт дөньясына чыгып, үзенең яңа язмышын эзләүче татар милләтен гәүдәләндерә. Киләчәк лирик герой күз алдына шомлы билгесезлек булып килеп баса: шагыйрь тормышның гомуми хәрәкәтен сиземенләсә дә, аның анык перспективасын күз алдына китерә алмый. Биредә художниклык куәтенең сыйнфый чикләнгәнлеге фаҗигасен күрәбез.

**Чыкты җилләр,**
**Купты дулкын —**
**Ил корабын җил сөрә!..**
**Кайсы юллар,**
**Нинди упкын**
**Тарта безне җан сорап!!**

Дәрдмәнд иҗатында үзәк урынны туган ил темасы алып тора. Ил — шагыйрь өчен барысыннан да югары мәңгелек, изге төшенчә. Туган илне шагыйрь иң зур корбанnарга лаек бердәнбер олы нәрсә итеп карый.

**Атам-анам йорты өчен**
**Булса мең җаным фида;**
**Туган-үскән илем өчен**
**Соң тамчы каным фида.**

Ил Дәрдмәнд иҗатында халык төшенчәсе белән үрелеп бара. Бу темада ул әзлекле һәм азагынача үз иманына тугры. Социаль язмышның үтә драматик борылышы чорында, сыйныфташлары бар өметләрен чит илгә баглаган бер вакытта ул:

**Илдә бер дус булмаса гәр,**
**Ил бөтен дошман түгел,—**

дип чыкты.

Шагыйрь илгә зур ышаныч белән карый. Ул үзенең каршылыклы, ләкин гуманистик кыйммәте өстен булган иҗатын яхшыны яманнан аера белүче илнең тугры хөкеменә калдырып китте.

**Ил мөмәйез, аңлар ул тиз,**
**Син аны сизмәс димә.**

Галимҗан Ибраһимов 1921 елда шагыйрьнең вафаты уңае белән: «Болар уяну күгендәге беренче йолдызлардан иде»,— дип язды.

# ТАТАР ФИЛОЛОГИЯСЕНӘ ЗУР ӨЛЕШ КЕРТКӘН ГАЛИМ

*Латыйф Җәләйнең тууына 75 ел тулуга карата*



Татар тел гыйлеменең үсүенә зур өлеш керткән күренекле белгеч, филология фәннәре докторы, профессор Л. Җәләйнең тууына 75 ел тулды.

Галимнең тәрҗемәи хәле Совет власте чорында фәнгә килгән бик күпләрнең тормыш юлын хәтерләтә.

Латыйф Җәләй 1894 елның 17 ноябрендә Самара губернасы, Мәләкәс өязе Кызыл Су авылында ярлы крестьян гаиләсендә туа.

Кызыл Суның табигате үзенең гүзәллеге һәм байлыгы белән аерылып торган: авылның иген капкасын чыккач та уңдырышлы туфраклы басулар,ерактарак урманнар сузыла. Авыл яныннан гына елга уза. Латыйфның бала чагы әнә шунда үтә.

Ләкин кечкенә Латыйфка табигать кочагында хозурланырга мөмкинлекләр булмый. Аңа тормышның ачысы-төчесе белән бик иртә очрашырга туры килә. Кышларын ул мәхәллә мәктәбендә укый, җәйләрен, 9 яшьтән алып, төрле эшләрдә эшли. Мәхәллә мәктәбен тәмамлаганнан соң, 1906 елда Мәләкәс мәдрәсәсенә укырга керә. Җәйге ял айларында ул чакта да эшләргә мәҗбүр була, чөнки бу вакытта аның әтисе үлеп китә.

Мәдрәсәне уңышлы тәмамлаганнан соң (соңгы 2 еллык укуны бер елда бетерә) 1911 елда ул Самара губернасы Иске Җүрәй авылына мөгаллим-укытучы булып китә...

1914 елда Латыйф Ташкентка юл ала. Аның Ташкенттагы тормышы ул замандагы башка «бәхет эзләүче»ләрнең тормышына охшаш. Анда ул аш һәм ипи пешерүче дә, виноград арчучы да була, башка эшләрдә дә йөри.

1915 елда Л. Җәләй яңадан үзенең туган авылы Кызыл Суга кайта һәм, шул ук елны армиягә алынып, Беренче бөтендөнья сугышына җибәрелә. Февраль революциясен Румыния фронтында каршы ала. 1917 елның ахырларында Л. Җәләй фронттан туган иленә кайта.

Бөек Октябрь социалистик революциясеннән соң аңа эшләү һәм уку өчен киң мөмкинлекләр ачыла. Һәм Л. Җәләй җиң сызганып эшкә керешә. Төрле авылларда беренче баскыч мәктәпләрендә укыта һәм үзенең белемен күтәрү өстендә бик нык эшли. Өч елдан соң өяз мәгариф бүлеге аны Самара шәһәрендәге педагогия техникумына татар теле һәм әдәбияты укытучысы итеп күчерә. 1924—1925 елларда ул шул ук шәһәрдә детдом мөдире дә булып эшли. 1925—1928 елларда башта Бозаулыкта шәһәр, аннан соң Самарада губерна мәгариф бүлегендә инспектор хезмәтен башкара. 1928 елдан алып 1932 елга кадәр Самарада өлкә партия-совет мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укыта.

1932 елда Л. Җәләй Самара педагогия институты каршындагы аспирантурага укырга керә, 1933 елны Казан педагогия институтына күчеп, аспирантурада укуны дәвам иттерә һәм, 1935 елда аны тәмамлап чыгып, шул ук институтның татар теле һәм әдәбияты кафедрасында укытучы булып эшли башлый.

1939 елда Татарстан тел, әдәбият һәм тарих фәнни-тикшерену институты ачылгач,

анда Л. Җәләй тел секторы мөдире итеп билгеләнә. 1944 елда ул яңадан Казан педагогия институтына кайтып укыта башлый һәм шул ук елны, Казан дәүләт университетында татар филологиясе бүлеге ачылгач, анда да кайбер курслар буенча лекцияләр алып бара. 1946 елда Татарстан тел, әдәбият һәм тарих фәнни-тикшеренү институты СССР Фәннәр академиясе Казан филиалы составына кергәч, Л. Җәләй бу филиалга күчте һәм пенсиягә чыкканчы (1962 елның апреленә кадәр) башта фәнни сотрудник, 1956 елдан башлап тел секторы мөдире булып эшләде. Галим 1966 елның 1 августында Казан шәһәрендә вафат булды.

Профессор Л. Җәләй татар теленең тарихи грамматикасын өйрәнү өлкәсендә зур эшчәнлек күрсәтте. Татар тел белеменең бу тармагы буенча аерым китап һәм бик күп мәкаләләр бастырып чыгарды. Шуның белән бергә, тарихи грамматика буенча кандидатлык диссертациясе язды һәм 1942 елда аны уңышлы яклады. 1954 елда галимнең «Тарихи фонетика буенча материаллар» дигән китабы басылып чыкты. Бу хезмәттә татар теленең фонетикасындагы төп тарихи үзгәрешләр билгеләнә һәм тикшерелә.

Шулай ук профессор «Татар теленең тарихи морфологиясе буенча очерклар» дигән фәнни хезмәт язды. Бу тикшерену авторның озак еллар буенча тарихи грамматика өстендә эшләү нәтиҗәсе булып тора. Ләкин бу монографиянең басылып чыкканы юк әле. Тарихи грамматика өлкәсендә Л. Җәләй эшчәнлегенең әһәмияте шунда ки, ул татар тел белемендәге бу тармакның төп проблемаларын билгеләп тикшерде һәм бу дисциплинаны фән югарылыгына күтәрде.

Тарихи грамматика белән беррәттән Л. Җәләй татар диалектларын өйрәнү буенча бик күп һәм зур эшләр башкарды. Мәгълүм булганча, татар диалектлары Октябрь революциясенә кадәр үк тикшерелә башлаган. Татар диалектологиясе белән теге яки бу дәрәҗәдә академиклар В. В. Радлов, А. Г. Бессонов, профессорлар Н. Ф. Катанов, С. Е. Малов, тикшеренүчеләр С. Кукляшев, Г. Әхмәтов һәм башка галимнәр шөгыльләнәләр. Ләкин Октябрь революциясенә кадәр татар диалектологиясе системага салып эшкәртелә һәм аерым фән югарылыгына күтәрелә алмый.

Октябрь революциясеннән соң татар диалектологиясе белән күренекле тел галиме Җ. Вәлиди кызыксына һәм бу өлкәдә шактый эш башкара. Эстафетаны Җ. Вәлиди кулыннан Л. Җәләй ала һәм моннан соң татар диалектлары эзлекле рәвештә бөтен киңлеге һәм тирәнлеге белән өйрәнелә башлый.

Турыдан-туры Л. Җәләй катнашлыгында һәм җитәкчелегендә татарлар яшәгән Идел буе һәм Урал районнарына диалектларны тикшерү-өйрәнү өчен бик күп экспедицияләр оештырыла. Шуның нәтиҗәсе буларак, 1947 елда галимнең «Татар диалектологиясе» дигән монографиясе басылып чыга. Автор бу хезмәтендә татар диалектларының өйрәнелү тарихын, аларның классификациясен бирә һәм нигез диалектларның төп үзенчәлекләрен ача. Шулай ук галимнең катнашлыгы һәм җитәкчелеге белән өч китаптан гыйбарәт «Диалектологик сүзлек» чыгарыла. Бу сүзлекләрнең эчтәлеген экспедицияләр вакытында тупланган лексик материал тәшкил итә.

Татар диалектларын практик өйрәнү һәм тирән теоретик белем Л. Җәләйгә татар диалектологиясендә капиталь хезмәт булып торган монография язарга мөмкинлек бирә. «Урта диалект» дип аталган бу хезмәтне Л. Җәләй докторлык диссертациясе итеп яклап, филология фәннәре докторы дигән дәрәҗә ала.

Л. Җәләй татар әдәби тел тарихын тикшерүгә зур көч куя. Тел белеменең бу тармагы аңарга кадәр бөтенләй өйрәнелмәгән диярлек иде. Галим үзенең Ә. Ахунҗанов белән берлектә язган «Татар милли әдәби теле туу мәсьәләсенә карата» дигән мәкаләсендә татар әдәби теленең барлыкка килү һәм формалашуы процессын яктырта. Л. Җәләйнең әдәби тел тарихына караган бик күп материаллары архивта саклана. Архив материаллары галимнең әдәби тел тарихын бик тирән һәм җентекле тикшерүен күрсәтә.

Хәзерге татар теле мәсьәләләре дә профессор игътибарыннан читтә калмый. Аның бу өлкәгә караган «Фигыль юнәлешләре» (1938) дигән мәкаләсен, «Татар теленең орфоэпик нигезләре» (1953) дигән китабын һ. б. хезмәтләрен күрсәтергә була. Аның югарыда күрсәтелгән мәкаләсендә хәзерге татар телендәге фигыль юнәлешләренә тирән фәнни анализ ясала һәм бу мәсьәлә буенча оригиналь фикерләр әйтелә. Орфоэпиягә багышланган хезмәтендә исә хәзерге татар теленең орфоэпик системасы бирелә, нормалары ачыклана.

Педагог галим буларак Л. Җәләй мәктәп белән дә үзенең бәйләнешен өзми. Мәктәпләр өчен «Туган тел» (1930), «Уку китабы» (1933—34), «Систематик диктантлар җыентыгы» (1941), «Тыныш билгеләре буенча күнегүләр» (1941), 8 нче класслар өчен «Әдәбият буенча дәреслек-хрестоматия» (1940), 8 нче класс өчен «Әдәбият дәреслеге» (1945—47) дигән китаплар һәм кулланмалар бастырып чыгара.

СССР Фәннәр академиясе Казан филиалы, Казан дәүләт университеты чыгарган бик күп китапларның һәм хезмәтләрнең фәнни редакторы буларак та Л. Җәләй күп эш алып барды. «Диалектологик сүзлек»ләрне, мәктәпләр өчен язылган грамматика дәреслекләрен редакцияләү буенча ул гаять дәрәҗәдә җаваплы һәм авыр эш башкарды.

Л. Җәлил матур әдәбиятны бик нечкә сиземли торган галимнәребезнең берсе иде. Ул татар әдәбияты, аерым әдәби әсәрләр буенча бик күп тәнкыйть мәкаләләре язды, рецензияләр белән чыгышлар ясады. Аның бу өлкәгә караган 60 тан артык мәкаләсе һәм рецензиясе бар. Галим үзенең әдәбиятка багышланган чыгышларында бигрәк тә язучының теленә һәм стиль проблемаларына игътибарын юнәлтте. Ул, аерып әйткәндә, Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Ш. Камал, К. Нәҗми, Г. Бәширов, М. Мак-

суд, М. Әмир, А. Расих, С. Хәким һ. б. иҗаты һәм әсәрләре турында мәкаләләр бастырып чыгарды. Бу чыгышлар язучыларның иҗатына, гомумән, татар әдәбиятының, аның тел-стиль төзеклегенең үсешенә, һичшиксез, уңай йогынты ясадылар. Л. Җәләй СССР язучылар союзы члены иде.

Л. Җәләй һәрвакыт студентлар, яшь белгечләр арасында булды. Алардан бик күп фәнни хезмәткәрләр, галимнәр җитештерде. Казан дәүләт университетында, СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалында аның һәрвакыт аспирантлары булды. Ул яшь галимнәрне үстерү өчен бөтен көчен бирде, аларга бөтен яклап ярдәм итте. Аның турыдан-туры җитәкчелегендә бик күп белгечләр галим булып җитеште: филология фәннәре докторы профессор М. З. Зәкиев, филология фәннәре кандидатлары Н. Борһанова, К. Сабиров, В. Хаков, Г. Ахунҗанов һ. б.

Л. Җәләй татар тел белеме өлкәсендә армый-талмый бөтен көчен бирел эшләде — аның бу эшчәнлеге татар филологиясе үсешендә үзенә бер баскыч булып тора.

**Ф. ГАНИЕВ,**
филология фәннәре кандидаты.

# ЛАТЫЙФ ҖӘЛӘЙНЕҢ АФЗАЛ ШАМОВКА ЯЗГАН ХАТЫ

**Зур мактауга һәм ихтирамга лаек якын дустым, замандаш вә каләмдәшем Афзал, гомерең озын, ямьле һәм данлы булсын. Бу — миннән эчкерсез, саф, самими теләк сиңа.**

18 ноябрь тарихлы котлау хатың шул чаклы җылы язылган ки, аның хәтта һәрбер хәрефеннән әҗәлгә дару булырлык логика, эмоция, якынлык рухы бөркелеп тора. Һәм синең бу хатың, турысын әйтим, мине — карт бәндәне — тергезеп җибәрде. «Мин — бичаракай ялгызмын, ташландык бер кеше кисәгемен, бугай»,— дигән уйлар башыма үрмәли башлаган минутларда синең шушы хатыңны китереп бирделәр. Һәм мин яңадан тугандай бер хәлдә сиздем үземне: гадәтемчә, куанычтан күзләремнән яшьләр тәгәрәделәр.

Мин 17 ноябрьда яшем 70 кә тулачагын беләдер идем. Әмма минем гомер юлымда очраган бу датаны юбилейлап уздырачаклары миңа мәгълүм түгел иде.

28 ноябрьда кич белән өемә килеп, зур табын корып, мин сиңа әйтим, 70 еллыгымны олылап, шаулап котладылар. Бу процедураны Тел, әдәбият һәм тарих институты белән Язучылар союзы бергәләп оештырганнар һәм алар ук кешеләрне дә үзләре чакырып китергәннәр икән.

Димәк, шул рәвешчә, кунакларны мин каршылаучы һәм озатып калучы сыйфатында гына булып калдым. Ул мәҗлестә сине дә күрәсем килгән иде, ләкин ни эшләтмәк кирәк, максатка ирешә алмадым. Әйдә, хәерле булсын, син безгә килеп чыгарсың, мин сезгә дигәндәй, үчен алырбыз әле.

Мин синең исәнлегең-саулыгың турында белеш-танышлардан сораша торамын. Алар миңа яхшы хәбәрләр сөйлиләр: син инде тулысынча савыгып, урамнарга да чыгып йөри алу хәленә ирешкәнсең, дип әйтәләр. Мин моңа куанып утырамын һәм үзем дә йөри алу көченә ирешермен дип ышанып ятамын.

Кыскасы, бер сүз белән әйткәндә, 28 ноябрь кич өемә килеп уздырылган мәҗлесләре чынлап та юбилей булып чыкты. Татарстан Верховный Советы Мактау язуы (Почетная грамота) бүләк итте. Язучылар союзы исеменнән Мирсәй Әмир бик җылы һәм бай эчтәлекле адрес-хат укыды.

Мирсәй иптәшнең үзе килү күңелне күтәреп җибәрде. Мин аның ихтирамын беркайчан да истән чыгармаячакмын, әлбәттә.

Моннан кала тагын 4—5 адрес китерделәр. Боларның җыенысы бергә миңа рухи канат куйдылар, һәм миндә яңабаштан яшисе килү дәрте уянды. Бераз яшәп карарга кирәк булыр әле чынлап та!

Сәйфи Кудаш — атаклы шагыйребез. Ул да миңа котлау хаты җибәргән. Аның хатын укыгач, шагыйрь Акмулла сүзләре хәтергә килеп төштеләр: «Шагыйрьләрнең сүзләре чыгар хикмәт илә»,— дигән ул Ш. Мәрҗанигә багышлаган мәдхиясендә.

Сәйфи Кудаш әле бу араларда гына килгән хатында миңа түбәндәге дүрт юллыгын язып куйган. Мин аны, кәмаһүә (нәкъ үзенчә) күчерәмен:

Иң яхшы шигыре — шагыйрьнең
Әле язмаган шигырь;
Иң якты гомере кешенең —
Әле узмаган гомер.

Илтифат итче, дөрестән дә, хикмәтле сүзләр тезелгәннәр ич монда! Шигъри тышчага төренгән хикмәтнең көче шунда ки, ул авыруны савыктыра, дәртсезне дәртләндерә, өметсезне өметләндерә, җансызны җанландыра...

Шагыйрьнең бу дүртюллыгы мине әллә узачак гомерем яктырак булыр дип дәртләнергә юл ачты, һәм мин Сәйфи Кудашка моның өчен дустанә рәхмәтләр укыймын, укыячакмын да.

Тукта әле, Афзал, мин кыскача бер чигенеш ясап алыймчы? Хәтерлисеңдер, М. Гали дигән бер язучыбыз бар иде. Аның «такылдама» [дигән] терминны еш кабатлавы хәтеремдә нык саклана. Ул — мәрхүм кайберәүләрнең мәкаләләрен шушы термин белән атап йөртә иде. Мәсәлән, ул — мәрхүм миңа:

— Җәләй иптәш, безнең дусларыбыздан берәүнең чираттагы такылдамасы чыккан, укыдыңмы? — дип берничә тапкырлар сорау биргән иде. Хәтерлим, күп вакыт ул минем үземә дә:

— Җәләй иптәш, синең бер такылдамаң чыккан икән, укыдым,— дип әйтә торган иде, мәрхүм. Ләкин мин аңа сорау куеп, «такылдама»ның киң шәрхын, аңлатмасын сорый алмый калдым. Уйлыймын ки, бу атаманы ул да халык телендә йөртелгәнчә, «буш сүз» төшенчәсе белән алгандыр. Мин үзем дә шулай күзаллыймын.

Кыскасы, әйтәсем килә ки, минем бу хатым такылдамага әйләнеп бара, бугай, дигән уй төште башыма.

Ярый, инде үземчә житдирәк санаган кайбер мәсьәләгә тукталып карыйм әле, бәлки, мишәр агай-эне әйтмешли, берәр ябәләсе булыр шунда.

Быел, хәтерем алдамаса, синең дөньяга чыккан әсәрләрең булмадылар, бугай. Аңлыймын, авырып ятуың комачаулагандыр. Әйдә, исәнлегең кайткан булса, шунысы житкән. Бу уңайда минем сиңа бер үтенечем бар. Шуны әйтеп карыймчы: мин синең «Хәйрулла абзый» [дип] аталган очеркыңны укып бик яраткан идем. Син аны шул дәрәҗәдә оста сурәтләгәнсең ки, ул үзенең кыйланышлары белән, мин сиңа әйтим, социалистик реализм калыбына салынган чын-чын совет карты, түм-түгәрәк образ булган да чыккан. Мин ишеттем, имеш, язучылар җыелышында (берәр секциядәдер инде) «очерклар жанрын үстерергә, яхшы очерклар язарга кирәк» дигән фикер күтәргәннәр, ди. Минем бәлам шунда — мин ул җыелышларга бара алудан мәхрүм.

Бәлки, мин ялгышамдыр, бәлки, үземә куйган таләпләрне башкаларга да куеп маташамдыр. Һәрхәлдә, әйтергә теләгән сүземне йотып каласым килми. Мин әйтәм, сезнең кайбер язучыларыгыз (гафу ит, алар безнекеләр дә, әлбәттә) үзләрен иҗатчылар санаган булып та, иҗат өчен белем, әзләнү, казыну, гыйлем һәм тәҗрибә кирәкләгән башларына китереп һәм тартып-сузып, үлчәп-бизмәнләп карамыйлар, ахрысы.

Мин үзем тикшерә торган маузугыга караган һәрбер вак кына факт турында хәтта атналар буена уйланып ятамын. Нишләмәк кирәк, шунсыз эш барып чыкмый. Миңа һәрбер сүзем өчен җавап бирәсе бар ич! Менә нәрсә мине тезгенли.

Кайбер язучылар, күрәм, андый җаваплылыкны сизмиләр. Әгәр дә мәгәр шулай булса, бетте баш! Ул чагында безнең ишеләргә сөйләргә урын да калмый.

Язучы, барыннан да элек, укучылары алдында, аннары фән-культура һәм тарих алдында җаваплы. Л. Н. Толстой «Әдәбият турында» дигән бер китабында Шекспирга сылтап: «Китап үз бәхетенә укучы кулына кергәч ирешә»,— дип әйтә. Бу — һичшиксез хакыйкать.

Тагын такылдама чокырына төшеп барамын, ахрысы?

Гафу ит, хәзер түгәрәклимен, бетте, хәзер бетерәм.

Әле бу араларда хәл белергә дип яшь галимнәребездән берәү килеп кергән иде.

Шул иптәш сүз арасында түбәндәге мәкальне китерде: «Аны бер тиен биреп сөйләтә алмыйсың, ун тиен биреп туктата алмыйсың дилэр»,— диде.

— Син, дустым, бу хикмәтле мәкальне кайдан алдың? — дидем.

Ул миңа:

— Мин моны моннан 4—5 ел элек Иске Кулаткыдан алып кайткан идем,— дип аңлатты.

Бу хатымны яза-яза мин дә ун тиен бирсәң дә туктата алмаслык хәлгә килдем, бугай. Әмма язарга билгеләп куйган фикерләрем һаман чират көтеп торалар әле. Менә ул фикерләрдән берсе: үзең дә беләсеңдер, «Совет әдәбияты» журналы быел берничә «роман» чыгарды. Мин аларны көч-хәл белән, мишәр әйтмешли, начила укыдым да, сезнең Тау яклары әйткәнчә, пышман булдым. Ник дисәң, аларның берсе дә романның киртәсенә керү түгел, хәтта ул киртәнең янына да килми ич!

Турысын әйткән туганына ярамаган, имеш. Шулай булса да, мин турысын әйтергә яратам. Бу «романнар» минем вөҗданымны җәберләделәр. Ник дисәң, мин бу әсәрләрнең идеологияләре чатак, дип әйтергә җыенмыймын. Алла сакласын, андый уйда булырга тузан кадәр генә дә каем (сәбәп) юк! Унай, изге, яхшы идеяне сәнгатьчә матур, гүзәл калыпка салып бирә алу да кирәк ич!

Әдәбият кануннары дигән нәрсә бар һәм аны бүген генә төземәгәннәр дә. Чөнки ул кануннар бөтен кешелек дөньясы уздырган, туплаган тәҗрибә нигезендә үсә-үстерелә килгәннәр. Мәсәлән, роман (грек сүзе) жанр буларак дөньяга китерелгән тарихи сәбәпләр бар. Һәм шунда ук романның стилистик үзенчәлекле яклары да инде урнашканнар — законлашканнар.

Теоретиклар романда өч элемент табылырга тиеш диләр: а) сказочность (әкиятчәлек), б) увлекательность (мавыктыргычлык), в) мечтательность (уйландыргычлык).

Габдрахман Сәгъди мәрхүм әдәби әсәрләрдә «уйгынлык» һәм «тойгынлык» табылырга тиеш дип әйткән иде. Аның уйгын һәм тойгын дигән терминнары роман төзелешенә бик тапкыр килә.

Кыскасы, димәкче буламын ки, «Совет әдәбияты»ның быелгы саннарында басылган «романнар» бүгенге көнне бездә әле роман яза алучылар аз дип торалар. Ник дисәң, ул, ягъни быелгы, романнарда әнә шул югарыда саналган өч шартның берсе дә табылмый.

Соң моңа кем гаепле? Минемчә, гаепләләрне эзләргә керешүдән элек гаепләребезне тулырак барларга кирәк. Безнең һәркайсыбыз, дип була, адым саен эстетика, эстетик чаралар кебек терминнарны телгә алабыз. Ләкин әле берәүнең дә (безнең татар әдәбиятында!) бу зур, актуаль мәсьәләгә карата колакка ятарлык сүз әйтә алганы юк.

Үзеңә мәгълүм, Үзәк Комитетның үз карамагында дөньяга чыгарылган шактый зур күләмле бер кулланма-китап бар. Мин уйлыйм, бу китап синең дә өстәлеңдә, кул астында ята торгандыр. Китапның атамасы «Основы марксистско-ленинской эстетики». 1961 елгы басма. Мәскәү.

Бу бай кулланманың эчтәлегенә тукталмыймын. Тик шуны гына әйтәсем килә ки, син менә шушы китапны тәрҗемәләү эшен оештырсаң, язучыларыбызга да һәм укучылар гаммәсенә дә зур хезмәтең — бүләгең булыр иде. Иш янына куш рәвешенчә, минем дә булышлык күрсәтергә дәртем бар, дәрманым җитә калса.

В. И. Ленинның пролетариат интернационализмы принципларына нигезләнгән милли политикасы яктылыгында татар әдәбият белеме тарихта күрелмәгән биеклекләргә күтәрелеп үсте. Бу — һичшиксез инкарь итә алмаслык хакыйкать. Бүгенге көнне безнең татар әдәбияты буенча докторлык дәрәҗәсе, профессорлык исеме алган ике кешебез бар. Монысын кая итәсең! Бу бит бер кадак йөзем генә түгел. Ләкин, гайбәттән булмасын, гыйбрәттән булсын дигәндәй, бу профессорларыбыз әлегә әдәбиятыбызның чиратта торган ихтыяҗларын капларлык зур эшләр эшләп күрсәткәннәре юк. Уңышларыннан башлары әйләнеп калды, бугай?! Ярый ла, Тукайның «Бер ишан-хәзрәт үстердем, күркә-тавык ашатып; сагынсам, корсагына карыйм, чүмәләгә охшатып»,— дигән фразасына тиң назым уйлап табарга туры килмәсә. Әйдә, алар — яшьләр әле. Бер көн килер, аңларлар үз бурычларын. Шулай да әдәбиятыбызның тәненнән майлы калҗа йолкып алырга күз салып йөрүчеләрнең күбәеп барулары бераз борчып куйгалый, чын дөресен әйткәндә. [...]

Мәгълүм ки, эстетика — борынгы греклардан калган сүз-термин. Грек философлары «яхшы» белән «яман» төшенчәләрен анкларга тырышканнар, бу юнәлештә фикерләр күрәше алып барганнар. Нәтиҗәдә яхшылыкның төп билгесе итеп эстетиканы алганнар. Руслар эстетика төшенчәсен «прекрасное» дип алганнар. Безнең телдә, минем уемча, боларның тәңгәле г ү з ә л сүзе була ала.

Философия үзенең эшкәртелү, өйрәнелү дәвамында, һәм реакцион һәм прогрессив төрләргә әйләнеп, төрле төсләргә кереп беткән кебек, эстетика да ничәмә гасырлар буена аристократия, хаким сыйныфлар зәвыгына хезмәт итә килгән.

Бүгенге көнне исә буржуазия идеологлары, капитализмны әҗәл чокырыннан тартып чыгару өчен, сәнгатьне шәрәләндерү, җимерү мәкерен алга сөреп маташалар. Абстракционизм, формализм, натурализм һәм башка шундый «изм»нарның барысы да чын сәнгатьне, социалистик эстетиканы киртәләргә юнәлтелгәннәр.

Марксизм-ленинизм тәгълиматында эстетика иҗтимагый фәннәр катарына кертелә. Әдәбият үзе дә — иҗтимагый фән. Димәк, эстетиканы әдәбияттан һәм әдәбиятны эстетикадан (билгеле, без монда марксистик эстетиканы аң үзәгендә тотабыз!) һичбер төрле юл белән аерып булмый һәм аерырга ярамый да!

Инде шулай булгач, безнең кайбер әдип һәм шагыйрьләребез [нигә] үзләренең әсәрләрен эстетик тәм һәм ямь белән бизәмиләр? Бу — бик авыр сорау. Син, бәлки: «Бизиләр ич!» — дип тә куярсың. Анысы — синең үз татымың. Сүзне озакка җибәрмәс өчен, мин ул бизәксез әсәрләрне монда санап тормыймын. Булмаса, дустым, әнә шул быел басылган романнарны тагын бер кат укып карачы, алардан хәзерге чорга лаек эстетика-гүзәллек табарсыңмы икән?!

...Афзал дус, гафу ит, бу араларда көтелмәгән йомышлар бер-бер артлы килеп чыккалау сәбәпле, мин бу хатчыгымны әле һаман төгәлли алмый маташтым,— монысы бер яктан. Уй-фикерләрең сыек, сай, таркау, үзәксез, бер күчәр тирәсендә әйләнми торган булсалар, аларны аник, йомыры тышчага — тел калыбына салу шактый кыенга туры килә,— монысы икенче яктан.

Боларның барысы да — житмеш яшь бәласе! Атамасы үзе үк аңлатып торганча, житмеш — житкән, ягъни кеше гомере инде үзенең чигенә, түшәменә барып житкән була. Сан атамалар этимологиясен — борынгы төп мәгънәләрен тикшерүчеләр шулай дип аңлаталар «житмеш»не.

Ярый, анысы шулай булсын, әмма безнең төп теләк — житмешне узып китеп, яшәү сапламын түшәмнең өстенә үк сузу әле.

Сүзем артык озынга китсә дә, тагын бер үтенечемне әйтеп калдырырга уйлыйм. Советлар чоры татар әдәбиятын татып, аңа күңел бирүемнең башлану чорында мина аң һәм ямь биргән әсәрләрдән берсе һәм, әйтергә кирәк, иң көчлесе синең «Рәүфә»ң булган иде. Шунлыктан булырга тиеш, минем бүгенге көнне дә ул «Рәүфә»не кайтадан укыйсым һәм аның соңгы язмышы белән танышасым, уртаклашасым, хәтта, кулын кысып, аны — замандашны котлыйсым килә. Кулак кансызлыгы, явызлыгы киртәләрен ул чорда җимереп чыккан хатын-кызларыбыз хәзерге көнне зур, эшлекле кешеләр дәрәҗәсенә үсеп чыктылар: мин Рәүфәнең зур кеше — фән иясе булуын күрер идем, менә хәзер — белдек!

Син, брат, трилогия яки романга әйләндереп, безгә яңа «Рәүфә»не бирү чараларын күр әле. Монысы — беренче үтенеч.

Туп-туры әйтәм: әдәби жанр буларак, очеркларның әһәмияте бик зур. Татар һәм башка төрки халыкларның әдәбиятлары тарихында очерк жанры иң карт, иң борынгы жанр булып тора. Ул борынгы каберташъязмаларына теркәлгән мемуарлар белән башлана. Орхун-Енәсәй язмалары (безнең эрадагы IV—VIII йөзләр) мемуаристик әсәрләр ич!

XIV йөз татар әдәбияты ядкарьләреннән «Нәһҗел-фәрадис» (Гали Болгари әсәрләре җыентыгы), шул ук чорда язган Мөхәммәдьярның хикәят дип атаган әсәрләре арасында да байтагысы — очерклар. Аннары XVII йөзгә күчкәч, очерк жанрының бер төре рәвешендә, юлъязмалар (сәяхәтнамәләр) туа башлыйлар. Шундый тарихи фактлар очеркларның әдәбиятыбыз үсешендәге саплам сузылуы турында тулы мәгълүмат бирәләр.

Кызганычка каршы, соңгы елларда язучыларыбыз бу жанрны читләтә башладылар. Минемчә, бу — яхшы фал түгел. Каләмнәрен кайсы кулларына тотарга икәнен

рәтләп төшенеп, ипләшеп житмәгән яшьләребез озынрак текст язсалар, аны «роман» дип атарга ашыгалар. Моның бәласе — әлбәттә, әдәби жанрларның үзләренә хас якларын төшенеп житмәүдән килә.

Менә шундый күренешләрне булдырмас өчен, хәзерге вакытта яхшы, мөкәммәл очерклар үрнәкләрен матбугатта күбәйтергә кирәк. [...]

— Теләнчегә якты йөз күрсәтсәң, ул кунарга сорый, имеш,— дигәннәр теге теләнчеләр чорында яшәгән бабайлар.

Мин дә, сорау артыннан сорау, теләк янына теләкләр тезә-тезә әнә шул теләнче методына күчеп барамын, ахрысы. Нишлим соң, дустым? Мин бит бүгенге көнне татар әдәбияты барышында кытлык сизәм. Бәлки, бу минем субъектив кимчелегемнән киләторгандыр. Шулай булса, артык куркыныч юк дип тынычланырга да мөмкин әле! Соңгы елларда басылган шигырьләрнең ямьнәре дә һәм тәмнәре дә бетте ич, үзең дә сизәсендер.

Җыеп кына әйткәндә, әдәбиятыбызга карата чын-чыннан һәм ап-ачык тәнкыйть ачарга вакыт: моны озын-озакка сузарга ярамас.

Сүзләр күп иде, мохтасар кылдык.

Афзал, бер көнне вакыт табып, минем янга килеп чык? Ләкин килер алдыннан шалтырат. Телефоным 2—54—12.

Ибраһим Газины күрсәң, сәлам әйт үзенә миннән. Кыргыйланмаса, алып кил аны да минем янга!

Сез — яшьләр, картлык бәласен татымаган кешеләр. Шуңлыктан картлар хәлен тулысы белән күзаллап житкерә алмыйсыз.

«Житмеш — үлем угы тикмеш»,— Мәүлә Колыйча итеп әйткәндә.

Хуш!

Сиңа исәнлек-саулык теләп калучы Латыйф карт Җәләй дип белгәйсезләр.

Хатадыр дип, хатасын орма йөзгә:
Хатадин хали ирмәс хакдыйн үзгә.

(С. Бакырганыйдан, бугай?)

Латыйф ҖӘЛӘЙ.

25 декабрь, 1964 ел.

---

Профессор Латыйф Җәләй әдәбиятыбызны еллар буенча җентекләп күзәтеп баргак күренекле галимнәребездән берсе иде. Ул язучыларыбызның матбугатка чыккан яңа әсәрләрен бик кызыксынып укып чыга һәм бу укып чыгудан алган тәэсораты турында автор белән дусларча ачыктан-ачык сөйләшә. Әсәре уңышлы булса, аны чын күңелдән котлый, аңа тагын да зуррак иҗади уңышлар тели, аның белән бергә шатлана иде. Әгәр әсәре кимчелекле булып, әдәби эшләнеп бетмичә басылып чыккан икән, Латыйф Җәләй ага бу юлда дә, язучының кемлегенә, аның дәрәҗәсенә, картлыгына, яшьлегенә карамастан, үзенең фикерен яшермичә, боргалап-сыргалап тормыйча, туп-туры әйтә иде. Шуның аркасында ул кайберәүләрне үпкәләтә дә иде. Шулай да аңлаган иптәшләр аның каты тәнкыйтеннән үзләренә кирәкле нәтиҗәне чыгара беләләр иде.

Аның тагын бер үзенчәлекле матур гадәте бар иде: кайчакларда ул берәр яңа әсәрне укып чыгу белән үк үзенең фикерен язып куя һәм, уңае туры килгәндә, аны авторының кулына тоттыра иде. Кайбер очракларда ул үзенең фикерләрен якын дусларына озын хат рәвешендә язгалап та җибәрә иде. Кыскасы, әдәби тәнкыйть мәкаләләре белән матбугатка еш чыкмаса да, ул әдәбиятыбыз алдында торган мөһим мәсьәләләр һәм яңа әсәрләр турында үзенең фикерен теге яки бу формада әйтмичә калмый иде.

Профессор Л. Җәләйнең мондый әдәби хатлары аз түгел. Алар төрле кулларда сакланалар. Минем кулда да андый хатлар берничә.

Мин аның шундый хатларыннан берсен, әдәбиятыбыз алдында торган мөһим мәсьәләләргә багышланганын, матбугатка бирергә кирәк таптым.

Монда бер нәрсәне ачыклап китәргә кирәк: Латыйф Җәләй ага бу хатларның берсен дә матбугат өчен язмаган, хәтта ул аны кайчан да булса бер басылыр, укучылар кулына бирелер дип уйламагандыр да. Бу хатлар — аның якын дуслары белән ике арадагы шәхси язмалары гына.

Матбугатка бирергә әзерләгәндә, бу хатның кайбер җөмләләре сызылды. Андый урыннар текстта квадрат җәяләр эченә алынган өч нокта белән күрсәтелде. Автор онытып яисә ашыгып язмый калдырган аерым сүзләрне, җөмлә тәзеклеге өчен, өстәргә кирәк табылды. Андый сүзләр шулай ук квадрат җәяләр эчендә бирелде.

Афзал ШАМОВ.

**Равил Фәйзуллин**

## Дүрт сүзе бар улымның

Улымның бар дүрт сүзе:
«Әннә»се,
«Әттә»се,
«Тәттә»се,
«Мәммә»се,—
Менә шул һәммәсе!

Аның сүзе тансыкмы,
Тыңлаучы бармы, юкмы,
Иртәдән кичкә кадәр
Сөйләнәме-сөйләнә,
Ничек теле әйләнә!
«Әннә-нә»!
«Мәммә-мә»!..

Үткәндә дә бәйләнә,
Сүткәндә дә бәйләнә:
«Әттә-тә»!
«Тәттә-тә»!
Яраткач «тел бистәсен»,
Әтисе соң нишләсен!
Иңеннән сыйпап үтә,
Маңгаеннан «пәп» итә.
Ә ул сөйли дә сөйли,
Һаман көйли дә көйли!
«Әннә-нә»,
«Мәммә-мә»!
«Әттә-тә»,
«Тәттә-тә!»
Йөргәндә урам-чатта,
Дөнья бик иркен чакта,
Ялгышкалап та куя:
Автобус «әннә» була,
Агачлар «мәммә» була,
Агайлар «әттә» була,
Бәбиләр «тәттә» була...



Ә өйдә ул ялгышмый!
Үз бүлмәсенә кайткач,
Ник ялгышып торсын ди,
Ник оятлы булсын ди! —
Бер ягында әннәсе,
Бер ягында әттәсе,
Бер кулында тәттәсе,
Бер кулында мәммәсе...

...Бүтән сүз нигә кирәк?
Дөньясы түп-түгәрәк!
Үскәч, сүзе артыр әле,
Тормыш тәмен татыр әле!



## Бәлли-бәлли

Бәлли-бәлли-бәү итә.
Улым йокыга китә.
Аңа әле ябынырга
Бер кулъяулык та җитә.

Имезлек авызында,
Бар көче авазында,
Берәр нәрсә теләсә,
Бер кычкырып җибәрсә,—
Тәрәзәләр зың итә!
Әнисе килеп җитә,
Әтисе килеп җитә,
Әбисе килеп җитә!

Бәлли-бәлли-бәү итә.
Улым йокыга китә.
Килешле соң ятагы!
Шул килешле ятагында
Ял итеп алыр чагы!
Үрти күрмәгез тагы! —
Бик бәләкәй дип, көлеп,
Куәте юктыр, диеп...
Белеп торыгыз аны —
Сәгатьләп үскән чагы!

Күзләрен йомсын әле,
Бераз көч җыйсын әле,
Аннан уяныр әле,
Бер аваз салыр әле!
Менә шунда күрерсез,
Менә шунда белерсез
Аның нинди икәнен! —
Әнисен йөгерткәнен,
Әтисен йөгерткәнен,
Әбисен йөгерткәнен,
Дөньяны селкеткәнен!

Тс! Улым йоклап китте!..

# Роза Хәлиуллина

## «Бөрлегән»

Төлкеле дә,
Бүреле дә
Бер совхоз бар
Бөреледә.
Поход белән күпләр килә
Төрле җирдән Бөрелегә.

Без дә килдек класс белән —
Үзебезнең Бөреледән.

Ник борчыла икән врач?
Сәбәбен без белдек аннан:
Бер күк төлке чирләп үлгән,
Өч көчеге ятим калган...
Елый төлке балалары...
Җәлләмәгән бер нәни юк.
Елый төлке балалары:
«Әни кая? Ник әни юк?»
Кинәт йөгерде Марзия,
Нәрсә кирәген сизгән ул,—
Куенына песиен тыгып
Алып та килде тиздән ул.


Песинең исеме — «Бөрлегән»,
Шуннан инде — Бөреледән.

И көчекләр! Бәләкәчләр!
Мәчегә чит түгел алар:
Ятимнәрне бик яратыр,
Имезер, юатыр — ялар...

Сөенештек бөтенебез,
Сөенде врач абый да:
Хәзер инде
Ятим түгел
Нәни төлкеләр — сабыйлар...

Бер ел үтеп китте моңа,
Без дә инде икенчедә.
Көчекләр бик зур үскәннәр,
Ә «Бөрлегән» гел кечкенә...

Төлкеләр үскәч, «Бөрлегән»
Үз өенә кайтып киткән.
Көчекләрен бик сагынса,
Хәл белергә килә икән.



Кечекләре аны күргәч
Тотына ди сөенергә.
...Менә нинди «Берлегән» бар
Төлкеле дә,
Кезәнле дә,
Бүреле дә
Береледә!»

Чакыртып алды үзенә
Врач абый безне бер мәл.
«Берлегән»нең муенына
Бәйләде ул алтын медаль.

Береледәге нәниләр
Чабып китте өйдән-өйгә:

«Берлегән»гә медаль килгән!
«Берлегән»гә медаль килгән!

Кайберәүләр сораганнар:
— «Берлегәнгә»?
Медаль?
Нигә?
— Һе, нигә! Мәче булса да
Ятимнәргә ул әни лә!!!

Береледә
Кешеләрнең
Әле дә булса исендә:
Утыз төлке үстерергә
Туры килгән бу песигә...

## Илгиз, без һәм үгез

Беләсезме без ничәү?
Безме? — Җидәү, минемчә.
Ә Илгиз — сигезенчебез,
Тугызынчы — бозау-үгез.

Бозау-үгез дә Илгиз —
Икесе буйга тигез.
Шул бозау-үгезебез
Сөзеп өйрәнсен, дибез.

Җидәүне куа үгез,
Без качабыз үзебез,
Өстергән була Илгиз —
Әйтерсең, маэмай үгез:

«Үстерсен үгез мөгез —
Әйләнсен чын үгезгә,
Үгез күрке — мөгездә!»
Муенында муенчак,
Үгез-бозау уенчак.
Өстерә бирә Илгиз —
Тәмам котырды үгез.
Нишләргә дә белмибез,
«Котыртма, Илгиз!» — дибез.
Өстереп торган Илгизне
Өстерәп китте үгез.
Яман булды Илгизгә,
Кызганыч булды безгә...



### ТАГЫН БЕР ЮГАРЫ УКУ ЙОРТЫ

Быел республикабыз башкаласы Казанда тагын бер югары уку йорты артты: культура работниклары әзерли торган институт ачылды һәм эшли башлады. Н. К. Крупская исемендәге Ленинград культура институтының Казан филиалы буларак оештырылган бу институт ике факультеттан — китапханәчеләр һәм культура-агарту эше факультетларыннан тора. Гадәттә, китапханәченең эше укучыларга китап биреп торуга гына кайтып кала, дип уйлаучылар бар. Хәлбуки, ул һич тә алай гына түгел. Китапханәченең эше күп төрле һәм ижади. Ул бөтен яңа әдәбиятны өйрәнеп барырга, барлык фәннәр буенча диярлек яңа чыккан китапларны белеп торырга тиеш. Болардан тыш, китап укучылар конференцияләре, диспутлар үткәрү һәм анда чыгышлар ясау да аның өстенә төшә. Үзеннән үзе аңлашыла, бу эшләрне яхшы итеп алып бару өчен китапханәче зур белемгә, югары культурага ия булырга тиеш. Культура институтының китапханәчеләр факультеты әнә шул таләпләргә җавап бирерлек югары квалификацияле китапханәчеләр әзерләп чыгарачак.

Институтның икенче — культура-агарту эше факультеты клуб работниклары, халык театрлары, үзешчән хор, хореография, драма, оркестр коллективлары җитәкчеләре әзерләячәк. Быел бу факультетка режиссерлыкка укучы студентлар кабул ителде. Биш ел уку дәвамында бу факультет студентлары режиссерлык һәм актерлык сәнгатен үзләштерәчәкләр. Гомуми предметлардан тыш, марксистик-ленинчыл эстетиканы, сынлы сәнгать, театр һәм кино тарихларын өйрәнәчәкләр.

Әлегә сәнгать институты студентлары читтән торып укыйлар. Алдагы елларда институтның Казанда торып уку (очное) бүлеге ачылырга тиеш. Моның өчен әзерлек алып барыла башлады инде. Институтның уку корпусы, концерт һәм спорт заллары, ашханәсе төзелә. Уку бинасы янында гына студентлар өчен 640 урынлы тулай торак та салыначак.

### ЗУР ҖЫЕЛЫШ

Татарстан язучылары союзы идарәсе шушы елның 12 сентябрендә балалар әдәбиятының бүгенге хәле турында сөйләшүгә багышланган зур җыелыш үткәрде. Доклад белән чыгучы Шәүкәт Галиев, Шамил Рәкыйпов, Туфан Миннуллин, Разил Вәлиев һәм Хәмзә Зарипов иптәшләр балалар әдәбиятыбызның бүгенге хәленә тирән анализ ясадылар, аның уңай якларын билгеләп үттеләр һәм кимчелекләрен күрсәттеләр. Докладчыларның барысы да соңгы елларда татар балалар әдәбиятында гомумән алга китеш, жанлану сизелсә дә, күп кенә кимчелекләр: тема тарлыгы, кош-корт һәм җәнлекләр турында язу белән артык мавыгу, бүгенге яшь укучыларның рухи таләбен канәгатьләндерерлек әсәрләр азлыгын билгеләп үттеләр.

Фикер алышу барышында сөйләүчеләр дә балалар әдәбиятына игътибарны көчәйтергә кирәклекне куәтләделәр һәм конкрет тәкъдимнәр керттеләр.

Шул ук җыелышта РСФСР язучыларының III съездына бару өчен әдипләребез арасыннан делегатлар да сайланды. Делегат итеп Гариф Ахунов, Николай Беляев, Ян Винецкий, Гомәр Бәширов, Ибраһим Гази, Аяз Гыйләҗев, Рафаэль Мостафин, Туфан Миннуллин, Зәки Нури, Шамил Рәкыйпов, Атилла Расих, Валерий Синев, Хәсән Туфан, Равил Фәйзуллин, Сибгат Хәким, Ренат Харисов, Фатих Хөсни һәм Илдар Юзеев иптәшләр сайландылар.

### СОВЕТ КИНОСЫНА 50 ЕЛ

1919 елның 27 августында В. И. Ленин фотография һәм кинематография сәүдәсенең һәм промышленностеның дәүләт карамагына күчүе турындагы документка кул куйган иде. Шул тарихи документ белән, сәнгать буларак һәм дәүләт промышленностеның мөһим тармагы буларак, совет киносына нигез салынды. Шуннан соңгы 50 ел эчендә совет киносы бик нык үсте. Безнең илебездә эшләнгән кинофильмнар дөньякүләм дан алуга иреште. Халыкка кино күрсәтү көннән көн яхшыра һәм киңәя бара. Әле 1919 елда гына, мәсәлән, Татарстан авылларында нибары 225 киноустановка булган булса, 1968 елда аларның саны 2140 ка житте. 1940 елда республикабыз авылларында стационарлар 105 кенә иде, ә хәзер 1881 инде. Тамашачылар саны да арткannan арта бара. 1940 елда республикабызда 3 460 000 кеше кино караган булса, узган елда кино караучылар саны 24 290 000 кешегә житте. Совет киносына 50 ел тулу уңае белән, КПССның Татарстан өлкә комитеты, Татарстан Министрлар Советы һәм ТАССР Верховный Советы Президиумы республикабызның иң яхшы кинофикация хезмәткәрләре эшен киң рәвештә билгеләп үттеләр. Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы кинофикация системасында уңышлы эшләгәннәре өчен 5 кешегә **«Татарстан АССРның атказанган культура работнигы»** һәм культура өлкәсендә озак еллар эшләгәне өчен Казан кинохроника студиясенең нәфис фильмнарны милли телләргә тәрҗемә итү режиссеры Ф. М. Шәрәфиевкә «Та-

тарстан АССРның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исемнәр бирде. Бик күп иптәшләр ТАССР Верховный Советы Президиумының Почет грамотасы һәм КПССның Татарстан өлкә комитеты һәм ТАССР Министрлар Советының Почет грамотасы белән бүләкләнделәр. Юбилейга багышланган тантаналы җыелышта кино работникларын язучылар, композиторлар һәм рәссамнар исеменнән шагыйрь Зәки Нури котлады.

## КАЗАН КУНАКЛАРЫ

1968 елда Татарстан китап нәшрияты Мөхәммәт Садри тәрҗемәсендә молдаван шагыйрәсе Агнесса Рошканың «Безнең



А. Рошканың Татарстан китап нәшриятында басылган китабы тышлыгы

Җәлил» исемле шигырьләр җыентыгын бастырып чыгарган иде. Ул китапны татар укучылары яратып кабул иттеләр — җыентык бик тиз сатылып бетте. Инде менә шул китапның авторы Агнесса Рошка үзе



А. Рошканың рус телендә Мәскәүдә басылган китабы тышлыгы

дә Казанга кунак булып килде. Безнең язучыларыбыз шагыйрәне Казанның истәлекле урыннары, культура казанышлары белән таныштырдылар, Иделдә сәяхәт иттерделәр.

* * *

Франциядәге Гренобль университетының славян телләре кафедрасы мөдире профессор Робер Клод Казанга килеп, шәһәребездә берничә көн торып китте. Ул В. И. Ленин исемендәге Казан дәүләт университетының кафедралары, бигрәк тә тарих-филология факультетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укыту эшләре һәм рус әдәбиятын һәм телен өйрәнү белән кызыксынды. Француз профессоры Ленин музееи, Казан Кремлен, тарих музеен карады һәм шәһәрнең бүтән тарихи урыннары белән танышты. Соңыннан Робер Клод, Татарстан язучылар союзына килеп, әдипләребездән И. Гази, М. Әмир, Х. Госман, Р. Мостафин, С. Хәким һәм М. Шабаев белән очрашты. Әңгәмә барышында ул татар культурасы һәм әдәбияты үсеше белән кызыксынды.

## КАРАКАЛПАК АССРда ПОЭЗИЯ КӨННӘРЕ

28 августтан 3 сентябрьгә кадәр Каракалпак АССРда поэзия көннәре үткәрелде. «Ленин йөри Аму буйларында» дигән девиз белән уздырылган бу бәйрәмдә катнашу өчен илебезнең төрле республикаларыннан шагыйрьләр чакырылган иде. Поэзия бәйрәменә килгән шагыйрьләр, алты көн буе Каракалпак АССР буйлап йөреп, колхоз-совхозларда, заводларда һәм җәйләүләрдә укучылар белән очраштылар. Кугейлы, Хоҗейлы, Дүрткүл, Чембай, Муйнак, Бируни районнарында булганнан соң, поэзия кәраваны республиканың башкаласы Нукуска килеп туктады һәм драма театры бинасында йомгаклау кичәсе булды. Каракалпак язучылар союзы председателе шагыйрь Ибраһим Юсупов кичәне ачып җибәргәннән соң, партиянең Каракалпак өлкә комитеты секретаре Р. К. Рзаев поэзия көннәрендә катнашкан тугандаш республика шагыйрьләренә котлау сүзләре әйтте. Аннары шагыйрьләрнең үзләренә сүз бирелде. Казакъ шагыйрь Хәмит Ергалиев, үзбәк шагыйре Эркен Вахидов, әзербәйҗан шагыйре Аяз Вафалы, кыргыз шагыйре Сапар Ураев, рус шагыйре һәм тәрҗемәчесе Сергей Северцов, татар шагыйре Илдар Юзеев һәм Каракалпак шагыйрьләренең чыгышларын тамашачылар зур кызыксыну белән тыңладылар.

## ЯҢА ЕЛ КАЛЕНДАРЕ

Татарстан китап нәшрияты 1970 елга татар телендә Яңа ел календаре бастырып чыгарды. Календарьне төзүчеләр илебез халыклары тормышына, партиябезнең XXIII съезды карарларын тормышка ашыру буенча киң җәелдерелгән хуҗалык һәм культура төзелешенә бәйле мәсьәләләрне шактый киң яктырткannар.

Анда, В. И. Ленинның тууына 100 һәм Татарстанның төзелүенә 50 ел тулу уңае белән, юлбашчыбызның тормышын һәм эшчәнлеген күрсәткән материалларга, язучыларыбызның, шагыйрьләребезнең аның турындагы әсәрләренә шактый күп урын бирелгән.

Календарьда республикабызның ярты гасырлык үсешен күрсәткән материаллар да, чит илләрдәге әһәмиятле вакыйгалар, фән-техника дөньясындагы яңалыклар, тормышның башка тармакларында иреșелгән яңа ачышлар да мул бирелгән. Укучыларның тормышында, эшендә көндәлек кинәшче булырдай материаллар да күп.

Күпчелек укучыларның соравын искә алып, 1970 ел календаре узган елдагыга караганда күбрәк — ягъни 310 000 данә басып чыгарылды.

Татарстаннан читтә яшәүчеләр календарьне, урында түләп алу шарты белән, «Книга-почтой» аша соратып ала алалар. Мөрәҗәгать итү өчен адреслар:

*г. Казань—57, ул. Октябрьская, дом 18. Книжный магазин № 14, «Книга-почтой».*

*г. Казань, Баумана, 19, Книжный магазин № 1, отдел «Книга-почтой».*

## КОНСУЛЬТАЦИЯ БЮРОСЫНДА

Яшь язучы Фәләх Насыйровның «Доктор Илдар» исемле повесте тикшерелде. Автор өчен файдалы булган ул индивидуаль семинарда Нурихан Фәттах, Барлас Камалов һәм Язучылар союзының әдәби консультанты Илдар Юзеевлар катнашты.

* * *

Шундый ук семинар Уфада яшәүче яшь язучы Рәшит Фазлыевның «Тормыш куркаклары яратмый» исемле повесте буенча үткәрелде. Сөйләшүдә катнашкан язучылардан Нурихан Фәттах, Сафа Сабиров, Хәсән Сарьян, Илдар Юзеев һәм Фәнил Мансуровлар повестьтагы уңай һәм кимчелекле якларны күрсәттеләр. Авторга файдалы киңәшләр бирделәр.

* * *

Әдәби консультант Илдар Юзеев Зеленодольск районының Бәчек авылында яшәүче прозаик Хәбиб Хәлилов янына барды. Анда авторның басылып чыккан повесте һәм яңа хикәяләре турында сүз барды. Хәбиб Хәлиловның «Тарлавык кичүе» исемле хикәясе «Идел» альманахына тәкъдим ителде.

* * *


Сарман район газетасы редакциясе каршындагы әдәби түгәрәкнең утырышы үткәрелде. Анда яшь авторларның яңа әсәрләре тикшерелде. Утырышта әдәби консультант Илдар Юзеев катнашты һәм әсәрләргә анализ ясады. Әдәби түгәрәк членнары һәм Илдар Юзеев Чураш авылында яшәүче Вәсимә Хәйруллина янына бардылар һәм яшь шагыйрәнең иҗаты белән таныштылар.

## ОЧРАШУЛАР, ӘДӘБИ КИЧӘЛӘР

Шагыйрьләребездән Зәки Нури, Илдар Юзеев, рус язучысы Юрий Белостоцкий республикабыз районнарыннан һәм шәһәрләреннән килгән пропагандистлар белән очрашып, аларга бүгенге әдәбиятыбыз турында сөйләделәр, үзләренең яңа әсәрләрен укыдылар.

* * *

Яшь язучылар Роберт Батуллин һәм Разил Вәлиев Пермь өлкәсе Барда районында булдылар. Авыл һәм шәһәр эшчәннәре Роберт Батуллинның хикәяләрен, татар әдәбияты турындагы чыгышларын, Разил Вәлиевнең шигырьләрен зур кызыксыну белән тыңладылар. Яшь язучылар Пермь телевидениесе һәм радиосында, район һәм өлкә матбугатында чыгышлар ясадылар.




# БӘХТИЯР БАТЫР

*(Баллада)*

**Рөстәм Яхин** музыкасы

**Мостафа Ногман** сүзләре

*Бәхтияр Канкаев — Пугачев хәрәкәтенең җитәкчеләреннән берсе. Хәрби дәрәҗәсе — главный полковник. Пугачев гаскәрләре Казан янында җиңелгәннән соң да Канкаев патша армиясенә каршы кискен көрәш алып бара. Канкаевны тотып китерүчеләргә зур бүләк вәгъдә итәләр. Кайбер риваятьләргә караганда, Канкаев үзенең турылыклы көрәштәшләре белән Төркстан якларына китә.*

Бәхтияр батыр дигән зур полковник
Пугачауда гаскәрбаш икән,
Доньяларны гизгән ир егеткә
Егерме алты гына яшь икән.

Бәхтиярнең аткан ай туплары
Уралларда койган бакырдан,
Уң канатым булырсың дип аны
Пугачауның үзе чакырган.

Ул Пугачау, Салават һәм Бәхтияр —
Өч баһадир килгән өч юлдан,
Дон, Агыйдел, Идел ташкынланып
Ак патшага каршы кушылган.

Күтәрелгән шаулап ир егетләр,
Кулда айкап сәнәк-чалгысын,
Хур булмабыз, дигән, яубашчыбыз
Бәхтияр батыр гына сау булсын.

Бәхтиярнең менгән аргамагы
Ярсып торган тимеркүк икән,
Юлларында ак патшаның явын
Калтыраткан чагы күп икән.

Ул китәсе җирләр — сахра, чүлләр...
Барасылар ерак ара икән,
Бәхтияр батыр, гаскәр туплаймын дип,
Аргамакта очып бара икән...

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА
ПИСАТЕЛЕЙ
ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210